


# КАЗАН УТЛАРЫ

9
СЕНТЯБРЬ
1980

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

9
СЕНТЯБРЬ
1980

## Бу санда

Ф. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ. Елганың борылган төшендә... Повесть . . . 3
Г. ЛАТЫЙП. Мин бәләкәй чакта күрдем Димне... Шигырьләр . . . 34
Ю. ӘМИНОВ. Очрашырбыз, Гөлсылу. Җитди комедия . . . 38
В. ТУКТАРОВА. Кыска шигырьләр . . . 71
Р. РӘКЫЙПОВ. Диңгез өсте сыек зәңгәр томан... Шигырьләр . . . 72
М. НАСЫЙБУЛЛИН. Ярканат. Повесть . . . 74

КЛАССИК ПОЭЗИЯДӘН ҮРНӘКЛӘР

А. КОНАНБАЕВ. Кыран бөркет нәрсә генә алмас 123

Яшьләр иҗаты . . . 126

КПССның XXVI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Р. ИШМОРАТ. Замандашым. Очерк . . . 130
Н. ФӘТХУЛЛИН. КамАЗ кешесе: кем ул! Социолог язмалары . . . 139

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Чын кеше булып яшәүнең серләре . . . 146

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

И. НИЗАМОВ. Тел байлыгын — матбугат битенә 156

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Табышлар һәм югалтулар . . . 162
К. ТИМБИКОВА. Шагыйранең яңа ачышлары . . . 165

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СӘНГАТЬ

**Н. ХАЛИТОВ.** Казан татарлары архитектурасында милли үзенчәлекләр . . . . . . . . . . 167

ӘБҮ ГАЛИ ИБН-СИНАНЫҢ ТУУЫНА 1000 ЕЛ

**Я. АБДУЛЛИН.** Күренекле фикер иясе, галим һәм әдип . . . . . . . . . . . . . . . . 171
**М. ФӘЙЗУЛЛИН.** Мәшһүр врач . . . . . . . 175

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**З. ХӘЙРУЛЛИНА.** Халкым белән бергә . . . . 177
**Ф. ШӘМСЕТДИНОВА.** Күңелдәге моң чишмәсе . 180

Мәсәлчеләр мәҗлесе . . . . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 27/V-1980 ел. Басарга кул куелды 14/VIII-1980 ел. ПФ 09030. Кәгазь форматы 70×108$^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 92600 экз. Заказ У-237. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

**Фәрит Гыйльметдинов**

# ЕЛГАНЫҢ БОРЫЛГАН ТӨШЕНДӘ

ПОВЕСТЬ

...Елганың борылган төшендә,
Бик хәтәр төшендә елганың...

*С. Хәким.*

## I

Идел-йортның көнчыгышында җилсез көннәр сирәк була. Төрле биеклектәге, төрле формадагы электр баганалары, ялкау гына селкенеп утыручы нефть көянтәләре, бораулау вышкалары белән тулы үзәннәр, бөек Уралның ерак кардәшләре булган тәкәббер тау тезмәләре моңа инде күнегеп беткәннәр. Кырыгар градуслы зәһәр суыкта ачы җилләр тау түбәләрендәге имәннәрне тарый. Агачлар дәшми. Кырыгар градуслы эсседә хыянәтче җил болын, үзән, кырларның соңгы дымын эчә — дәшми табигать. Гомумән, бу төбәктә сыкранучы, зарланучылар юк диярлек.

Иң үзәктә, дүрт яклап — Җүкәтау, Пугач тавы, Кала һәм Еланлы таулар белән чикләнгән Зөяле үзәнендә йомылып, артык читкә җәелми генә, чамасыз таралып та китмичә, сирень, гөлҗимеш куакларына төренеп, ак шәһәр утыра. Зөя елгасы эчкә керергә кыймый; шәһәр әйләнәсен ярым ай ясап урый да, кайбер урыннарда гына, батыраеп китеп, йортларның почмакларына ук орынгалап ала, таулар кочагында бикләнеп калудан курыккандай, әрәмә белән капланган итәген җыештырып, көнбатыштагы ачыклыктан Камага ашыга.

Иртә-кичле шәһәр уянып, «тузынып» ала. Ак, кызыл, яшел, зәңгәр, кара, сары автобусларын, зур-зур машиналарын, тузан, төтен болыты күтәртеп, дөньяның мең ягына озата да, кичен шул рәвешчә үзенә җыя.

Шәһәр кечкенә: дөнья картасында ул төртке белән генә күрсәтелә.

Шәһәр зур: кичләрен тоташ ак нурга әйләнә дә галәм каршында үзе йолдыз булып кабына. Кан тамырын, җир тәненә яшереп, меңнәрчә чакрымнарга сузган ул. Даны күп илләр, диңгез, океаннар аръягына таралган...

Читтән, тау түбәсенә үк менеп караганда шәһәр ак биләүгә уранып яшел бишектә йоклаучы сабый сыман тоела; бишек кысасына элэктерелгән таза, киң каешлар — асфальт-бетон автотрассалар — тау итәкләре белән текә күтәрелеп, биеккә-биеккә, күк гөмбәзенә хәтле үк сузылганнар. Ирексездән күңелдә, шул каешларның якындагысын сузылып кына элэктерәсе иде дә, тибрәндерәсе иде сабыйны, дигән шаян теләк уяна.

Яз айлары бетеп, җәйнең саф, садә, бөтен дөнья чәчәк исенә исереп, хозурланып утырган төне иде, нәкъ шәһәр өстендә, исәпсез-хисапсыз сандагы төсләре белән җемелдәп балкыган күк йөзендә кинәт йолдыз атылды, ул яктыдан үзән, урман кошлары сискәнеп куйды, тау түбәсендәге агачлар, аланнарның кыяк, тукранбаш, абага үләннәре нурланып алгандай булдылар.

•

Фәнис кулын күз турына күтәрде: саз бакасыдай җәенке, «итләч» сәгатьнең фосфор йөгертелгән яшел уклары сигез туларга биш минут калганлыгын күрсәтә иде. Почмаклары кыршыла башлаган күн папкасын эсселәнеп киткән уң учыннан сулына күчерде. Каты, сөякчел бармаклары белән мангаен уды, болай да пөхтә итеп таралган чәчен сыпыргалады, өр-яңа яшел костюмының ипле торган кесәләрен рәтләде. Халык белән шыгрым тулы тукталыш мәйданчыгыннан читкәрәк атлап, карашын йөз дә беренче мәртәбә урамның аргы башына текәде. Троллейбус һаман күренми. Болай булгач, имтиханга беренче төркемдә керергә дип, кичтән үк килешенгән вәгъдә җилгә очачакмы? Очачак! Ачу белән, каты итеп маңгаен уып куйды. Техникумда дүрт ел уку дәверендә утызлап имтихан бирелгәндер. Шуларның күпчелегенә беренче булып керде Фәнис. Ә бүген?! Җитмәсә иң соңгы сынауга, диплом проектын бишлегә яклаган башың белән, дәүләт имтиханына соңга кал инде! Сүз дә юк, бөтен группа техникум залында хәзер. Алынасы чират алынган, ашаласы өчпочмаклар бетеп килә, ботарланасы конспект, китаплар күлмәк, костюм эченә туларга тиеш — димәк, иң соңгы кеше булып керергә кала. Бәйрәм бүген, бәйрәм Фәнискә! Ярты көн буена хәзер ничек кенә түзеп йөрмәк кирәк! Я хода!

Адәм баласына бер килмәсә килми икән. Иртәсе үк хәерле башланмады ич аның. Башта Ильяс, аннары — туфли. Салкын су белән билгә хәтле юынып, чүл кояшыдай кызарганчы, сөлгене өзелеп чыгар дәрәҗәгә җиткереп ышкынды, сөртенде дә кичтән үк үтүкләп куйган күлмәк, чалбарларын кия-кия бүлмәдәшләрен — рәхәтләнеп гырлап йоклаучы өч егетне — уятырга тотынды. Футболчылар маршы ритмына сызгыра-сызгыра, иләмсез озын гәүдәле, шыксыз ябык Ильясның юрганын кайтарып ташлады. Кабырга, кул, аякларны белгертүче, аркылы-торкылы килеп беткән эре сөякләрнең очына чыгып, кытыршы, калын табанын кытыклады. Селкенми дә теге. Транзисторны бөтен көченә акыртып, егетнең колак төбенә куйды. Гырлый бу. Мендәре астыннан кәгазь очы чыгып тора. Фәнис шуны тарткан иде — һооп! — шпаргалка метр ярымга сузылды. Ә-ә-эһһмм!! Беренче билетка җавап, икенче, өченче... егерме сигезенчегә. Менә почерк ичмасам бу. Фәнни коммунизм дәреслеге тулысынча сыеп беткән ич! Фәнис сокланудан авызын ябарга өлгермәде, үтереп авырттырып, кулларын артка каердылар, инсәдән кысып алган тимер келәшчә, аны һавада җилпеп торды-торды да дыкылдатып караватка сузып салды. Көтелмәгән, хыянәтчел рәвештә арттан кысып алудан Фәнис тынсыз калды.

Күзләрен ачканда, егетләр аның өстенә иелгәннәр, алтын кысалы шакмаклы күзлеген киеп алган Ильяс һавада чайкала иде.

— Ну куркыттың, малай, сине бит әллә кем дип торам! Шушы

шпаргалка дип, экзамен беткәнче хыялланмасам, үлгәнче яшим инде мин.

Нәкъ каршында ук, аяк очында гына күгәрченнәр чупләнеп йөри, гөрләшәләр икән. Фәнис, башын күтәреп, йөз дә икенче мәртәбә юлга карады. Юк машиналар, юк, үләм дип хет юлга аркылы ят! Килмәсә килми икән... Җәяү йөгерсәң? Уйлап бетерә алмады, күкрәк эчендә нәрсәдер озак итеп, сузып чәнчеп куйды. Ильяс бүләге. Арттан килде шул, югыйсә миндә дә буй бар анысы — бер дә җитмеш биш. Десантныйга рәхәтләнеп үтәрлек. Юк, бу хәлдә өч чакрым түгел, өч йөз метрны үтү дә газап булачак. Ичмасам, тулай торак ашханәсендә капкалап алмадым ич. Баш! Йөр хәзер җил йотып.

Троллейбус күренми!

Ә туфлиләр тарихы! Тфү! Көчкә сулыш ала-ала киенеп беткән иде, туфлиләре юк. Шифоньерны туздырып ташлады. Сыкрана-сыкрана карават астына кереп китте. Юк! Дүртәүләп тотындылар. Карамаган почмак калмады, бүлмәнең асты-өскә килде, аптырагач, чүп чиләген актардылар. Юк!! Өч көн элек кенә дүртесе дә диплом эшләрен уңышлы яклаганнар иде, нефть техникумының технология факультетында дүрт ел шәкерт булып йөреп, дипломнар яклау, билгеле, шалкан ашау түгел, моны барысы да яхшы белә, яхшы аңлый иде. Группа җитәкчесен дә чакырып (ир-егет укытучылар яшәсен!) тарихка язылырлык бу вакыйганы билгеләп үткәннәр иде. Шуның истәлекләре — хәмер, шифалы су шешәләре идәндә бертуктамый тәгәрәделәр. Юк!! Табылуына өмет бөтенләй киселде дигәндә, ишек ачылып китте, Фәниснең туфлиләре пәйда булды, аларны күтәргән күрше бүлмә малае, борын тарта-тарта, өстәл янына узды: «Кая, минем чүәкләрне табыйк әле, боларын ялгыш киеп чыкканмын...» Ильясның тартадай булып күтәрелгән кулын күргәч, бүлмәдән ук булып атылды.

Тукталыштагы халык төркеме, көчле давыл җиле китереп бәргәндәй, тибрәлеп куйды. Урам тутырып бер-бер артлы өчме-дүртме троллейбус килә иде. Шыгрым тулган беренче троллейбус сәлам дә бирми ары китте. Икенчесенең дә туктап торырга исәбе юк иде, ахры, әмма ул, бәхетсезлегенә каршы, тизлеген акрынайтты. Шунда машинаның кронштейн бавын эләктереп, аска тарттылар. Контакт аерылып, троллейбус туктап калгач, халык болыт булып аңа сарылды.

Ничек килеп җиткәнен аныклый алмыйча озак баш ватты Фәнис. Күкрәге, кабыргаларының сулкып-сулкып әрнүен яхшы белә, бөтен тәне, хәтта күзәнәкләре белән тойды ул моны, әмма озак килделәрме, ничә тукталыш үттеләр — бусын хәтерләми. Әйтерсең, тюбиктагы теш пастасын кысып-кысып чыгарып бетергәндәй, аның зиһенен, уйларын суырганнар. Фәнис буп-буш, җип-җиңел иде. Кирәк бит... Троллейбуслар махсус рәвештә дүрт ел буе шушы соңгы имтихан көнен көтеп торганнар диярсең.

Группадашлары Фәниснең коридорга күтәрелгәнен сизмәделәр дә. Егетләр кызлардан бушаган конспектларга чумганнар. Имтихан бара торган бүлмәнең ишеге шыгырдап ачыла башлады, йозак тишегенә өелгән кызлар, чуар йомгак булып, кирегә тәгәрәделәр. Югарыдан, очына кадәр үк тирләп чыккан борын, шакмаклы күзлек йөзеп чыкты— Ильяс канәгать елмая иде. Фәнисне күрүгә, кулларын төркем аша аңа ыргытты: «Тизрәк, чиратың үтә бит, Харитон өзелеп көтә үзеңне. Ни пуха...»

«Кая этә ул мине, Хәсән Исламович үзе генә түгел ич анда, комиссия утыра, баламут, буровой, миңа зиһенне тәртипкә салырга кирәк!»

Әмма соң иде инде. Фәнис кызыл материя белән капланган өстәл янына кыюсыз гына якынлашты. Тигез рәт итеп таратып ташланган билетларның иң кырыйдагысын суырды. Үнөченче, дип пышылдады билет номерын. Карашын каядыр, аңлап булмастай бушлыкка текәгән,

бюст кебек хәрәкәтсез утыручы экзаменатор беренче рәттәге буш урынга ымлады. Хәзерлән!

Беренче сорау: «Социализм төзүдә пролетариат диктатурасының роле». Белә Фәнис. Һәйбәт. Әмма икенчесе? «Шәхес, коллектив, җәмгыять». Туктале, нәрсә сөйләргә мөмкин соң болар хакында?

Фәнис бар белгәнен, укыганын, кыскасы, сандык запасында күпме калган, барысын сыгып чыгарырга тырышты, күзләрен йомды, учы белән маңгаен уды. Диктатура хакында бит ярым язды. Теләсә өчне дә яза ала. Әмма икенче сорау бар бит әле. Ә хәзер сөйләргә аның чираты.

Фәнис бөтен кыяфәтенә җитдилек кертергә тырышты. Текстны яттан белүчеләр сыман, җөмләләр арасында паузалар да калдырмыйча, башлап китте. «Капитализмнан социализмга күчү чорында, Маркс билгеләмәсе буенча, пролетариат диктатурасы хәлиткеч роль уйный. Алай гына түгел, ул яңа җәмгыятьнең җиңүе өчен зарур шарт. Аның әчтәлеге...» Иң мөһиме — беренче сорау белән комиссияне егып салырга! Интонацияне түбәнәйтмәскә! Ленин әсәрләреннән мисаллармы? Рәхим итегез! Сөйли Фәнис, мин сиңа әйтим!

Фән укытучысы философ «Харитон», күзләреннән елмаю очкыннары сирпеп, канәгатьлек белән баш кагып утырды да, сөңгедәй кодрәтле, кара, зур авторучкасын ведомость кәгазенә текәде. «Бик яхшы! Сездә сораулар юкмы», — дип комиссия членнарына борылды.

Фәнис әчке сизенү белән, өстәлнең сул ягында утырган шомырт кара чәчле чибәр ханымга борылды. Кабыргалары янә чәнчеп куйды. Бозлы су эчкәндәй, гәүдәсе бөрешеп китте.

Интуиция алдамады.

— Сезнең икенче сорау ничек иде әле?

«Парашют ачылмады!» — дип, сызланып уйлап алды Фәнис. «Харитон» канәгатьсез төс белән егеткә текәлде.

— Хәсән Исламович, без үзебезнең студентлар белән бу темага бик кызыклы дискуссия уздырган идек, — дип дәвам итте чибәр апа,— кызык, сезнекеләр ни уйлый икән?

Фәнис күз очы белән генә эләктереп алды: анда утыручы чал чәчле имтиханчы апа да дискуссия уздыруны мәгъкуль күрми иде, ахры, төксе генә итеп сәгатенә карап алды.

Булса була, булмаса инде... дигәндәй, егет капитализмны сүгүдән башлады. Анда менә шәхес иреге болай, инде килеп үзләре бездә кеше хокукы тикшергән булып, әчке проблемаларын йомып калырга... дибрәк тотынган иде, тәти апа тиз туктатты.

— Юк, юк, сез менә, фамилиягез ничек әле? Ә-ә, Гайсин, менә, иптәш Гайсин, безнең җәмгыятьтә ирек һәм шәхеснең бурычы, җаваплылыгын ничек аңлыйсыз? Китапча түгел, үзегезчә, Гайсинча итеп сөйләгез.

Фәнис алдында бу сорау кара урман иде. «Көрмәү хәерлерәк булыр, шундый буталырсың, мәңге чыгалмаслык булып, шунда калырсың!»

— Бу хакта мин кайчак үз-үзем беән генә сөйләшкәлим. Кешеләр белән чын дәрәҗәдә бәхәсләшерлек шәхес булып өлгермәдем әле.

— Хм-мм! Алайса, бик кечкенә, өлгермәгән шәхес инде сез, иптәш Гайсин.

Хатын-кыз укытучыга эләкмә! Фәниснең ачуы килә башлады.

— Артык бәләкәй дә түгел. Уртача, гадәти шәхес.

— Менә, менә, дөрес. Хәзер бурычлар хакында. Сезгә булышам: диплом алганнан соң кая барырга уйлыйсыз?

— Авылга кайтам. Печән әзерләргә көтәләр.

Чибәр ханымның да ачуы кузгалды.

— Хәзергә кечкенә шәхес әле сез, Фәнис иптәш. Чөнки тормышка әзер түгелсез. Аңлашылдымы? — Ул Хәсән Исламович ягына борылды. — Минем тәкъдим: Гайсинга өчле куярга.

— Ә мин — дүртле, —фән укытучысы уң ягындагы пеләш имтиханчыга борылды.

Әмма ханым, кызарып, кабарып чыкты: «Сез нәрсә, ул икенче сорауга бөтенләй җавап бирмәде ич!»

Кара сөңге ведомостька башта өчле төшерде, аннары җәяләр эченә «канәгатьләнерлек» дип тутырып язды.

Ишекне ябар алдыннан Фәнис өстәлгә борылып карады. Өлкән экзаменаторның калын кашлары җыерылып, бергә кушыла язган, йөзе кара, пеләш йокымсырый, ә чибәр апа җиңүче кыяфәте белән прическасын төзәтә иде.

Коридорда Фәнис үзен сырып, кочаклап диярлек алган кызлардан котылгач, ханымны тагын күз алдына китереп, «Ну шәхес!...» дип башланган җөмләгә тагын берничә сүз өстәп, тел шомартып алды да урамга чыкты.

Көн кояшлы, дөнья матур, тротуар халык белән тулы иде, бәрелеп-сугылып кайтканчы дип, егет машиналар йөри торган үзәк урамга чыкты. Арыганлык, рәхәт ваемсызлык дулкыны бөтен гәүдәгә таралмакчы, әмма юк, дүрт ел буе укып, беренче тапкыр алган өчле чибәр ханымның үчле елмаюы булып, һаман йөрәкне ярсыта, тырный әле.

Кайта Фәнис. Көләр иде — авыз буйсынмый, елар иде — горурлык кушмый.

Кинәт арттан кемдер аның сул калак сөяге турысына «док» иттереп китереп сукты. Тегеләй дә әрнеп йөргән кабыргалары барысы бергә чәнчеп алды. «Хәзер мин аңа шәхесне күрсәтәм! Бар көчкә, бөтен ачу чыгып бетәрлек итеп, чыраена ямыйм да тротуардагы халык эченә чумам!»

Фәнис һавада уйнаган кувалдадай йодрыгы белән инде «манам» дип, кырт борылган иде, югары көчәнешле чыбыкка орынган кешедәй, калтыранып куйды, күтәрелгән кулы ташландык кое сиртмәсе сыман хәрәкәтсез катып, чайкалып торды, күзләрен бер ачып, йомгалап карады. Юк, ул саташмый, үз акылында. Сугучы «хулиган» — алты почмаклы бура зурлыгындагы троллейбус — аңа терәлеп бетеп үк туктаган иде.

Ялтырап торган яшел калай, зур, биек тәрәзә, рулен калдырып, шул тәрәзәгә капланган, гаҗәпләнү, курку, каушау катыш нишләргә белми өзгәләнгән кыз... тротуарга «чумганда» шулар Фәниснең зиһененә фоторәсем булып, сеңеп калдылар.

## II

Кешеләрне киеренке халәттә тоткан ямьсез тынлыкны секретарь бозды.

— Иптәшләр, кабатлап әйтәм: партиянең ачык җыелышы тәмам.

Урындыклар шыгырдый башлады. Гөрләү китте.

Гәрәев кузгалырга ашыкмады. Барысы да президиум ягына карый, махсус рәвештә аны күзәтәләрдер кебек тоелды аңа. Өстәл тулып яткан эш кәгазьләре, каралама, газета кисәкләрен папкасына тутырып бетергәч, секретарь да күтәрелде. Бу кыяфәттә утыру башка мөмкин түгел иде, Гәрәев аңа иярде.

Урамга чыккач, тукталып калды. Идарә каршындагы каен агачларының очында баеп килүче кояшның соңгы нурлары уйный, машиналар туктый торган мәйданчыкта дежур автобуска, ГАЗ-69, «Вазик»ларга халык төялә, ташландык чиркәү кебек шулай катып торса, чакырып аңа да дәшәчәкләр. Ул һич аңыша алмый: аны сагышмы, моңсулыкмы— нәрсәдер биләп алган да үз иркенә буйсындырып, каядыр, идарәдән, танышлардан читкәрәк тарта иде.

Берничә секунд икеләнеп торганнан соң, өр-яңа туфлиенең үкчәләре белән каты басып, ул урам буенча җәяү генә китте. Гадәттә ул җәяү аз йөри. Эшкә барганда дежур автобус килеп ала, китереп куя. Скважиналар, ремонт цехы, контора арасын вахта автобусында чаба.

Кеше аз йөри торган урамга борылды. Монда машиналарга керү тыелган, көлтә-көлтә булып утыручы акация, гөлҗимеш, сирень куаклары газонны тутырып, тротуарны каплап киләләр иде. Бөркү булып китте.

Ак күлмәк якасын ычкындырыйм дигән иде, кулы галстукка тиде, аны чишеп, пөхтә итеп кенә күкрәк кесәсенә салганда, эчкәрерәк яткан кәгазь тартмачык шупылдап китте. «Орден да кесәдә икән ич», — дип уйлап алды Гәрәев, артык исе китмичә генә. Ул аны үзе шулай йөртә. Кайбер җыелышлар алдыннан, яисә төрле очрашуларга чакырып, бу хакта исенә төшерсәләр, депутат значогы белән бергә тага да куя. Ә бүген? Гәрәев салынкы, ваемсыз торышыннан айнып киткәндәй булды. Йөрәге, нечкә сызык белән кискәндәй, берничә мәртәбә сулкып-сулкып, авырттырып типте. Гәрәев көтелмәгән авыртудан, хәтта бераз вакыт сулыш ала алмыйча, туктап, кулы белән таш коймага таянып торды. Йөрәк «бүләген» яңадан кабатламады. «Ә бит Җиһаншин чыгыш ясамаса, әлбәттә, автобус белән кайта идем, гомумән, эштән булсынмы, җыелышлардanмы, бу минем беренче мәртәбә җәяү кайтуым түгелме соң?» Ничектер игътибар ителмичә аяк астында гына уралып йөргән шул сорау бик кирәкле ачыш кебек, аны гаҗәпләндереп җибәрде. Юк, тукта әле, соңгы тапкыр кайчан җәяү кайтты соң әле ул эштән? Мастер булып алты ел эшләү дәверендә мондый хәл булмады кебек. Бораулаучы булып йөргәндә генә булса инде. Дөрес, ул чорда аңа шактый тәпиләргә туры килде. Җитмәсә, квартирасы да кире якта, шәһәр читендә, Зөя елгасына терәлеп торган кечкенә агач йорт иде.

Колак төбендә генә әкәмәт бер нәрсә безелдәп, лепердәп алды, ул искә-оска килгәнче, костюмының күкрәк турындагы яка өлешенә кунды. Июль аенда күбәләкләр булмый түгелме соң? Бу каян чыккан? Мәхлүк бер бөҗәк кенә булса да, йөрәк турына чамалый... Тән җылысы белән әз булса да гомерен озайтмакчымы.

Соңгы елларда гаҗәп сирәк була торган хәл: танылган нефтьче, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, республика хөкүмәте депутаты, шәһәрнең танылган кешесе, мастер Энәс Гәрәев, югары сыйфатлы корыч бораудай таза, токмач кунасыдай киң иңсәле, уртача буйлы гәүдәсе белән ашыкмыйча гына, салмак адымнар белән әз кешеле урам буйлап атлый. Гомергә каядыр ашыккан, чапкан, кемнәр беләндер әрепләшеп, кычкырышып алуны гадәти эшкә әверелдергән, ял көннәрендә дә цех мастерскоенда кирәкле инструментлар, җайланмалар ясап, шуны сынап ята торган кешенең шулай ваемсыз гына шәһәр эчендә буталып йөрүе бу кешенең үзе — Гәрәев өчен дә сер иде. Мондый халәттә йөрү төрле уйларга батыра икән, шушылай каңгырап йөренгәндә дөнья, тормыш, шәһәр... — барысы да бик тә, бик тә моңсу икән.

Күбәләк, кызыл төрткеле чем-кара канатлары белән җилпенеп урыныннан кузгалгач, Гәревнең күз алдына ап-ачык булып оператор Җиһаншин килеп басты. Каралык буенча бер-берсенә каршы торырлык болар, сүз дә юк, дип көлемсерәп, күбәләк белән Җиһаншинны чагыштырды. Менә Җиһаншин трибунада блокнотын ачып салган да, очынып-очынып, нинди скважинада ничә авария булганын саный. Аннары гап-гади, беркатлы нәтиҗә чыгара. Нефть алуда идарәнең ярты еллык планны үти алмавының төп сәбәбе — скважиналарның бик тиз сафтан чыгуында. Көлсәң көл, еласаң ела! Бер якка да кушылмый тыныч утыру мөмкин түгел иде. Гәрәев көлде. Беренчедән, идарә ярты еллык планны үтәде. Тартып-сузып, бөтен запасны агымга кертеп — нечкәлекләре күп инде бу эштә, аны администрация белә дә, Гәрәев белә,

әмма барыбер, идарә планны утызынчы июль көнне үтәп чыкты. Икенчедән, Гәраев бригадасы сафтан чыккан бер генә скважинаны да икеөч көннән артык тотмады. Соңгы ай эчендә генә дә унике скважина тапшырды ич алар. Җиһаншинны сукыр дияр идең, алай ук түгел, күзләре бар. Бик башсыз кешегә дә охшамаган. Кысыр катламнар күбәйде, чыганаклар вак, күп вакытта нефть урынына су бәреп чыга — хикмәт менә нәрсәдә! Сәбәпнең шулай икәнен шәһәрдә бишек баласы да белә. Җиһаншин, димәк, күптән белә. Ни өчен соң ул юкәдән чикләвек эзли? Ярый, бусын калдырып торыйк. Вариантның берсе игеп, Җиһаншинны хаклы дип фараз кылыйк. Ә менә бөтен администрация, актив, халык алдында аның, минем участоктагы скважиналарны ремонтларга Гәраев бригадасын кертмәгез, дип дөньяга кычкыруы нигә кирәк? Гәраевнең авторитетына сугу өченме? Моның өчен ул бик вак калибрлы кеше, практик рәвештә бу өлкәдә ул бер эш тә чыгара алмаячак. Гәраев — эш кешесе. Кулында көче бетеп, тәнендә җылы гына калганда да эшли торган кеше ич ул! Җиһаншин ни рәвешле, шулай ачыктан-ачык, бар көченә кычкырып авантюрага бара? Әгәр аның Гәраевкә түгел, бригаданың берәр кешесенә үче булса? Юк, охшамаган. Тегеләйме, болаймы — бу аның өчен зур табышмак иде.

Кирәкле йорт турысына җиткәч, Гәраев аны башта әйләнеп чыкты. Бакча якка караган икенче этаждагы почмак тәрәзә балкып утыра иде. Өйдә! Хәтерен җигеп, Нәсимәнең сыгылмалы гәүдәсен, иңсәсенә таратып ташланган озын, кара чәчләрен, сөрмәле керфекләргә яшеренгән кара күзләрен күз алдына китерде. Кызык, ул кергәч, Нәсимә сөенерме? Сөенергә тиеш! Кыз вакытта да ул аңа һәрвакыт елмаеп кына дәшә иде. Дәшә иде... Дәшә иде шул, елмаеп. Әмма Әнәс бозау булды. Егетлек күрсәтә алмады.

Подъезд эче шыксыз иде. Кечкенә генә пычрак лампочка сары яктылык сирпи. Почмакта икмәк калдыклары салырга дип куелган бачокның өсте ачык калган, эчендә нидер безелди. Гәраевнең кинәт кәефе сүрелеп калды. Бәлки кермәскәдер, кеше борчып йөрү генә булмасмы? Шул вакыт каршыдагы бүлмәнең йозагы шалтырый башлады. Костюмының төймәләрен каптыра-каптыра бер ир чыгып, «Иртәнгә калсак соң була, дурак тәре!» дип өй эченә акырынды да, дөбер-шатыр аска йөгерде. Гәраев ашыга-ашыга кнопкага басканын сизми дә калды.

— Әнәс, синме бу? — Нәсимәнең гаҗәпләнүдән кашлары югары күтәрелгән, күзләре зуп-зур, аптырап тик басып тора.

— Әллә замандашларны оныттың дамы?

— Исәнме, Әнәс. Түргә уз. Мин хәзер, халатымны гына алыштырыйм инде.

Бүлмә эче гаҗәп пөхтә, җыйнак. Идәндәге яшел келәм болын үләне төсен хәтерләтә. Шкаф, тумбочкалар китап белән тулганнар.

— Әнәс, өстәл янына үт, утырып тор. Китап-журналлар караштырырсың.

— Рәхмәт! — Гәраев үз-үзе белән сөйләшкән булып, чалбар кесәшына кыстырылган коньяк шешәсен өстәл астына, караңгыгарак шудырды.

— Мин — агач, урын тәкъдим итәргә дә онытканмын, Әнәс, кичер инде. — Нәсимә каршыдагы урындыкка утырды.

Тынлык урнашты. Китап шкафы өстендә шакмаклы, кара сәгать кызу-кызу текелди, өстәлгә таратып ташланган күксел, зәңгәрсу тышлы калын-калын китаплар, «Новый мир» журналлары люстрадан төшкән артык яктыны кайтарып, үзләре нур сирпегәндәй, җемелдәп күренәләр. Иң кырыйдагы ачык журналны Гәраев үзенә таба тартты. Зур хәрефләр беләнрәк язылган өстәге юл ачык укыла иде: «Юрий Скоп. Куркынычсызлык техникасы. Роман».

— Китапның калыннарын гына укыйсың. Повесть, хикәя ишеләр белән вакланы юк.
— Журнал сөючеләр конференциясе үткәрәчәкбез. Безнең, китапханәчеләрнең, эшен беләсең ич, Әнәс, житешсәң, укып чык. Синең өчен кызыклы булыр дип уйлыйм.
— Ә бу диңгез буенда йөргән ала эт турында кем укый? — Гәрәев бүлмәгә жанлылык кертергә тырышты.
— Кызым женләнә шундый китаплар белән. Яраткан язучысы.
Ул Нәсимәнең тар гына булып сузылган кара кашларының биек, йомры маңгаена таба күтәрелеп-күтәрелеп алуын тойды. «Ишек ачкандагы кебек. Сәер».
Гәрәев икенче темага күчәргә кирәклеген ниндидер эчке тоем белән сиземләде.
— Күңелле сездә, Нәсимә. Матур яшисез. Беләсеңме, өй эчендәге бар әйбер балкый, бүлмә үзе, кояш кебек, тирә-күршене яктыртып тора.
Аның килешсезрәк чыккан жөмләсен Нәсимә тиз бүлде.
— Арттырма, Әнәс, ялгызлыкның кояшка тиң булганын кайчан күргәнең бар. Кызымнан күчкән гадәт: кеше кергәч, шулай бар лампочкаларны кабызам. Ялгызлык яктыртмый шул. Чәй эчәбезме?
— Баш өсте.
Иркен кухняның идәне вареньелар салынган зур банкалар белән тулган, алма, жиләк-жимеш исе аңкып тора.
— Без үзебез сөт белән яратабыз, син, Әнәс?
— Хәзер, бер генә минут. — Ул шешәне өстәлгә куйды. — Нәсимә, булган булсын, бәйрәм ясыйк әле бүген. Нинди хөрмәткәме? Малай туды бит әле минем... нәкъ унжиде ел элек...
— О-о, котлыйм! Тик, зинһар, миңа салма инде, Әнәс, Зәйтүнә дә кайтыр вакыт житә. Әйтергә дә онытканмын: троллейбус йөртә бит ул хәзер. Икенче сменада.
— Үсә яшьләр. Ничә яшь инде аңа?
— Үткән гомер — аккан су. Унсигез. Әтисен сагына. Әллә шуңа инде, сәеррәк тә бугай. Ашаганы — китап, эчкәне — китап. Вакыты да кысан, югыйсә.
— Нәсимә, балалар бәхете өчен! Кара әле, рюмкага таба кара, билләһи, дим, чын алтын бу. Баш бар инде кешеләрдә, шайтан каны ясаганнар бит. Беләсеңме, безгә хәзер әз генә юләрлек житми, ахры. Күңел йоклаган, оеп беткән, менә шушы шайтан малайлары уята аны. Бу дөньяда мин генә белгән егерме юләр бар.
— Алай-болай мин дә кермимме аңа, бик туры карап куйдың? — Нәсимә үзен иркенрәк сизә башлады.
— Минем белән шушы минутта эчәргә теләмәүче табылса, бу сан егерме бер була. Балалар яшәсен!
— Пропаганда бүлегендә эшләргә кирәк сиңа, Әнәс. Киттек!
Берничә секунд сулыш ала алмыйча торганнан соң, икесе бергә вазага өеп куелган алмаларга үрелделәр.
Тынлык. Кара-каршы утырганнар. Нәсимә ияге белән ике учына таянган. Нәфис, алсу бармаклары, кыр чәчәгенең юка, тар таҗлары кебек, битенә сарылганнар. Карашын анык тотып булмый, ниндидер аңлаешсыз ерак бушлыкка текәлгән. Әнәскә күтәрелеп карап, тирән итеп сулады да керфекләрен аска төшерде, калтыранган тавыш беләнрәк табынга жан кертте.
— Әнәс, син миңа чит кеше түгел инде, шулай сөйләшеп утырыр башка якын да юк, сорыйсым килә. Ни өчен кешегә.... Кайчакларда моңсу, бик моңсу була?
Гәрәев, гажәпсенеп, башын артка ташлады, киң маңгае жыерыла төшкән. Уйлана.

— Нәсимә, уйлаганымны матур итеп әйтә белмим. Кичерерсең. Минемчә, моңлана белү кешедәге иң изге, нәфис тойгыларның берсе. Моң... Олы җанлы, бик тә, бик тә киң күңелле кешеләрдә генә була ул чын моңлану. Яшьрәк вакытта Тукайны укыштырдым бит. Моңлана белү — олы бәхет. Андыйларның җаны, күңеле чиста, керсез була. Кызганычка каршы, хәзерге тук, җитеш тормыш кайбер кешеләрдә шушы хисне үтерә кебек.

Нәкъ шушы вакытта ишектәге кыңгырау шалтырады.

— Эх, Әнәс, яшьлегемне исемә төшергән идем, шундый рәхәт, күңелле иде, күрәсең, без аның өчен ят кешеләр, хуҗалары кайтты бу яшел бакчаның. Кызым — Зәйтүнә.

Аны күрүгә Гәрәев уйлап куйган җөмләсен онытты. Я дөнья! Кыз анага шулкадәр охшаса охшар икән. Табигать нинди могҗизалар гына ясамый?

Кыз кыюсыз гына исәнләште, тавышсыз басып, түргә узды һәм... күз яшьләре белән әнисенең күкрәгенә капланды.

— Әнием, бүген кеше таптата яздым бит! Кычкыртам, кычкыртам— ул юлдан чыкмый... Тормозга басып өлгердем... Яшь кенә егет иде...

Бу йорт өчен ул хәзер чит кеше иде, Гәрәев ашыгып киенә башлады.

## III

Урман. Аның кырында гына, илле метрлар чамасы болын ягына үтеп, скважина ремонтлаучыларның кечкенә генә хуҗалыгы — тоташ тимердән ясалган чана өстенә утыртылган яшел будка, торбаларны күтәртү, төшерү өчен мачта һәм трактор тора. Мәйданчык тирәсе аксылсары измә белән тулган. Уртада, мачта төбендә ук, икәү кайнаша. Шуларның какча, яше иллеләргә якынлашып килсә дә, шактый җиңел гәүдәлесе һаман саен бертөрлерәк булган соравын кабатлый.

— Туктале, тукта! Син хәйләкәр егеткә охшагансың, ахры. Юк-бар белән баш катырма, сорауга туры җавап бир.

— Чынлап әйтәм, бу эшкә үзем теләп килдем. Башта һәрберебездән сорап чыктылар, кем кая барырга, кайда эшләргә тели. Аннары бер абзый, скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсенә белгечләр җитми, килегез, ди. Хәзерге чорда нефть алуның язмышы ремонтчыларга бәйле булачак, һәм... сөйләде инде теге абзый. Кул күтәрдем дә, мин барам, дидем. Шул!

— Юләрләрне чәчеп үстермиләр — үзләре чыга! Нәкъ үзе бу. Техникум бетереп, дүрт ел буе чиләнеп, шушы эшкә килдең инде, ә? Үкенмисең дәме?

— Әле эшләп караган юк ич, Хәйдәр абзый. Үкенмәскә исәп. Берәр алты ай эшләсәк, үзебезгә бригада бирәчәкләр. Хәзергә практика үтәбез.

— Алай икән. Карарбыз, карарбыз. Бу дегет оясыннан, апаем, әзмәвердәй егетләрең дә тиз сыптыра.

Трактор, җәлпәк борынлы кранын югары чөйгән дә, мачтаның югары очындагы роликка эленгән тростлар ярдәмендә шәмнәрне күтәртеп тора. Фәнис йозакка әз генә кагылсаң да бөтен буена ук чыңлап куя торган зифа шәмнең бер очын эләктерә дә, бияләен һавада уйнатып, ишарә ясый. «Бусы да булды. Өскә!» Ун метрлы өр-яңа торба һавада эленеп калгач, бораулаучы Хәйдәр, аның җиргә якын очын эләктереп ала да махсус җайланма белән тормоз барабаны оясында утыручы шәмгә ялгый. Хасил булган колоннаны яңадан җир астына куа.

Мастер Әнәс Гәрәев икенче вахта егетләре белән бу тирәдән берике чакрым ераклыкта гына булып, электр-батырма насосы сафтан чыккан скважинада көн-төн кайнаша, монда эшләр катлаулы булган-

лыктан, килеп тә карамый иде. Цемент житәрлек, хлорлы кальций измәсе ясау кирәкми, шулай булгач, техника, төрле жиһазлы машиналар алыр өчен заявкалар биреп йөрисе юк, шул сәбәпле бу хужалыкта баш булып өлкән бораулаучы Хәйдәр калган иде. Иртүк геологлар килеп киттеләр. Нефтьчеләрне скважинадан бик күп чыга торган тозлы су тәмам интектергән. Хәзер шуның өчен жир асты катламнарының гидрокартасы кирәк икән. Алар китү белән Хәйдәр командалар яудыра башлады.

— Әй, Дизель! — тракторчының янәшәдә генә икәнен күргәч, юашланып киткәндәй булды, тавышын әкренәйтте. — Һым! Бутыйм инде, туган. Гаптелхәй кардәш, машинаңны, күперчекне сулдан урап үтеп, менә шушы урынга гына куй әле.

Тракторчы Гаптелхәйнең брезент чалбары белән курткасы май, солидол тиеп, шундый каткан, һәрвакыт ышкылып йөргәнлектән, ялтырап тора, космонавтлар скафандрыннан әз генә дә ким түгелдер.

— Шәмнәр тростка чапрыш килә бит. Уңгарак алыйк, Хәйдәр абый.

— Ә-ә, шулай шул. Куй-куй, Гаптелхәй туган.

— Фәнис, вагонга керерсең, бер прибор күрсәткән идем ич, шуны гына алып чык әле. Таныйсыңмы аны? Әйе, әйе, кайда су катламы, басымы күпме — шул үзе үлчи инде.

Метр чамасы озынлыкта булган буынлы-буынлы приборны беренче шәм очына яхшылап беркеттеләр дә колонна буйлап жир астына куа башладылар. Көзге жил кузгалганлыктан, як-яктан суык ялый, күкрәккә үтә башлагач, үзләре дә сизмәстән, темпны артык кызулатып жибәрделәр. Тракторчы Гаптелхәй, изүен кайтарып куйган да, күз иярмәс тизлек белән рычагларны куша, аера. Хәйдәр агай белән Фәнис, машинаны көттермәс өчен, бер почмактан икенчесенә чабалар. Бияләйләре шәм маена тәмам манчылган Фәниснең кулыннан йозак ычкына башлады, ул аны ике куллап кочаклый, кыса, торбаны эләктергәндә тезләре белән ярдәмгә килә. Фәнис күз очы белән генә сиземләп алды. Хәйдәр агай да карашын әледән-әле юлга юнәлтә ич. Ниһаять, кузовы тент белән бөркәлгән «Газик» күренде. Трактор, гайрәт чәчеп, үкереп куйды да сүнеп калды. Арыганлык шактый сиздерә үзен, ашыкмыйча гына брезент курткаларны, вагон тирәли бастырып, тезеп чыктылар да кузовтан төшке аш салынган термослар эләктереп, вагон эченә юнәлделәр. Кәбестә, яңа гына пешкән икмәк исе таралды. Солярка ягып эшли торган торба мич күңелле гөрли, бүлмә эче чиста, жылы иде, нефтьчеләрнең кәефләре күтәрелеп китте.

— Их, егетләр, гомерем буе кыр ашы ашыйм, ашап туймыйм.— Хәйдәрнең кечкенә түгәрәк йөзен икегә бүлеп, зур авызы колакларына тиклем ерылган. — Менә сез әле яшьлегегез белән аңлап житкермисездер, бик олы бәхет бит менә шушылай утыру. Әйе, менә эпекәемдер, ихлас сөйлим!

Уртада утырган Фәниснең уң күршесе Гаптелхәй аның аяк йөзенә басып алды, Хәйдәр күрмәгәндә генә, нәрсәгәдер ишарә ясапмы, игътибар кушыпмы, күз кысты. Фәнис һични аңламады.

— Менә соңгы вакытларда күз алдыма килеп үтерә инде: мәрхүм Шаймуратов шушылай утырырга ярата иде. Шинелен иңсәсенә салыр иде дә, я, Хәйдәр, яшь вакытларны бер искә төшерик әле, дияр иде.

— Генерал Шәймуратовмы?! Хәйдәр абый, сез аны беләсезме?...— Фәнис дулкынланудан тотлыгып калды, тарелка хезмәтен үтәүче термос капкачын күтәргән килеш, торып басты.

— Я, утыр әле син, язгы боз кебек кабарма, — Гаптелхәй көзнең үзе кебек салкын, коры иде.

Хәйдәр изүләрен ычкындырды, компотын эчеп куйгач, салмак хәрәкәтләр белән папирос кабызып, төтенен Гаптелхәйгә таба өрде. Вагон

эчендә тартучыларны күрсә, Гәрәев дулый, кыза, теге кешене, көн нинди булуга карамастан, һавага куып чыгара иде. Ул булмагач, бу юлы дәшүче булмады.

— Хәйдәр абый...

— Яшь идек әле ул вакытта. Әйтик, миңа унҗиде генә иде, генералныкын анык кына хәтерләмим, әмма кырыкның өстендә — бусы хак. Үзем мин разведчик булдым, ләкин генерал, ни өчендер, һәрвакыт үзе янында тотты. Белмим, нәрсәгәдер яратты инде. Хәтта бервакыт минем аркада кителенең итәген дә яндыра язды. Кичтән шулай бер авылга җибәрделәр. Өчәү без. Мин алдан барам. Ерак та түгел бер авылга немецлар туктаган икән. Болар хакында безнең генерал берни белми, шуның өчен тел алып кайтырга тиешбез. Малай, каравылчы куйган тегеләр, эчкә табарак һич тә үтеп булмый бит. Сакчыларның берсен рәхәтләнеп алабыз инде. Анда сүз дә юк. Нәфсе бит. Штаб тирәсенәрәк үтәсе килә. Югарырак, эфицәр-мазары эләкмәсме. Таң алдыннан тәки кердек бит авыл эченә. Бик шәп алты почмаклы йорт эчендә ут яна. Тәккә янмый инде, кемдер бар. Чыкты бу. Без моны гөрс, аудардык, сүрибез. Мең могҗиза белән авылны чыгып, ярты юлга житеп килә идек, күтәрелде бит авылда тавыш. Кычкырыш башланды, танклар үкерә. Ә төн бетте инде, яктыра башлады. Бар да ап-ачык күренеп тора. Нәкъ безнең якка килә бит немецлар. Алдан танклар, солдатлары цепкә тезелгән. Аталар, кычкырышалар. Бәләкәй генә чокырга чумдык. Теге тавышны ишетеп безнең немец та дулый бит. Имән бармак белән маңгаена чиртеп алдым тегенең. Тынды. Ушы китте бугай. Инде танклар безнең турыга килеп житте дигәндә генә, бирә башладылар безнекеләр. Җир селкенә, өскә балчык ява. Мәхшәр! Шулай да танклары йөри боларның. Кыр буйлап чабалар тегеләр. Берсе безнең яннан гына үтте... Көне буе чокыр эчендә яттык. Без кайтып кергәндә, ике лампасын да кабызып куеп, генерал картасына карап утыра. Янында бер төркем офицер. Немецны ут яктысынарак бастырдым да, генералга рапорт бирәм. Шәйморатов башта миңа, ә аннары немецка карап тора да тора. Янып торган трубкасы авызыннан китель итәгенә төште. Сизми бу. Безгә карап тора да тора. Кителе яна бит моның, төтене чыга башлады! Китель өчен я виноват булырмын, бармак белән генә күрсәтәм тегеңә. «Это для нас ерунда, Хайдарушка. Син беләсеңме кемне алып кайткансың, рәхмәт, Хәйдәр», — генерал чытырдатып кочаклаган мине, җибәрми генә бит, тын бетә башлады... Баксаң, немецның бик яман, мәкерле командирын эләктергәнбез ич. Киң күңелле кеше иде Шәйморатов мәрхүм. Орденны да шаяртып көлә-көлә такты. Сугыш кына бетсен, Хәйдәр, синнән ким дигәндә министр ясыйм, ди иде. Мин калдым, ул — юк. Үзем гаепле, саклый алмадым. — Ул ике куллап битен каплаган, иңсәсе еш-еш күтәрелеп, кире төшә. — Саклый алмадым, үзем гаепле...

Бүлмәдә киеренке тынлык урнашты. Гаптелхәй йоклаган кыяфәттә утыра, Фәнискең күзләре зур булып ачылган. Алардан Хәйдәргә таба ниндидер илһамланган нур бөркелә. Фәнискә бик тә рәхәт иде бу минутларда. Гомумән, ул үзен сугышның ни икәнен чордашларыннан яхшырак аңлаучы итеп саный иде. Кинодан чыккач, шушы темага багышланган китапларны укып чыкканнан соң, ул үзен шул геройлар урынына куеп карый иде. Әйтик, менә аның кулында сыңар патроны калган пистолет, автомат, соңгы граната. Янәшәсендә ыңгырашып, үлеп ятучы иптәшләре. Ни өчендер аның күз алдына шундый картина баса: аклы-сары кояш уттай кыздыра, күк йөзенә, тирә-юньне күмеп, снарядлар шартлап тузгыткан сары тузан болыты күтәрелә, каршыда гына, окоп брустверларына терәлеп диярлек сүнеп калган немец танкларыннан куе кара сөрем бөркелә. Соңыннан, шушы күренеш турында уйланып йөргәндә, ул үзенчә, гади генә фәлсәфи нәтиҗә чыгарып куя. Танк

никадәр генә зур булмасын, снаряд, мина эченә нинди генә тол тутырмасыннар, атом бомбасы никадәр генә җегәрлекле булмасын, җирдә тереклек бетәчәк түгел. Җир тоташ янып, көеп чыкса да, аның кайсыдыр почмагында, кайсыдыр тирәнлегендә бер уч туфрак барыбер калачак. Ә анда йөзәрләгән җан, тереклек иясе. Җирдә яшәү, димәк, тормыш — мәңгелек.

Вагонда гадәти булмаган тынлык. Өстәл түренә үк көчеп утырган Хәйдәр терсәкләренә таянган да ике учына маңгаен салган. Карашы өстәлгә текәлгән. Гаптелхәй гамьсез генә кыяфәттә гәүдәсен урындык терәвенә ташлаган...

Көн уртасы булуга карамастан, куе соры караңгылык инде. Күк йөзен ямьсез, шөкәтсез кара болытлар һәммә тарафтан томалап алганнар иде, шыбырдап көзге салкын яңгыр коя башлады. Урамда калган киемнәрне алып керергә кирәк иде, һәммәсе дә тиз уянды.

— Хирург килә! — диде Хәйдәр, кулын каш өстенә куеп.

Чыннан да, басу юлы буйлап, турыдан гына бу таба «ЛАЗ» автобусы бар көченә чаба иде. Автобус килеп туктауга вахтаның яртысы, ягъни өлкән оператор, аның ярдәмчесе, машинист һәм Гәрәев үзе җиргә сикерделәр. Төшкән уңайга бар да ни эләксә шуны бөркәнеп, башларын каплап, җылы вагонга йөгерделәр, тик Гәрәев кенә машина янында мәш килде, шоферны дәшеп кул изәде.

— Булмаса, син әйдә, бик җебеткәнче асфальтка чыгып кал. Базада капкаларсың. Безне кичке биштә тукталышта көт.

Машина салулый, пычрак чәчә-чәчә китеп барды.

Бар иде заманалар: бөтен бригада — ун-унбиш кеше — бер смена булып эшлиләр иде. Бригаданың җиде-сигез члены бар көченә эшләп ята, калганнары йоклый, кәрт суга, әкият саталар, чөнки аларга эш юк, скважинада мәйдан кысан, урын җиткереп булмый. Бу хәлгә бик эче пошып, Гәрәев күрше бригадаларны да әйләнеп чыкты. Һәр җирдә шушы күренеш. Уйланды-уйланды да коллективны ике вахтага бүлде: берсе көндез, икенчесе төнлә эшли. Аннары алышыналар. Юк кына яңалык иде кебек, мәшәкате, шау-шуы айга якын сузылды, дөресрәге, Гәрәев айга якын йокы күрмәде. Башта икенче сменага транспорт бирми йөдәттеләр. Анысы булса, цемент, измә куа торган машиналар юк. Боларын гына җайлаган иде, бу хәбәрне каяндыр ишеткәннәр дә, берләшмәнең хезмәтне саклау бүлегеннән комиссия килеп төште. Тикшеренә, төпченә башладылар, кем күрсәтмә бирде, кәгазе кайда, кулын кайсы начальник куйган? Капиталь ремонт кебек катлаулы операцияне төнлә башкарып чыгу хакындагы фикер кайсы юләрнең башына килгән? Озын итеп акт төзеделәр дә китеп бардылар. Вакытны күп югалтканнар иде, Гәрәевләр ачу, үҗәтлек белән иртәнгә кадәр, секундка да туктап тормыйча, тәнәфессез эшләделәр. Гәрәевнең башына шул әйбер һич сыеша алмый иде, әгәр агымдагы темпта, бер бригада гына булып эшләсәк, кая барып чыгачакбыз без. Скважина, нефть чыгаручы, куучы нокталарның күбесе бер чорда — моннан унбиш еллар элек төзелгән. Димәк, алар бер чордарак сафтан чыга башлаячак, дөресрәге, башланды да инде ул процесс. Скважиналарга бик кызу рәвештә, кыска срокларда ремонт ясап чыгарга кирәк, моның белән шөгыльләнүче бригадаларның саны бармак белән генә санарлык. Әгәр шушы метод, ритм белән эшләсәк, сафтан чыккан скважиналар өчәр, алтышар ай чират көтеп утырырга тиеш булачак. Моны булдырмау өчен йөзәрләгән ремонтчылар коллективы төзергә кирәк. Ә бу мөмкин түгел. Бик гади сәбәп: республика күләмендә генә мондый санда бригадалар тотарга база да, техника да, ресурслар да юк. Алай әйтү дөреслеккә бик үк туры килми икән. Бар алар. Әмма алар икенче максатка тотыла. Безнең үзмаксат ремонтлар ясап яту түгел, ә нефть чыгару. Менә нәрсә төп бурыч!

Үз начальствосы кыса башлагач, ул аларга шушы уйларын ачып салды. Партоешма секретаре дә шушында иде. Тегеләр бик озак дәшми утырдылар. Ниһаять, начальник урыныннан торды.

— Әгәр төнлә авария ясасаң? Үзеңне нәрсә көткәнен беләсеңме?

— Аварияләрнең сәбәбе төн түгел, ә начар, иске инструментлар. Безгә сыйфатлы насос, компрессор торбалар җитми. Сез моны яхшы беләсез.

Начальник тагын уйга калды. Тирән җыерчыклы озынча йөзен, каш астыннан сөзеп карап, Гәрәевкә текәде.

— Шулай, шулай... Әгәр без берни белмәдек, күрмәдек ди, Әнәс Гәрәевич, син шушы рухта дәвам итәсең ди, билгеле инде, төнге вахта белән, әлбәттә, үзең буласың ди... Безгә, һич югы, икенче сменада авария булдырмауны конкрет гарантияли аласыңмы?

Гәрәев мондый вариант булу мөмкинлеген алдан ук күңеленнән үткәргән иде. Начальник — карт төлке. Турыдан атака ясау броня щитка барып бәрелү белән бер. Маневр кирәк. Фланглардан яки тылдан сугарга. Ә ничек? Нинди юллар, сукмаклар белән генә булмасын, бу эшкә аны да тартырга. Кызыксындыру алымы акланмады. Мәҗбүр итәргә кирәк! Юкса, бар мәшәкать, җаваплылык үзенә — Гәрәевкә генә кайтарылып калачак. Бу — җиңелү дигән сүз. Чөнки ул болай да алҗыды. Көче җитмәячәк.

— Әнәс Гәрәевич, ашыкмыйча уйлагыз. Сезнең вәгъдәнең бәясен яхшы беләм, аңа ышанам.

«Ну карт төлке, койрыкны матур болгый! Тагын хәйлә, матур сүзләр! Әмма барып чыкмас, парашютың ачылмас бу юлы! Без дә мәктәп баласы түгел!»

— Авария минем ихтыярга бәйле түгел. Гарантия бирә алмыйм.

Гәрәев торып басты, кулларын урындык аркасына куйды, барлык игътибарын, акыл сәләтен җыеп, берничә җавап төрен тагын бер кат зиһененнән үткәргәннән соң, тәвәккәлләп, соңгы патронын атарга булды.

— Аптыраганнан тырышабыз инде. Квартал планы яна, простой күп. План үтәлеше туксан процентка да тулмый. Хәзергә... — Гәрәев начальникның йөз сызыгындагы һәр үзгәрешне отып калырга тырышты. — Болай барсак, белмим, мине һәм сезне нәрсә көтәдер...

Тиде. Унга тигерде Гәрәев! Начальник авыр, аркылыга шактый җәелгән гәүдәсенә кысан креслосын дөбер-шатыр китереп, егетләрчә энергия белән торып басты, кулын сузды.

— Уңышлар телим. Ничек башладың, шулай дәвам ит. Бергәләп эшлибез.

Акыллы, кыю начальник иде мәрхүм. Соңыннан, берничә елдан соң, аның каберенә беренче туфракны үзе салды Гәрәев, беренче чәчәкне үзе утыртты. Әзмәвердәй гәүдәсе булса да, йөрәге соңгы чиккә җитеп таушалган булган икән шул.

...Гәрәев вагон эченә кергәндә, аның егетләре кәефләнеп ашап утыралар иде инде.

— Сыпыра буран!

— Кодагыйныкын түгел, үзебезнең ашханәнекен сыпыртабыз.

Хәйдәр, укып утырган газетасын ташлап, Гәрәевкә дигән термосны өстәлгә куйды.

— Кыстый-кыстый ашатам әле боларны, Әнәс Гәрәевич, ашамасаң бу суыкта эшләп булмый ул. Күбрәк ашарга кирәк.

— Алай да Хәйдәр абзый бар... аш тәрләндерергә.

— Болары пүчтәк әле аның, егетләр. Менә Хәйдәр абзый елга якын инде сатащмыйча, хәтта ки төш тә күрмичә йоклый икән. Сорыйм, сорыйм, ярты куям дим, әйтми инде серен. — Тракторчы Гаптелхәй сүнеп калган рацияне рәтләп утыра иде, эшен куеп торды. — Монда,

бригадир, местком члены бар, безне санга сукмасаң, алар хакына сөйлә инде, Хәйдәр абзый.

— Әнәс Гәрәевич, әйтегез инде, сөйләсен.

— Ник, сөйлим бик ачуны китерә башласагыз. Ул әйтмәсә дә, сөйлим. Кешедән яшерер сүзем юк. Менә шулай: сез әле миннән яшьрәк, кайберләрегез бала гына, дөньяны минем кебек үк аңлап бетермисез. Турысын әйтәм, хәзер икенче сорт халык китте җир шарында. Элеккеге халык юк ул. Юк! Ник юк! Чөнки кешеләр җирдән аерылдылар. Менә кайда төп сәбәп! Шәһәр, өйләр асфальт, таш, бетон өстендә утырамы? Утыра. Хәзер басуда йөрибез ди — аякта итек, ботинкалар. Өскә карагыз әле, түшәмгә димим, һавага карагыз: электр баганалары күкнең яртысына тиклем менгән, ә шәһәрдә ул гүпчим, хәтта җир астында да бар. Димәк ки, без электромагнитик дулкыннар оясында яшибез. Зыяны бармы аның? Бар кәнишне. Чөнки тәндә электр туа. Кичтән утны сүндереп, күлмәк, майкагызны салып карагыз әле, аннары белерсез. Бөтен кием чытыр-чатыр килеп тора. Тәндәге шушы токны бетерергә кирәк. Җиргә генә китәр иде ул, булмый, бөтен җирдә изоляция. Казанда әнә, малай күреп кайткан, башлырак кешеләр, кырга чыгып, яланаяк йөриләр ди. Ә мин бер уткәргечне йоклый торган карватка бәйләдем дә, икенче очын җиргә тоташтырдым. Шуннан бирле саташмыйм. Тәнне кытыклап тора торган электр тогы җиргә китә.

Хәйдәр, сүзенә бирелеп, әсәрләнеп, бүлмә буенча ишекле-түрле йөренә башлады. Кыяфәт җилле моның, ике кул кесәдә, ике күз маңгайда, йөз нәкъ урталай бүленгән: елмая Хәйдәр. Утыртты бит малай-шалайны. Сизеп тора, ул бит баскан, югарыдан бар да күренә, тегеләр ни чынга, ни уенга алырга белмиләр. Аптырашкан үрдәкләр кебек, таралып утырганнар да катып калганнар. Хәйдәр абзагыз булыр ул! Гәрәевкә текәлгәннәр. Хет ун Гәрәевне утырт, мондый речькә каршы чуртым да эшли алмыйлар.

Һич көтмәгәндә, барысын да сискәндереп, ватык рация телгә килде. Ниндидер буровой янында торба ташучы «ЗИЛ»лар баткан. Базадан трактор сорыйлар.

Онытылып киткәннәр, ахры. Берничә урында сигарет пыскыта башладылар. Гәрәев сәгатенә карады.

— Я, гвардия, кузгалабызмы, оета да башлады.

— Бигрәк яңгыр ич, Әнәс Гәрәевич, әллә берәр сәгать утырышмы?

— Эшкә башлаганчы берәр сәгать болай да үтәр. Тән кычыта, егетләр, кичкә чаклы җиргә басып бөтен электрны чыгарып бетерик әле! Юеш балчык токны итек аша да суыра ул. Кузгалдык!

Шыбыр-шыбыр яуган эре тамчылар, майга буялып, шомарып беткән брезент курткаларга, чалбарларга бәрелеп, яшькелт-кара төскә керәләр дә, җиргә коелалар.

Төркем икегә бүленде. Ремонт көтеп ятучы чираттагы скважина якын — километр чамасы гына иде, шуна күрә Гәрәев, вахтаны икегә бүлде дә, төп көчне үзе белән шунда алып китте.

Монда башлык булып Хәйдәр калды.

Ике көннән соң иртүк геологлар килеп җиттеләр. Прибор әле җир өстенә чыгып бетмәгән, берничә шәмне күтәртәсе бар иде. Туристлар кебек тезелешеп, Хәйдәр белән Фәнисне тамаша кыла башладылар. Ниһаять, Фәнис йозакка соңгы торбаны эләктерде. Гаптелхәй, тракторына әз генә газ биреп, шәмне күтәртте, геологлар приборны ычкындыру өчен егеткә ярдәмгә ашыктылар. Хәйдәр килеп басты.

— Яле, бәгърем, абзаларыңа ниләр сөйләрсең икән?

Метрга якын озынлыктагы колбасага охшаш прибор, ян-яктан яньчелеп, изелеп беткән, түбәнге очы экраэп ыргакка әйләнгән иде.

— Бу нинди фокус тагы, үз гомеремдә, беренче тапкыр күрәм, — Геологларның партия начальнигы, күзләренә ышанмыйча, түш кесә-

сеннән күзлегеи алып киде. — Энем, безнең заявка кәгазен генә алып кил әле?
Фәнис тимер шкаф эченнән кирәкле кәгазьне китерде.
— Я, ремонтчылар, сезнең кайсыгыз начальниграк?
— Ник, ник? — Хәйдәр, нидер сизенеп, сагая калды. — Икебез дә начальник.
— Эш башлаганчы, менә бу кәгазьне укып чыктыгызмы? Мин сездән сорыйм, таныштыгызмы бу документның эчтәлеге белән?
Хәйдәр кәгазьне кулына алды. Әйләндерә-әйләндерә тикшерә башлады. Кояш яктысына куеп, бер күзен кысып карады.
— Таныштык. Ә нигә!
— Артистлар! Шәп укыгансыз икән. Гәрәев үзе кайда? Миңа Гәрәевне табыгыз! Чукынып китсен күрше скважинаң, энем, бармак белән каләмне аерырга өйрән башта, аннары тыгылырсың безнең сүзгә. Аңлашылдымы? Нәрсә авызыңны ачтың, аңлашыламы дим!
Фәнис, каушавыннан үзе дә сизмичә, артка таба чигенә башлады. Геологның күзләре техникум печате кадәр булганнар, пыяла аша зәһәр ялтырап, кара булып күренәләр. Кысып йомарлаган йодрыкларын өскә күтәргән дә һаман Фәнис өстенә килә.
— Аңлатыйммы, гипопопопо.... потом.... — теле буталып, тотлыгып калды. — Ну алайса үзебезчә, татарча гына әйтим инде, сарык!! Өч мең сумлык приборны харап иттегез! Миңгерәүләр! Соңгы вакытта орден, медальләр генә ала өйрәнгән идегез, тагын берне бирдерәм әле мин. Иң зурысын! Аңлашылдымы? Юк, син әйт, аңлашылдымы? — Йодрыкларын уйнатып, ул тагын егет өстенә килә башлады.
Фәнискә чигенер җай юк, артта пычрак чокыр иде. Ул-бу була калса дип, җавап удары ясарга әзерләнде.
— Аңлашыламы?!
— Аңлашыла.
— Башта ук шулай диләр аны. Иң кадерле приборны ватасыз, аннары нервыда уйныйсыз. — Ул сүрелеп калды. Тәмәке кабызды. — Абый кеше, карагыз әле, заявкага ничек язылган?
Хәйдәр, кәгазьне алып, тагын әйләндерә башлады.
— Ничек язылган, шулай эшләдек.
— Приборның маркасына карагыз әле?
— Әйтәм ич, ничек язылган, шулай эшләдек. Маркасы да дөрес.
— Маркадан соң ике цифр — алтмыш миллиметр дигән сүзен укыдыгызмы? Менә шул шул! Сез приборның кырык миллиметрлысын төшергәнсез! Өч көнлек эшегез һәм приборыгыз тү-тү! Әнә бригадирыгыз да килә. Бүлешегез калҗаны!
Ә Гәрәев шат, елмая. Изүен чишеп җибәргән.
— Геологлар белән эш беттеме? Шәп! Хәзер насос куа башлыйбыз. Кабель ярты сәгатьтән булыр. Юлда.
— Әнәс Гәрәевич, килегез әле, — Хәйдәрнең тавышы шактый мескен яңгырады. — Мин карт юләр дә гаепле монда. Бик зур хата чыкты бит. Стажер малайга гына кушкан идем, бөтенесен бутаган! Өч көнлек эш җилгә очты. Укыган кеше булгач, ышанган идем...
Фәнис исе китеп, Хәйдәргә шаккатып карап тора.
— Нәрсә?! — Гәрәев, ук булып, партия начальнигы янына атылды.
— Эшегезнең нәтиҗәсе бу, кара, соклан! Монысы — заявка.
— Так. так... Хәйдәр дус, аңлатыгыз әле?
— Үзем карт юләр инде, укыган кеше дип стажерга тапшырган идем, тикшермәдем...
— Әнәс абый, мин монда нейтраль, аны Хәйдәр ага үзе...
— Тай дим яхшы чакта күперчектән! — Гәрәевнең зәһәр карашы егетне көйдереп, тагын да бөрештереп җибәрде.

— Иптәш орденлы Гәрев, бик читен булса да, приборны баланстан алып, сезгә күчерәбез. Рәхим итеп, акт төзик. Пардон!

— Так, так... Қил әле бирегәрәк, иягеңне күтәр!

— Сез нәрсә? Қаерма башны!

— Иягеңне күтәр дим! Телеңдәге орденыңны иягеңә генә тагам да, күз төбеңә печатен басам! Күтәр иягеңне!

— Сез нәрсә?! Закон бар!

— Ә-ә, закон исеңә төштеме? Ә ни өчен үзең закон буенча эшләмисең?! Кем кулына тапшырдың заявканы, инструкция үткәрдеңме? Кая аларның подписе? Ни өчен мин белмим!

— Ә-ә... Син инде боларны уйлап чыгарасың, иптәш Әнәс Гәрәевич, без бервакытта да алай эшләмибез. Заявканы без калдырабыз гына.

— Қалдырасыз гынамыни?! Ә ул практикант егет аны каян белсен? Кеше хезмәт юлына беренче көн аяк баса, син таяк тыгасың? Җавап бир, син бит безгә үзегезнең линия буенча эш тапшырасың. Заказчик. Сөйләштеңме соң егетнең үзен күреп? Син аңа сәлам дә бирмәгәнсеңдер әле. Акт язам! Ә без язсак!

— Сез яза алмыйсыз. Закон безнең яклы!

— Сез дә яза алмыйсыз. Бездә дә бар закон!

— Алайса, нишлибез?

— Уйла, ни өчен партия начальнигы!

— Списать итәбез. Брак булган. Бәлки, әле ул заводтан ук дефект белән чыккандыр.

— Пожалуй.

Мәсьәләгә чишелеш табылды. Қызу-кызу атлап, вагонга юнәлделәр. Йөгереп барып, Хәйдәр аларга ишек ачты...

Фәнис бер читкә баскан да, юл баганасы кебек, кыйшаеп төшкән. «Фронтовик, Шәйморатовның разведчигы». Үзе ишеткән сүзләргә ул һич кенә дә ышана алмый, аңындагы ниндидер уй бу эпизодны кире этәрә. Ни өчен ул шулай эшләде, заявканы бит Хәйдәр үзе алып килде. Фәниснең тырнак очы хәтле дә катнашы юк бит бу вакыйгада. Ике ут арасында Фәнис. Ышанып иде — дөреслек коточкыч. Аның зиһененә, аңына сыя алмый. Ышанмас иде — колак төбендә Хәйдәрнең кыланышы, сүзләре чыңлый. Үч итеп, ачу итеп, скважинаны ташлап, шушы минутта җәяү кайтып китсәң? Юк, бу качу булачак. Мондый әйбер аның характерында бөтенләй булмас. Кемдер иңсәсенә кулын салды. Караса — Гаптелхәй.

— Уйга талган безнең егет.

— Гаптелхәй абый...

— Беләм, егет, ишеттем.

— Ничек ул шулай... Ул бит сугышта катнашкан. Солдат.

— Ха-ха! Ышанган аңа безнең егет. Әйтик, табынган. Төкер син барысына да. Ир булып кал! Малайлыктан чыгарга вакыт. Алдый бит ул. Алдый! Ә син мөкиббән китеп, тыңлап утырасың. Синең яшьтә кеше белән кешене аера белергә кирәк инде.

— Әнә Гәрәевич та Хәйдәргә ышанды. Ул аера белмимени?

— Белә. Ул Хәйдәргә ышанмады. Списать итү өчен сәбәп кирәк идеме? Баш! Геологларны кысу өчен Гәревкә син бик яхшы сәбәп булдың. Югыйсә, ул өч мең өчен җавап бирергә тиеш иде. Шулай хәлләр, дус кеше. Хәзерлән, приборның дөрес маркалысын алып чыгачаклар хәзер. Эшне яңадан башлыйбыз.

Вагоннан дәррәү чыктылар. Геологлар китеп барды. Гәрәев кулын алга сузды.

— Урыннарга! Вахтадан калып эшлисезме, башкачамы — анда катнашым юк. Әмма иртәгә кичкә бу театр беткән булсын! Тагын һәйкәл кебек катып калдыгызмы? Башларга дидем мин сезгә!

— Тотындык, тотындык, Әнәс Гәрәевич. Аллаһе боерса, иртәгә кичкә өлгертербез. Әйдәле, Фәнис туган, ачкычны үзеңә таба бор. Шулай, шәп.

IV

Сәет урманнары бетеп, Буләр болынлыгы башланып киткән җирдә, сөзәк яры карабаш үләне, камыш, куе вак талларга төренгән, кеше күзенә чалынырга яратмаган йомры күл утыра. Төньяктан салкынча җил исеп куйды. Атналап яуган яңгырдан су парлары белән туенган тынчу табигать сулыш алып җибәрде. Урман шыбырдап алды, күл өстеннән зәгыйфь дулкыннар йөгереште. Камышларга сыенып, йокымсырап утырган кыр казы сискәнеп башын күтәрде. Әле аңа бер яшь тә булмаса да, үз гомерендә көзне беренче тапкыр гына каршы алса да, эчке тоем белән ачык сиземләде: дөньяда, җир йөзендә ниндидер үзгәреш бара. Шушы үзгәрешкә бәйле рәвештә ул каядыр очып китәргә тиеш. Ләкин кая, кайчан, кемнәр белән? Каз тагын сагышта.

Җил көчәя, суыгая төште. Күңелне оетып, йокыга тарта торган болытлар тарала, урман ягыннан ара-тирә генә булып йолдызлар калка иде. Эңгер-меңгер куера барса да, казның силуэты әле ачык күренә. Аның түше, гәүдә өлеше ак, ә канатының төп һәм оч өлешләре соры, нәкъ баш очында кара түгәрәк — бүреге бар иде. Ала канат үзенә белергә тиеш булган «белем» запасының барлык төрен дә яхшы үзләштергән иде, шуңа күрә ул азык, җимне иптәшләренә караганда тизрәк, күбрәк тапты, гәүдәгә дә калкурак, тазарак булып үсте. Билгеле, дедуктив уйлау сәләте юк иде, шуңа күрә аны, ни өчен ул ялгызы гына, ни өчен бу якларга эләккән, нәрсә китергән аны монда, кебек сораулар борчымый, башына да килми. Ул ялгызы. Шуңа тынгы таба алмый. Аның бөтен барлыгын сагыш сарган иде. Дөресен әйткәндә, Алаканатның шушылай корбан хәлендә калуында кошның үз гаебе бөтенләй юк иде.

...Яз көне Шотландиянең төньяк-көнбатыш ярын океан дәһшәтеннән саклап тора торган бихисап күп утрауларның берсеннән казлар төркеме күтәрелде. Хәтсез биеклеккә күтәрелгәч, иң дәү, күпне күргән, күп яз, көзләр кичергән ата каз төркемнең алдына чыкты, калганнары өчпочмакка тартым чөй хасил итеп, аңа сыендылар. Болай очуның берничә сәбәбе бар иде. Чөнки, мондый формада тезелү алдагы коштан кала торган өермә һава дулкыннарына эләгүдән саклый, аннары, болай очканда казларның канатларыннан ясалган агым, горизонталь таралып, арттан килүче көчсезрәк казга яхшы терәк тә була.

Аста күп күлләр, урман, болын, сулар калды. Көнчыгышка күз тотып, казлар оча. Алда ата каз, аннары — ана каз, ата-ана... Бик арысалар, урыннарын алышалар.

Казлар очуыннан җиргә яз җыры, ишетелер-ишетелмәс моң агыла. Кешеләр кояшка каршы басалар да, кулларын каш өстенә куеп, казларга таба, күккә карыйлар. Аларның күңелендә бик эчкәре яшерен, төреп куелган хис — нәфислек хисе уяна.

Караңгы төшкәч, казлар йолдызлардан аерылдылар да, җирдән бөтенләй сизелми, әмма югарыдан ап-ачык булып, ялтырап яткан күл өстенә төштеләр. Тамак туйдырып, черем итеп алганнан соң, төркем башлыгы горур каңгылдап, сәфәрне дәвам итәргә чакырды. Шул чак ике казда табигатьнең гаҗәеп могҗизага тиң күренеше уянды. Алар үзләренең илен, ерак үткәндәге ватанын таныдылар. Моннан егерме, унбиш еллар элек бу җирдә аларның туганнан туган токымнары яшәгән, һәр җәйне шушында тереклек кылып, нәселләрен арттырганнар. Әмма кара, канлы еллар килеп, кешеләр тарафыннан бөтенләй кырылып бетә язган, аз санлы кардәшләре икенче җиргә күчәргә мәҗбүр булганнар.

Казлар канатлары белән ярсып-ярсып кагына, талпына башладылар. Көн тыныч, әз генә дә җил булмаганлыктан, һава тыгыз, авыр иде, зур көч куеп, казлар судан аерылдылар да, күл өстен тагын бер кат кыйгач, ярым түгәрәк ясап ураганнан соң, мари урманнарына таба юнәлделәр. Төркем башлыгының сузып-сузып кыйгаклаганы, ягъни су өстендә утырып калган бер пар — ата һәм ана казны чакырганы яңгырап ишетелде. Ләкин тегеләр кузгалмадылар. Алар үзләренең илен — Татарстан җирен таныдылар.

Танымаган булсалар икән...

Белмәделәр шул алар. Үзләрен өч кешенең иртәдән бирле күзәтеп, сагалап йөргәнен сизенделәр, әмма игътибар биреп житкермәделәр. Көз житте. Аның артыннан зәһәр, ачы сулышын өреп кыш житәчәк. Шуңа күрә, ерак юлга кузгалырга вакыт житкән иде, алар әзерләнеп тә беткән иделәр...

Кешеләрнең сөйләшүләрен дә ишетте ич алар. Аңламадылар шул. Менә бит ул җил китергән авазлар:

— Зөягә казлар төшкәли диләр, шушыларммы инде ул, Әхтәм бажа.

— Шушылар. Мин аларны җәй буе карап үстердем инде. Башта икәү генә иде. Күз маңгайга менде. Каян чыккан болар дим. Ят ризык тешеңне сындырып керер, ди. Мин аларны шунда ук тәвәккәлләгән идем инде. Өлгермәдем. Анасы юкка чыкты, әһә, минәйтәм, ояга утырды бу. Сабыр итик. Бөтен уй рас килде бит. Әнә, күрәсеңме, дүртесе гәүдәгә бераз калыша, бәбкә ие алар кайчандыр.

— Ярар, егетләр, күп сүз — юк сүз. Җәһәтрәк кыланыйк. Я кичәге кебек очып китәрләр. Хәзерге хайваннарның акылы керделе дә чыктылы. Дөньясы кебек.

— Әти, патронның үрдәккә дигәнен корыйммы?

— Алдыралмас ул. Төлкегә дигәнен, берле номеры сугылганын куй. Кабаланма. Иң сулдагысына төзә. Калганын үзебез...

Малай ашыкты. Борчак зурлыгында, йомры ядрәләр Алаканатның берничә каурыен гына су өстенә алып аттылар.

Төн тәмам аязды. Салкынча рәхәт җил исә. Һавага күтәрел генә, җилгә таянып, көчне гел сарыф итмичә, тәүлекләр буе очарга мөмкин. Алаканат тынычлыгын тәмам югалтты, күл суы, сары сагыш булып, үзеннән аны һич аерырга теләми. Күктә балкып-балкып йолдызлар җемелди. Алар Алаканатны чакыра, әйди. Каз үзенә юлны йолдызларга карап сайлаячагын да тоемлый.

Әмма каз ялгыз. Ул ялгызлыктан курка, өченче көн рәттән ул үзенә иптәшләр көтә. Туганнары да, иптәшләре дә юк... Юлга кузгалырга, бер көн дә кичектермичә, сәфәр чыгарга кирәк. Ул ялгыз. Яшь әле ул. Курка. Тирә-ягы — сары сагыш. Күктә — йолдызлар... Алаканат шулар арасында. Ул сайларга тиеш...

* * *

Ярты сәгатькә генә туктап торган яңгыр төштән соң кабат ява башлады. Авыр, катлы-катлы, мендәргә тартым күпереп торган шөкәтсез болытлар, агач башларына тиярдәй булып, түбәннән агылалар. Бодай басуы аксыл утрау булып калган. Берничә чакрымнан ары берни күренми: горизонт, су парлары, күксел томан белән аралашып тоташ стена хасил иткәнлектән, артык якынайган.

Иртәдән бирле Фәниснең күңеле боек.

Иртәдән бирле җиргә кирәкмәгән яңгыр ява.

Кичен начальник бүлмәсендә контораның барлык җаваплы әһелләре, мастер, бригадир, техник, инженер хезмәткәрләр колхозга ярдәмгә

кем, кайсы бригада, ничә кеше бару мәсьәләсен хәл итеп, бүлешеп ятканда туган ыгы-зыгыны Гәрәев бүлде. Дөресрәге, бу мәсьәләгә нокта куйды. Барысы да күршеләренә салгалаша, әллә нинди сәбәпләр, кеше житмәүне, план януны казып чыгара, сатулаша, шаулый башлагач, начальник, дилбегәне артык ычкындырып җибәреп, шуны җыя алмыйча аптыраган кыяфәттә, партиянең шәһәр комитеты күрсәтмәсе басылган кәгазен болгаган иде инде, тавышы да күмелеп калган иде, Гәрәев торып басты.

— Иптәшләр, — калын, көр тавыштан бераз тына төштеләр, — иптәшләр, горком күрсәткән цифр буенча безнең контораның утыз процентны барырга тиеш. Шушы сан һәр бригадага тигез итеп бүленсен. Минем бригада бара дисезме? Бара. Кайгыртуың өчен рәхмәт, күрше! Безнең коллективның нәкъ яртысы — ун кеше иртәгә колхозга китә. Башка сораулар юкмы? Булмаса, бигайбә, кайтып киттем.

— Стоп, стоп! Син нәрсә, Гәрәев, начальник булдыңмы? Контора өстеннән командовать итәргә ни хакың бар?! Безне тагын сыгасың? Кара аны, план буенча үзеңне дә бер кисәрбез! Кендегеңнән югары сикермә дим сиңа! — Ярсыган бригадирны, иңнәренә басып, урындыгына утырттылар.

— Тыңла, күрше. Әгәр мин начальник булсам, бу бүлмәдә синең кебек җилкуарларның эзе дә булмас иде. Инде ялгышып эләксәң, монда чакырганчы үзеңне генә берәр көн басу буйлап җәяү йөртер идем. Крестьян дусларның ничек эшләвен күрер идең. Так что, ераграк йөр! Монда эшлисең килсә! Сораулар бармы?

Аңа кабат дәшүче булмады.

Иртән колхозга баручылар янына Хәйдәр дә килеп басты. Кемдер Карабаш күленнән үткән ялда метр ярымлы җәен тотуы белән мактана иде, Гаптелхәй сүзгә кушылды.

— Я, арттырма инде, Хәйдәрләнмә...

Тәмәке капкан Хәйдәр кызарынды, бүртенде, әмма ишетмәмешкә сабышты. Гәрәев аны үз янында, скважинада калдыра. Ул ничек тә аннан ычкынырга җай эзли. Хет җәһәннәмгә барырга булсын — риза, шушы көннәргә генә калмаска. Шайтан аны җиңә алмас, барыбер котылу җаен табар, ләкин Гәрәевтән... Эшләтеп үтерер, ике-өч көн вакыт эчендә айлык көчеңне суырыр, җенле тәре! Соңгы чорда, геологлар белән булган вакыйгадан соң, мастер аның белән аерата кызыксына. Моның нәрсә икәнен ул яхшы аңлый.

Кызу-кызу басып, Гәрәев килә иде. Хәйдәр төркем ягыннан читкәрәк китүне дөрес тапты.

— Егетләр, ара ерак, куна калырга туры килер. Безгә егерме гектар җирдә егып ташлаган симәнә бодаен, көлтәләр ясап, торгызырга кирәк. Шулай суда ятса, үрә башлаячак, ди. Өч көндә өлгерә алырсызмы? Хмм, ну сез, дуслар, ике көнгә тырышып карагыз әле! Үзегез беләсез, эш монда да тыгыз. Кемне башлык итәбез?

— Гаптелхәй эш кешесе инде. Булса...

— Юк, әле монда яшьләр бар, белем, акыл иярә. Кая әле ул?— Гаптелхәй Фәнисне эзләп тапты. — Алгарак чык, начальник.

— Бара инде, бара. Чәче дә озын түгел.

Иртәдән бирле Фәниснең күңеле боек. Метр да житмеш бишле гәүдә нелә дә бөкрәеп торып баса, нелә дә торып баса... Үтереп эрнеп, биле арыды. Башта бик бик пүчтәк күренгән эш тора бара тәмам басты, муеннан гарык итеп туйдырды. Кара балчык резин итекләрне үзенә суыра, нелгән саен, яңгыр суы муенга җыелып өлгерә дә, бөтен буеңа күтәрелгәч, утлы сызыклар булып, аркаңы телгәли, тәннән пар күтәрелә.

Беренче көнне эш ярыйсы барды. Күңел көр, тамак тук иде әле. Арылмаган. Эшләделәр дә эшләделәр. Участокның яртысына җитә яздылар. Күрше бригадалардан юкны-барны карап, тикшереп йөрүче

«турист»лар, көлтәләр утырып торган мәйданны күреп, шаккатылар. «Гәрәев үзе котырган, кешеләре дә котырган, кешелектән чыккан икән болар», — дип, үчекләшеп йөрделәр. Ләкин бүген эш авыр бара. Дөрес, алар башкалардан күп алда, ләкин кичкә бетерә алмаячаклар. Иртәгәсен көндезгә кадәр сузылмаса. Көндез бик начар ашаттылар. Кәбестә шулпасына чүмәкәүләп өелгән дуңгыз ите шыр тоз иде, ашны кабып та карамадылар. Бәрәңге, алып баруын барырмын, әмма кайтуын үзегез чамалагыз, дигән. Ачлы-туклы корсакка чәйнең файдасы, үзбәкләр әйтмешли, шул хәтле генә. Кешеләр ачулы иде. Ә Фәниснең, никтер, ачуы да кабармый, аңа дөнья, тормыш, бодай басуы — барысы да моңсу, бәгыренә үтеп керә торган моңсу иде.

Авыл ягыннан атка атланган бригадир — шушы кырның хуҗасы күренде. Нефтьчеләр бердәм җанланды, барысына да дәрт өстәлде, шатланышып, ниндидер могҗиза белән исән калган, басу уртасында утыручы имән төбенә җыела башладылар.

— Ну кабер тактаңны! Койса да кояр икән!

— Чынлап әйтәм, малайлар, тәннең чыланмаган бер генә җире дә калмады бит. Аяк бармакларына хәтле, ышанасызмы, ойый. Ул-бу булмаса инде.

— Бармак еруңда, башка җирләрең сакла. Үпкәгә эләктерсәң...

— Җирнең сүрүен тишеп бетерделәр. Көн дә бер спутник җибәреп кенә торалар.

— Аллаһе тәгаләнең тотнагы бетте.

— Әллә америкаңнкылар берәр нәрсә маташтыра микән? Ышанасың икән...

Инсәсе аша кайтарып ике сумка аскан бригадир килеп җитте.

— Ашыкмагыз, арысланның асыллары, исемлек буенча таратам. Растрата ясата күрмәгез. Башладык: Шәвәлиев бригадасы — ике ярты, Хуҗин — өч ярты, Щербинин — ике ярты, Исламов — алты кызыл... Закускага иң әйбәт турист әбәте булыр, арысланнар, ашап калыгыз. Башкасына акчагыз җитми.

Фәнис тә ярты стаканлап аракы эчеп карады. Бераз җылыткандай итә, әмма берәүнең дә башына китми. Мөгаен, тир, пар белән агуы чыгып барадыр.

— Бригадир, кая соң синең кешеләрең? Нишләп басуда берәү дә юк.

— Безнең кешеләр сез инде, арысланнар. Шәһәргә каберең якын булмасын икән. Барысы качты. Карт-коры да, шәһәр эшенә керә алмаган хәчтерүшләр генә калды. Фермага кеше җитми. Хет кырыкка ярыл!

— Күзгә карап Хәйдәрләнмә, бригадир. Бездә шундый арттырып сөйләүче бар. Кешеләрегез җитәрлек сезнең. Дәлил кирәкме? Тыңла!— Гаптелхәйне бик борчыган сорау иде бу, кызып китте. — Кешеләрегез бар сезнең, әмма алар юньләп эшләмиләр. Менә без фатир төшкән йортта кичә тап-таза бер ир белән хатыны көне буе эчеп яткан. Хатыны сыер савучы, ире комбайнер. Сөт планыгыз үтәлдеме кичә? Шул шул. Ул бөтенләй эшкә барып та карамаган. Комбайнчының хезмәте күз алдыбызда. Покоска бастырып, көлтә ясатасы иде аннан да. Коры көннәрнең кадерен бераз аңлар иде. Иртән кергән аз-маз әйткән идем, фатирдан да куып чыгардылар менә. Биш кеше без.

— Бәй, безгә дә кайтмаска куштылар.

— Беләм инде, арысланнар, миңа барысын да житкерделәр. Онытканчы теге комбайнчыны сөйлим әле. Үлә язды бит ул, кабәхәт. Мин очрамаган булсам, киткән дә булыр иде. Шәһәрдән килгән АТХ шоферлары көндезен ничектер инде моңа ике ярты ак биреп калдырганнар. Кичен бергә чамаларбыз диптер инде. Шуннан ул көнне яңгыр китте. Машиналар килмәгән. Карыйм, басу уртасында комбайн. Бункерында икмәк калмаганмы — белешим әле минәйтәм. Килдем якынга ук, күзгә һич ышана алмыйм бит. Ачам да йомам. Комбайн баскычы-

на аркасы белән сөялеп баскан бу, куллары өстә — тотынган, башы артка каерылган. Аптыраудан ми катты. Үлгән булса куллары өстә булмас иде, терегә дә охшамаган. Бармакларын баскыч тимереннән каерып ычкындырдым да кулларын аска төшердем. Башы алга чөйлекте дә, моның ачык авызыннан аракысы түгелеп китте бит. Вәт гад! Аракыны эчә-эчә эче тулып, авызына менеп җиткән! Шул түгелмәсен дип, хәсис, ятмыйча, басып тора икән. Ияргә аркылы салып, көчкә алып кайттым. Өченче көн инде, әле айный алмый.

Хикәя ирләрнең кәефенә хуш килде. Арыганнары онытылып киткәндәй булды.

— Тагын онытыла яздым бит, арысланнар. Искә дә төшермисез. Йокларга урынны кыр станында хәзерләтәм. Шәһәрдән бер группа яшәп ята анда. Зарланмыйлар.

Караңгы төшә башлауга, соры кожан плащын бөркәнгән, америка фермерларын хәтерләткән аксыл чәч, шакмаклы иякле бригадир, зур гәүдәсен ат өстендә төз тотып, чаптырып килеп тә җитте. Камчы сабын, Александр Невский кылычы кебек иеп, алга сузды.

— Арысланнар, минем арттан! Алга!

Фәнис, тураеп басып, бер мәл билен тотып торды. Бар гәүдәсе әрни, әмма билгә түзәр әмәл юк. Участокны бетерә алмадылар. Ярты көнлек эш калды. Бәлки аязып җибәрер? Хәзер ул гына ярдәм итәр микән соң? Башакларның җиргә тиеп торганнарында орлыклар бүртә, күбенә башлаганнар. Хәзерге минутта бердәнбер дөрес юл — аларны җирдән аерып, көлтәләр ясау. Икмәк — изге әйбер. Фәнис өчен ул әни, ватан дигән төшенчәләргә тиң. Шуңа күрә ул, менә шушылай юләрләрчә бөтен басуны егып ташлаган комбайнчыга да, квартирадан чыгып китүне таләп иткән кызмача апага да, һич урынсызга, зыянга яуган яңгырга да ачуын кабартмаска тырышты. Бу хакта уйлану бөтенләй урынлы түгел кебек иде аңа. Бәлагә тарган икән, икмәкне коткарырга кирәк. Кемнәрдә гаеп киткән, соныннан колхозчылар үзләре тикшерерләр, ачыкларлар, шуның өчен тиешле кешеләр куелган.

Тырпаеп торган кыска камылларга лач-лоч басып, Фәнис төркемгә иярде.

Яңгыр туктап калган иде. Төньяктан салкынча җил исеп куйды. Дымлы һава тибрәнеп алды. Түбә булып, шуның астына өелгән икмәк көшелләре, чи орлык киптерү корылмалары, җилгәргеч аппаратлар һәм ифрат зур лампочкалардан тәрәзәләре гөлт итеп балкып утырган ике ишекле озын гына йорт янына килеп чыктылар.

— «Россия» гостиницасымы әллә бу?

— Фәнис, начальник бит син, сораш әле, рестораны бар микән?

— О-о, бер атнасыз кайту юк, егетләр, анда хур кызлары йөри.

— Арысланнар, тәпиләрегезне менә бу лаканда юып керүегез сорала. Минем арттан.

Өй эче чиста, якты, җылы иде. Лач су булган өске киемнәрен өйалды өлешендә чишенеп, эчкә таба тула башладылар. Борыннарны кытыклап аш, лавр яфрагы исе таралган. Ишек катындагы ян бүлмәдән чуар чәчәкле алъяпкыч бәйләгән таза, бар җире дә күпереп торган, юантык апа чыкты. Йортның хуҗасы бу дип уйлап алды Фәнис.

— Хәмдия, егерме биш арысланны кабул итеп ал әле. Берсен генә дә качыра күрмә берүк. Ашат, эчерт, йоклат. Калганнарын авылга алып китәм.

— Бик рәхмәт, бик рәхмәт, ашатырбыз да, эчертербез дә, эшләсеннәр генә. Йоклау гына идәндә булыр. Бу хәтле миргә койка ничек җиткезәсең. Ярый әле, мәктәп интернатыннан матрацлар китерделәр. Түлке бераз сабыр итәрсез, анда ашыйлар әле, урын җитми. — Апаң тегү машинасы мени, текелди генә. Теле телгә йокмый.

Ашханәдән чалбар кигән кызлар чыга башлады. Егет, ир халкы, гомерләре буена беренче тапкыр хатын-кыз күргән кыяфәттә, боларны каш астыннан, сөзеп күзәтә башлады. Кызлар да бурычсыз калмады.

— Йоклыйбыз икән оҗмахта. Миңа теге юаны!

Юан кыз-очлы колак, ара ерак булса да тәки ишетте.

— Йоклагычың сынар! Өметләнмә, абзый!

— Сөбханалла! — Чандыр, кечкенә гәүдәле бораулаучы ник сүз катканына чын күңелдән үкенде. — Йокларга язмасын, тәки үтерер.

Шул чак, кухня ягына дип атлаган җиреннән, Фәнис кисәк туктап калды. Аның каршында бик тә, бик тә таныш кебек бер кыз басып тора иде. Кыз да туктады. Нәрсәдер исенә төшерә алмыйча, күзләрен тутырып егеткә карап тора. Аннары колакларына кадәр кызарды, озын, сөрмәле керфекләрен аска төшерде.

Ник туктадылар әле алар? Нәрсә булды? Шулай, мультфильм киносындагы геройлар кебек, бер-берсенә карап, мөкиббән китеп торуларыннан оялып, икесе дә бер мизгелдә диярлек, урыннарыннан кузгалдылар. Нефтьчеләр шаулаштылар, пешекче хатынга реплика ыргыттылар, яңгырны сүктеләр, ашны, сарык итен мактадылар, әмма аларның сүзләре Фәниснең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Аның үз хәле хәл иде. Кем ул? Ни өчен бу кыз аңа ниндидер якын танышын хәтерләтә? Аптыраудан гаҗиз Фәнис. Аш кайгысы качты, үзенең группасына юньлерәк җирдән йоклау урыны алып калу турындагы планы башыннан чыгып очты. Әледән-әле, чәчен рәтләгән булып, кытыршы учы белән маңгаен уа. Рәхмәт әйтеп, табыннан да кузгалдылар. Фәнис механик рәвештә аларга иярде. Кызлар урнашкан бүлмә кухня белән янәшә генә икән ич. Өстәлләр юк. Кызлар тимер койкаларына ничек кирәк шулай урнашканнар да кәефле кәяфәттә чыгып килүче нефтьчеләрне күзәтәләр. Фәнис, өлгермәүдән курыккандай, кабаланып, үзенә кирәк кешене эзләде. Әнә ул! Почмак караватта утыра, кулында китап, күзе Фәнистә. Керфекләрен аска төшерде. Иптәшләреннән калырга ярамый, егет бүлмәдән чыгарга мәҗбүр булды. Урамга чыгып, икенче ишектән үзләренең торакларына керделәр. Ярыйсы гына күңелле күренә, җылы, чиста. Хуҗа хатынның кулыннан эш килә икән.

Фәнис җанына һич тынгы таба алмый. Курткасын мич башына элгәннән соң, свитердан гына урамга чыкты. Баскыч төбе тәмәке тартучылар белән тулган. Күңелләрен тырнаган темаларга әңгәмә корып җибәргәннәр.

— Икмәк кызганыч. Болай торса, чери тек чери инде. Күпме байлык.

— Колхоз кешеләрендә җаваплылык житми. Бөтен дөньясын егып ташлаганнар бит. Сугу турында әллә уйлаганнар, әллә юк.

— Үткән атнада ике көн буш яттык. Булган цементны Гәрәев алып китә. Безгә машина калмый.

— Начальникка әйтәм, кеше җитми, юк, дим. Тап ди, хатыныңны алып кил, ди. Синеккенме, дим.

— Американы, француз, татар бер ракетада Венерага очалар икән. Юлда корабль ватылган бит...

Фәнис, итеген киде дә, бер почмагы балкып, икмәк киптерә торган башнясы гөрләп торган ындыр табагына килде.

Яңгыр, ниһаять, туктаган, җил чыккан, салкынча булса да, сулыш алуы рәхәт иде. Күтәрелеп карагач, Фәнис шатлыгыннан тагын маңгаен уып куйды. Күкнең бер чите ачыла барып, анда йолдызлар балкый иде. Әкрен генә кыр ягына атлады. Гомумән, ниндидер авыр мәсьәлә чишкәндә, имтиханга хәзерләнгәндә башы бик арыса, яки, киресенчә, эшләмичәрәк, иренеп кенә уйласа, ул, төннең кайсы вакыты булуга карамастан, урамга чыга иде. Тулай торак булганлыктан, вахтерша орыша, ишекне бикләп куя. Әмма Фәнис аңа игътибар да итми. Кирәк икән, беренче каттагы туалет тәрәзәсеннән чыга, рәхәтләнеп уйлап

туйгач, керә. Зиһененең иң шәп эшләгән чоры яңгыр астында әкрен генә, салмак йөргәндә. Ул моны яхшы белә, күп сынады.

Кайда гына очратты соң Фәнис бу кызны. «Гамлет» киносыннан Офелияне хәтерләтә. Әмма буе әз генә озынрак та, чәчләре карарак. Биек, йомры маңгай, озын, сөрмәле керфек, чиста, сыйфатлы пыяладай шома йөздә, аерылып, игътибарны җәлеп итәрдәй зур зәңгәр күзләр. Күзләр... Тукта, тукта! Имтихан биргәннән соң, аны таптый язган троллейбуста ул түгел иде микән? Бик озак вакытлар буе шул зәңгәр күзләрне оныта алмый йөрде ич ул.

Егет кирегә борылды. Күксел җирдә, кан тамырларын хәтерләтеп, аксыл покослар сузылган. Хәтсез ара үтелгән икән. Адымнарын кызулатты. Әгәр ул булса? Кызык. Ындыр табагы тирәсендә гармун тавышы ишетелде. «Бусы тагын нинди кәмит булыр. Тизрәк, киеребрәк атла, хирург ассистенты! Гәрәев хирург булгач, Фәнис ассистент булырга тиеш ич. Логика шулай куша. Музыка, гомумән, яхшы әйбер ул. Күптән Чайковскийны тыңлаган юк иде».

Иртәдән бирле Фәниснең күңелен боек, төшенке халәттә йөрткән көч эреде, яңгыр пары булып, суык җилгә иярде.

Фәниснең исе китте. Менә булдырганнар. Әзер түбәсе баганаларда утырып, стеналары өелә дә башламаган, келәткә охшаш нәмәрсә астында сызгыра-сызгыра, шау-гөр китереп, биеп яталар. Халыкны ерып, тагы да эчкәре узган иде, янә хәйран калды. Агач тартма өстенә утырып, күрүген төрлечә кыландырып, хромка гармунын тартучы Гаптелхәй иде. Русча да, татарча да җибәрә тракторчы. Сабантуй! Фәнис пошаманга калды. Килә килүгә, берничә секунд эчендә күз карашы белән төркемне айкап, сөзеп чыкты инде ул. Ләкин теге кыз күренми. Өйгә керде. Беркем юк. Юеш булса да курткасын элде, алты кырлы, гадәттә таксистлар киеп йөри торган күн фуражкасын киде. Кешеләр арасында кыз юк. Караңгыдан күзәтим дип, багана күләгәсенә басkан иде, коелып төште: багана янында сөялер-сөялмәс ул тора иде. Фәнис гел кирәкмәгәнгә маңгаен уып алгач, үзен бераз кулга алды.

— Исәнмесез!

Кыз яктыга чыкты. Фәнис дөрес чамалаган. Бу — ул. Ул булырга тиеш!

— Гафу үтенәм. Күптән сезне эзли идем. Чөнки сез минем бик матур... газраилем!

— Сез... таныдым! Кичерегез, зинһар... Мин кычкырттым...

— Борчылмагыз. Тормозны туздырмас өчен таптасагыз да була иде. Нык мин, барыбер терелер идем. Троллейбус ватылыр дип курыксагыз гына инде.

— Зойка! — Юан кыз болар ягына карап тора икән.

— Безнең диспетчер, — диде кыз, аңа ымлап. — Начальник. Рөхсәтеннән башка читтә йөрергә ярамый. Танцыга керергә теләмисезме?

— Әлбәттә. Рәхмәт! Бу минем күптәнге хыялым!

Юан кыз Фәнискә сынаучан, шикле караш ташлады. Ә Гаптелхәй гармунда ут уйната бирде. Бик дәртле темпта вальс башлап җибәрде. Янәшә басканнар. Кыз күтәрелеп, кыяр-кыймас Фәнискә карады. Егеткә нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Атналар, айлар буена туп суккан чы биергә өйрәнгән булсам соң, дип әрнеп үкенде ул. Фәнис танцы, бию эше һөнәрләрне белми иде. Өйрәнергә җае чыкмады. Цементланган идәндә кирза, резин итек табаннары чыжлап кына тора. Шәһәрдә булса, бер-берсенә сәлам дә бирмәс кешеләр — нефтьчеләр белән троллейбус йөртүчеләр — әйтерсең, алар бодай басуында түгел, ә Кара диңгез ярында ял итүчеләр, дөньяларын онытып, якын дуслар кебек, бер-берсенә ачылып, тартылып, дөбер-шатыр бәйрәм ясап яталар. Күзләрдә — очкын, шатлык, нур, йөзләрдә — елмаю. Күрәсең,

зур, киеренке, мөһим хезмәттән соң, бергә җыелгач, кеше күңеле бөтен байлыгы, эчкерсезлеге, юмартлыгы, мәхәббәтлелеге, барлык уңай яклары белән ачыладыр. Егет шулай уйлап алды. Анысы шулай, әмма хәзер танцыга керергә тиеш ич алар! Нишләргә? Фәнис үзе дә бик үк уйлап та бетермичә Гаптелхәйгә ымлап, әйтеп салды.

— Их, кызганыч, тактны бутый!

Кыз күтәрелеп аңа карады.

— Безнең кызлар андый нечкәлекләрен үк тоеп бетермиләр әле. Сәхнә түгел ич бу.

— Әз генә фальш булса да миңа үлем: аяклар буйсынмый!

Кыз тагын карап куйды. Бу юлы игътибар белән. Моны егет тә сизде. «Хәйдәрләнмә!» — диде ул үз-үзенә. Гармун салмак, әкрен көйгә күчте. Мондыйга Фәнис селкенә ала. Ашыгып кызга дәште. Кешеләр күп җирдә ритм-фәлән саклану зарури булырга тиеш түгел, шуны чамалап, бәрелә-сугыла булса да, Фәнис төркемнең үзәгенәрәк тартылды. Кыз аның ихтыярына буйсынды.

— Исемегез мәзәк. Зойка. Авылда... — Вакытында тыела алды егет. Чүт кенә, Зойка исемле сыер бар иде, дип ычкындырмады.

— Хәзер мода инде, кем ничек тели, шулай әйтә. Баш хәрефе туры килсә, ярый дип уйлыйлар. Кул куйгандагы кебек. Әни Зәйтүнә, ди.

— Без фәкыйрегезне Фәнис дип атамышлардыр.

Ярый әле, Зәйтүнә туктатты. Кирәк бит. Гаптелхәй күптән уйнаудан туктаган, ахры, авызын ерып, боларга карап тора. Ә Фәнис һаман әйләнеп азаплана икән. Кызарынып, кешеләр янына атладылар. Икесе өчен дә уңайсыз тынлык урнашты. «Беренче таймны оттырдым. Юньлерәк шөгыль, тәкъдим уйла, мәшһүр танцор!»

— Рәхмәт, Фәнис, кызлар янына барыйм. — Ул кыюсыз гына бер адым ясады да кебек.

— Зәйтүнә! — егет чын күңелдән аның янында озаграк булуын тели иде. — Көн аяза.

— Төн диген.

— Җил.

— Суытачак.

— Шәһәргә кайчан кайтабыз?

— Иртәгә?

— Без дә.

— Бик тиз.

— Ремонтчыларга артык тоткарланырга ярамый. Сүнгән скважиналар күбәйде. Җан кертергә кирәк.

— Фәнис, мин кызлар янына...

— Зәйтүнә, планета яралганда җирдә бик көчле җилдер булган. Инде бер сәгать баш ватам: амбар башында җил дингездәге кебек, ә монда таманча гына. Ышанмасагыз барып карыйм... әгәр син дә иярсәң.

— Җир шары амбар почмагы турысында ясала башлаган дисезме? Карарга була!

— Әлбәттә. Күптән инде дөнья турында да уйлаган юк иде. Йолдызларга багам, беренче тапкыр күргән кук. Кемнәр генә карамаган аңа! Тереклек яралганнан бирле күпме кешенең күз нуры йолдызларга йоккан! — Егет җавап алганчы күңеленнән яңа, китапчарак сүзләр уйлый торды.

— Кешелек агачы теориясенә ышанасың, димәк. Минемчә дә, игътибарга лаек, кызыклы фикер ул.

Фәнис маңгаен уып куйды.

— Э-э-э... Соңгы вакытта бигрәк күбәйде теория дигәннәре. Зәйтүнә, гафу, син кайсы хакында. Конкретрак.

— Аңлата алсам. Кешелек, шул исәптән кеше дә, мәңгелек. Борын-

гы грек философларының бер мәктәбе, ягъни төркеме шулай аңлата: кешелек — зур агач; вакыт, пространство үзгәрми, бер урында тора, ә кешелек агачы мәңгелек үсештә. Алар фикеренчә, менә хәзер без сәгать күпме үтте, дип түгел, күпме үстек, дип сорарга тиеш булыр идек. Һәр буын кешеләре актив чор кичерә, каусә формсында агачны күпмедер күләмдә үстерәләр дә, агач төбендәге түгәрәкләр рәвешендә шунда мәңгегә калалар. Аларны яңа, киңрәк түгәрәк күмеп китә, тегеләре диалектик үсеш тәртибендә. Әйтик, моннан сигез йөз ел элек яшәгән мәңгелеккә кереп, агач тәнендә ятып калалар. Түгәрәкләр охшаш һәм кешеләрнең дә безнең кебек яшьлеге, хезмәте һәм картаю чоры булган. Яз, җәй, көз аннары кыш... Тагын яз, яшьлек, яңа түгәрәк...

Амбарлар. Арырак басу. Уртада икәү. Төн ап-ак. Яңа калыккан ай нурыннан кыр җемелдәп, елкылдап тора. Җир, камыллардагы су тамчылары юка пыялага әверелгәннәр, бассаң, зеңгелдәп коелыр, уалыр, чатнар сыман.

Алар икәү. Дөнья тын. Күктән ак нурлар түгел, сер ява. Җирнең шундый халәте уянган: һәркемне каядыр чакыра, көч бирә, орлыкка шыту көче, мөгаен, шушындый мизгелдә кереп каладыр; ашкындыра— кешеләргә хыял дигән зур көч, шушындый минутларда салынадыр, мәңге кавышмас гигантлар, җир белән күк шушындый чорда бер-берсенең хәлен белешәләрдер. Җиһан акка төренгән. Алар икәү.

— Фәнис, торнамы ул?

— Кыр казы. Көнбатышка таба оча.

Алаканат — җиргә, Фәнис белән Зәйтүнә күккә карый. Күз нурлары, сызык булып сузылып, бер ноктада кисешteләр... Табигать белән кеше очрашты...

Зәйтүнә, кисәк хәрәкәт белән, Фәниснең кулын каты итеп үзенә кысты.

— Фәнис, ул ялгыз бит! Ишетәсеңме, кыр казы ялгыз!..

## V

Фәнис үзенә ударны гел көтмәгән яктан, тылдан алды. Хәйдәргә аның хәзер исе дә китми. Бергә эшлиләр — дәшүче юк, ял итәләр — икесе ике шөгыль белән мәшгуль. Фәнис, скважиналарны капиталь ремонтлау буенча кулланма дигән, ротаторда гына басылып, кулдан төпләнгән кызыл тышлы китапны «кимерә», Хәйдәр черем итеп алырга азаплана. Кайвакыт Гаптелхәй белән дөнья хәлләре турында гәп корып җибәрәләр, Хәйдәр дә кушылып китә. Әмма Гаптелхәй төрле төртмә сүзләр белән тегене томалый да куя. Йөри аннары Хәйдәр көннәр буе дәшмичә.

Кичәге җыелыштан соң, Хәйдәр бөтенләй «сүнгән». Хәтта Гаптелхәй үзе аның янына килеп сәлам биргәч тә дәшмәде. Сәгать иртәнге җиденче ярты булып килә. Әмма Гәрәев күренми. Башка бригадалар кузгала да башладылар. Техникага заказ алучы диспетчер да папкасын шапылдатып япты. Димәк, махсус техник машиналар бүленеп беткән. Берничә нефтьче Фәниснең кулын кысып китте: «Молодец, егет, сөйли беләсең икән, начальник булырсың, аңа хәтле Гәрәев кумаса!» Вокзал тирәсе бушап калды.

Асфальт мәйданчыкка сызгыртып кара «Волга» килеп туктады. Машинадан Гәрәев һәм аннан да мәһабәтрәк гәүдәле берәү чыкты. Икесе дә туннарының төймәләрен ычкындырып җибәргәннәр. Мастер ике кулын артка куйган да, башын иеп, тыныч кына җиргә карап тора. Әңгәмәдәшенең норка бүреге чапрыш утыра, сизми, ахры, кулларын бутый-бутый Гәрәевкә нәрсәдер аңлата. Тәрәзәгә капланган диспетчер, гаҗәпләнүдән пышылдап сөйләшүгә күчте.

— Егетләр, нефть чыгаручыларның алласы килгән! «Акташнефть» идарәсе начальнигы Сәләхов үзе! Башны кисәргә бирәм, егетләр, мировой авария булган! Монда керәләр!

Ул ялгышмады. Тегеләр, күз ачкысыз кара бураннарда өелеп доминю суга-суга полировкасы кубып, яргаланып, таралырга торган өстәл артына уздылар. Идарә начальнигы шундук сүз башлады.

— Иптәшләр, мәсьәлә контора начальнигы һәм Гәрәев белән килешенгән иде, әмма сезнең белән сөйләшеп алуны кирәк таптым. Мәгълүм факт, скважинага ремонт ясату өчен, безнең хезмәткәрләр заявканы бер ай алдан бирәләр, ул план булып раслана. Әмма бу традицияне бозарга туры киләчәк. Чөнки идарәнең иң көчле, нефтьне мул бирә торган скважиналарының берсе туктап калды. Кызганычка каршы, алар хәзер бармак белән генә санарлык. Шул сәбәпле, безнең план үтәлеше сорау билгесе астына куелачак. Аңлатансыздыр, скважинаны айлар буе тик яткыру хакында сүз дә булырга мөмкин түгел. Гәрәев вәгъдә иткәнчә, бу эш белән сезнең коллектив шөгыльләнәчәк. Иптәшләр, идарәнең барлык нефтьчеләре исеменнән скважинаны сафка бастыруда батырлык, фидакарьлек үрнәкләре күрсәтүегезне сорар идем. Үтенәбез, зинһар, бер атна срокка сыеша күрегез. Түләү, премия директорски фондтан булачак. Читенлекләр чыкса, турыдан-туры миңа мөрәҗәгать итәргә. Килештекме? Срок, иптәшләр, тагын кабатлыйм: бер атна!

Ул чыгып киткәч, аның урынын Гәрәев алды.

— Тору урыны машина будкасында, кайтып йөрүләр булмаячак. Ара туксан чакрым. Аңлагансыздыр. Күтәртү мачтасы, башка кирәк-яраклар төш турында шунда булыр. Мин монда калам. Сезнең белән цехтан нженер-техник барачак. Әле ул үзе ялда ди бугай, чакыртырга булдылар. Инженер килгәнче, житәкчелек эше Гайсинга йөкләнә. Сүзгә остарып китте, эшләп күрсәтсен әле. Алмаш кием, шуның ишеләрне күтәреп, нәкъ сәгать бергә диспетчер бүлмәсенә җыелырга. Кузгалыгыз. Гайсин каласың, цехка кереп, аулау инструментлары сайлыйбыз.

Фәнис гаҗәпләнүдән, кечерәеп, бөрешеп калды. Кичәге җыелышта сөйләү Гәрәевкә ошамаган! Вахта машинасы белән цехка барганда, сәбәбен төпченде.

— Әнәс Гәрәевич, партком секретаре белән үзегез куштыгыз ич сөйләргә. Хәзер мин юләр булып калдым.

— Шикләнәм. — Гәрәевның кашы җыерылган иде.

— Нәрсәгә?

— Синең акыллы булуыңа! Мин бит нәрсә хакында сөйләргә кирәклеген якынча аңлаттым. Акылың булган булса, төшенер идең.

— Бу хакта үзегез сөйләдегез ич! Ничек итеп мин аны кабатлыйм.

— Хм, ә ни өчен Хәйдәр хакында сөйләп киттең, — Гәрәевның тавышы кырыс, кашлары тагы да җыерыла төшкән, — каян алдың ул фактны.

— Үзем күрдем. Шәмнең резьбалы туры бер урыннан буйга чатнаган иде. Туктап, алыштырыйк, бер-ике айдан килеп чыгачак, дидем. Тыңламады. Яңа шәмнәр китергәнен көне буе көтеп ятар хәлем юк, диде. Әнәс Гәрәевич, менә күрерсез, ул скважинада тагын авария булачак, тагын үзебезгә төзәтергә. Дөрес түгелмени?

— Хм, ремонттан чыккан скважиналарга сыйфат гарантиясе булдырылсын диден. Кем котыртты? Партком секретареме?

— Юк, уйладым, уйладым да, шундый фикергә үзем килдем. Гомум эш өчен файда гына була ич. Хәйдәр агайны мисал итеп кенә сөйләдем. Нефть чыгаручы операторлардан ишеткән бар. Сан артыннан гына куасыз, торбаларыгызның парафины да чистартылмаган була, диләр.

— Хм, син ул Хәйдәр дурачок хакында сөйләгәндә бригаданың авторитеты хакында уйладыңмы? Мин үземне исәпкә кертеп тормыйм инде. Юк, уйладыңмы? Әллә без шулай забойга чатнаган, парафины чистартылмаган торбалар гына куабызмы? Уйла, егет! Кем белә, бәлки әле акылың да бардыр. Минемчә, соң түгел кебек.

Менә сер нәрсәдә булган! Гәрәев, тешләрен кысып, сүзләрен сөзеп чыгарып кына сөйләде. Әмма Фәнис өчен ул кеше шәхес булараk үлде. Баксаң, ул да башкалар кебек, үз даны-дәрәҗәсен, мин-минлеген алга сөрә икән ич! Фәнис чыгыш ясау өчен атлыкмады. Әрсезләнеп сорап йөрмәде. Аңа тәкъдим иттеләр, Гәрәев тә яклады, планны тугыз айда үтәдек, шуңа басым яса, дигәч, ул риза булды. Ә Фәнис бөтен чыгышын, Гәрәевкә ошасын, бүтәннәрне кабатлау булмасын, мастер конкрет сөйләгәнне ярата, шуңа күрә яңа, бөтен конторага файдалы сүз ишетелсен иде, дип төзегән иде. Көне буе гел шуның хакында гына уйлаган иде. Ә чынлыкта... Гәрәев булып Гәрәев тә шундый вак кеше булып чыккач, кем генә соң бу конторада?!

Фәнис үзе дә сизмичә торып басты. Аның башыннан берөзлексез зәһәр уйлар агылалар. Орденлы кеше дә шундый булгач... Я, кемгә таянырга аңарга? Уйларын кемгә сөйләргә? Хәйдәргәме? Әллә Гаптелхәйгәме? Гаптелхәй артык күзгә ташланырга яратмый. Бәхәсләрдә, Хәйдәр кебек, бүрекләрен җиргә бәреп, чәчрәп чыкмый. Кешегә ташланмый. Сирәк-мирәк әйтеп куя, әмма бәгыренә үтәрлек итеп. Эшләгәне сизелми дә аның. Мөгаен, шуңадыр, кеше эшкә башлаганчы инде ул тракторында була, эштән киткәндә, тракторында кала. Моның шулай булачагына бар да күнеккән, гадәти әйбер дип карыйлар. Әйтик, кояш чыга, бата... Кайсы исемлеккә кертергә инде сине, дус кеше, Гаптелхәй?

Фәнис тынычланып калгандай булды. Дөресрәге үз-үзен кулга алды. Аныңча, чын ир бик олы шатлык, яки бик олы кайгы килгәндә дә чагыштырмача, һич югы, тыштан тыныч булырга тиеш. Шул ук Гаптелхәй кебегрәк. Артистлану, хис, эмоциягә бирелү хатын-кызга килешәдер бәлки. Әмма чын ир-егеткә... Гәрәев белән янәшә утырды да ап-аек, салкын кан белән уйлый башлады. Ул тагын ялгышты: Хәйдәрдән, аның кебекләрдән сакланырга кирәк дип уйлаган иде. Җыелышта ул, алдан уйлап, аларга кечкенә генә сугыш ачты, бөтен уяулыгын, зиһенен җыеп, җавап удары көтте. Хәйдәр Фәнискә иртән сәлам бирмәде. Аның җавабы шул иде. Чын удар тылдан, Фәнис үзенең кумиры итеп йөрткән кешедән, Гәрәевтән ясалды. Аның ачысын егет бер атна татыды.

## VI

Эшне башлауларына инде икенче тәүлек бара. Гаптелхәй бульдозер белән чистартып ясаган мәйданга җәяүле буран кар ташый. Декабрьның зәһәр җиле, әле генә урнаштырып өлгергән күтәртү мачтасының рәшәткәләренә уралып, мәгънәсез дулый, сызгыра. Цемент кебек катkан җиргә, лом, төрле рычаглар ярдәмендә изалана-изалана штопорлар борып, тәмам хәлдән тайган ремонтчылар ГАЗ-66 машинасы өстенә утырган будкага тулдылар. Шофер егет тә боларга булышканлыктан, будка ягылмаган, суык иде. Тәрәзәгә әледән-әле күз салаcала, Фәнис түгәрәк мичкә ут элде. Гәрәев вәгъдә иткән инженер юк та юк.

Бик нык арылгангадыр, барысының да сөмсере коелган. Будка җылына башлагач, як-якка беркетелгән йомшак эскәмияләргә ятып, хәл җыярга булдылар. Фәниснең күңелен һаман бер сорау борчый. Әгәр инженер килмәсә? Ул ялда бит, әгәр берәр якка китеп өлгергән булса? Аның ярдәмчесе авырый да бугай. «Ремонтчы булып исәпләнәсең бит, бригада биреп куюлары да бар. Чын эшнең ни икәнен бел әле! Ниш-

ләрсең икән, карарбыз!» Озатканда Гәрәевнең соңгы җөмләсе ни өчен шундый булды? Нәрсә аңлата ул? Әллә конторага кайтып килергәме? Бәлки Гәрәевнең үзен җибәрерләр? Мондый эштә бүре ашаган карт албасты кебек бит ул.

Чәй кайнап чыгып, табадагы итле бәрәңге чыжлый башлагач, өстәл тирәли утырыштылар. Шешенгән йөзен урталай бүлеп, Хәйдәрнең авызы ерылды.

— Начальниктан уңдык, җәмәгать. Обедны да үзе хәзерләп ашата. Оҗмах! Чәй дә ясап бир инде, Фәнис, синең кулдан тәмле була ул.

Тамак ялгагач, киенеп мәйданчыкка чыгып бастылар. Суык егерме-егерме биш градуслар чамасы булыр, җәяүле буран котыра.

— Я, агайлар, нишлибез? — дип Фәнис, карашын Гаптелхәйгә текәде.

— Һаман күңелне тырный, балчык измәсен әзрәк кудык шикелле. Иң көчле скважина бит бу, басым көчле.

Гаптелхәй белән Хәйдәр дә шул фикер белән килеште.

— Әллә инженерны көтәбезме?

— Юкка газаплама үзеңне, Фәнис. Килмәячәк ул. — Гаптелхәй тыныч, әйтерсең, бик гадәти әйбер хакында сөйли.

— Алайса, конторага кайтып килим? Гәрәев үзе килер.

— Расчетны Гәрәев нәкъ менә шуңа корды да инде. Контора, идарә алдында кадер, дәрәҗәңне арттырып калырга кирәк. Очрак менә дигән. Шулаймы, Хәйдәр?

— Шулай, шулай, җәмәгать.

— Я, уйлагыз, нишлибез? Вакыт бара.

— Тырыштырып карыйк. Дәрт иткән...

— Үзебез генәме? Сез нәрсә, агайлар?

— Бар, алайса, кайт та, Гәрәев алдына тезлән! Кулын үп! — Гаптелхәй тракторына таба китте. — Бәлки...

— Хәйдәр агай!

— Уйла, син начальник.

— Гаптелхәй, кабыз тракторыңны!

— Шулай, эшлибез, үзебез! Ничу анда-монда йөрергә.

Беренче эш итеп, страховка йөзеннән, авыр, юан шлангтан төпкә хлорлы кальций эремәсе кудырдылар. Җәяүле буран уйный, тимер суыгы бияләйләр аша тәнгә үтә, күтәртү мачтасы җил бәрелүдән гүләп утыра, шоферлар белән Гаптелхәй янып-пешеп Хәйдәргә булышалар, аста, җир астында забой, күпмедер тирәнлектә өзелеп калган, нефтьне җир өстенә күтәртә торган торба, катламга очкан электр-батырма насосы, мәйданчык уртасында — Фәнис.

Нәрсәдән башларга эшне? Иел иде дә, колонnaның җир өстенә чыгып торган очыннан аска карап, бел иде аста нилэр барын. Забой ерак, караңгы, кешеләр иңсәсенә ишелеп төшкән бәлане, сер итеп, куенына яшергән. Нәрсәдән башларга эшне? Уйла, Фәнис? Гәрәев булып Гәрәевкә чакыру ташлагансың икән, егет бул, Гәрәевтән көчлерәк ир бул! Дөньяда егерме ике ел яшәп, гомер елгаң борылмага җиткән икән, уйла, Фәнис!

Бүтәннәр дә Фәнис янына җыелдылар. Зур җитдилек, игътибар белән аңа текәлгәннәр. Егет үз гомерендә беренче тапкыр иң җаваплы, мөһим карар кабул итәчәк. Моңарчы ул үзе хакында гына уйлады. Кайгыртты. Әллә каян, диңгез төбеннән чыгарыла торган нефтьтән күкерт составы өйрәнгәнче, техникумда шушыңарак охшаш тренажлар үткәрелгән булсачы, дип, әрнеп уйлап алды. Вакыт үтә, я тәкъдимең, егет! Иң гади юл: колокол төшереп, өзелгән торбаларны аулый башлау. Әмма... Калай белән тышланып, тимер каптырмалар белән торбаларның бөтен буена беркетелгән кабель ни хәлдә? Әгәр ул каптырмаларыннан ычкынган булса? Насосны тотып, күтәртә башлагач, ул барыбер, уралып, тор-

баларны колонната китереп кысачак ич. Анары, утыр берәр ай казынып!

— Тотындык, иптәшләр! Иң хәтәре кабель. Аулап карыйбызмы?

— Дөрес, ул кабель ишегә каберең якын булмасын Бисмилла ирраһман...

Бораулау торбасына күп япьле озынча кармакны беркетеп, шәмнәрне куа гына башлаганнар иде, Фәнис аста җиңелчә гүләү авазлары тоеп алды. Скважинаны тизрәк томаларга, хәзер атачак!

— Измә! Тизрәк шлангны сузыйк! Хәйдәр ага!..

Кичкә чаклы шуның белән азапландылар. Фәниснең, кем белә, бәлки әле килеп тә чыгар, дигән яшерен өмете акланмады, инженер машинасы горизонтта күренмәде. Балчык измәсе бетте, күпме булган, барын скважина авызына тутырдылар. Юләр көч авызлыкланды сыман. Әз генә дә хата җибәрмәскә, очраклылык мөмкинлеген нульгә калдырырга. Фәнис, шуны уйлап, май, эремәгә батып беткән «Краз»ны запас измә артыннан җибәрде. Сәгатенә күз салды. Бишенче ярты. Караңгылана башлады. Кулын югары күтәрде.

— Булмаса, чәй эчеп алыйк.

— Селкеник әле берәр сәгать. Иртәрәк бит.

— Курыкма, Хәйдәр ага, ял итеп алыйк та тугызларга тиклем селкенербез. Прожекторлар янып тора.

— Ә-ә? Тугызга хәтле?..

Эш белән мәшгуль булган ремонтчыларга сәгать тугыз тулуы сизелми дә калды. Күнегелгән, җае алынган булгангамы, шәмнәр җир астына берсе артыннан икенчесе шуа гына тордылар. Хәйдәр, оста гына хәрәкәт итеп, торбаны тростка эләктереп өлгерүе була, трактор кабинасында утырган Гаптелхәй рычагка кул аркасы белән суга да, һоп, ут яктысында шәм кара балыктай ялтырап, һавада асылынып кала. Фәнис аны әле бөтен гәүдәсе белән җир куенына чумып өлгермәгән торбага ялгый. Тормоз рычагыннан кулын алуы була, баш очында икенче шәм асылынып тора.

Фәнис төзегән забой схемасы буенча өзелеп калган торбалар һәм насос тугыз йөз-мең метр тирәнлектә ятарга тиеш. Сиксәненче торбаны ялгап, егет тормозны ычкындырган иде, шәмнәр җир астына төшү түгел, селкенмәделәр дә. Тыны-көне бетеп, Хәйдәр чабып килде. Тормоз рычагын боргалап карады. Гаптелхәй дә кабинасыннан чыкты. Шик юк, инструмент тиешле тирәнлектә, өзелгән торбаларга төртелеп, туктап калган иде.

Дулкынланудан Фәниснең бит алмалары яна. Нәрсә көтә аларны аста? Унар метрдан әз генә озынрак шушы сиксән торбаны тагын ничә тапкыр күтәртерләр дә, ничә тапкыр забойга куарлар? Әлегә беркем берни белми. Мондый авариялар кайвакыт берәр, икешәр айга да сузыла. Ә монда срок — бер атна! Гәрәев үзе юк, катлаулы авариялар буенча махсус белгеч-инежнер килмәде. Кешеләр житеш түгел, аста гына түгел, җир өстендә ниләр көтә аларны? Конторадан килеп, хәлләрен ник белешмиләр? Гәрәевкә ышаналармы? Ә Гәрәев Фәниснең кайтканын көтеп ятса?! «Энәс Гәрәевич, сез булмасагыз, без нульгә тиң икән, без бер эш тә кыралмыйбыз икән, зинһар, килеп китегез! Моннан соң дөнья сез күрсәткәнчә генә барыр, юл гына күрсәтегез!» Бәлки ул Фәнистән шул сүзләрне көтеп ятадыр! «Нәрсә кырырсыз икән, карарбыз!» — диде ич!

Тау сыртларындагы шәрә имәннәрнең ботакларын җил ачу белән тарый-тарый да, үзәнлек буйлап йөгерә. Кыр уртасында, шул җилгә каршы, тун изүләрен каерып ачып, өч ир-егет баскан. Дәшмиләр. Прожектор яктысында гәүдәләре алыпныкыдай озын, киң булып күренә.

— Иптәшләр, әллә аулап карыйбызмы?

— Ашыкма, энекәш. Олы эшне ата-баба иртәнге сәгатьтә башлаган. Ял итеп алыйк. Вакыт күпме, Хәйдәр?

— Унынчы ярты. Черем итик. Иртән башларбыз.

Яңа көнне ремонтчылар мачта төбендә каршыладылар. Фәнис юньләп йоклый да алмады. Башта авыл, өйдәгеләр, әти-әнисе, энеләре белән саташып чыкты. Бер ун көн элек төшендә әтисе, көтүдән тана югалды, милициягә килгән идем әле дигән иде. Фәнис авылдан ерак түгел, Сәет урманыннан сыер эзләп азапланды. Аннары — Зәйтүнә... Беренче тапкыр аның белән квартираларына бару, әнисе белән танышу... Кирәк бит, ничек булган, нәкъ шул рәвешчә, төштә кабатлана.

Ул уянганда сәгать алтынчы ярты иде. Прожекторны кабызды. Ишеген ачып, машина сигналына басты.

Мышный-мышный, дүртәүләп, авыр инструменты кул белән әйләндерәләр. Гел килми торса, барыбер, бер килер дигән. Бәхетләренә каршымы, шофер егет әле күз генә армиядән кайткан, бар әйбер белән кызыксына, бер минут та тик тормый, гел ремонтчылар белән. Фәниснең нинди хәлдә икәнен ул сүзсез аңлаган иде. Тавышка шундук сикереп торды, ялт-йолт киенде, барысы белән бергә авыр инструментны кул белән әйләндерергә ябышты. Сәгатьтән артык шулай азапландылар. Астагы өзелгән кабельнең бер очы «ау» коралының кармак ябе кебек тимерләренә эләгергә, һәм ул әйләнгәнлектән, аңа уралырга тиеш иде.

Иртәнге чәйдән соң да Фәниснең күңеле тынычланмады. Шәмнәрне күтәрә башларга да мөмкин иде, югыйсә. Әмма ул, үзенә иң охшаган кешеләрнең берсе, шахматчы Карпов кебек, соңгы минутка кадәр «практик» булып калырга омтылды. Уйланган икән, үтәләчәгенә, барып чыгуына ул эш йөз процент гарантия бирерлек булсын. Хәзерге минутта аның иң олы дошманы — очраклылык. Инструмент сизелеп авырайды, тыгызланды, димәк, аңа кабель уралып, «ау»ны колонна стенасына кыса башлады. Тик километрга якын ара үтеп, өскә күтәрелгәнче, бушап, кире аска очмасмы ул? Аннары нәрсә булыр? Тагын сорау билгесеме?

— Гаптелхәй ага, әллә шәмнәрне бераз күтәртеп, эләккән булса, кабельне тыгызлыйбызмы? Юл озын...

Гаптелхәй күтәрелеп, бөтен буена торып басты. Вальс уйнавын туктатып, әле һаман әйләнеп маташкан Фәнисне күзәткәндәге кебек, авызын ерды.

— Молодец, егет! Эшлекле фикер бу. Син укыган кеше, уйла, күбрәк уйла!

Ах-ух килеп, инструментны кабат әйләндерделәр дә, торбаларны кире җир өстенә чыгара башладылар. Җитмеш тугыз торба — өскә. Картина гадәти төс алды: Гаптелхәй трактор кабинасында, мачта төбендә Фәнис, Хәйдәр белән солдат егет сәяхәттән кайткан шәмнәрне штабельгә өяләр.

Бер сәгать үтте... Ике сәгать... Вакытның санын Фәнис төгәл алып бара. Беркем дәшми. Хәтта ара-тирә тәмәке тарткалап ала торган Хәйдәр дә бу «һөнәрен» онытты. Егет анык сизә: бар да дулкынланалар, түземсезлек белән нәтиҗәне көтәләр, әмма берсе дә бу уен тышка чыгарырга омтылмый.

Гаптелхәй газны кысып бетереп диярлек, әкрен генә җитмеш тугызынчы шәмне югары күтәрә... Фәнис күзен йомды... Ачкан иде... судагы еланга тартым аксыл кабель колонка авызыннан өскә шуыша!

Туксан метрлар озынлыктагы үткәргеч өеменә Хәйдәр эт тиресеннән тегелгән унта очы белән тибеп тора: «Учны җәеп, сиңа таба бер генә өргәниек, җир астыннан килдең дә чыктың, хашәрәт!»

Фәнис уенча, бу эшнең яртысы иде. Хәзер кул көчен, физик көчне генә кызганмаска кирәк. Скважинаның тирәнлеге бер мең дә йөз метр. Аска насос белән бергә унбишләп торба очкан булырга тиеш. Кабель-

нең озынлыгы? Шулай, туксан, йөз метр. Димәк, каптырмалар очып бетеп, кабель насоска тоташкан урыннан өзелгән! Кичекмәстән забойга печать төшерергә.

Төшке ашны әллә ашадылар, әллә юк. Зур уныштан барысы исергән, шат иде, торба башына гудрун печатьне беркеттеләр дә, шәмнәрне куа башладылар.

Җитмеш тугыз торба, аска, марш!

Җитмеш тугыз торба, өскә!

Печать ике яктан сыдырылган, бераз эчкә батып кергән, калган җире бөтен, исән иде. Аңа карап, Хәйдәр бүреген салды да башын кашыды. Гаптелхәй мондый очрак белән таныш түгел иде. Кашларын җыерды. Сәгать төнге ун тулып килә.

— Я, начальник, ни уйлыйбыз?

— Уйламыйбыз, Хәйдәр ага. Йокларга!

Иң мөһиме: кешеләрнең гайрәте чикмәсен. Ут яктысында йокламаячаклар, Фәнис дәфтәрен, каләмен алды да машина кабинасына керде. Аккумуляторны кушып, кечкенә лампочканы кабызды. «Колоннаның диаметры унике ярым сантиметр, печать шушы рәвешчә төшә, тирәнлек шушылай, забойда унбиш торба һәм иң аста — насос. Печать ике яклап яньчелсен өчен, җиргә якын торбаның очы нинди халәттә булырга тиеш?» Ачыграк күз алдына килсен дип, рәсемен ясады. Утны сүндерде дә һавага чыкты. Җил басыла төшкән, ишелеп-ишелеп кар ява иде.

Яңадан «кабинетына» күтәрелде. Дәфтәрен ачып, каләмен алды. Икенче вариантны ясады. Печатьнең уртасы киселеп эчкә керергә тиеш. Бармый. Өченче очрак? Килми. Төгеләй итсә дә, болай гөманлап караса да, чишелеш бер чыга: торбаның очы бер якка авышып, колонна стенасына таянган, шушы очракта гына печатьнең урта өлеше исән кала. Чөнки нәкъ үзәктә бушлык. Эшне забойга колокол куудан башларга. Астагы торбалар күп түгел, берәмләп, икешәрләп югары күтәртергә була. Иң дөрес юл — шушы!

Ул йокларга кергәндә дүртенче көн башланган иде инде. Көне буена дүрт торба күтәрделәр. Тагын унберәү калды.

Бишенче көнне биш шәм көн яктысы күрде. Алтау калды.

Ниһаять, алтынчы көн киткәч, буран басып киткән юлдан үрмәләүче «ГАЗ-69» машинасы күренде. Ул тырыша-тырмаша мәйданчыкка килеп җиткәч тә, ремонтчылар аңа артык әһәмият бирмәделәр. Чөнки иң кызган вакытлар иде: җитмеш тугыз торба, өскә! Соңгы тапкыр, соңгы тапкыр, өскә!!

Машинадан Гәрәев белән партоешма секретаре чыкты. Гаптелхәй тракторның мотор тавышын әкренәйтте.

Гәрәев килгән! Гәрәев үзе килгән! Җил, будка, трактор, ишетәсезме, Фәнис кайтмады, ә Гәрәев үзе килде! Фәнис ярсуын көчкә тыеп тора. Их! Әгәр үзе генә булса, кыр буйлап китәр иде тәгәрәп! Тыны-көне беткәнче чабар иде җилгә каршы! Әллә соң, куллар белән генә күтәрелеп, мачта түбәсенә менәргәме?

«Әкрен! Әкрен, Фәнис! Гәрәев сиңа таба килә! Я, артистланма, ир бул! Хисләрең җиде кат сандык эченә яшерелгән булсын! Акыл, баш заманы хәзер. Тынычлан, Фәнис!»

Гәрәев Фәнис каршына басты. Кул сузды.

— Я, хәлләр ничек, начальник? Эшләр барамы?

Фәнис кулын сузды. Ул ифрат дәрәҗәдә тыныч иде.

— Хәлләр ярыйсы, Әнәс Гәрәевич. Эшләр бара кебек. Менә бүген бетерергә исәп тота идек әле... Рөхсәт итсәгез...

Шулай да, әз генә контрольне югалтты Фәнис: сизелер-сизелмәс елмаеп алды.

## Галимҗан Латыйп

●

Мин бәләкәй чакта күрдем Димне,
Кырүрдәкләр бала чыгарганда.
Әнкәй миңа: «Оятлы иттең», диде,
Өстем-башым манма чыланганга.

Дим буена төш тә чыланма да,
Кунак малай, имеш, ярамый.
Үрдәк бибиләрен куа-куа
Йөгердек без камыш аралый.

Дим суында чирткән ак балыклар
Төшләремә кереп йөдәтте.
Ул һаман да шулай балыклымы,
Ул һаман дамы соң үрдәкле?

Бер күрәсе килә тагын Димне,
Ничегерәк барып чыгарга!
Үзгәрмәгән, өшәнмәгәндер ул,
Шулай яши бит ул җырларда.

### Җыерчыклар телен белсәң әгәр

Кичке шәфәкъ яна,
яна, яна...
Чыга кызлар көтү каршыларга.
Шәфәкъ нуры кунган тук башаклы
Өлгерешеп килгән арышларга.

Шул кырларда безнең ышанычлар,
Безнең өмет, безнең куанычлар.
Туасы таң безнең өчен бәйрәм,
Туар таңнар булса, юаныч бар.

Арыш исе, кара туфрак исе
Җаныбызга кергән сабый чактан.
Буразналар булып җыерчыклар
Маңгайларга сызым-сызым яткан.

Укып була аны, тәрҗемәсез,
Җыерчыклар телен белсәң әгәр.
Анда яшьлек,
сөю,
үкенечләр,
Салкын чишмә, зәңгәр әрәмәләр.

Барысы да шунда: күз яшьләре,
Кыр өстендә калган каберләр.
Дошманнарның кара шәүләләре,
Тораташтай каткан бәгырьләр.

Жиңү тантанасы. Туган туфрак.
Якыннарның изге сулышлары.
Башакларның кырда кыштырдавы,
Магнитканың кайнар корычлары.

Уеп-уеп ташка язылгандай,
Маңгайларда безнең бөтен үткән...
Үзебезгә сиздермичә генә
Әнкәй аны ничә тапкыр үпкән.

●

Тышта тагын зәңгәр суык,
Зәңгәр боз өстенә чыгып
Шартлады зәңгәр куык.
Өйләр жылы,
Безнең хәлләр шекер-шекер.
Абзардагы малкайларның
Хәле мөшкел.

Куеныма тутырып үзләренә
Жылы алып чыгам.
Сер бирмиләр алар бер дә болай:
— Без түзәбез, чыдам...
Уч төпләрем белән сыртларыннан
Сыйпаштырам, назлыйм.
— Бу суыклар үтеп китәр менә,
Озакламый яз, — дим.

Яткан жирләреннән торып берәм-берәм
Сыеналар миңа.
Аңлашылып бетмәсә дә сүәләр,
Жан жылысы жиңә.

## Бар икән

Бар икән яшьлек вакытның
Онтылмас, алтын чагы.
Ни тапса, шуны эреткән,
Бер тоташ ялкын чагы.

Ашкынып сөйдем, сөелдем.
Яндырдым, тапламадым.
Хыянәт жиле кагылса,
Берсен дә якламадым.

— Сиздерә күрмә, — диделәр,
Минме сер сакламадым?
Бирелгән вәгъдәләремне
Минме соң акламадым?

Барлыгым белән яраттым
Дөньяның хәл-әхвәлен.
Булдылар шундый чакларым,
Тамдылар күз яшьләрем.

Тамдылар — якыннарымнан
Аерылган чакларымда.
...Гел изге теләкләр белән,
Сагынычлы сәламнәр генә
Килделәр хатларында.

●

*Мостай Кәримгә*

Сәфәр чыккан чакта, Мостай,
юл капчыгыма иң элек
синең җырларны салам,
аннан әнкәй сүзен тыңлыйм:
— Исән-сау йөре, балам!

Әниләр гел шулай алар,
изге уй, изге теләк.
Беркемдә юктыр дөньяда
әниләрдәге йөрәк.

Тыныч бул, әнкәй, борчылма,
юлдашым яхшы минем.
Исемен беләсең килсә,
«Мостафа атлы», димен.

— Исеме затлы икән шул,
мин тыныч, тыныч, балам.
Икегезгә дә бер очтан
догалар укып калам...

●

Рәхмәт минем әнкәемә,
мине тапкан.
Кеше иткән,
үзе киткән.
— Миңа, — дигән, —
шул да җиткән.

Кем буласымны белмәгән,
үзе һаман йон эрләгән.
Бәбкәемнең кул, аягы
туңмасын дип,
көн эрләгән,
төн эрләгән.

Йөрәгенең бар җылысы
күчкән миңа.
Ата-ана мәхәббәте
шулай булган.
Шулай килә.

Ә балалар, алай түгел,
көйсезләнә,
ваемсызлар.
Әниләрнең йөрәкләре
көнен сызган.
Төнен сызган.

Яшәр елларын яшәми
китеп бара алар иртә.
Үкенечләр безгә һаман
соңлабырак килеп җитә.
Килеп җитә,
вәйран итә,
хәйран итә.

## Шуңа күрә

Күлләр зәңгәр, күкләр мәрмәр тоелалар,
Йолдызлардан җем-җем нурлар коелалар.

Тынгы белми Җир әйләнә күчәрендә.
Алмагачлар! Туй күлмәге өсләрендә.

Чәчәкләрдән көн яктырган, җир яктырган.
Җан рәхәте — язлар килде кыш артыннан.

Язлар килде кошлар җыры белән бергә,
Көн озайды: төн кыскарды бермә-бергә.

Бар тереклек үз эшендә, үз хәстәре;
Бал кортлары барлап оча чәчәкләрне.

Алмагачлар төшләрендә алма күрә, —
Шау чәчәктә утыралар шуңа күрә.

## Кар бөртекләре

Уйнады кар бөртекләре урамнарда,
Йөгерде кар бөртекләре бураннарда.

Йоклады кар бөртекләре җиргә ятып,
Җемелди кар бөртекләре нур уйнатып.

Елмайды март, елык-елык ак бөртекләр,
Җитте апрель, юешләнде ак керфекләр.

Тотынды яз җирне-күкне камчыларга,
Әйләнде кар бөртекләре тамчыларга.

Сеңде җиргә, сеңде тамчы өмет булып,
Шытты орлык, китте өскә күтәрелеп.

Шаулады кар бөртекләре уңыш булып,
Калмадык дип, без бу җиргә бурыч булып.

## Синең белән

Яшь чагымда син мине бер үпкән идең,
Шунда кайнар күз яшемне түккән идем.

Минем яшь кыз, әле синең егет чагың,
Син кабатламакчы булдың тагын-тагын.

Күктә йолдыз, түгәрәк ай торды карап,
Мин оялдым йолдызлардан, эшем харап.

Мин оялдым синең зәңгәр күзләреңнән,
«Сөям» дигән синең назлы сүзләреңнән.

Янды йөрәк, янды җирләр, янды күкләр,
Аерылыштык, инде күпме гомер үткән.

Язмыштырмы? Мәхәббәтең синең — бүтән,
Ә мин һаман синең белән гомер итәм.

## Юныс Әминов

# ОЧРАШЫРБЫЗ, ГӨЛСЫЛУ

ҖИТДИ КОМЕДИЯ

КАТНАШУЧЫЛАР:

Сарбулатов Мөхәррәм — автомеханик.
Шәмсенур — аның хатыны, ташчы.
Әссар — аларның улы, абитуриент.
Гөлсылу — аларның кызы, сигезенче классны тәмамлаган.
Нигъмәтҗанова Ләбибә — Мөхәррәмнең ерак туганы, сыер савучы.
Фидаһи — Ләбибәнең улы, абитуриент.
Наҗилә — абитуриент кыз.
Мөкатдимә — секретарь-машинистка.

Безнең көннәр.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Август башы. Шәһәрнең биек таш йортлары күренә. Алгы планда такта белән тышланган верандалы агач йорт. Йорт әйләнәсендә җиләк-җимеш, яшелчә бакчасы. Бер кырыйда урамнан керү өчен кечкенә капка. Кичке сәгать бишләр. Әссар верандада чалбар үтүкли. Гөлсылу яшелчә түтәлләре йомшарта.

Гөлсылу. Абый, иртәгә нишләргә тиеш әле син?
Әссар. Техникумга керү имтиханы тапшырырга.
Гөлсылу. Нинди фәннән?
Әссар. Математикадан ла.
Гөлсылу. Ә син сәгать буе чалбар үтүклисең. Билгене чалбарыңа карап куярлар дисеңме?
Әссар. Кием — эчке дөньябызның тышкы көзгесе!
Гөлсылу. Мин сине аңламыйм, абый. (*Уйланып.*) Техникум тәмамладың, автомашиналар ремонтлаучы механик булып чыктың, ди. Аннан соң нишләрсең?
Әссар. Шул ук белгечлек буенча институтка керәм.
Гөлсылу. Керә алмасаң?
Әссар. Беренче баруда керә алмасам, икенче тапкыр барам... унынчы тапкыр барам... керә алганчы барам!
Гөлсылу. Институтны да тәмамладың, ди. Шуннан соң?
Әссар. Институт дипломын эләктерсәм, яши белер идем...

Әлмәт театрында 1979 ел башыннан бирле куела. Сәхнәдә ике йөздән артыграк уйналган.

**Гөлсылу.** Син яши белер өчен генә укыйсыңмыни?

**Әссар.** Тагын нәрсә өчен укырга соң?

**Гөлсылу.** Китапларда: «Халыкка хезмәт итү өчен»,— диелгән.

**Әссар.** Гафу ит, сеңлем, син анадан тумагансың, китаптан гына төшеп калгансың. (*Аңлатып.*) Яши белеп яшәү рәсми телдә «Халыкка хезмәт итү!» дип атала. (*Китабын ала.*) Алгебра... Күпме кагыйдә ятларга!..

**Гөлсылу.** Ятлаган кагыйдәләр белән генә мисал, мәсьәләләрне ничек чишәрсең? Техникумнан документларыңны кире алсаң дөресрәк булмасмы, абый?

**Әссар.** Мин шуышып булса да техникумга керергә тиеш. (*Китабын ташлап.*) Башым катты.

**Гөлсылу.** Миңа булыш, башың да ял итәр.

**Әссар.** Түтәлдә казынсаң, тырнак астына балчык тула.

Мөхәррәм кайта.

**Мөхәррәм** (*өйгә таба*). Шәмсенур, Шәмсенур!..

**Гөлсылу** (*бакчадан*). Әни кайтып җитмәде әле, әти.

**Мөхәррәм.** Үскән кызым һаман бакчада. Рәхмәт, кызым. (*Әссарга карап.*) Үскән улым һаман китап кимерә.

**Әссар.** Иртәгә имтихан шул!.. Әти, син мотоциклны карасаң иде. Моторы тартмый.

**Мөхәррәм.** Ни булды икән ул уңгырыга? Үзең яхшылап тагын бер кара әле.

**Әссар.** Ун карадым инде.

**Мөхәррәм.** Мотоциклын мин алып бирдем, моторын да миңа такма инде. Унны бетереп мотоциклны да белмәгәч... (*Шәмсенур кайта.*) Күтеп кенә тора идем. (*Акча биреп.*) Зарплата. Чутлап ал.

**Шәмсенур.** Чутламыйча да ышанам.

**Мөхәррәм.** Чутла, чутла, акча чутлау — үзе бәйрәм.

**Шәмсенур** (*санап*). Йөз кырык. Шуңа авансыңны да өстәсәк! Үзең әйткәндәй, рәхмәт! (*Хәтерләп.*) Бу айда газ белән электрга түләнмәгән, шуларның исәбен өзеп кайтчы, сиңа әйтәм.

**Мөхәррәм.** Йортын мин җиткердем, газ белән электрга үзең түлә инде, уңгыры.

**Шәмсенур.** Икмәк тә аласы бар.

**Гөлсылу.** Икмәккә мин йөгерәм, әни. (*Китә.*)

**Әссар** (*китабын ташлап*). Мин арыдым, әни, башны ял иттерәсе иде дә кесә буш икән.

**Шәмсенур** (*биреп*). Өч тәңкә.

**Әссар.** Молодец, әни, рәхмәт, әти. (*Китә.*)

**Мөхәррәм.** Акча белән малайны узындырмыйсыңмы син?

**Шәмсенур.** Вак өчен дә тавыш чыгарма инде, сиңа әйтәм. Бала иртәгә имтиханга бара, шул хакта берәр сүз әйтсәң иде.

**Мөхәррәм.** Әйтер сүзем юк.

**Шәмсенур.** Әй, Мөхәррәм, онытлыңмыни класс җитәкчесе сүзләрен? «Улыгыз институтка барам, дип расход чыгарып йөрмәсен, барыбер керә алмас, берәр техникумга тыгарга тырышыгыз», диде бит.

**Мөхәррәм.** Үзе тыгыла алса — тыгылыр, тыгыла алмаса — юк. Менә мин җиде класс башым белән ике йөздән дә ким алган аем юк. Шуңа өстәп: «Сменаң беткәч, машинамны төзәт әле», дип, көн саен ун-унбиш кеше тагылып йөри. Шуларның яртысы институт тәмамлаган гыйлем ияләре. Төптәнрәк уйласаң, минем эше кара эшчегә почет хәзер.

Автомобиль тавышы ишетелә.

Шәмсенур (*капкадан карап*). Такси?..

Мөхәррәм. Мине алырга килделәр. Шәйхенуров дигән бер адәм «Жигули»ен ваткан. Дүрт-биш көнлек эше бар. Ике йөз сум һәм ике ярты әрмән коньягына килештем. Ул да югары белемле әнә. Математика укыта.

Шәмсенур. Төзелеш техникумында түгелме икән, сиңа әйтәм?

Мөхәррәм. Аның кайда укытуы сиңа нәрсәгә?

Шәмсенур. Әссарыбызга ярдәм итә алмасмы дим.

Мөхәррәм. Итә алмас. Пенсиядә бугай ул. Итә алса да кешедән ярдәм сорамас идем.

Юл сумкасы күтәргән Фидаһи керә.

Фидаһи. Саумысыз!

Мөхәррәм. Бик сау, үскән егет.

Фидаһи. Бераз үстек инде, Мөхәррәм абый. Танымыйсыз бугай?

Мөхәррәм. Таныйм да төсле...

Шәмсенур. Ләбибә малае түгелме соң?

Мөхәррәм. Кайсы Ләбибә?

Шәмсенур. Бертуган энеңне оныттыңмыни? Шуның хатынының сеңлесе бит.

Мөхәррәм. Ә, белдем, белдем. Исемең...

Фидаһи. Фидаһи.

Шәмсенур. Без авылга соңгы тапкыр кайтканда сиңа биш-алты яшь булдымы икән?

Фидаһи. Шул чамадыр. Ул кайтуыгыздан Әссар белән урманда җиләк җыюыбыз гына хәтердә.

Автомобиль гудогы.

Мөхәррәм (*капкага карап*). Бигрәк сабырсыз кеше икәнсең, математик. (*Фидаһига.*) Мине чакыралар, ә мин ашамаган да. (*Капкага карап.*) Кәтәрсең. (*Өйгә уза.*)

Шәмсенур (*Фидаһига.*) Әниең: «Тешләрем белән газапланам, бездә юньле итеп ямамыйлар, сезгә барам», дип язган иде, килмәгән икән.

Фидаһи. Җае чыкмады. Менә аз гына күчтәнәч җибәрде. (*Өстәлгә банка белән бал, какланган каз куя.*)

Шәмсенур. И бу Ләбибәне!.. Берүзе өч бала тәрбияләп... Әтиегез бигрәк яшьли вафат булды шул. (*Балны карап.*) Умарталарыгыз бармыни?

Фидаһи. Умартабыз юк. Узган ел казларыбыз бер көтү булды. Әни күршеләрдән казга алмаштырып алды. (*Сүзне башкага борып.*) Шәһәрегез матур гына.

Шәмсенур. Рәхәтләнеп кунак бул.

Фидаһи. Кунакка килмәдем. Төзелеш техникумына имтихан тапшырырга килдем мин.

Шәмсенур. Документларыңны китергән чакта ник безгә сугылмадың?

Фидаһи. Почта белән генә җибәрдем.

Шәмсенур. Ничек почта белән генә? Техникумда танышың бармы әллә?

Фидаһи. Техникумын да күргән юк әле, танышым каян булсын.

Шәмсенур. Ышаныч үзеңә генә инде. (*Урамда кызлар көлүе.*) Гөлсылу кайта. Кемлегеңне әйтми тор әле, үзе таныймы икән?

Гөлсылу керә.

Ф и д а һ и. Исәнмесез.

Г ө л с ы л у *(уңайсызланып).* Исәнмесез, абый.

Ш ә м с е н у р *(шаяртып).* Бу абыең сине эзләп килгән.

Г ө л с ы л у. Ни йомыш, абый?

Ф и д а һ и *(шаяртып).* Сез мине онытттыгыз дамы әллә?

Г ө л с ы л у. Сез мине башка берәү белән бутыйсыздыр.

Ф и д а һ и. Җиләк белән сыйлаганымны хәтерләмисезмени?

Г ө л с ы л у. Нинди җиләк белән?

Ф и д а һ и. Урманда үсә торган каен җиләге белән, Гөлсылу.

Г ө л с ы л у. Исемемне дә беләсез...

Ш ә м с е н у р *(Гөлсылуга).* Ләбибә апаң дип сөйли идекме?

Г ө л с ы л у. Ә-ә, Ләбибә апа!.. Сез Фи... Фи...

Ф и д а һ и. Әйе, Фидаһи абыең мин.

Г ө л с ы л у *(кул биреп).* Исәнмесез, Фидаһи абый! Кунак бусагада торырга тиеш түгел. Өйгә керегез.

Ф и д а һ и. Юынып аласы иде.

Г ө л с ы л у. Юынгыч әнә. Хәзер сөлге чыгарам. *(Өйгә уза.)*

Ш ә м с е н у р. Мин өстәл әзерлим. *(Кучтәнәчләрне алып өйгә уза. Гөлсылу сөлге чыгара. Фидаһи юына.)*

Ф и д а һ и *(Гөлсылу алып чыккан сөлгегә карый да сумкадан үз сөлгесен ала.)* Мин юлдан...

Г ө л с ы л у *(Фидаһиның сөлгесен кире салып).* Юлда тузан икәнен мин белми дисезме әллә?

Ф и д а һ и *(сөртенеп).* Рәхмәт... Имтиханга килчеләр күпме икән?

Г ө л с ы л у. Килүчеләрен әйтә алмыйм, ә минә әти-эниләре техникумны чебен урынына сырып алганнар. Ә сез — ялгыз...

Ф и д а һ и. Керә алмасам, кире кайтып китүе күңелсез булыр инде, Гөлсылу. *(Карап.)* Бакчагыз әйбәт. *(Бакчага уза.)*

Ләбибә керә. Зур сумка күтәргән.

Л ә б и б ә. Исәнме, кызым. Син Гөлсылу буласыңдыр инде. Мин Ләбибә апаң.

Г ө л с ы л у. Исәнмесез, Ләбибә апа.

Л ә б и б ә *(күреп).* Улым да килеп җиткән икән... Гөлсылу, кар базыгыз булса, бу сумканы шунда төшереп куйыйк әле.

Г ө л с ы л у *(сумканы күтәреп).* Эчендә таш мәллә?

Л ә б и б ә. Банкалар гына. Бәреп вата күрмә тагын. Кар базыгыз бикләнәме?

Г ө л с ы л у. Хәзергә ачык, төнгә бикләрбез. *(Базга төшеп китә. Фидаһи керә.)*

Ф и д а һ и *(гаҗәпләнеп).* Син түгелме соң бу, әни?

Л ә б и б ә. Мин инде, мин...

Ф и д а һ и. Өйдә генә торам, акчам да аз дигән идең.

Л ә б и б ә. Теге сарыкны саттым.

Ф и д а һ и. Сатма дидем бит, әни.

Л ә б и б ә. Алтмыш тәңкәлек малга үзләре үк сиксәнне биреп торгач тәвәккәлләдем инде. Менә, килдем әле.

Ф и д а һ и. Мин кайтканчы сабыр итәргә иде. Имтиханга әнисен ияртеп килгән дип уйларлар.

Л ә б и б ә. Ай алла, мин сиңа ияреп килмәдем бит, улым. Син чыгып китү белән, тешләремнең дүртесе берьюлы сызлый башлады. Үрле-кырлы сикердем.

Шәмсенур күренә. Гөлсылу баздан чыгып өйгә уза

Ш ә м с е н у р. Син түгелме соң бу, Ләбибә?

Л ә б и б ә. Мин бу, Шәмсенуркаем, мин. *(Курешәләр.)*

Фидаһи өйгә кереп китә.

Саумы, үзең ни эштә.

Ш ә м с е н у р. Һаман кирпеч тезәм. Ә син?

Л ә б и б ә. Фермада сыер савам. *(Кәгазьләр чыгарып.)* Сезгә дә күрсәтим дип алып килдем. Мактау кәгазьләре. Ел саен бирәү. Бөтенесе сигез!

Ш ә м с е н у р. Хуҗалыгың да бар. Фермасына ничек җитешәсең?

Л ә б и б ә. Балаларым булыша. Бигрәк тә Фидаһием! Укуы бетү белән, ярдәмче булып тракторга утырды. Рәттән утыз көн эшләде дә кулыма шыгырдап торган сигез унлык тоттырды.

Ш ә м с е н у р. Бәхете генә була күрсен инде.

Л ә б и б ә. Техникумга эләгә алса, бәхетле булыр иде дә... Председателебез әйтте: «Фидаһи укырга керә алса, техникумны бетереп чыкканчы колхоз стипендиясе түлибез», диде. Малаема: «Тешләремне яматырга килдем», дигән булдым инде. Нинди теш! Бала өчен үрсәләнеп йөрү. Керә алырмы икән?

Ш ә м с е н у р. Әйбәт укыдымы соң?

Л ә б и б ә. Әйбәт укыса да, монда имтихан вакытында бик буташтыралар ди. Таныш-белеше булмаган авыл баласына «биш»лек сөйләсә дә «өчле» генә куялар ди.

Ш ә м с е н у р. Белмим инде, Әссарым да шул техникумга кермәкче иде дә...

Л ә б и б ә. Синеке керер. Техникумда танышың да бардыр әле.

Ш ә м с е н у р. Кирпеч тезүченең кайлардан килеп техникумда танышы булсын инде, Ләбибә?

Л ә б и б ә. Сөйләмәсәнә, Шәмсенуркаем, син хәстәрен алдан күрә торган кеше. Алла хакына дип ялынам, мине дә берәрсе белән таныштыр әле.

Ш ә м с е н у р. Танышым юк дим бит, Ләбибә.

Л ә б и б ә. Юк дип, килеп кермәс борын өметкәйләремне кырт кисә күрмә берүк! Синнән башка бер таянычым да юк бит бу дөньяда. Таныштыр инде, таныштыр. Коры кул белән килмәдем. Буш итмәм.

Ш ә м с е н у р. Мөкатдимәгә генә әйтеп карамасам...

Л ә б и б ә. Кем ул?

Ш ә м с е н у р. Чины әллә кем түгел. Техникумда секретарь гына. Кәҗүнни квартир алганчы бездә торды.

Л ә б и б ә. Мәгънә белә торган хатынмы соң?

Ш ә м с е н у р. Чикләвекле агачны тауның теге ягыннан ук күрә.

Өйдән Мөхәррәм чыга.

Л ә б и б ә. Сау гынамы, Мөхәррәмкәем?!

М ө х ә р р ә м *(курешеп.)* Бик сау.

Л ә б и б ә. Менә, килеп чыктым әле...

М ө х ә р р ә м. Сизәм: малаең ачасы ишекләрне майларга инде.

Л ә б и б ә. Майларга дип... Ай алла... Күрше Бәнатбану авыл буенча: «Тәпән белән бал илткән кешеләрнең балалары укырга эләгүсез-сораусыз керә», дип йөргән булды.

М ө х ә р р ә м. Тәпән белән бал!.. Хәзерге ришвәтчеләр бал белән, бер йөз, ике йөз сум акча белән кул пычратмый. Бирсәң син аларга меңәрләп бир! Өч мең! Биш мең!

Л ә б и б ә. Башыма сыймый: кешедән ничек меңләгән сумнар аласың инде?

Мөхәррәм. Ришвәтне юньле кеше алмый да, бирми дә. Юньсезнекеннән юньсез тартынып тормый.

Ләбибә. Ник аларны тотып япмыйлар?

Мөхәррәм. Тиз генә танып булмый шул. Мужыт, минә минем Шәмсенур да ришвәтчедер?

Шәмсенур. Әстәгафирулла, әстәгафирулла...

Мөхәррәм. Мужыт, менә син дә ришвәт бирергә дип килгәнсендер...

Ләбибә. Тьфү, тьфү...

Мөхәррәм (*фикерен дәвам итеп*). Замана үзгәрде, кеше генә үзгәрми, кеше һаман алырга гына ярата.

Ләбибә. Алырга үзең дә ярата торгансыңдыр әле, Мөхәррәм?

Мөхәррәм. Мин эшләп алам. Миңа ике машина кирәк. Берсен улым туенда Әссарга, икенчесен кызым туенда Гөлсылуга бүләк итәм. Соңыннан: «Әти безгә бер нәрсә дә калдырмады», дип үпкәләп йөрмәсеннәр. Ә син, Ләбибә, малаең артыннан тагылып йөреп дөрес эшләмисең.

Ләбибә. Баланы саклап йөртү хәерлерәк инде.

Автомашина гудогы.

Мөхәррәм. Миңа ялыналар! Калганын кайткач сөйләшербез. (*Китә.*)

Өйдән Гөлсылу белән Фидаһи чыга.

Гөлсылу. Әни, аш суынып бетә бит инде.

Шәмсенур. Әйдә әле, Ләбибә, утырыйк әле чөкердәшеп.

Ләбибә. Синдә чөкердәшү кайгысы... (*Өйгә узалар.*)

Гөлсылу. Кәефегез кырылдымы соң сезнең?..

Фидаһи. Әнинең килүен көтмәгән идем.

Нәҗилә керә, кулында дәреслек.

Нәҗилә. О Гулечка, кавалерың белән мине дә таныштыр.

Гөлсылу. Таныш булыгыз: туганыбыз Фидаһи, авылдан. (*Фидаһига Нәҗиләне күрсәтеп.*) Ә бу кыз — Нәҗилә, ләкин үзен Надежда дигәнне ярата.

Нәҗилә. Миңа урын тәкъдим итегез, Фидаһи.

Фидаһи. Итәгем бөгәрләнә димәсәгез утырыгыз.

Нәҗилә. Бөгәрләнсә үтүклибез аны, Фидаһи.

Фидаһи. Әниегез үтүклиме?..

Нәҗилә (*усал карап*). Бәрәңге ашап үскән авыл егетләре ак чырайлы була диләр иде.

Фидаһи. Без хәзер бәрәңгене сыерга бирәбез, үзебез ит ашыйбыз.

Нәҗилә. Шулаймы? Хәзер авыл егетләре дә озын яллы чәч йөртә икән.

Фидаһи. Ник йөртмәскә? Без ялкау кызлар шикелле чәч тарарга иренмибез.

Нәҗилә (*чәчен сыпырып*). Тарадым.

Фидаһи. Үзегез тарадыгызмы, әллә...

Нәҗилә (*бүлдереп*). Әнием тарады, мин көзге каршында тордым. (*Китабы төшеп китә.*) Ай!..

Фидаһи (*китапны ала, тышлыгын карап*). Алгебра?..

Нәҗилә (*җитди*). Математикага гашыйкмын. Акыллылар дөньясына. Физика белән химиягә — серләр дөньясына. Иртәгә төзелеш техникумының плановиклар бүлегенә имтихан тапшырырга барам. (*Үзенә киная белән.*) Анда бер генә ел укыйсы.

Ф и д а һ и (*җитди*). Математикага гашыйк булгач, сезгә институтка имтихан тотасы иде.

Н а җ и л ә. Әни кушмады шул. «Тизрәк укуыңны тәмамла да эшкә кер, кияүгә чыгып балага батканчы миңа булыш», диде.

Ф и д а һ и. Үги анамы әллә?

Н а җ и л ә. Үземнеке дә... эчә. Әти ташлап китте. Их!.. (*Җырлап җибәрә.*)

Үсәдер таллар Сакмар су буенда...

(*Бакчага уза.*)

Г ө л с ы л у. Әнисе хакында бүтән сорашмагыз, Фидаһи абый.

Әссар кайта, йөзе чытык.

Ә с с а р (*берсенә дә игътибар итмичә, юынгычка атлый*). Хайван! Гөлсылу, одеколон кайда?

Г ө л с ы л у. Менә бит.

Ә с с а р (*юынгыч янындагы шкафтан мамык ала, одеколонлый, шуның белән кулын сөртә*). Ишәк!..

Г ө л с ы л у. Ни булды, абый?

Ә с с а р. Үзәк урамга чыксам, каршыма бер ир белән хатын килә, хатынның бер кулында бәрәңге тутырылган сумка, икенчесе белән исерек ирен җитәкләгән. Шуларны озаттым.

Г ө л с ы л у. Таныш кешеләр идемени?

Ә с с а р. Кирәк кешеләр иде: хатыны техникумда укыта. Ире төчкерде. Төкереге кулыма чәчрәде сыман. (*Мамыкны читкә ыргыта.*) Зараза!

Н а җ и л ә. Исәнме, царь мой дорогой.

Ә с с а р. Сәлам, милая Надежда. (*Фидаһины күрә.*) Фидаһи бит син.

Ф и д а һ и. Саумы, Әссар, патша булып җиткәнсең, туган.

Ә с с а р. Теләмәсәң дә булырсың, брат. Исемгә әллә кайдан килеп тагылган бит: Әс-сар — царь. Ни эш бетерү?

Ф и д а һ и. Автомеханикага дип килдем.

Ә с с а р. Сират күперен бергә кичәбез икән. Безнең бүлектә конкурс: бер урынга өч гариза.

Ф и д а һ и. Алай икән.

Ә с с а р. Шулай шул. Кинога билет алдым, Надя.

Г ө л с ы л у. Син аз укыдың, абый.

Ә с с а р (*шаяртып*). Укыган кадәрлесе җитәр, җитмәгәненә госпожа шпаргалка ярдәм итәр.

Г ө л с ы л у. Шпаргалка! Үзең «Яшьләр намусы» дигән сочинениене бишлегә яздың. Күңелеңдәгесен язмадыңмыни соң?

Ә с с а р. Мин бишле куярлык итеп яздым, Гулечка. (*Билетын болгап, Наҗиләгә.*) Барабызмы?

Н а җ и л ә. Күлмәгемне алмашыйм инде. Подъездда көтәрмен. (*Китә.*)

Г ө л с ы л у. Наҗилә апаны яратасыңмы син, абый?

Ә с с а р. Чибәр ул. Яннарыннан без узганда аңа карап хәтта кызлар да «ах! итә.

Мөкатдимә керә.

М ө к а т д и м ә. Исәнмесез. (*Фидаһига карап.*) Арагызда яңа егет тә бар икән.

Ә с с а р. Авылдан. Фидаһи. Техникумга кермәкче.

М ө к а т д и м ә (*Фидаһига*). Теләгегезгә ирешегез.

Ф и д а һ и. Рәхмәт.

Ә с с а р. Мөкатдимә апа, мин фәкыйрегезгә математикадан булышсагыз иде.

М ө к а т д и м ә. Ничек итеп?

Э с с а р. Абитуриентларга биреләчәк билетларны сез басасыздыр бит. Бер-икесенең күчермәсен кыстырып килсәгез, шул җиткән.

М ө к а т д и м ә. Якынрак кил әле. (*Эссар килә, Мөкатдимә аны эләктереп ала да маңгаена чиртә.*) Менә сиңа бер билет, менә сиңа ике билет, менә өченчесе.

Э с с а р. Икене генә сораган идем, өчәү булды. Җитте, җитте, Мөкатдимә апа.

М ө к а т д и м ә (*бармак янап*). Җитмәде бугай әле. (*Өйгә уза.*)

Э с с а р. Надюша көтәдер. (*Китә.*)

Ф и д а һ и. Абыегыз тыныч.

Г ө л с ы л у. Тыштан гына тыныч ул. Эче тулы ут. Җәй буе әзерләнде.

Өйдән Шәмсенур белән Мөкатдимә чыгалар.

Ш ә м с е н у р (*Мөкатдимә белән каласы килеп*). Кызым, помидорларыңа су сибәргә вакыт.

Ф и д а һ и. Мин дә булышам. (*Гөлсылу белән бакчага уза.*)

М ө к а т д и м ә. Кызыңның җәй буе бакчадан башы чыкмый.

Ш ә м с е н у р. Квартирга күчсәк, Гөлсылуым да бакчадан котылыр иде.

М ө к а т д и м ә. Сезгә квартир бирүләре тәгаенмы соң?

Ш ә м с е н у р. Бирмичә, мин төзелештә егерменче елымны эшлим. Абыең бер урында егерме икенче елын. Тырыша торгач, бу йортны «торырга яраксыз» дип актлаттык инде.

М ө к а т д и м ә. Тузуын да тузган.

Ш ә м с е н у р. Шуңа күрә бушлай диярлек бирәбез: өч кенә мең.

М ө к а т д и м ә (*бакчаны күзәтеп*). Әти белән әнигә тыныч кына почмак. Ике пенсионер рәхәтләнеп казынсыннар.

Ш ә м с е н у р. Аларны бу йортка чыгаргач, үз квартирың да иркенәеп кала.

М ө к а т д и м ә (*Шәмсенурны тыңламыйча*). Туганымдай кешеләр белән сатулашып торасым килми. Өегезгә ике мең.

Ш ә м с е н у р. Мөхәррәм абыең ул бәягә ризалашырмы икән соң?

М ө к а т д и м ә. Ризалашыр. Яраксыз дип актланган йортны «Яраклы» итү өчен өч пар туфли туздырырга кирәк.

Ш ә м с е н у р. Өе — өй инде. Эссарым керә алырмы икән, Мөкатдимә?

М ө к а т д и м ә. Техникумның дилбегәсе минем кулда булса, Эссарны тройкада чаптырып кына кертеп утыртыр идем дә...

Ш ә м с е н у р. Син техникумда секретарь бит!..

М ө к а т д и м ә. Кабат-кабат уйладым инде, бик үрсәләнсәм дә, сезгә ярдәм итә алмыйм.

Ш ә м с е н у р. Көннәрен төнгә ялгап укыган иде, бәбекәем. Техникум дип утлар йотып тора... Ай, бу башкайларымның хәсрәтләрдән арыныр көне булырмы икән бер? (*Күзен сөртә.*)

М ө к а т д и м ә. Өметне бөтенләйгә үк өзмик әле, Шәмсенур апа.

Ш ә м с е н у р (*ялтырып*). Шулай дисеңме? Өзмик дисеңме?

М ө к а т д и м ә. Мин тырышып карармын каравын да...

Ш ә м с е н у р. Син тырышсаң булдырасың да булдырасың инде!

М ө к а т д и м ә. Гаеп итмәсәгез, зур бер үтенечем бар иде.

Ш ә м с е н у р. Нинди гаеп ди ул, язмаганны сөйлисең. Әйт кенә, кулдан килә торган эш булса...

М ө к а т д и м ә. Шәл китергәннәр. Кәҗә мамыгыннан, өйгә дип куйган акчама кагыласым килми. Әҗәткә өч йөз сум биреп тора алмассызмы?

Ш ә м с е н у р. Теләсәң дүртне дә бирәм. Эссарым дип, имтиханга дип.

Мөкатдимә (*бүлдереп*). Бу акчаның Әссарга да, имтиханга да катнашы юк. Ике айдан кайтарырмын. Көтәрсезме?

Шәмсенур. Көтмичә, язмаганны... (*Акчаны алдан әзерләгән.*) Менә.

Мөкатдимә (*санап*). Монда өч йөз егерме биш. (*Бер егерме бишлекне кире кайтарып.*) Алыгыз.

Шәмсенур (*уңайсызланган булып*). Ялгыш санаганмындыр.

Мөкатдимә (*акчаны кесәсенә салып*). Кунак егете дә укырга дип килгән икән.

Шәмсенур. Килүчеләр белән шәһәр тулды инде.

Мөкатдимә. Әнисе дә ялгыз, имеш.

Шәмсенур. Ирсез хатыннар аяк атлаган саен ул хәзер.

Мөкатдимә. Үзем авылда үскәнгәме, Ләбибә апаны жәлләп куйдым.

Шәмсенур. Төшенеп җитмим әле: әллә аларга да булышмакчы буласыңмы? (*Кисәтеп.*) Сиңа бер генә кеше — минем малай гына.

Мөкатдимә. Әйе, әйе, миңа Әссар гына. Ләбибә апага ярдәм итәргә бүтән кеше табып булмасмы икән дим.

Шәмсенур. Бүтән кеше дисеңме? (*Эндәшеп.*) Ләбибә! Ләбибә!.. (*Ләбибә өйдән чыга.*) Мөкатдимә белән таныш әле.

Мөкатдимә. Без таныш бит инде. (*Шәмсенур өйгә уза. Мөкатдимә, битен җиләсләндереп.*) Чәйдән соң тирләтеп җибәрде. Балыгыз бик әйбәт.

Ләбибә. Нефть төтене сеңмәгән андый бал хәзер безнең якларда гына шул.

Мөкатдимә. Умарталарыгыз күпмени?

Ләбибә. Бик күп! Ун баш!

Мөкатдимә. Аларны кем карый инде?

Ләбибә. Улым карый, Фидаһием. Белмәгәне юк аның. Унынчыны да әйбәт тәмамлады. Билгеләрен кара әле син аның, билгеләрен. Кирәк булса-нитсә дип, аттестатыннан күчереп алдым.

Мөкатдимә (*карап*). Арифметика — биш, алгебра — биш, геометрия — биш.

Ләбибә. Шул бишлеләр имтиханда өчкә калмас микән?

Мөкатдимә. Абитуриентлар, кагыйдә буларак, имтиханда каушыйлар.

Ләбибә. Иремнән өч бала белән калдым. Фидаһи өлкәне. Бөтен өметем шуңарда.

Мөкатдимә. Авылда бишлегә укыганнар, кагыйдә буларак, монда өчлегә генә бирәләр.

Ләбибә. Дүртлегә бирә алсын иде ул менә! Әз генә сабыр ит әле. (*Кар базына китә.*)

Мөкатдимә. Фидаһи математикадан тапшырыр инде ул... Рус теле язмадан өчле генә. (*Бал, каклаган каз күтәреп, Ләбибә керә.*)

Ләбибә. Балыбызны исәр мактадың. Ал әле.

Мөкатдимә. Картлар әйтмешли, аллам сакласын, юк, юк!

Ләбибә. Зинһар, рәнҗетмә инде, Мөкатдимәкәем.

Мөкатдимә. Ирексезләмәгез, булмый. (*Китә башлый.*)

Ләбибә. Тол хатынның бирдәнбер үтенечен аяк асларына салма инде, Мөкатдимәкәем.

Мөкатдимә (*кире килеп*). Өлкәннәр үтенечен тыңласаң да кыен, тыңламасаң да кыен. Ярый инде. (*Балны ала.*) Ничә сум түләргә?

Ләбибә. Күчтәнәч өчен акча алалармыни, Мөкатдимәкәем? Сумкаң бик җайлы икән, казын да салыйк әле.

Мөкатдимә. Анысы ничә сум?

Лəбибə. И алла, сум дип инде...

Мөкатдимə. Бушлай ала алмыйм, Лəбибə апа. Менə сезгə ун сум. *(Ике бишлек бирə.)*

Лəбибə. Бездə казның бозау чаклысы да биш сум.

Мөкатдимə. Каз — тавык түгел.

Лəбибə. Тавык бездə бер тəңкə. Бер бишлеге артык. *(Бишлекнең берсен Мөкатдимə кесəсенə тыга.)*

Мөкатдимə. Рəхмəт. Хушыгыз. *(Капкага юнəлə.)*

Лəбибə *(аңа ияреп).* Мөкатдимəкəем, Фидаһиемнең фамилиясе Нигъмəтҗанов булыр... *(Китəлəр.)*



Артларыннан Гөлсылу карап кала.
Фидаһи Гөлсылу янына килə.

Фидаһи. Нинди уйга баттыгыз?

Гөлсылу. Əниегез Мөкатдимə апага бал белəн каз биреп җибəрде. Болай булгач бал ярдəмендə баллар җыясыз да техникумга каз канатлары белəн генə очып керəсез.

Фидаһи. Əни андый нəрсəлəр дə алып килгəнмени?

Гөлсылу. Сандык кадəр сумка!

Фидаһи. Ул сумка кайда соң?

Гөлсылу. Кар базында.

Фидаһи. Мондый чакта сез нишлəр идегез?

Гөлсылу. Əнине тиргəр идем, елый-елый.

Фидаһи. Əнине тиргəргə? Əти үлгəндə əнигə утыз яшь кенə иде əле. Кияүгə сорап күплəр килде. Балаларымны үги итəрлəр дип бирсенə дə чыкмады. Безне үлеп ярата ул. Бу ялгышы да балаларына мəхəббəттəн. Белəсезме...

Гөлсылу *(бүлдереп).* Миңа белгəн кадəресе дə бик җиткəн. *(Өйгə уза.)*

Фидаһи *(ишеккə килеп).* Əни, чык əле.

Лəбибə чыга

Лəбибə. Ни бар, улым?

Фидаһи. Нигə чакырганымны чамалыйсыңдыр инде?

Лəбибə. Килүемне өнəмədең.

Фидаһи. Əйе шул. Бу дөньяда минем өчен иң кадерле кеше син, əни, шулай да үтенеп сорыйм, син өйгə кайтып кит.

Лəбибə. Ни өчен куасың мине?

Фидаһи. Мине аңлап бетермисең, əни. Укыйм икəн, майламыйча укыйм, эшлим икəн — майламыйча эшлим. Техникумга да арткы ишектəн керергə телəмим, керсəм — парадныйдан, ə син...

Лəбибə. Əйе, мин теш яматырга гына килмəдем, əз булса да хəлеңне дə җиңелəйтə алмаммы дидем. Сарыкны саттым, ул җитмəсə, сыерны да сатармын, өйне дə. Мунчада яшəрмен. Укы гына. Минем телəгем шундый, əтиеңнең васыяте шулай.

Фидаһи. Əтинең васыятен үтəячəкмен, əни, əмма синең хəзер монда булуың миңа комачаулый гына. Бөтен нервларым кыл кебек тартылды. Ялынып сорыйм: кайт, əни, шул чагында гына мин имтиханга тыныч күңел белəн бара алам.

Лəбибə. Кайт... Кайтасым килмəсə дəме?

Фидаһи. Син китмəсəң, мин кайтып китəм. Я, кайсыбыз?.. *(Җавап юк. Фидаһи ишеккə юнəлə.)*

Лəбибə *(аны туктатып).* Мин китəм, улым.

Фидаһи. Рəхмəт, əни. Соңгы «Метеорга» җитешəсең əле.

Лəбибə өйдəн сеткасын алып чыга, аны артыннан
Шəмсенур белəн Гөлсылу чыгалар.

Ш ә м с е н у р. Ай алла, нинди генә килү булды соң бу?

Л ә б и б ә. Килдем, үзегезне күрдем, хәлегезне белдем, Фидаһием кайткач, яңадан иркенләп килермен әле, боерган булса. Сау булыгыз. *(Ләбибә белән Фидаһи китә башлыйлар.)*

Г ө л с ы л у. Ләбибә апа, баздагы әйберләрегез кала бит.

Л ә б и б ә. Анысы сезгә күчтәнәч, Гөлсылу.

Ут сүнеп ала һәм кабына.

Төн. Тәрәзәләрдә — ут. Комган тотып Шәмсенур чыга. Бакчада бер күләгә күренә дә, Шәмсенур каршына килеп баса.

Ш ә м с е н у р. Ай!..

К ү л ә г ә. Курыкма, Шәмсенуркаем, мин — Ләбибә бу.

Ш ә м с е н у р. Йөрәгемне яра яздың. Кайтып киткән кеше бит син, ничек инде...

Л ә б и б ә. Шәһәрдән чыгу белән, автобустан төшеп калдым. Мөкатдимә кебек ярдәмче табылгач кайтып китә алмадым инде. Бала бит.

Ш ә м с е н у р. Өйгә кер алайса.

Л ә б и б ә. Фидаһи холкы белән суйган да каплаган нәкъ әтисе. Монда икәнемне белсә, төн дип тормас, хәзер үк кайтыр да китәр. Син мине сарайга биклә. Бер генә төнгә. Фидаһиның математикадан ничәгә тапшырганын белгәнче генә.

Ш ә м с е н у р. Сизмәсләрме соң?

Л ә б и б ә. Зинһар, сиздерә күрмә, Шәмсенуркаем. Өстемнән ат башыдай йозак белән биклә дә ачкычын югалттым диген.

П Ә Р Д Ә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Көндезге сәгатьләр. Шәмсенур кайта. Эш киемнәреннән. Өйгә кереп чыга, бакчаны күзәтә.

Ш ә м с е н у р. Кая булыр болар? *(Сарай ишеген ача, аннан Ләбибә чыга.)*

Л ә б и б ә. Болай ятулары бик кыен икән.

Ш ә м с е н у р. Әссар кайтмадымы?

Л ә б и б ә. Ярыктан минут та күземне алмадым: кайтмады. Шәмсенуркаем, син иректәге кеше, техникумга бар әле, балаларның ничек имтихан биргәнен тәрәзәдән булса да карап тор.

Ш ә м с е н у р. Алар өченче катта икән, буй җитәрлек түгел.

Л ә б и б ә. Ник шул шәһәр мәктәпләрен әллә ничәшәр катлы итеп салалар... *(Сарайга йөгерә.)*

Ш ә м с е н у р. Ул ишектә мотоцикл. *(Ләбибәне икенче ишектән кертеп җибәрә.)*

Мөхәррәм кайта.

М ө х ә р р ә м. Сарайда кем ул, әле генә ишеге шапылдап ябылды?

Ш ә м с е н у р. Мотоциклны урыныңдамы икән дип карадым. Әссар кайда?

М ө х ә р р ә м. Син белмәгәнне мин каян белим?

Ш ә м с е н у р. Мөкатдимәдән шалтыратып сорарлар — кайтып киттеме икән, юкмы.

М ө х ә р р ә м. Китсә кайтыр әле.

Шәмсенур. Имтиханын бирә алмаса, шул хурлыктан кайтмаса? Җир читенә качса?

Мөхәррәм. Аягы бар, кулы бар — эшләр дә ашар.

Шәмсенур. Менә бит!.. Нинди ата инде син? Кичә Шәйхенуровка әйтергә онытмаган идеңме?

Мөхәррәм. Нәрсә?

Шәмсенур. Улыбызның исеме Эссар, фамилиясе Сарбулатов дип.

Мөхәррәм. Әйтмәсәң дә фамилиямнең Сарбулатов икәнен Шәйхенуров белә.

Шәмсенур. Ә Эссарның исемен?

Мөхәррәм. Эссарның Эссар икәнен белү Шәйхенуровка кирәкми.

Шәмсенур. Миңа кирәк иде.

Мөхәррәм. Үзеңә кирәкне үзең әйтәләр аны.

Сөт, икмәк күтәреп Гөлсылу кайта.

Менә ичмасам үскән кызым минут та тик тормый.

Гөлсылу. Тик торган кеше үсми диләр, әти.

Эссар кайта, бик яхшы киенгән.

Мөхәррәм. Кайтты бит! Өстәлдә бөтенесе дә өелеп торганда, җир читенә качарга минем улым ахмак мыни? Бераз гына капкалыйм да... *(Өйгә юнәлә.)*

Шәмсенур *(аны туктатып)*. Ашавың качмас. Башта малаеңның хәлен сора: тапшыра алганмы?

Мөхәррәм. Тапшыргандыр, уңгыры, мондый егетнең кыяфәтенә карап та бишле куярсың.

Шәмсенур. Син дә әйттең инде сүз. *(Эссарга.)* Ничәле булды, улым?

Эссар. Хәзергә билгесез әле.

Мөхәррәм. Ничә булса шул булыр. *(Эссарга.)* Кайгырма, улым, керә алмасаң, техникумсыз да инженерлардан ким яшәмәбез. *(Өйгә уза.)*

Шәмсенур *(Мөхәррәм артыннан)*. Ата диген инде син аны! *(Эссарга.)* Ә керә алдыңмы соң, улым?

Эссар. Керүен кердем дә...

Гөлсылу. Фидаһи абый да кердеме?

Эссар. Ишек төбендә генә калды әле ул. Чират көтеп.

Шәмсенур. Имтиханнарыңны нинди рәк кеше алды?

Эссар. Бер кипкән балык шунда. Шәйхенуров диделәрме. Мине белә ул. Фамилиямне әйтү белән: «Син Мөхәррәм малаемы әллә?» ди. Әйе, дидем.

Шәмсенур. Сорауларына җавап бирә алдыңмы соң, улым?

Эссар. Берсенә бирдем, икенчесенә такы-токырак. Өченчесе мәсьәлә иде, анысына баш җитмәде.

Гөлсылу. Абый, имтихан листыңны күрсәт әле.

Эссар. Листны Кипкән балык бирмәде. Имтихан комиссиясе секретареннан алырсыз, диде.

Шәмсенур. Нигә соң Мөкатдимәдән алып кайтмадың?

Эссар. Аның безгә сугылмаган көне юк. Үзе алып килер әле.

Гөлсылу. Хәерлегә түгел бу.

Шәмсенур. Юньсез! Хәерлегә булсын диген.

Мөхәррәм чыга

Гөлсылу. Әти, бакчаның әнә теге баганасы кыйшая башлаган.
Мөхәррәм *(Әссарга)*. Үскән улым, терәү куй.
Әссар. Минем үземә терәү кирәк бүген.
Мөхәррәм *(Әссарга)*. Уңгыры...
Әссар *(бүлдереп)*. Әти, сатыйк без бу бакчаны.
Гөлсылу. Сатасың килсә, үзең үстергәч сатарсың.
Мөхәррәм. Үзегез карагыз инде, уңгырлары, мин сез ничек дисәгез шуңа риза. *(Китә.)*

Нәҗилә керә, борчылган.

Нәҗилә. Барыгызга да хәерле көннәр. *(Әкрен генә эскәмиягә барып утыра.)*
Әссар. Ни булды, Надюша?
Нәҗилә. Берсе бетте...
Шәмсенур. Беттем дисеңме?
Гөлсылу. И әни, Нәҗилә апа нишләп бетсен инде. *(Нәҗиләгә.)* Фидаһи абый күзегезгә чалынмадымы?
Нәҗилә. Ул чиратта күренмәде. Кереп киткән булса кирәк. *(Имтихан листын чыгарып.)* Бер имтиханым бетте.
Гөлсылу *(листны карап)*. Нәҗилә апа математиканы бишлегә тапшырган.
Әссар *(Нәҗиләгә)*. Дорогая, милая...
Нәҗилә *(туктап)*. Кирәкми, котлама. Гитара алып чык әле. *(Әссар өйгә уза.)*
Шәмсенур. Сиңа җырларга да, биергә дә була...
Нәҗилә. Әгәр мин елап җибәрсәм?
Гөлсылу. Мондый көнне еларга ярамый, Нәҗилә апа, мин рөхсәт итмим. *(Шәмсенурга.)* Сөтне кайнатып куйыйм әле. *(Өйгә уза.)*

Әссар гитара алып чыга.

Әссар. Нәрсә уйнарга, сударыня?
Нәҗилә. Бир әле. Үзем. *(Гитараны ала, уйный, җырлый.)*

Үсәдер таллар Сакмар су буенда...

Шәмсенур *(болай җырлауны өнәмичә)*. Китсәнә, кызым. Дөнья белән бәхилләшкәндәй...
Нәҗилә. Бәхилләшмим, Шәмсенур апа, саубуллашам.
Шәмсенур. Кем белән саубуллашасың?
Нәҗилә. Әле иртән генә бер урынга җиде кыз идек, хәзер инде дүрткә генә калдык. Икегә, өчкә тапшырганнар кайтып китте. Шулар белән саубуллашам.
Әссар. Китсә соң!
Нәҗилә. Алар да: «Керербез. Укырбыз», дип килгәннәрдер. Өзелгән өметләр... Берничәсе көлешә-көлешә генә кайтып китте. Күңелле концерттан чыгып баралар диярсең. Андыйларын уйламыйм да мин аларның. Агарынган йөз белән кайтып киткәннәре җәл. *(Пауза.)* Кайбер кызларны тиргәп ташлыйсы килә. Сәләтлеләр. Ялкауланганнар. Укымаганнар. Үз талантыңны үзең буу бит бу! Их!

Үсәдер таллар Сакмар су буенда...
Үсәдер кызлар әнкәсе куенында...

Шәмсенур. Уйнадыгыз да, җырладыгыз да дигәндәй. Алдагы имтиханыгыз рус теленнән бит. Китабыгызны алыгыз, балалар.
Нәҗилә. Китапны да аласы килми... Укыйсы да килми. *(Кузгалып.)* Паркта йөрим әле.
Шәмсенур. Хәзерге яшьләрне һич аңлар хәл юк. *(Өйгә уза.)*

Әссар. Паркка мине дә аласыңмы, Надюша?

Нәҗилә. Бүген минем ялгызым гына буласым килә. (*Китә.*)

Әссар. Ярар соң... Попутного ветра. (*Кинәт, өйгә.*) Гөлсылу, Гөлсылу!

Гөлсылу чыга.

Иртәгә среда бит?

Гөлсылу. Чәршәмбе.

Әссар. Мин киттем.

Гөлсылу. Кая киттең? Имтихан билгеңне дә белмичәме?

Әссар. Ул билгене белеп тә торасы юк инде. Миңа машина табарга кирәк, автомашина! (*Китә.*)

Гөлсылу өйгә уза, сарайдан Ләбибә чыга.

Ләбибә. Менә син агай, менә син агай, Әссар да кайтты, минеке генә һаман юк. Балакаемны икеле куеп харап иттеләрме әллә?

Өйдән Гөлсылу чыга, уйга талган Ләбибә моны абайламый.

Шулайдыр, икеледер, авыл малаен аяк атлавыннан ук таныйлар шул, сыер савучы хатын баласына, ятимгә...

Гөлсылу. Сез түгелме соң бу, Ләбибә апа?

Ләбибә. Юк, юк, мин түгел, мин түгел... (*Сарайга таба йөгерә, абынып егыла.*) Ай!..

Гөлсылу (*Ләбибәне торгызып*). Нык авырттымы?

Ләбибә. Юк, авыртмады, җибәр, җибәр.

Гөлсылу. Сез Фидаһи абыйның кайтып китүен телисезмени?

Ләбибә. Юк, юк, аллам сакласын.

Гөлсылу. Улыгыз хакына сорыйм, кайтыгыз, Ләбибә апа, комачауламагыз аңа.

Ләбибә. Математикасын гына белим инде, аннан соң минут та тормыйм, бүген үк ычкынам.

Гөлсылу. Бүген үкме?

Ләбибә. Гөлсылукаем, бүген үк! Ай... (*Сарайга йөгерә.*)

Гөлсылу. Тагын егыласыз бит инде... (*Ләбибә сарайга бикләнә, Гөлсылу җырлап җибәрә.*)

Агып китте, тота алмадым,
Яулыгым кар суына...

Фидаһи кайта.

Фидаһи абый кайтты!.. Әни, Фидаһи абый кайтты.

Шәмсенур чыга

Шәмсенур. Озак тордың. Нишләп сине генә шулай ярты көн азапладылар, улым?

Фидаһи. Ярты көн түгел, егерме минут чамасы гына.

Шәмсенур. Егерме минут кына? Ул арада белгәнеңне дә белми калганнардыр бит.

Фидаһи. Анда белә торган кешеләр.

Гөлсылу. Листыгызны күрсәтегез инде. (*Имтихан листын Фидаһи Гөлсылуга бирә.*) Ләбибә апа!.. Күккә сикерер иде монда булса. (*Сарайга ишетелерлек итеп.*) Дөрес күрәмме соң, дүртле, дүртле!

Шәмсенур (*карап*). Дүртле шул. Авыл бишлеләре шәһәрдә я икелегә, я өчлегә кала дип чүбек чәйнәүләре гайбәт кенә микәнни?

Фидаһи. Гайбәт кенә, Шәмсенур апа... Мисалда әләктем. Плюсны плюска тапкырлагач минус дип куйганмын.

Гөлсылу. Плюсны плюска — минус? Моны ясле баласы да белә бит инде.

Фидаһи. Плюсның буй сызыгын куйдым, шунда әни искә төште: кичке «Метеор»га өлгерә алдымы икән, төнге йокысы тыныч уздымы икән, борчылмыймы икән... Шуннан шул инде, плюсның аркылы сызыгын куярга онытканмын.

Гөлсылу. Бу хата түгел бит инде, сезгә бишле тиеш иде.

Фидаһи. Хата, Гөлсылу, мондый хаталар өчен безнең укытучы Гөлнур апа күзен дә йоммыйча икеле куя иде, ә Шәйхенуров абый — дүртле...

Гөлсылу. Ул бер баллның соңыннан бик кыйммәткә төшүе ихтимал.

Фидаһи. Үзем гаепле.

Гөлсылу. Бәлки... сезне борчыган әниегез гаепледер.

Фидаһи. Әнигә тимәгез, әни минем өчен үз гомерен бирергә әзер ул.

Гөлсылу. Өлкәннәр әйтмешли, хәерлегә булсын. Дүртлегез өчен сыйлыйм әле. (*Бакчадан җиләк-җимеш салынган ике тәлинкә тотып чыга, Фидаһига.*) Ишекне ачыгыз, плюска плюс. (*Өйгә узалар.*)

Шәмсенур. Фидаһины хорошо-о...

Сарайдан Ләбибә чыга.

Ләбибә. Дүрт булган бит, Шәмсенуркаем, менә син агай!.. (*Уйланып.*) Фидаһи: «Мондый хата өчен Гөлнур апа икеле куя иде», диде бит... Мөкатдимә кулы уйнаган монда, Мөкатдимә кулы! Рус теленнән дә аңа ялынырга туры килә инде. (*Уйланып тора.*) Майлаган тәгәрмәч тизрәк тәгәри диләр. Тукта әле. (*Кар базына таба китә.*)

Шәмсенур. Әссар техникумга керә алмаса, солдатта да бәрәңге әрчергә генә өйрәтерләр инде. Ай, башларым!..

Мөкатдимә керә.

Мөкатдимә, улымның листы сиңдә икән.

Мөкатдимә (*ридикуленнән эзләнеп*). Ну бу Әссарны... Шәйхенуров абый белән ассистенты аптырашып утыралар. Икеле куйыйкмы, өчлеме, янәсе. Ассистенты әйтә: «Абитуриент чи надан, икеле тиеш», ди. Шәйхенуров абый да каршы килми: «Имтиханнар беткәч, мин тагын лаеклы ялымны дәвам итәм. Студентны сез укытасы, сез нәрсә дисәгез, мин шуңа риза», ди. Сөйләшә торгач, икелегә килештеләр!

Шәмсенур. Икелегә?!. Җитмәсә, Мөхәррәм абыең шалкан бәясенә шул Шәйхенуровның үтилен төзәтеп ята. Ашаган табагына төкергән нәмәрсә.

Мөкатдимә. Яхшылыкның кадерен белә торган адәм түгел ул. Икеле куймакчы булып, Шәйхенуров абый ручкасын да алды. Чыдамадым, кулына барып асылындым. «Егетнең этисе автомеханик, малае да моторны биш бармагы кебек белә», дип ут чәчә башладым. Өчле тиеш, мин әйтәм. Ярты сәгать тарткалаштым, барыбер үземнекен иттем: шытырдатып өчле куйдырттым. (*Листны бирә.*)

Шәмсенур. Уф, йөрәккәйләрем... Мең рәхмәт. Гомерем буйларына онытмам.

Мөкатдимә. Математикасыннан котылдык котылуын да, сочинениесе дә бар бит әле аның.

Шәмсенур (*шомланып*). Имтиханда икеле алса?

Мөкатдимә. Ул өчлегә яза да алыр бәлки, әмма конкурс бит, дүртле булуы хәерлерәк!

Шәмсенур. Шулай шул, Мөкатдимә, математикасына җанфәрман тырыштың, рус телендә дә ярдәмеңнән ташлама инде... Өй

турында Мөхәррәм абыең белән сөйләштем. Ике мең азрак дип ыңгырашты ыңгырашуын да, шулай да бөктем.

Мөкатдимә. Сез өйне актлаттык дигән идегез. Карыйк әле, ул актка кемнәр кул куйды икән?

Шәмсенур. Кара, рәхәтләнеп кара. (*Өйгә узалар.*)

Кар базы ягыннан Ләбибә чыга.

Ләбибә. Менә син агай, менә син агай... Хәерчегә җил каршы дигәндәй...

Гөлсылу чыга.

Гөлсылу. Нишләп йөрисез инде, Ләбибә апа, Фидаһи абый күрсә?

Ләбибә. Юлга җыенмакчы идем дә... Син теге сумканы баздан алып бүтән җиргә куйдыңмыни?

Гөлсылу. Куймадым.

Ләбибә. Кар базында сумка юк.

Гөлсылу. Юк?.. Ишегалды уртасында тормагыз инде, Ләбибә апа. Карап килим әле. (*Китә.*)

Ләбибә (*почмакка посып*). Әрҗә чаклы ул базның нәрсәсен карыйсың инде? Баз төбендә яткан менә шушы сәдәпне дә табып алдым, ә сумка...

Гөлсылу керә, Ләбибә почмакка ныграк сыена.

Гөлсылу. (*өйгә*). Әни... Әни дим.

Шәмсенур (*чыга*). Ник дәштең?

Гөлсылу. Бүген базга төшмәдеңме, әни? Анда бер сумка бар иде.

Шәмсенур. Әй, кызым, миндә сумка кайгысымыни! (*Кереп китә.*)

Ләбибә (*почмактан чыгып*). Болай булгач урлаганнар.

Гөлсылу. Шуңа охшый шул. Милициягә хәбәр итсәк?

Ләбибә. Әстәгафирулла! Кунакка килеп качып яткан җиремнән хуҗа өенә милиция чакыртырга... Аллам сакласын.

Гөлсылу. Фидаһи абый нindирәк киңәш бирер икән?

Ләбибә. Яман хәбәр белән җанын борчый күрмә. Сумканың бар икәнен белми иде, юкка чыгуын да сизмәсен.

Гөлсылу. Койма буйларын карап килим әле.

Ләбибә. Баздан алып чыкканны койма буена ташлап калдырырга караклар безнең кебек дивана түгел бит алар.

Гөлсылу. Шулай да карап килим әле. (*Китә.*)

Ләбибә. Коры кашык авыз ерта диләр. Мөкатдимәне нәрсә белән майларга инде? Сарык бар бит! (*Акча чыгарып.*) Сиксән тәңкә. (*Уйлана.*) Иллесен генә бирсәм — аз, сиксәне түгәрәк сан түгел. Юлга дигән егерме сумны да өстәсәм, түгәрәкләнә икән дә... (*Йөз сумны төреп.*) Сау бул, сарык! Кем карчыгы әйткәндәй, Фидаһиемны сыртыңа атландырып имтихан күпереннән имин алып чык. Кайтырга Шәмсенурдан алып торырмын.

Өйдән Шәмсенур белән Мөкатдимә чыга. Ләбибә яшеренә.

Мөкатдимә. Шулай итеп, ике меңгә килештек инде?

Шәмсенур. Алма кебек кеше белән дә килешмәсәң! Менә Әссарым гына...

Мөкатдимә (*бүлдереп*). Сезнең өчен җаным да җәл түгел, Шәмсенур апа. Хушыгыз.

Л э б и б э *(аның каршына атылып чыгып).* Сау гынамы, Мөкатдимэ?

М ө к а т д и м э. Котымны алдыгыз.

Шэмсенур экрен генэ өйгэ уза.

М ө к а т д и м э *(сөйлэшэсе килми).* Бер килеш кенэ, Лэбибэ апа. Мин ашыгам.

Л э б и б э *(тыңламыйча).* Мөкатдимэкэем, Фидаһием дүртле алып кайткан бит, дүртле! Синең ярдэм белэн инде ул!

М ө к а т д и м э. Ярдэм дип...

Л э б и б э. Улым үзе эйтеп тора, миңа икеле тиеш иде, ди. Кем кулы уйнаганын сизэм мин.

М ө к а т д и м э. Укытучысына бер-ике сүз эйттем эйтүен дэ...

Л э б и б э. Менэ-менэ! Синең бер сүзеңме? Синең бер сүзең! Русчадан да, зинһар, күз-колак бул инде.

М ө к а т д и м э. Күз дип... Аттестатында өчле генэ. Кагыйдэ буларак, авылдан килгэн өчлелэр икелегэ кала.

Л э б и б э. Ул көннэрне күрсэтмэ инде, Мөкатдимэкэем. Бу укытучысына да бер генэ сүз эйт тэ...

М ө к а т д и м э. Булмастыр, Лэбибэ апа. *(Сэбэп эзлэп.)* Рус теленнэн имтихан аласы хатын мине иреннэн көнли.

Л э б и б э. Синнэн дэ көнлэшкэч үзе шундыйрак хатындыр ул.

М ө к а т д и м э. Аларын тикшермик. Укытучылары белэн сөйлэшэ алмавымны аңладыгыз инде. Хушыгыз.

Л э б и б э *(юлын бүлеп).* Э ассистенты? Анысы да тискэрегэ тегелгэн нэрсэме эллэ?

М ө к а т д и м э. Ассистенты алай ук түгел дэ...

Л э б и б э. Алайса бер сүзеңне шуңа эйтерсең. *(Акча сузып.)* Менэ моны ал эле.

М ө к а т д и м э. Монысы булмый. Минем эш урыным бар, кешелэр арасында үземэ күрэ дэрэҗэм бар. Мондый акчаларга гомеремдэ борылып караганым юк.

Л э б и б э. Үзеңэ түгел бу. Ассистентка.

М ө к а т д и м э. Бераз уйлагыз эле, Лэбибэ апа: улыгыз имтиханын тапшыра алмаса, ул акчаны ничек кире сорап алырмын?

Л э б и б э. Мондыйны сорый күрмэ. Сорасаң да бирмэслэр. Екма инде, Мөкатдимэкэем.

М ө к а т д и м э. Үзегезне җэллэп кенэ. *(Акчаны ала.)* Бүген безнең арада сөйлэшү булмады.

Л э б и б э. Булмады, булмады. *(Мөкатдимэне озата бармакчы.)*

М ө к а т д и м э *(аны туктатып).* Безне бергэ күрмэүлэре яхшырак. *(Китэ.)*

Л э б и б э. Алды бит, шөкер, алды! Болай булгач өмет бар.

Гөлсылу бакчадан чыга.

Г ө л с ы л у. Сумка юк бит, Лэбибэ апа.

Л э б и б э. Хэерле каза булсын, бүтэн хэсрэт килэ күрмэсен.

Г ө л с ы л у *(сизенеп).* Фидаһи абый чыга!.. *(Аркасы белэн өй ишегеп тери, Лэбибэ сарайга биклэнэ.)*

Ф и д а һ и *(ишекне бер-ике тапкыр этеп караганнан соң).* Гөлсылу, шаярмагыз.

Г ө л с ы л у. Гафу итегез, кайгыдан уйга калганмын. Кичэге сумканы урлаганнар, Фидаһи абый.

Ф и д а һ и. Ул сумка өчен борчылмагыз. Гомумэн, энигэ аны сөйрэп йөрмэскэ иде.

Г ө л с ы л у. Эниегез сезгэ үзенчэ яхшылык эшлэргэ тырышкан.

Ф и д а һ и. Әниләр барысы да яхшылык кына эшләргә тырыша,, тик кайбер яхшылыклары балаларын кимсетү икәнен аңламый. Ни өчен ул кемгәдер каз бирә?

Г ө л с ы л у. Алучысы булганга.

Ф и д а һ и. Алучысы бирүчесе булганга бар аның.

Г ө л с ы л у. Минемчә, әниегез техникумга кабул ителүегезгә ышанып җитми.

Ф и д а һ и. Анысына үзем дә ышанып җитмим, Гөлсылу. Имтихан бирүчеләр арасында көчлеләр күп.

Г ө л с ы л у. Сез кабул ителерсез.

Ф и д а һ и. Каян беләсез?

Г ө л с ы л у. Каян дип... шулай уйлыйм. Уйларым дөрескә чыкмаса, күңелсез булыр инде...

Әсҗар кайта.

Ә с с а р. Атаң Сарбулатов булсын да машина тапма, имеш! «Жигули», Гулечка!

Г ө л с ы л у. Ул машина нәрсәгә соң?

Ә с с а р. Иртәгә Мышинскийның туган көне. Идел буена бармакчылар.

Ф и д а һ и. Кем соң ул Мышинский?

Ә с с а р. Студент. Институтның соңгы курсында. Монда кайтып ике-өч ел эшләсә, ярты начальствоны сакалыннан тотып биетәчәк.

Г ө л с ы л у. Аның сиңа ни кирәге бар?

Ә с с а р. Әгәр миңа киләчәктә аның кул астында эшләргә туры килсә?

Г ө л с ы л у *(киная белән)*. Киләчәктә кирәк булачак кеше икән.

Ә с с а р. Әйе, иртәге көнне бүген кайгыртырга кирәк. Тормыш таләбе! Техникумнан да өмет өзелде...

Г ө л с ы л у. Өзелеп үк җитмәгән әле. Өчле куйганнар сиңа.

Ә с с а р. Өч!.. *(Гөлсылуның кулын үпмәкче була.)*

Г ө л с ы л у. Кыланма инде, абый. *(Бакчага уза.)*

Ф и д а һ и. Мышинский кирәкле кеше дидең. Син Наҗилә белән дә дус. Ул да кирәкле кешеме?

Ә с с а р. Мин Наҗиләгә бурыч түлим.

Ф и д а һ и. Бурыч?

Ә с с а р. Җиденчедә укыганда ук Наҗиләнең ярдәмчел икәнен сизеп алдым. Яратам дип хат яздым. Икенче көнне үк корреспонденциям үземә әйләнеп кайтты: кып-кызыл булган. Ялгышларын Наҗилә төзәтеп чыккан. «Гашыйк егеткә болай язу килешми, хатасыз хатларыңны гына кабул итәчәкмен», дигән. Шуннан соң хат язганда грамматикага да күз салгалый башладым, әдәбият белән дә кызыксынып киттем. Наҗилә дә булышты: паркка чыккач, кышын карга, җәен комга язып, нинди сүзнең ничек язылганын бәйнә-бәйнә аңлата иде.

Ф и д а һ и. Бу дуслыгыгыз мәхәббәткә әйләнеп бара сыман. Торабара өйләнешеп куярсыз бәлки?

Ә с с а р. Юк, Наҗиләгә өйләнмим, чөнки ул ахмак.

Ф и д а һ и. Ахмак?

Ә с с а р. Наҗилә — дыңгычлап тутырылган белем капчыгы. Андагы баш миндә булса, институтның теләсә кайсы ишеген каерып ачар идем. Ә ул, укыйсы бер генә ел дип, план бүлегенә. Дура!

Ф и д а һ и. Алай икән, өйләнмисең икән.

Ә с с а р. Вообще, мин өйләнергә ашыкмыйм. Йөрим әле мәхәббәт бакчасында вольный гражданин булып кырык яшем тулганчы.

Ф и д а һ и *(сынавын дәвам итеп).* Кырык тулгач унҗиде яшьлеккә өйләнергәдер инде ният?

Э с с а р. Юк, брат, мин егерме биш яшьлеккә өйләнәм. Минем хатын институт тәмамлаган булыр, акчаны умырып алыр, кирәк чагында балаларны да, мине дә атландырып йөртердәй менә мондый калын җилкәсе булыр.

Ф и д а һ и. Синең планнар, туган, чыннан да, по-царски икән.

Э с с а р. Бу теманы калдырыйк. Бүген дә гыйбрәтле картина диләр. Әйдә кинога.

Ф и д а һ и. Бара алмыйм. Сочинение язарга хәзерләнәм.

Э с с а р. Юкка баш ватма. Сочинение язганда  яныма утыр да миннән генә күчереп бар.

Ф и д а һ и. Киңәшең өчен рәхмәт. Кеше дәфтәренә ялгыш кына күзем төшсә дә, бөтен тәнем чемердәп китә минем.

Э с с а р. Очень жаль *(Гөлсылуга.)* Гулечка, кинога барасыңмы?

Г ө л с ы л у. Эшем бар.

Э с с а р. Ялына торган гадәтем юк. До свиданья. *(Китә.)*

Ф и д а һ и. Миңа балта белән кадаклар бирегез әле, Гөлсылу.

Г ө л с ы л у. Нәрсәгә алар?

Ф и д а һ и. Әнә ул кыйшайган бағананы күргән саен эчем поша.

Г ө л с ы л у. Сезгә укырга кирәк, Фидаһи абый.

Ф и д а һ и. Кул эшләгәндә баш тик тормасын өчен миңа тема бирегез.

Г ө л с ы л у. Нинди тема?

Ф и д а һ и. Сигезенчене тәмамлаганда сез сочинениене нинди темага язган идегез?

Г ө л с ы л у. «У человека все должно быть прекрасно».

Ф и д а һ и. Кешенең бөтен ягы да гүзәл булырга тиеш.

ПӘРДӘ.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ләбибә ялгызы.

Л ә б и б ә *(дога кылгандай).* Бүгенге эшен «өч»легә яза алса, күкләргә сикерер идем. Вакыты да узмый бит аның!

Себерке алып, өй алдын себерә башлый, тыңланып тора да сарайга йөгерә, кулындагы себеркесе ишеккә кысыла, ишекне бикли алмый азаплана. Шәмсенур кайта, аксый.

Ш ә м с е н у р. Качма, качма. Мин генә бу. (*Сыкранып.*) Уф-эһ...

Л ә б и б ә. Ай аллам, тагын ниләр булды инде, Шәмсенуркаем?

Ш ә м с е н у р. Аягыма кирпеч төште. *(Аягын селкеп.)* Берни сизми.

Л ә б и б ә. Менә син агай, менә син агай, әҗәлең судан булса, чынаяктагы чәйгә батып үләрсең дигәндәй...

Ш ә м с е н у р. Барысы да — Эссар кайгысы. Укырга керә алмаса, ул да кирпеч тезәчәк!

Л ә б и б ә. Тезсә соң, кирпеч тезүчеләр дә кирәк.

Ш ә м с е н у р. Малаеңны да укырга кертмә алайса, кирпеч тезергә генә калдыр.

Л ә б и б ә. Калдыра алмыйм. Җыелыш саен: «Колхозга автомеханиклар кирәк», диләр.

Ш ә м с е н у р. Эссар күренмәдеме?

Л ә б и б ә. Юк шул.

Ш ә м с е н у р. Сочинениене сәгать эчендә язып атам дигән иде.
Л ә б и б ә. Синеке язар да, атар да, менә минекен әйт син.
Ш ә м с е н у р. Синеке дә бер кергәч язмый чыга алмас. *(Кузгалып.)* Ай!.. Чәй куймакчы идем дә, аяклар...
Л ә б и б ә. Үзем куям. *(Өйгә узмакчы.)*
Ш ә м с е н у р. Сарайга йөгер!

Ләбибә сарайга бикләнә. Мөхәррәм кайта.

М ө х ә р р ә м. Шәмсенур!.. Тизрәк чәй куй.
Ш ә м с е н у р. Ут капкандай, кая ашыгасың?
М ө х ә р р ә м. Шәйхенуровка инде.
Ш ә м с е н у р. Ул Шәйхенуровның һаман бетмәдемени әле?
М ө х ә р р ә м. Тагын ике көнлек эше бар.
Ш ә м с е н у р. Ике йөз тәңкә өчен... Арзан килешкәнсең.
М ө х ә р р ә м. Мине өйрәтмә, уңгыры. Нинди эшкә күпме сорарга икәнен беләм.
Ш ә м с е н у р. Бәя килешкәндә кемнең нинди кеше булуын да белергә кирәк, сиңа әйтәм. Ул Шәйхенуров адәм түгел икән.
М ө х ә р р ә м. Хайван мыни?
Ш ә м с е н у р. Эттән туган дуңгыз ул. Чатнатып дүртлегә җавап биргән Әссарыбызга чак кына икеле куймаган.
М ө х ә р р ә м. Әссар — дүртлегә? Адәм ышанмасны!
Ш ә м с е н у р. Белгән сораулары туры килгән. Шәйхенуров өчле генә куйган.
М ө х ә р р ә м. Шуны эшләгән булса, сөйләшә белермен мин аның белән!
Ш ә м с е н у р. Хәзер сөйләшергә соң инде. Акчасын 300 диген.
М ө х ә р р ә м. Акчасына караганда миңа гаделлек кыйммәтрәк.
Ш ә м с е н у р. Гаделлек! Бармы соң ул? Тотып караганың булдымы?
М ө х ә р р ә м. Гаделлек тотып карый торган нәрсә булса, явызлар аны күптән буып үтерер иде. *(Өйгә юнәлә.)*
Ш ә м с е н у р. Әссарыбыз һаман юк. Кайда йөри икән?
М ө х ә р р ә м. Кайтыр, сыер да ашаган җиренә кайта.

Әссар кайта, кулында морожный

Ш ә м с е н у р. Улым кайтты!
М ө х ә р р ә м *(сәгатенә карап)*. Миңа вакыт. *(Өйгә юнәлә.)*
Ш ә м с е н у р. Сабыебызның хәлен сорашмадың бит.
М ө х ә р р ә м. Башы муенында, нервасын тынычландырырга морожные кулында. Тагын сиңа ни кирәк? *(Өйгә уза.)*
Ш ә м с е н у р. Булса да булыр икән бу чаклы...
Ә с с а р. Этине ачуланма, әни. Әйбәт кеше ул. Акчасын тиенен тиенгә алып кайта.
Ш ә м с е н у р. Ә эчүе?
Ә с с а р. Анысы сулдан кергән акчага, аппетит өчен генә. Кайбер аталар урамда ауный, ә минеке — һәрвакыт машина астында.

Нажилә керә.

Н а җ и л ә *(үпкә катнаш)*. Падишаһның кәефе — по-царски!
Ә с с а р *(урын биреп)*. Прошу, милая Надежда.
Н а җ и л ә. Кыланма, зинһар. Имтиханнан чыкмагандыр дип, ишек төбегездә сине ярты сәгать көттем.
Ә с с а р. Чынлапмы, Надежда?
Н а җ и л ә *(үртәлеп)*. Чынлап көтмәдем, юри генә.

Ш ә м с е н у р *(Нәҗиләгә).* Борчылгансыңдыр инде, балакаем?

Н а җ и л ә. Рус телен җиденче класстан бергә әзерләдек бит, Шәмсенур апа.

Әсс а р. Көтмәгән тема туры килде: «Подвиг на Каме». Үзем Чаллыда эшләмәгәч, нәрсә язарга да белмәдем. Икелегә яздым. Икелегә.

Ш ә м с е н у р *(маңгаен ышкып).* Ай, башым... *(Кулындагы әйбере төшеп китә.)*

Н а җ и л ә. Шәмсенур апа, Шәмсенур апа...

Ә с с а р. Шаярттым гына, яздым мин. Икелегә яздым дип кызык өчен генә әйттем, әни.

Н а җ и л ә. Мондый кызыкларың өчен уклау белән кундырасы иде сиңа.

Ш ә м с е н у р *(күзен ачып).* Бишлегә мени, улым? Бер шатландырырсың әле дигән идем шул.

Н а җ и л ә. Бишлегә язганыңны каян беләсең?

Ә с с а р. Иң алдан сочинениене мин бетердем. Укытучы эшемне күз алдымда ук тикшереп чыкты. «Грамоталы, эчтәлеге яхшы», диде. *(Листын биреп.)* Бишле куйды.

Н а җ и л ә *(листны карамыйча капкага юнәлә).* Двойку бы тебе.

Ә с с а р. Надюша, шаярттым. Прости.

Н а җ и л ә. Бу дөньяда гафу ителмәстәй әйберләр дә бар. *(Капкага юнәлә.)*

Ш ә м с е н у р *(Нәҗиләне туктатып).* Ай алла, үпкәләп китәсең түгелме соң, кызым? *(Әссарга.)* Син дә, атаң шикелле, хатын-кыз белән адәм рәтле сөйләшә белмисең. *(Нәҗиләгә.)* Русчадан үзең яза алдыңмы соң, Нәҗилә?

Н а җ и л ә. Бишле булыр дип торам.

Ш ә м с е н у р. Нишләп соң йөзеңдә һаман болыт?

Н а җ и л ә. Уйлар, Шәмсенур апа, уйлар.

Ш ә м с е н у р. Нинди бетмәс уйлар инде алар?

Н а җ и л ә. Нинди уйлар икәнен иртәгә әйтермен. Барыгызга да.

Ш ә м с е н у р. Әниең сәламәттер бит?

Н а җ и л ә. Бүген чирләячәк — получка алган көне. Их!..

Үсәдер таллар Сакмар су буенда...
Үсәдер кызлар әнкәсе куенында...

Сау булыгыз. *(Китә.)*

Ш ә м с е н у р. Бу кызның нинди кайгысы бар икән, улым?

Ә с с а р. Үз кайгым үземә җитәрлек, әни, кеше хәсрәте өчен борчылырга вакытым юк.

Өйдән Мөхәррәм чыга.

Ш ә м с е н у р. Сиңа әйтәм, малаебыз бишлегә язган.

М ө х ә р р ә м. Рәхмәт, улым, молодец.

Ә с с а р. Әти, мотоцикл моторы...

М ө х ә р р ә м *(бүлдереп).* Бер мотор турында ике сөйләмибез.

Автомобиль гудогы ишетелә

Бигрәк тынгысыз кеше булды бу Шәйхенуров. *(Әссарга.)* Конкурстан уза алмасаң да, борыныңны төшермә, үскән улым. Техникумда узачак дүрт ел гомер эчендә исемең бөтен шәһәргә шаулардай механик итәм үзеңне. Сине дә менә шулай машина белән генә килеп алырлар, машина белән генә китереп куярлар.

Ш ә м с е н у р. Ә диплом?

М ө х ә р р ә м. Диплом дигәннәре әкренләп тәти кәгазьгә әйләнеп бара, улгыры. Хәзер хикмәт үз һөнәреңнең остасы булуда. Эшеңне начальствоң сокланырлык итеп эшли алмасаң, дипломыңа карап тормыйлар. Синең кебекләрнең поты бер тиен диләр дә — выжт ишектән! *(Китә.)*

Ә с с а р. Синең, әти, акчаңнан да бензин исе аңкып тора. Ак күлмәк белән ак перчатка киеп кенә алсаң иде син аны! *(Кесәсен капшап.)* Нервларны тынычландырыйм әле дисәм, теге өчлекнең очына чыкканмын икән, әни.

Ш ә м с е н у р *(акча чыгарып)*. Бишлегә язгансың, бишлек бирәм.

Ә с с а р. Башта өч сумны хуҗаларча тотарга өйрәним әле, әни, шуннан соң гына бишлек бирә башларсың. *(Акча алып.)* Рәхмәт. *(Китә.)*

Сарайдан Ләбибә чыга.

Ш ә м с е н у р. Күрдеңме минем малайны? Өч сумны дүрт көнгә җиткерә.

Л ә б и б ә. Ай, аллам, өч сумны айга җиткерә башласа ни булыр? Чегән аты кебек үзе ачтан үлмәсме?

Ш ә м с е н у р. Кайчагында һич кирәкмәгәндә әллә нинди сүз әйтеп куя торган гадәтең бар. Ләбибә, чап!

Ләбибә сарайга кереп бикләнә. Фидаһи кайта.

Сине көтә-көтә күзем күгәрде. Ничегрәк яздың?

Ф и д а һ и. Үзем белгән хаталар да өчәү.

Ш ә м с е н у р. Өч хатага өчле тиешме соң?

Ф и д а һ и. Үзем белгәннәре генә өч! Мин белмәгәннәре бәлки биштер, Шәмсенур апа.

Ш ә м с е н у р. Булсани, авылда үскән татар малае өчен сигез хата күпмени ул? Өчле куярлар әле.

Ф и д а һ и. Монда шәһәр малае, авыл малае дип тормыйлар. Өчле куймаслар, Шәмсенур апа.

Ш ә м с е н у р. Әй, бала, бала, монысы икеле булса сине алмыйлармыни инде?

Ф и д а һ и. Алмыйлар... Миңа җыена башларга кирәктер. Озакламый билгеләрне стенага эләрләр... Кичке «Метеор»га өлгерәм әле.

Ш ә м с е н у р. Әгәр хаталарың кимрәк, сигез түгел, әйтик, биш кенә булса, ул чакта өчле куярлармы?

Ф и д а һ и. Биш кенә булса куярлар да... *(Өйгә юнәлә.)*

Ш ә м с е н у р. Күпкә түзгәнне азга түзәрсең. Билгеңне белмичә, беркая да кузгалмыйсың.

Әссар белән Гөлсылу кайталар, икесенең дә чәчләре тузган, агарынганнар.

Ә с с а р *(Гөлсылуга)*. Хәзер иманыңны укытам.

Г ө л с ы л у. Кешегә иман укыту өчен үз иманың булу кирәк.

Ш ә м с е н у р. Нинди тавыш бу? Язмаганны...

Ә с с а р. Нинди тавыш икәнен үскән кызың сөйләсен. *(Гөлсылуга.)* Тегендә бик әтәчләнгән идең бит. Сөйлә инде, сөйлә.

Г ө л с ы л у. Сүзем бер генә: син әйбәт кеше түгел.

Ә с с а р. Үзең гаепле килеш миңа шулай дип торасыңмы әле? *(Гөлсылуның өстенә килә.)*

Г ө л с ы л у *(баскан җиреннән кузгалмыйча)*. Сук, сук, оялмасаң...

Ш ә м с е н у р. Ник абыеңны үртисең, Гөлсылу?

Г ө л с ы л у. Абый җиләкләрне чәчте.

Ш ә м с е н у р. Нинди җиләкләрне?
Э с с а р. Морожныйга дип базарга керсәм, стаканлап кура җиләге сата.
Ш ә м с е н у р. Эстәгафирулла, язмаганны.
Э с с а р. Сатып алучылар арасында мине таныган кызлар да бар. Елмаеп, көлеп торалар. Базар уртасында Сарбулатовлардан көләләр, әни. Чыдамадым, чиләкләрен алдым да җиләкләрен аяк астына чәчтем.
Г ө л с ы л у. Шунда берсе сиңа: «Чәчең генә озын, акылың кыска икән, ахмак!» диде.
Э с с а р. Ахмак исемен җиләкләр аркасында тактылар миңа. Дәрәҗәмне җиргә салып таптадың. Дус малайлар, таныш кызлар алдында кем мин хәзер? Кем?
Г ө л с ы л у. Кемлегеңне яхшы аңладылар. Мин шуңа шат.
Э с с а р (*Гөлсылуга якынлашып*). Син шат?
Г ө л с ы л у (*чигенмичә*). Шат! Шат!
Э с с а р (*кире борылып*). Сугып та булмый бит син имгәккә.
Ш ә м с е н у р (*арага кереп*). Алай әчелешмәгез әле. (*Гөлсылуга.*) Җиләк сату безнең өчен оят, хурлык. Чиләк тотып ничек базарга керә алдың?
Г ө л с ы л у. Урлаган җиләкләр түгел бит алар.
Э с с а р. Урлап та сатар идеңме әллә?
Ш ә м с е н у р (*Гөлсылуга*). Ни хаҗәткә дип сатадыр идең ул җиләкне?
Г ө л с ы л у. Бүләк алырга уйлаган идем.
Э с с а р. Ә-ә, бүләк! Кемгә, кемгә?
Г ө л с ы л у. Ләбибә апага.
Ф и д а һ и. Минем әнигә?
Г ө л с ы л у. Базны бикләмичә калдырып, сумкагызны урлаттым. Шуның чирек бәясен булса да кайтара алмаммы дип уйлаган идем. (*Күзен сөртә.*)
Ф и д а һ и. Ул сумка югалмады, мин аны баздан алып мунча алдына куйдым.
Г ө л с ы л у. Нигә алай иттегез инде?
Ф и д а һ и. Әни... әнигә юлга йөк булмасын дидем.

Мөкатдимә керә.

М ө к а т д и м ә. Барыгызга да хәерле кич.
Ш ә м с е н у р. Шулай булсын. Нинди хәбәрләр алып килдең, Мөкатдимә?
М ө к а т д и м ә. Улыгыз бишлегә язган. (*Эссарга.*) Котлыйм, кавалер.
Г ө л с ы л у. Ә... ә Фидаһи абый?
Ф и д а һ и. Минекен сорап торма инде, Гөлсылу.
М ө к а т д и м ә. Кызганычка каршы, синеке бишле түгел шул, Фидаһи.
Ф и д а һ и. Икеле дип турысын әйтегез инде.
М ө к а т д и м ә. Синеке, егет, өчле.
Г ө л с ы л у (*шатланып*). Чынмы? Өчлеме?
Ш ә м с е н у р. Чыны булмаса да, өчле булуы хак булсын.
М ө к а т д и м ә. Язмаңның күләме артык зур түгел. Укытучы белән ассистент: «Ничәле куйыйк?» дип аптырабрак торалар иде дә мин килеп кысылдым: «Язуы матур, фикерләре кыю, өчле тиеш», дим. Сүземне тыңлап, өчле куйдылар. Шулай итеп, яшьләрнең имтиханнары тәмам.

Шәмсенур. Имтиханы тәмам да конкурс дигәне бар лабаса әле аның. Әссар уза алырмы икән?

Мөкатдимә. Ул бүлеккә сигез балл җыйганнарның бөтенесен дә кабул итәргә дип торалар икән.

Әссар. Минеке сигез балл, ягъни кавалерыгыз кабул ителде!

Мөкатдимә. Ашыкма, егет. Автомеханика бүлеге ич: әгәр беренче чиратта математиканы дүрткә тапшырганнарны алсалар?

Гөлсылу (*онытылыбрак*). Ул чагында сез кабул ителәсез, Фидаһи абый.

Шәмсенур. Ул чагында абыең кабул ителми.

Гөлсылу (*уңайсызланып*). Шулай шул... (*Мөкатдимәгә.*) Җиде балл җыйганнарның хәле ничегрәк соң?

Мөкатдимә. Ул бүлектә җиде балл җыючылар утыз кеше. Шул утызның бишесен генә кабул итәчәкләр.

Фидаһи. Егерме бишенә документларын кире аласы икән.

Шәмсенур. Сиңа кайгырмаска да була: математикаң дүртле!

Фидаһи. Рус телем өчле. Бу хәсрәтне онытып торыйк әле. (*Әссарга.*) Әйдә, вакыт та тизрәк узар, мотоциклыңны карыйк.

Әссар. Аны ялгызың гына карый алмассыңмы, брат? Мотоцикл сарайда, сарай ачкычы менә. (*Ачкыч бирә.*)

Фидаһи. Ялгызым да карармын. (*Ачкычны ала, сарайны ачмакчы.*)

Гөлсылу. Ай-ай, Фидаһи абый, ул сарайда... мотоцикл түгел, мотоцикл калай белән тышланган әнә теге сарайда. (*Китәләр.*)

Шәмсенур. Фидаһига үзең дә булышырлар, улым.

Әссар. Дусларны ашыгыч күрәсем бар, әни, базардагы хәлне гайбәт итеп тарата күрмәсеннәр. (*Китә.*)

Шәмсенур. Һаман шул Әссар! Конкурста да булыш инде, Мөкатдимә.

Мөкатдимә. Абитуриентны конкурстан уздыру үтә катлаулы, искиткеч четерекле һәм коточкыч куркыныч эш.

Шәмсенур. Шулайдыр шул, шулай... (*Уйлап торгач.*) Ишеттеңме әле, сентябрьдән алтынның бәясе күтәрелә диләр. Үзеңә запаска алтын балдак белән алтын алка алып куйсаң, мин әйтәм, ә?

Мөкатдимә. Әйбәт булыр иде дә, кесәмнең җегәре юк.

Шәмсенур. Алкасын да ал, балдагын да. (*Акча биреп.*) Ике йөз.

Мөкатдимә. Бу хәтле бурычны тиз генә түли алмам бит.

Шәмсенур. Бер түләрсең әле. Биргән чагында... әй, арзан чагында алып кал.

Мөкатдимә (*акчаны алып*). Әссар өчен җаным-тәнем белән тырышырмын. Өметне өзмик, Шәмсенур апа.

Шәмсенур. Рәхмәт инде, рәхмәт.

Тамагын кыра. Шуны көтеп торган Ләбибә сарайдан чыга.

Ләбибә. И, сиңа нинди рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр, Мөкатдимәкәем: малаема тәки өчле куйгансың бит.

Шәмсенур әкрен генә өйгә уза.

Мөкатдимә. Мин куймадым, укытучылар куйды.

Ләбибә. Шулай шул, укытучылар куйган. Техникумына да керә алса...

Мөкатдимә. Анысы авыр мәсьәлә.

Ләбибә. Авыр инде, сиңа да авыр, миңа да. Кеше баласы өчен мәшәкатьләнеп йөрү...

Мөкатдимә. Минем кеше баласы өчен мәшәкатьләнгәнем булмады да, булмас та, Ләбибә апа.

Л ə б и б ə. Ачуланма инде, исəр гадəтем бар: үтə кирəкле урынга кирəкмəс сүз кыстырам. Ялынычым бер генə: конкурста да малаема күз-колак була күр инде.

М ө к а т д и м ə. Монысын вəгъдə итə алмыйм. Комиссиядə унлап кеше.

Л ə б и б ə. Өметемне кисмə инде, Мөкатдимəкəем... (*Тиз генə сумкасын алып килə, ачмакчы.*) Менə монда...

М ө к а т д и м ə. Ачмагыз. Кирəкми.

Л ə б и б ə. Ачам инде, ачмыйча булмый бит инде.

М ө к а т д и м ə. Ачсагыз чыгып ук китəм.

Л ə б и б ə. Ачма дигəч ачып тормыйм, сумкасы белəн генə ал.

М ө к а т д и м ə. Лəбибə апа, минем беркемнəн дə берни алганым булмады.

Л ə б и б ə. Булмады, булмады. Шуңа күрə монысын гына ал инде.

М ө к а т д и м ə. Кулымнан килгəн ярдəмне болай да җəллəмəдем. Хушыгыз.

Л ə б и б ə. Ялынып сорыйм!

М ө к а т д и м ə. Сез бала түгел, минем хəлемне дə аңлагыз. (*Китə.*)

Л ə б и б ə. Алмады. Малаең кабул ителмəс дип əйтүеме инде бу?.. Əгəр шулай булса? (*Мактау кəгазьлəрен саный.*) Берəү, икəү...

Өйдəн Шəмсенур чыга.

Ш ə м с е н у р. Нəрсə син, кəгазьлəреңə карап, төш күргəндəй?..

Л ə б и б ə. Шушыларны күтəреп директорның үзенə барсам, мин шундый-шундый кеше, сез минем улымны алырга тиеш дисəм?

Ш ə м с е н у р. Тавыш-тын басылгач, яныңа керермен əле, шунда сөйлəшербез. Килəлəр...

**Лəбибə сарайга бикленə, сөйлəшə-сөйлəшə Гөлсылу белəн Фидаһи керə, Шəмсенур бер читтəрəк тора.**

Ф и д а һ и. Миңа булышмыйсызмыни инде?

Г ө л с ы л у. Абый үз мотоциклын үзе төзəтергə тиеш иде.

Ф и д а һ и. Ярый, шулай да булсын, ə менə мин сезгə булышам. Əйдəгез, яшелчəлəрегезгə су сибəбез.

Г ө л с ы л у. Сипмибез. Корысыннар. (*Кырт борылып өйгə уза.*)

Ш ə м с е н у р (*Фидаһига*). Нишлəп син, Фидаһи, Мөкатдимə апаңа рəхмəт тə əйтмəдең?

Ф и д а һ и. Минем сочинениене күрдем дип алдаша ул, язма эшемнең күлəме дə ул əйткəнчə кечкенə түгел иде. Мин аңа ышанмыйм. (*Сарайга китə.*)

Ш ə м с е н у р. Нəкъ əтисе! (*Ярсып Мөхəррəм кайта.*)

М ө х ə р р ə м. Шəмсенур, Шəмсенур!

Ш ə м с е н у р. Монда бит инде. Нишлəп иртə кайттың?

М ө х ə р р ə м (*коньяк чыгарып*). Эчəргə.

Ш ə м с е н у р. Нинди шатлыктан?

М ө х ə р р ə м. Шəйхенуров белəн якалаша яздык. Шул сөенечтəн.

Ш ə м с е н у р. Кеше белəн кешечə сөйлəшергə өйрəнə алмадың инде.

М ө х ə р р ə м. Əссарга икеле куя язган дип үзең котыртып җибəргəч!

Ш ə м с е н у р. Дөресен əйттем.

М ө х ə р р ə м. Шəйхенуров: «Əссарыңа шытырдатып икеле куярга кирəк иде, синең малай булганга гына өчле куйдым. Моның өчен миңа гомерең буе рəхмəт укырга тиеш син», ди.

Ш ə м с е н у р. Дисə соң, рəхмəт диялəр дə...

М ө х ə р р ə м. Ни өчен мин аңа гомер буе рəхмəт укырга тиеш?

Укый алмаслык малайны укытабыз диган булып, улыбызның дүрт ел гомерен җилгә генә очырачаклар анда.

Шәмсенур. Җилгә генә булмас. Дүрт ел буена нәрсә дә булса әләгер әле.

Мөхәррәм. Әләксен өчен әләктерердәй баш кирәк.

Шәмсенур. Ул Шәйхенуров белән исәбеңне өзеп кайттыңмы соң?

Мөхәррәм. Үздем: акчаларын атып бәрдем, солярканы чиләген тибеп очырдым.

Шәмсенур. Ә акча?

Мөхәррәм. Бер тиене дә кирәкми. Шакшы кулдан акча алырга җирәнәм!

Шәмсенур. Җирәнәм дип, ике йөз сумны? Бик беләсең килсә, ул өчле — Мөкатдимә хезмәте!

Мөхәррәм. Малайга Мөкатдимә дә булышамыни әле?.. Бушлай гына булышамы соң ул?

Шәмсенур. Бушлай гына...

Мөхәррәм. Чәнчелеп китсәм дә ышанмыйм. (*Кисәтеп.*) Синдә күпме акча барлыгын төгәл чамалыйм. Иртәгә ревизия. Растратаң чыкса, кара аны!

Шәмсенур. Эчәм дип кайткансың, бар әле, бар, рәхәтләнеп эч.

Мөхәррәм. Эчәм шул, уңгыры. Нигә укый алмаслык баланы укый аласың дип алдыйлар? Кеше гомерен урлау лабаса бу. Иртәгә техникумга барам, директорга керәм, Шәйхенуровны да, Мөкатдимәне дә милиция белән китертәм. Малайга икеле куйсыннар.

Шәмсенур. Җенләнеп йөр тагын!

Мөхәррәм. Җенләнәм. Куйдыртам. Икеле куйдыртам!..

ПӘРДӘ.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төн узган. Сәхнәдә Фидаһи ялгызы. Мотоцикл төзәткән.

Фидаһи (*кулын чүпрәк белән сөртә*). Моторы тартмый диган була бит.

Гөлсылу чыга, халаттан.

Гөлсылу. Хәерле иртә, Фидаһи абый.

Фидаһи. Хәерле көн инде, йокы чүлмәге. Авыл кызлары бу вакытка кадәр йокласа, исемен радиодан кычкыралар. Лейкаларыгызны алыгыз, шәһәр ялкавы, су сибәбез.

Гөлсылу. Әйттем бит: корысыннар.

Фидаһи. Корытырлык булгач, үстермәскә иде. Йокыгызны дәвам итегез. Үзем сибәм. (*Бакчага уза, су сибә.*)

Гөлсылу (*карап*). Ай, җиләкләрне таптыйсыз!

Фидаһи. Корысыннар.

Гөлсылу. Помидорларымны сындырасыз!..

Фидаһи. Сынсыннар.

Гөлсылу (*шланг алып*). Чыгыгыз бакчадан!

Фидаһи. Чыкмыйм.

Гөлсылу. Чыкмаганны куып та чыгара беләбез. (*Шлангтан су җибәрә, Фидаһи бакчадан атылып чыга.*)

Фидаһи. Колакка су керттегез. (*Җиңүче кыяфәтендә торган Гөлсылуга.*) Үзегезне дә коендырам. (*Чиләк белән су ала, Гөлсылуны куа башлый.*)

Гөлсылу. Әни!..

Өйдән Шәмсенур чыга. Фидаһи колагына кергән суны чыгару өчен титаклап йөри.

Шәмсенур. Ни булды тагын?

Гөлсылу. Фидаһи абыйның колагына су керде.

Шәмсенур. Котымны алдың, кыланчык. (*Өйгә уза.*)

Фидаһи (*җитди*). Сез булганда бу бакча корымаячак. Гөлсылу. (*Сәгатенә карап.*) Техникумга барсам, исемлек чыкмагандыр әле...

Гөлсылу. Кабул ителсәгез нишләр идегез, Фидаһи абый?

Фидаһи. Шатлыктан үзегезне үбәр идем. (*Гөлсылу иренен турсайта.*) Ачуланмагыз. Шаярттым гына. Кабул ителсәм, әнине шатландырырлык итеп укыр идем.

Гөлсылу. Кабул ителерсез.

Фидаһи. Каян беләсез?

Гөлсылу. Төшемдә күрдем. Ак күлмәк кигәнсез. Аягызда ак туфлиләр. Кулыгызда ак портфель. Ак портфелегездә ак дәфтәрләр. Ак асфальт буйлап техникумга ашыгасыз. Килеп җиттегез, ак баскычлардан менеп киттегез. Мин сезгә ак кулъяулык болгап калдым...

Фидаһи. Әйбәт төш! (*Пауза.*) Керә алмасам, кайту белән тракторга утырам, көз җиткәч — Армиягә. Армиядән соң — авыл хуҗалыгы институтына.

Әссар кайта.

Әссар. Салют! Парк әйләнә биш круг бирдем — биш километр! Һәр иртәне йөгерәм. Райком инструкторы артыннан!

Гөлсылу. Киләкле кеше артыннан йөгерәсең икән!

Әссар. Чәнчемә, зинһар. (*Фидаһига.*) Сәламәтлек өчен файдалы. Сиңа да йөгерергә иде, брат.

Фидаһи. Авылда йөгерергә вакыт тими: эш. (*Сарайга таба китә.*)

Әссар. Эшнең бетәчәге юк аның. (*Гөлсылуга.*) Нишләп минем белән исәнләшмәдең!

Гөлсылу. (*төксе генә*). Хәерле иртә.

Әссар. Бу исәнләшүдә хөрмәт сизмим. Базар өчен ачу саклыйсыңмы?

Гөлсылу. Ул рынок бугазда төер булып тора. Аяк астына чәчелгән җиләкләр: «Безне шуның өчен үстердеңмени?» дип, күзләрен мөлдерәтеп, һаман да миңа карап торалар сыман. Син яман кеше, сине техникумга да кабул итәргә тиеш түгелләр.

Әссар. Сигез балл беләнме?

Гөлсылу. Әгәр Фидаһи абый кабул ителмәсә, техникумнан үз документларыңны аласың да алар урынына Фидаһи абыйныкын илтәсең. Синең урынга аны алсыннар.

Әссар. Шундый тәртип бар дип уйлыйсыңмы?

Гөлсылу. Барын-югын белмим. Шулай да вәгъдә бир: мин әйткәнчә эшләрсеңме?

Әссар. Ни өчен минем урында Фидаһи укырга тиеш әле?

Гөлсылу. Ул синнән сәләтлерәк.

Әссар. Килештек: син әйткәнчә булыр.

Гөлсылу. Вәгъдәме?

Әссар. Вәгъдә.

Гөлсылу. Рәхмәт. (*Өйгә уза.*)

Фидаһи сарайдан чыга.

Фидаһи. Гаеп карбюраторда булган.

Әссар. Мотоцикл әзме?

Фидаһи. Бәхетсез мотоцикл.

Э с с а р. Бәхетсез?

Ф и д а һ и. Машина тере түгел, тик аның да җаны бар: кадерләгәнне ярата.

Э с с а р. Мин дә аны кадерлим, имтихан тапшырганда вакыт кына җитмәде.

Ф и д а һ и. Әйдә, гаепнең нәрсәдә икәнен күрсәтәм.

Сарайга китәләр. Мөхәррәм белән Шәмсенур күренә.

Ш ә м с е н у р. Нишләп болай иртә уяндың? Шимбә, ял көнең.

М ө х ә р р ә м. Саклык кенәгәләренә ревизия ясадым. Өч йөз сум җитми. Кая куйдың?

Ш ә м с е н у р. Ай алла, күршеләргә бурычка бирдем.

М ө х ә р р ә м *(ботинкаларын киеп)*. Малай өчен дип Мөкатдимәгә сузмадыңмы? Менә шуны белү өчен техникумга барам. (*Аягына баса.*) Директорны күрәм.

Ш ә м с е н у р (*Мөхәррәмне җибәрмәскә тырышып*). Бик зур киңәшем бар иде, сиңа әйтәм.

М ө х ә р р ә м. Зур киңәшне бергәләп киңәшик. (*Эндәшеп.*) Эссар!.. Гөлсылу!.. (*Эссар белән Гөлсылу киләләр.*) Әниегез киңәш бар ди. (*Шәмсенурга.*) Кәгазьдән укыган шикелле озын сөйләмә, вакыт тар.

Ш ә м с е н у р. Бу йорт-җирне сатабыздыр инде, Мөхәррәм?

М ө х ә р р ә м. Үскән улым ни әйтер?

Э с с а р. Сатыйк.

Ш ә м с е н у р. Сатам, улым, килешенгән кешем дә бар.

М ө х ә р р ә м. Үскән кызым ни әйтер?

Г ө л с ы л у. Сатмагыз.

Ш ә м с е н у р. Җәй буе бәйләп куйган кебек бакчада ятасың, үзеңә эш кимер..

Г ө л с ы л у. Сез күчегез, мин шушында калам. (*Бакчага карап.*) Мине үз көчемә ышандырган туфрак бу! Уч төбе чаклы шушы җир аша киләчәктә үзем үстерәчәк йөзәр гектарлы бакчаларны күрәм.

Э с с а р. Үз хуҗалыгына ябышып каткан капитализм калдыгы. Сатабыз!

Г ө л с ы л у. Башта үстер, аннары сатарсың.

М ө х ә р р ә м. Гөлсылу — бакчаның хуҗасы. Хуҗа сүзе — закон!

Гөлсылу, аны үбеп, шатланып өйгә кереп китә.

Ш ә м с е н у р. Сатмасак, вәгъдә куйган кешем алдында оятлы булам бит. Хәсрәтсез узган берәр көнем булырмы икән?

М ө х ә р р ә м. Хәсрәтне үзең эзләп тапмасаң — булыр. *(Кузгалып.)* Мин киттем.

Ш ә м с е н у р. Йөрмә инде, сиңа әйтәм.

М ө х ә р р ә м. Миңа гаделлек кирәк! Бөтенесенең астын өскә әйләндерәм. *(Китә.)*

Ш ә м с е н у р. Көйләнгән эшнең көен җибәреп кенә кайтмаса ярар иде.

Нәҗилә керә, күңеле күтәренке

Н ә җ и л ә.

Үсәдер таллар, Шәмсенур апа,
Сакмар су буенда...

Ш ә м с е н у р. Ни булды, Нәҗилә?

Н ә җ и л ә. Өлкән кеше сабыр була, Шәмсенур апа. (*Эссарга.*) Сәлам, царек мой ненаглядный.

Эссар. Сәлам. Надежда прекрасная.

Нажилә. Мин коры сәламгә генә риза түгел. *(Үбәргә кулын суза.)*

Эссар. Рәхәтләнеп юешләтәбез. *(Кулын үбә.)*

Нажилә. Фидаhи!..

Фидаhи сарайдан чыга.

Котлагыз мине, Фидаhи.

Фидаhи. Техникумга кабул ителүегез белән!

Нажилә. Техникумны онытыгыз. Техникум юк ул.

Эссар. Төш күрәсеңме әллә?

Нажилә. Мин бүген җиңдем.

Эссар. Кемне җиңдең?

Нажилә. Үземне җиңдем. Мине аңлавы кыен сиңа.

Шәмсенур. Нажилә, йөзең кояш кебек. Техникумга кабул ителү шатлыгыннандыр инде.

Нажилә. Мин техникумнан документларымны алып кайттым. Укымыйм дидем.

Шәмсенур *(гаҗәпләнеп)*. Кеше балалары конкурстан уза алмыйча газап чигә, ә син техникумның түренә менеп утыргач...

Нажилә. Техникумны тәмамласам да, ул эштә эшләмәс идем. Эшләрлек булмагач, нигә анда урын биләп ятарга? Озак икеләндем. Бүген хәл иттем инде: алдагы елга институтка керәм. Минем урыным институтта, математика факультетында. Монда техникумнан соң төзелештә эшләрдәй кыз укысын. Быел мин эшләрмен. Өс-башымны карармын. Бераз акча запасы да туплый алмаммы?

Шәмсенур. Бу хакта берәрсе белән киңәштеңме соң?

Нажилә. Киңәштем, үзем белән үзем киңәштем.

Шәмсенур. Энкәң нәрсә әйтер бит?

Нажилә. Энигә әйтәсе сүзем шул: быел ул я эчүдән туктый, яки мин аны дәваланырга озатам. Ярый, хушыгыз.

Эссар. Кичке сеанска киноga барабызмы?

Нажилә *(тынлыктан соң)*. Сине язарга өйрәтә алсам да... Сине техникумга кабул да итәрләр бәлки. Тик тормыш кабул итәрме сине? *(Китди.)* Шул хакта уйлансаң иде, царь мой дорогой!

Үсәдер таллар Сакмар су буенда... *(Чыгып китә).*

Эссар *(аның артыннан)*. Тормышның кабул иткәнен көтеп ятарга кирәкми, ләди! Тормыш үзе кабул итәргә теләмәсә, лом алып, аның ишеген үз кулларың белән каерып ачарга кирәк!

Шәмсенур. Балалар, кабул ителгән кешеләрнең исемлеген чыгармадылар микән? Сәгать ун.

Эссар. Әйе шул. *(Фидаhига.)* Мотоцикл белән барабыз, брат.

Фидаhи. Рәхмәт, мин җәяү генә. *(Өйгә уза.)*

Эссар. Авыл егетенә мотоцикл ярамый. Ха!.. *(Мотоцикл янына китә.)*

Өйдән пинжәген киеп Фидаhи, аның артыннан Гөлсылу чыга.

Гөлсылу. Шатлыклы хәбәр алып кайтыгыз, Фидаhи абый.

Фидаhи. Стенага язылганы булыр инде, Гөлсылу. *(Китә.)*

Шәмсенур. Син ник болай моңаеп калдың, кызым? *(Скамейкада кулъяулык күреп.)* Фидаhиныкы түгелме соң бу?

Гөлсылу. Аныкы, хәзер юып эләм. *(Өйгә уза.)*

Шәмсенур. Син дә сабыйлыгың белән саубуллашып барасың, балам.

Ләбибә кайта, ят киемнәрдән.

Л ә б и б ә. Уф!..
Ш ә м с е н у р. Директорларын күрә алдыңмы соң?
Л ә б и б ә. Җыела торгач, минем кебекләр алтмышлап булды анда. Барыбызны да бер бүлмәгә кертеп утырттылар да, директорлары әйтә: «Һәркайсыгыз белән аерым сөйләшсәм, аңа өч көн кирәк, бергәләп сөйләшик», ди.
Ш ә м с е н у р. Сөйләдеңме соң?
Л ә б и б ә. Беренче булып сикереп тордым. Колхозда тугыз ел сыер савам, мәйтәм. Арадан бер хатын: «Мин егерме ел савам!» дип кычкырмасмы! «Ирем үлде, өч бала белән калдым», дим. Икенче почмактагы бер хатын: «Мин биш белән калдым», ди. Аңа колак салмадым, һаман үземнекен сукалыйм: «Минем улымны колхоз җибәрде», дим. Шуннан унлап тавыш: «Минекен дә колхоз җибәрде!» «Минекен РТС!» «Минекен — автохуҗалык!» диләр. «Малаем тракторист!» дим. «Минеке шофер!» «Минеке машинист!» диләр. Шунда алтын тешле, алтын алкалы бер хатын үкереп елап та җибәрде. Мәхшәр мени!
Ш ә м с е н у р. Мактау кәгазьләреңне күрсәттеңме соң?
Л ә б и б ә. Оялдым. Хәтсезенең түшендә орден! Минекендә медаль дә юк. Кеше арасында бик бәләкәй кеше икәнмен. Орден алырлык итеп тә эшләргә була идедер!
Ш ә м с е н у р. Әллә кайсысы килә...

Ләбибә сарайга йөгерә, итәге ишеккә эләгә.

Ерта күрмә инде, кеше киеме түгелме?

Мөкатдимә керә.

М ө к а т д и м ә *(кул бирә).* Улыңны конкурстан уздырдым, Шәмсенур апа.
Ш ә м с е н у р. Рәхмәт, Мөкатдимә.
М ө к а т д и м ә. Мин өй мәсьәләсендә килгән идем.
Ш ә м с е н у р. Без ул хакта киңәшләшеп караган идек тә...
М ө к а т д и м ә. Күңелегезгә авыр алмагыз, миңа баштагы ниятемнән кайтырга туры килә. Кыйбатрак булса да, без Әбүзәровлар йортын алырга булдык.
Ш ә м с е н у р. Ун меңгәме?
М ө к а т д и м ә. Тугызга килештек. Кирпечтән бит.
Ш ә м с е н у р. Акчасын да берьюлы булсын диләр иде.
М ө к а т д и м ә. Тырыша торгач, җыйдык инде. Биш йөз генә җитми. Килүем дә шул биш йөзгә иде, Шәмсенур апа.
Ш ә м с е н у р. Биш йөз үк юк шул. Бер йөз дисәң, анысын табарга була.
М ө к а т д и м ә. Юк чагында бер йөз дә акча.

Шәмсенур өйгә уза.

Малае укырга кергәнче меңне бирергә дә риза иде...
Ш ә м с е н у р *(чыга, акча бирә).* Санап ал.
М ө к а т д и м ә *(ала).* Сезгә санамыйча да ышанам. Өегез өчен аптырамагыз. Аңа үзем ия табам, дүрт меңнән дә кимгә бирмәбез.
Ш ә м с е н у р. Өйне сатмаска булдым әле. Йортыгызны алып ташлагыз дигән кеше юк. Ашарга сорамый, бакчасы да матур гына.
М ө к а т д и м ә. Анысы сезнең эш.

Үз киемнәрен киеп, сарайдан Ләбибә чыга.

Л ә б и б ә. Сау гынамы, Мөкатдимә?

М ө к а т д и м ә. Искечә.

Л ә б и б ә. Техникумда эзләп тә таба алмагач, авырып киттеңме әллә дип уйлаган идем.

М ө к а т д и м ә *(нык борчылып)*. Мине шунда эзләп йөрдегезме әллә?

Л ә б и б ә. Йөри торгач, сине эзләүчеләр өчәү булдык без анда.

М ө к а т д и м ә. Өчәү? Алар мине башка берәү белән бутаганнардыр.

Л ә б и б ә. Бутамадык. Аптырагач, сынықка сылтау табып, директордан сорадык. «Мөкатдимә ханымның бездән расчет алганына ике атна инде», диде.

М ө к а т д и м ә. Нигә анда төпченеп йөрисез?

Ш ә м с е н у р. Син техникумнан киттеңмени, Мөкатдимә?

М ө к а т д и м ә. Үзем китсәм, дусларым калды.

Мөхәррәм кайта, ярсыган.

М ө х ә р р ә м *(эшләпәсен атып бәрә)*. Ну бу коньякны!..

М ө к а т д и м ә. Хәерле көн, Мәхәррәм абый.

М ө х ә р р ә м. Син дә мондамыни әле, алдакчы?

М ө к а т д и м ә. Сез ни сөйлисез?

М ө х ә р р ә м. Техникумда сине дүрт хатын эзләп йөри!

М ө к а т д и м ә. Мин беркемне белмим.

М ө х ә р р ә м. Белмәссең! «Балаларыгызны укырга урнаштырам», дип акча алгансың, ә балалары керә алмаган. Прокурорга барабыз диләр.

М ө к а т д и м ә. Берәүдән дә акча алганым юк.

Л ә б и б ә. Берәүдән дә?

М ө к а т д и м ә. Менә сездән мин бер тиен булса да алдыммы?

Л ә б и б ә. Бер тиен дип инде... алдыммы дип...

М ө к а т д и м ә. Алсам, шуны раслардык берәр дәлилегез, әйтик, документыгыз бармы?

Л ә б и б ә *(йөрәген уып)*. Менә син агай, менә син агай...

М ө х ә р р ә м *(Шәмсенурга)*. Уңгыры, теге өч йөз сумны таптыңмы?

Ш ә м с е н у р. Кисәк кычкырма әле.

М ө х ә р р ә м. Мөкатдимәгә төрткәнсең. «Математика өчен куелган өчле Мөкатдимә хезмәте», дидең. Шәйхенуров: «Мөкатдимә ханымны быел күргәнем дә булмады», дип ант итте.

Ш ә м с е н у р *(Мөкатдимәгә)*. Шәйхенуров белән очрашмавың хакмы?

М ө к а т д и м ә *(ярсып)*. Хак! Хак!

Л ә б и б ә. Теге ассистент белән дә сөйләшмәдеңме?

М ө к а т д и м ә. Нинди ассистент?

Л ә б и б ә. Ай алла, аңа бирермен дип миннән 100 тәңкә акча алдың ләбаса!

М ө к а т д и м ә. Кайчан алдым? Кем күрде? Аңа кем ышансын?

Ш ә м с е н у р. Мин ышанам. Шәйхенуров белән бер генә тапкыр сөйләшкән булсаң да, бу кадәр ачуым чыкмас иде. Син мине — анаң кебек кешене алдагансың.

М ө к а т д и м ә. Ни дип алдадым?

Ш ә м с е н у р. «Малаеңны конкурстан уздырдым», дидең ич.

М ө к а т д и м ә. Мондый сүзнең авызымнан чыкканы булмады.

Ш ә м с е н у р. Малайны укырга кертәм дигән сылтау белән миннән «бурычка» акча да алмадыңмы?

М ө к а т д и м ә. Алмадым. Минем берәүгә бер тиен бурычым юк.

Ш ә м с е н у р *(Мөхәррәмгә).* Теләсәң ачулан, теләсәң кыйна, минем аңа биргәннәрем — мең сум!

М ө к а т д и м ә. Мең сум?! Бар, прокурорга бар! «Ник бирдең?» дип, миннән алданрак үзеңне ябып куярлар. *(Чәчен тузәтә, иренен буйый.)* Мин сезне кеше дип йөргән идем... Бу нахак бәлаларыгыз өчен мин сезне бугазыгыздан әҗәл алган минутта да бәхилләмәм. *(Китә.)*

Ләбибә, йөрәген тотып, сарайга керә.

Ш ә м с е н у р (*Мөкатдимә артыннан*). Авылдан килгәндә алмашка туфлие дә юк иде бит, хәзер тугыз меңгә кирпеч йорт алган. Замана дуңгызларын үзебез симертәбез шул. (*Мөхәррәмгә.*) Директорны күрәм дигән идең...

М ө х ә р р ә м. Айныгач килерсең диделәр. Шәйхенуровның квартирасына барып сөйләшеп утырдым да...

Мотоцикл тавышы. Өйдән Гөлсылу чыга, Әссар керә.

Ә с с а р. Мин студент, әни!

Ш ә м с е н у р. Бер шатландырырсың дип күптән көткән идем.

М ө х ә р р ә м. Керүен кергәнсең дә, укуын ничек укырсың икән?

Ә с с а р. Укытучыларны тыңлармын. Дәресләрдән качмам. Өмәләрдә баш калкытмый эшләрмен. Җыелышларга чыгыш ясарга әзерләнеп барырмын. Мине быел ук староста итеп сайларлар.

Г ө л с ы л у. Фидаhи абый ничек икән?..

Ә с с а р. Әллә тагын... Үз исемемне тапкач, мотоциклга атландым да, сезне шатландырыйм дип очтым гына.

Фидаhи кайта.

Г ө л с ы л у. Фидаhи абый!.. Сезне котларга мөмкинме?

Ф и д а h и. Юк, Гөлсылу. Документларымны кире кайтардылар.

Сарайдан Ләбибә атылып чыга.

Л ә б и б ә. Кабул итмәделәр?..

Ф и д а h и. Әни?!.

Л ә б и б ә. Эндәшмә, улым, эндәшмә.

Ф и д а h и. Безгә юлга әзерләнергә кирәк. Әйдә, әни. *(Өйгә узалар.)*

Г ө л с ы л у. Ничек инде бу?.. Автомеханиклар әзерли торган бүлеккә мотоциклны да белмәгән абыйны кабул иткәннәр, ә Фидаhи абыйны, тракторчыны кире борганнар...

М ө х ә р р ә м. Төп ялгыш миндә булды, кызым. *(Әссарга.)* Техникумга мин керттем сине. *(Башын тотып.)* Каян туры килде шул Шәйхенуров? Сиңа ул өчле куймаган булса... *(Пауза.)* Техникумдагы урының — харам урын, улым.

Ә с с а р. Харам?

М ө х ә р р ә м. Әйе. Ул урында бүтән кеше укырга тиеш.

Юлга җыенып, өйдән Фидаhи чыга.

Ә с с а р. Фидаhи, сиңа үтенечем бар, брат. Мин документларымны кире алам. Син укы.

Ф и д а h и. Ә син?

Ә с с а р. Мин әти янына эшкә урнашам.

Ф и д а h и. Тормышта hәркем үз урынын үзе табарга тиеш.

Ә с с а р. Син үзең табуыңа ышанасыңмы соң?

Ф и д а h и. Армиядән кайту белән институтка керәм.

Ә с с а р. Керә алмасаң?

Ф и д а h и. Керәм дип әйттем — керәм.

Ләбибә. Килдем — сиңа комачауладым гына. Артыңнан мин агылып йөрмәсәм, плюсның бу сызыгын куйгач, аркылысын сызарга да онытмас идең. Минем аркада керә алмадың бит син, минем аркада гына...

Фидаһи *(бүлдереп)*. Бу хакта кирәкми, әни. *(Сәгатенә карап.)* Безгә кузгалырга вакыт.

Ләбибә *(борчылып)*. Авылга ни йөзебез белән кайтып керербез дә кешеләргә нәрсә дип әйтербез?

Фидаһи. Дөресен әйтербез. Авылдагы өчле монда да өчле булды, дүрткә калган бишлесе — гадел дүртле ул. Ә очраклы рәвештә кергән кешеләр — тормыш тәгәрмәченә ябышкан балчык кына алар: бер вакыт кубып читкә очачаклар. Мин андый ябышкак булырга теләмим.

Мөхәррәм. Болай булгач үпкәсез, рәнҗешсез китәсең инде?

Фидаһи. Кемгә? Рус телен өчлегә генә өйрәнеп килгәнем өчен гаеплләр кешем юк. Сәламәт булыгыз, Шәмсенур апа. Хушыгыз, Мөхәррәм абый. Сау бул, Эссар. *(Кул биреп чыга.)* Күрешкәнгә кадәр, Гөлсылу.

Гөлсылу. Күрешкәнгә кадәр.

Фидаһи. Кузгалдык, әни. *(Китәләр.)*

Шәмсенур *(Ләбибәләрне озаткач, Гөлсылуга)*. Юып элгән теге кулъяулык Фидаһиныкы түгелме соң? Кала бит.

Гөлсылу. Калсын, әни, калсын. *(Алдан әзерләгән чәчәк бәйләме ала.)*

Шәмсенур. Чәчәкләрне кемгә дип җыйган идең?

Гөлсылу. Аларга дип... Фидаһи абыйга дип... *(Алар артыннан чыгып йөгерә.)*

ПӘРДӘ.

# Венера Туктарова

## Кыска шигырьләр

●

— Бу матурлык сездә кайдан?—
Кешеләр сорау бирә.
Белмиләр микәнни шуны:
Нәчкә төшенә төнлә дә
Нур чәчеп Кояш керә.

●

Көя җаннар. Ком чүленнән
Бер йотым сусыз барам.
Бармы бу чүлнең чиге дип
Ялварудамы чарам?

●

— Аны оныттым, дип, кайчан
Тибәрсең син, йөрәгем?
— Булыр микән ул чагында
Минем сиңа кирәгем?

●

Җилләде көннәр буена,
Яумады яңгыр гына.
Өметләндергән болытлар
Таралды акрын гына.

Эндәште бер гөл: «Бу синме,
Чын яшәү биргән күгем?
Уйлаган идем, бардыр дип
Яндыруларга чигең?»

## Роберт Рәкыйпов

### Диңгез өсте сыек зәңгәр томан

Диңгез өстен зәңгәр томан басса,
Күңелләргә никтер моңсу була.
Гүя кораб диңгезләрдә түгел,
Бер урында тора, тоткын суда.

Ярларны да каплап куйган томан,
Уйларны да чикләп куйган сыман,
Яшьсез генә диңгез елый кебек
Шатлыгыннан, әллә кайгысыннан...

Эх, сызлана күңел корабларның
Ерак киткән шундый чакларында,
Туган ярлар гүя, сөйгән ярлар
Шул томанның теге якларында...

Диңгез өсте сыек зәңгәр томан —
Моңнар арта торган чаклар әле.
Диңгезләрен күрми түзмәс кояш —
Пәрәнҗәсен алып ташлар әле...

Офыгына кадәр таныш булган
Туган як бер чыгар каршыбызга.
Иң беренче аны күрү бәхете
Туры килер икән кайсыбызга?..

●

Йөрәк тагын шулай дулкынлана —
Тәүге чыгаммыни диңгезгә.
Малай учындагы кошчык кебек
Талпынасың шундый мизгелдә...

### Бар шул...

Сөям икән Җирне, үлеп сөям —
Миндә кемнең нинди эше бар!?
Диңгезләрдән янып кайтып киләм —
Бар шул,
Җирнең тарту көче бар!

Чәчәк аткан зәңгәр кыналарым —
Үзләрендә Җирем төсе бар.
Күз алдымда ярлар — кыяларым —
Бар шул,
Җирнең тарту көче бар!

Серкәләре очкан арышларның
Күңелемә сеңгән исе бар.
Җирдә генә шатлык-сагышларым —
Бар шул,
Җирнең тарту көче бар!

Зәңгәр Җирдә Туган илем бар дип,
Бәхетеннән шашкан кеше бар.
Мин ул шулай шашам Җирем бар дип,
Бар шул,
Җирнең тарту көче бар!

## Туган як

Кояш нурында шаяра
Энҗе чык тамчылары.
Авырттырып күзгә керә
Сибелгән чаткылары.

Диңгездән туган авылга
Сагынып кайтып барыш.
Тирә-ягымда бал исе,
Саргаеп килә арыш.

Син һәрчак яңа көн кебек,
Кичәнме, иртәсенме.
Мин сине ишетәм, Туган як,
Син мине ишетәсеңме?..

●

«Читтә, — дисез, — рәхәт диңгезчегә, —
Романтика тулы юл», — дисез,
Диңгездәге сагынуларның тәмен
Әй, белмисез әле, белмисез...

Ярдан ераккарак киткән саен
Киерелә бәгырь кыллары,
Сөйгән кешең күздән очкан кебек
Күздән оча Туган ил яры.

Җирдән ерак диңгезләрдә йөзәм —
Сагынулардан диңгез тар миңа.
Дулкын булып егыласым килә
Туган илнең мүкле ярына...

Мәгъсүм Насыйбуллин

# ЯРКАНАТ

ПОВЕСТЬ

## I

Милиция бүлегендә эш көне башланмаган иде әле. Дежур бүлмәсендә ниндидер язулар карап утырган өлкән лейтенант, бүлтәеп торган папкаларны ябып, тасмаларын бик пөхтә итеп бәйләде дә, өстәл тартмасына салып куйды. Аннары, урыныннан торып, тәрәзә янына килде, форточканы ачып җибәрде. Күкрәк тутырып саф һава сулагач, өлкән лейтенант, кулларын як-якка җәеп, гимнастика күнегүләре ясап алды.

Бүгенге төн хәвеф-хәтәрсез генә үтте, ахрысы, дип уйлап өстәлдәге графинга үрелгән генә иде, телефон шалтырады.

— Әйе, милиция тыңлый. Бүлек дежуры өлкән лейтенант... Туктагыз әле, кабаланмый гына сөйләгез. — Өлкән лейтенант өстәл тартмасын ачып, берничә бит кәгазь алды. — Кабаланмагыз, — диде ул, тавышын көчәйтеп. — Ачыграк аңлатыгыз әле. Кассирга һөҗүм иткәннәр? Кайда?.. Сәүдә конторында. Адресы?.. Адресын әйтегез дим!.. Ничә сум? Нишләп билгесез? Кассир үлем хәлендә. Так, хәзер үз фамилиягезне дә әйтегез инде. Контора директоры Нәгыймов? Аңлашылды, иптәш Нәгыймов, телефонограммагыз кабул ителде. Карагыз әле, анда берәүне дә кертмәгез. Эзләр тапталмасын дим. Мин хәзер үк тиешле чарасын күрәм.

Нәкъ шул чакта мәһабәт гәүдәле, киң күкрәкле милиция полковнигы Хәернасов авыр-авыр басып, дежур бүлмәсенә килеп керде. Эшкә җәяү йөрергә ярата ул, килү белән төнге дежурның рапортын тыңлый.

— Хәлләр ничек соң, иптәш өлкән лейтенант? — диде Хәернасов, кера-керешкә.

Дежур офицер урыныннан торды:

— Сәүдә конторында касса басканнар, иптәш полковник.

— Кайчан?

— Бүген төнлә.

— Нигә билгеле булу белән үк өйгә шалтыратмадыгыз? — диде полковник, кырыс кына итеп.

— Хәбәр әле генә алынды, иптәш полковник. Төп-төгәл җиде сәгать унбиш минутта.

Полковник сәгатенә карап алды. Җиде сәгать унтугыз минут.

— Хәзер үк минем машинаны чакырт. Тикшерүче белән инспекторны сәүдә оешмасына озатыгыз, — дип боерды. — Эш сәгате башланганчы, хәлне ачыкласыннар. Артларыннан үзем дә килеп җитәрмен.

— Бүтән хәвеф-хәтәр юкмы? — дип сорады аннары, йомшара төшеп.

— Юк, иптәш полковник. Монысы да төн тыныч узды — дип торганда гына.

— Әйе, бездә тыныч көннәр белән хәвеф-хәтәрсез төн кем әйтмешли, назлы кунак шикелле шул, әллә нидә бер, көттереп кенә килә... — дип, Хәернасов телефонограмма язылган кәгазьне алды да үз бүлмәсенә кереп китте.

Иң элек полковник сәүдә оешмасына шалтыратты. Булган хәл турында Нәгыймовтан тагын бер мәртәбә җентекләп сорашты да, башта шәһәр прокуратурасына, аннары Казанга хәбәр итте.

## 2

Чаллыдан тапшырылган касса басу турындагы телефонограмма унбер минуттан Казанда иде инде.

Зарьянов, ике-өч урынга шалтыратты да, ярдәмчесен чакырып:

— Хәзер үк машиналар җибәрегез, менә адреслары, — дип, аңа кәгазь тоттырды.

Ярты сәгать уздымы-юкмы, Зарьяновның ярдәмчесе бүлмәгә уктай атылып килеп керде.

— Кушылган кешеләргә әйтелде, иптәш подполковник, — диде ул.— Самолетка билетлар калдырылды.

— Әйбәт булган, — дип хуплады подполковник. — Иптәшләрне ашыгыч рәвештә Чаллыга озату сезнең өстә.

Сигез тулып, кырык тугыз минут үткәндә, Чаллыга оча торган самолет пассажирлары арасында подполковник Зарьянов әйткән кешеләр дә бар иде. Аларның берсе — Вилдан Камалиев. Нык бәдәнле, ягымлы, көләч йөзле бу кеше — республика прокуратурасының өлкән тикшерүчесе. Юстиция киңәшчесе дигән дәрәҗәле исеме дә бар.

Камалиевның инануынча, иң мөһиме булган хәлнең логикасына төшенү, һәр җинаятьнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен табу — шулар ачыклану белән, йомгак әкренләп сүтелә башлый. Бәләкәй генә бер деталь икенчесенә барып ялгана һәм җинаятьнең гомуми үзенчәлеген ачарга ярдәм итә.

Бүген керешәчәк эштә кайда күпер, кайда басма икәнен әле күз алдына китереп булмый. Хәзергә кирәге дә юк моның. Җинаятьнең мәгълүм өлеше: Чаллыда касса басканнар, кассир хатын үлем хәлендә — бары тик шул гына. Моны беренче булып күргән-белгән кешеләр Комлева белән Нәгыймов. Вакыйга булган урынны караудан, шулар белән сөйләшүдән башлаячак эшне Камалиев.

Нинди очрашулар көтә икән аны? Нинди шаһитлар белән очрашырга туры килер икән аңарга?

Самолетка кереп утыргач, иллюминатордан аска күз салып, төрлесен уйларга өлгерде Вилдан. Моннан ярты гына сәгать элек Вилдан бөтенләй икенче нәрсәләр планлаштырган иде. Шимбә көн бит. Башта Түбән Ослангдагы бакчасына барып килергә иде исәбе. Ганиләсе шунда. Кичә, ашыгыч эш чыгып, бара алмый калды. Ә бүген менә бәләкәй кызын тезләре өстенә утыртып иркәли дә алмыйча китә.

Иртәгә, якшәмбе көнне, үсмер улы белән ирләрчә гәпләшә-гәпләшә Идел буена төшеп, кармак салып утырырга ниятләгән иде Вилдан. Саф һавада, сызылып таң атканын күзәтә-күзәтә, тыныч суда йөзгән калка-

вычка төбәлеп утыру — үзе бер гомер! Дөрес, осталыгы җитмиме, бәхете юкмы, балыкны әллә ни күп эләктерә алмый Камалиев, әмма ул сихри калкавычка карап, эсәрләнеп сәгатьләр буе утырырга риза.

Тик бу ялда кармак урынына тикшерүче сумкасын алырга туры килде. Күпмегә сузылыр икән бу сәфәр: бер атнагамы, ун көнгәме, әллә бер айга ук барырмы?

Самолет моторы күңелле генә гүли башлады. Вилдан очучылар турында уйлап алды: «Маршрутлары билгеле аларның, күтәрелеп киту вакытлары расписаниедә күрсәтелгән. Хәрәкәтләрен, очышларын күзәтеп торырга диспетчер бар. Ә безнең эш? Хаер, без үзебез диспетчер,— дип көлемсерәде ул үзалдына.— Гаделлек эзләүчеләр диспетчеры. Самолет безне Бигеш аэропортына илтеп төшерер дә янә Казанга кайтып китәр. Без, капшана-кармалана, җинаятьченең кара сукмагын эзли башларбыз. Кайдан кузгалып, кая барып төртеләсеңне белмисең инде, анысын эш барышында абайларга кала».

Җир өстендәге юллар биектән тар сызык булып кына күренә. Кеше узган гомер юлы да күңелдә шулай сызылып каладыр, мөгаен. Тукта, кайчан, кайдан башланды соң әле Вилданның гомер юлы? Монысын ул кистереп кенә әйтә алмый, билгеле. Әмма шунысын яхшы белә, язмыш аңа бик үк мәрхәмәтле булмаган. Чирмешән якларында быел алтмыш сигезенче көзен каршылаучы әнкәсе аңа бик еш әйтә:

— Сабый чагында язмыш сиңа бер дә якты йөз күрсәтмәде, балакаем,— ди.

— Нигә алай дисең, әнкәй? — дип кызыксынганы бар Вилданның. Әнисе болай дип җавап биргән иде:

— Соң, ике яшьтән әтисез калдың бит. Аннары тагын, укырга да кермәгән идең әле — сугыш дигән яңа афәт килде, анысы бөтен илгә ябырылды... Алты яшеңнән нужа күреп үскән бала бит син, улым!

Ул кадәресен Вилдан инде үзе дә хәтерли. Тормыш авырлыгы ныгып та өлгермәгән иңнәргә күтәрә алмастай тау булып ятты. Михнәт диңгезе ул чагында чиксез иде кебек. Озак, бик озак йөзде Вилдан ул дәрьяда. Онытырлык булмады. Мохтаҗлыкның ни икәнен китап аша түгел, үз башыннан кичереп белә ул. Бер сынык икмәк күрми үткәргән озын тәүлекләрне, иксез-чиксез атналарны ничек онытмак кирәк! Әле дә төшкә кереп интектерә. Өндә булган хәлләр бит үзе югыйсә. Әмма Вилдан нык сөякле булды, берсенә дә — ачлыкка да, мохтаҗлыкка да бирешмәде, тешен кысып түзде. Барысына да үч итеп, үҗәтләнеп, һаман бер якны каерды, яшәргә, гыйлем алырга омтылды. Картлар белеп әйткән: «Җүләргә авырлык төшсә — жырлар, акыллыга төшсә — котылырга чара эзләр»,— дигәннәр. Вилдан да үзенекен итте: унынчы классны бик яхшы тәмамлап, Казан дәүләт университетына килеп керде. Уңга-сулга каранып түгел, көченә, белеменә таянып, ишекне киң ачып узды ул. Укый башлагач нужа-михнәттән котылган икән егет дип уйларга ярамый, әлбәттә. Студентның да ашыйсы, аның да адәм рәтле киенеп йөрисе килә. Бигрәк тә тирә-ягында чибәр студенткалар тыз-быз йөреп торган чакта. Яшьлек бит!.. Нужаны монда да әйләндереп салды егет. Пристаньга йөреп, баржа бушатты, укудан соң төзелештә кирпеч ташыды, кыскасы, михнәт дигән котсыз нәрсәне хәләл көче, тырышлыгы белән җиңде.

Илле сигезенче елның җәендә, студент пиджагыннан нужа тузаннарын кагып, дипломлы яшь юрист республика прокуратурасына эшкә килде. Аны тикшерүче итеп алдылар.

Прокуратура баскычыннан атлап менгән беренче көннәрдән соң унбиш ел инде сизелмичә дә үтеп киткән...

Камалиев үзен оста тикшерүче итеп танытты. Мактау сүзләрен дә күп ишетте, әмма масаймады. «Мин һәммәсен дә булдырам!» дигән уй башына да килгәне юк аның.

Камалиевның уң ягында милиция майоры Трофимов утыра. Урта

буйлы, тулы гәүдәле бу кеше Эчке Эшләр Министрлыгындагы җинаятьчеләрне эзәрлекләү идарәсендә өлкән инспектор булып эшли.

...Чит кеше Трофимовны аз эшләргә, тәмле ашарга, күп йокларга яратучан хода бәндәсе дип уйлар иде. Әмма Вилдан аны яхшы белә: Трофимов Казанда, эшче гаиләсендә туып-үскән кеше. Министрлыкта инде унсигез ел эшли. Сүлпәнрәк кешегә охшаса да, кушканны вакытында, төгәл үти торган гадәте бар. Камалиев бу кешене шуның өчен ярата да. Моңарчы да эзе җуелган җинаятьләрне бергәләп ачканнары бар иде аларның.

— Әйдә, тор, йокы капчыгы, җиттек Бигешкә, — дип, Камалиев көлә-көлә майорның сул кабыргасына төртте.

3

Бигеш аэропортында каршы алган лейтенант аларны туп-туры җинаять булган урынга алып китте. Юл буе сүз катмаган лейтенантның теле «Волга» туктагач кына ачылды:

— Килеп җиттек, иптәшләр.

Машинадан беренче булып Камалиев төште. Тиз генә лейтенант күрсәткән йортка таба китте. Камалиевның элекке килүендә бу биналарны әле салып кына яталар иде. Теләсә, һәммәсен булдыра шул кеше дигәнең. Әнә бит, йорт алдына матур итеп артлы эскәмияләр дә ясап куйганнар. Кайсылары сары, кайсылары ачык яшел төскә буялган. Мамыктай кабарып торган түтәлләрдә — чәчәкләр, кичтән су сипкәннәр булса кирәк, таҗ яфракларында көмеш тамчылар җемелди.

Кичә генә бу йорт каршындагы эскәмияләрдә аркаларын терәп әбиләр гәпләшеп утыргандыр, яннарында оныклары мәш килгәндер. Әнә, сап-сары комлыкта бер ташбашының уенчык машинасы да онытылып калган, ком төялгән килеш тора.

Камалиев боларның һәммәсен бер күз салуда күреп алды.

Бер ишек каршында халык төркеме кайнаша иде. «Чыбыксыз телефон» һәр җирдә шәп эшли. Камалиев сораулы карашын үзләрен каршылаган лейтенантка төбәде:

— Шушындамы?

— Әйе, — диде лейтенант һәм бүлмәнең номерын әйтте. — Беренче катта ул. — Һәм Камалиев артыннан эчкә атлады.

Касса бүлмәсе зур түгел икән. Стеналары акка буялса да, нигәдер бик шыксыз күренә.

Камалиев бүлмәне игътибар белән күздән кичерде. Сул як стена буенда, нәкъ ишек каршысында, кечкенә өстәл. Искереп, каралып беткән — чыгар да ташла үзен. Почмактагы сейф кысан бүлмәдә алагаем зур булып күренә. «Ике метр биеклегендәге сандык», дип бәя бирде аңа тикшерүче. Сейф ни җитте алай сарыга буялган. Шул иләмсез сейф белән иске өстәл арасында артлы урындык тора. Бүлмәдә бүтән җиһаз заты юк иде. Әмма булганнары да тикшерүчегә шактый гына мәгълүмат бирергә тиеш. Ничек кенә сак кыланмасын, җинаятьче ишек тоткаларына кагылган, идәнгә басып йөргән, бүлмә уртасындагы урындыкка кассирны бәйләп куйган, сейфны ачып, акча алган...

Экспертлар бүлмәнең һәр сантиметрын җентекләп тикшереп фотога алганнан соң, Камалиев, милиция офицеры белән, буш бүлмәләрнең берсенә керде.

— Баштан ук тикшерүнең юнәлешен билгелик. Я, кемдә нинди тәкъдим бар? — дип сорады ул.

Милиция майоры Трофимов белән Чаллы шәһәренең эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары капитан Соловьев эшне нидән башлап җи-

бәрү хакында уйлашканнарын әйтеп бирделәр. Камалиев аларның нияген хуплады.

Трофимов белән Соловьев киткәннән соң Камалиев үз эшенә кереште. Башта Зинаида Комлевадан, аннары Әхәт Нәгыймовтан сорау алды. Бүлмәне карап чыккач, шаһитларны тыңлагач, вакыйга менә болайрак булып күз алдына килеп басты.

## 4

Егерме бишенче август. Күк йөзе чалт аяз. Шимбә көн булса да, Чаллыда эш кайный.

Сәүдә конторасын җыештыручы Зина өеннән чыкканда, җиде тулар-га ун минут калган иде. Эшкә ул һәр көнне нәкъ шушы вакытта чыгып китә. Эш урыны ерак түгел, җәяүләп дүрт-биш минут кына барасы. Килү белән тиз-тиз генә идәннәрне юып ала, авыз эченнән нидер көйли-көйли, өстәл, шкафларны сөртә.

Ул көнне дә ашыкмый гына барды Зина. Бик матур, кояшлы иртә иде. Йортлардан, чәчәк түтәлләреннән сафлык бөркелеп тора.. Кама буеннан искән йомшак җил Зинаның битеннән сыйпап үтә. Хатын, бу рәхәтлекне сузарга теләгәндәй, ашыкмыйча гына барды. Контора ишеге төбенә житкәч тә, йөзе белән кояшка борылып, җылы нурларда иркәләнеп торды. Аннары, теләр-теләмәс кенә йозакны ачып, эчкә үтте.

Керсә, ни күзе белән күрсен, коридорда гомердә булмаганча ут яна, касса бүлмәсенең һәрвакыт биктә торган ишеге шар ачык иде. «Җебегән нәрсәкәй, ачык авыз!» — дип сукрана-сукрана, касса бүлмәсенә таба йөгерде Зина. Ачык ишекнең бусагасыннан атлауга, «аһ!» дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды, егылып китмәс өчен, ишек яңагына сөялде. Күзләре күрмәс, аяклары йөрмәс булды.

Зина хушына килеп өлгерә дә алмады, контора ишеге ачылып китте. Гадәттәгечә, ак күлмәк, шәп итеп үтүкләнгән чалбар кигән директорның күзләре чырае качкан Зинаны күреп, аптыраулы кысылып куйды:

— Ни булды, Зина? Авырмыйсыңдыр бит?

Җыештыручы хатын шунда гына аңына килде, касса бүлмәсенә ымлап:

— Ни-и-ин-на-а... — дип кенә пышылдады.

— Нина?!. Ни булган аңа?

Касса бүлмәсенә керүгә, Нәгыймов үз күзләренә үзе ышанмый торды. Өстәл каршындагы урындыкта кул-аягы бәйләнгән бер хатын утыра. Өлкән кассир Нина Игнатюк түгелме соң бу? Битләре кара янган. Ә уң як стенага терәтеп куелган зур тимер сейфның ишеге каерып ачылган килеш.

Нина директорга күз төшереп алды, тимгел-тимгел булып күгәргән башын боргалап, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй ыңгырашырга тотынды. Нәгыймов кызны урындыкка кысып бәйләгән бауларны ашыга-ашыга чишәргә тотынды. Авызындагы чүпрәкне тартып алуга, Нина «уф» дип сулап куйды да, башын бер якка янтайтып, күзләрен йомды.

— Нәрсә булды? — Нәгыймов авызыннан бары тик шул сүз генә чыкты. — Иптәш Игнатюк, нәрсә булды?

Кассир кыз шешенгән күзләрен ачарга тырышып карады.

— Вра-а-ач! — дип кенә әйтә алды ул, шуннан соң, башын иеп, тынып калды.

Директорның куллары калтырый башлады, сүзен әйтә алмас булды. «Милициягә шалтыратырга кирәк ләбаса», — дип кенә уйлый алды ул. Бераздан исенә килеп, телефонга үрелде.

Нәгыймов Нина Игнатюкны эшкә кассир итеп үзе алган иде. Кызның сәүдә конторына килеп кергән көнен бүгенгедәй хәтерли...

Аны директор бүлмәсенә кадрлар бүлеге мөдире алып керде.

— Безгә кешеләр кирәк, — диде Нәгыймов, әмма капылт үзен кенә җавап бирмәде, кадрлар бүлеге мөдире белгән кызга сынап карады. Сораша башлады. Новороссийск шәһәрендә туган икән бу кыз. Сахалин өлкәсендә яшәп торган җиреннән КамАЗ турында ишетеп, бик дәртләнеп, Чаллыга килгән. Туган каласында әнисе, сеңелләре яши икән. Әгәр дә Нина әйбәт кенә урнаша алса, сеңлесенең дә кубып киләргә исәбе бар, имеш... Боларны Игнатюк сөйләде.

— Хезмәт кенәгәгез бармы соң? — дип сорады Нәгыймов. Яшь-яшь кыяфәтле оялчан кызга мондый сорау бирү урынлы иде.

Кыз өчен кадрлар бүлеге мөдире җавап бирде:

— Бар, бар, иптәш Нәгыймов, менә ул, — дип, кулындагы кенәгәне директорга сузды.

Нәгыймов кенәгәне актара башлады, кайбер битләрендә тукталгалап та торды.

— Рәхмәт сүзләре дә язылган икән, анысы яхшы, — диде ул, бер бүлек мөдиренә, бер Нинага карап. — Егерме сигез яшь, димәк, тормыш тәҗрибәсе дә бар. Урта белемле дә икәнсез. Сезнең кебек кеше кирәк безгә. Рәхим итегез!

— Рәхмәт сезгә!— диде Нина, директордан күзен алмыйча мөлаем гына елмайды.

Нәгыймов хезмәт кенәгәсен бүлек мөдиренә кайтарып бирде һәм, Игнатюк чыккач:

— Эшкә керешсен, приказ языгыз, айлык сынау шарты белән, әлбәттә, — диде. — Читтән килгәнен дә онытмыйк. Кешенең кем икәнлеген белү өчен бергә күпме тоз ашарга кирәклеген үзегез дә беләсез. Игнатюкны тулай торакка урнаштыру ягын да карарга кирәк. Килештекме?

— Аңлашылды, иптәш Нәгыймов.

Нина тиздән эшкә дә керешә. Бер айлык сынау шартын уңышлы үткәрде. Эшли башлавына дүрт ай дигәндә Нина Игнатюк сәүдә оешмасында үз кеше иде инде, аны өлкән кассир итеп куйдылар... Бүген менә шушы кызның башына бәла төшкән. Аның гына башынамы әле?!

## 5

Комлева белән Нәгыймовтан сорау алганнан соң, Камалиев бухгалтерия бүлмәсенә керде. Анда, шалт та шолт счет төймәләре тартып, сейфтан урланган акчаны исәпләп утыралар иде. Исәнләшеп, танышып та өлгермәде, баш бухгалтер тикшерүче каршына килеп басты:

— Кассада кырык җиде мең өч йөз туксан бер сум акча җитми,— диде ул.

Камалиев белән бергә кергән директор, моны ишеткәч, авызын ачып катып калды. Кырык җиде мең сум! Ничәмә вагон, ничәмә машина товар бит бу! Бер көйгә, шома гына, уңышлы гына бара торган сәүдә хезмәтенең кинәт асты-өскә килгән кебек тоелды аңа.

Камалиев утырды да, гадәтенчә, кабаланмый-китми генә нидер яза башлады. Директор тикшерүченең шундый чакта да сабыр була алуына хәйран калып, почмактагы урындыкка барып утырды. Йөрәге ярсый иде аның...

Республика прокуратурасыннан өлкән тикшерүченең милиция хезмәткәрләре белән Чаллыга очуы мондагы кешеләргә ышанмаганлыктан түгел иде, әлбәттә. Җинаять булган урынны үз күзләре белән күреп, хәлне ачыклау өчен җибәрделәр Камалиевны. Аңа, кирәк була калса, җитди карарлар чыгару хокукы да бирелгән. Җинаятьне ачыклаганда, тикшерүче үз исеменнән түгел, дәүләт вәкиле буларак эш йөртә.

Эш барышында, контораның рәсми кәгазьләрен карап утырганда, Камалиевның колагына күрше бүлмәдән елаган тавыш ишетелгәндәй

булды. Тикшерүче, эшеннән тукталып, колагын сагайтты. Әйе, кемдер үкси-үкси елый, нидер әйткәли дә иде сыман.

Камалиев милиция капитаны Зәйнулла Соловьевны чакыртты:

— Кем елый анда, Зәйнулла? Әллә миңа гына ишетеләме?

— Кем дип, ни, кассир Игнатюк инде, — дип җавап бирде Соловьев.

— Нишләп монда утыра ул?

— Сезнең белән киңәшмичә... — Капитан аңа сораулы караш ташлады. — Ашыгыч ярдәм машинасына алмадылар үзен. Врач дару бирде, беренче ярдәм күрсәтте. Кассирны больницага озатырга куштылар. Менә белешмәсе. — Соловьев аңа кәгазь сузды.

Камалиев врач калдырган белешмәне кат-кат укыды. Үзе бер Соловьевка карый, бер әлеге белешмәгә текәлә, ничә кат укыса да, һаман бер үк сүзләр:

«Гражданка Нина Игнатюкны җентекләп карадык. Тәненә, бигрәк тә йөзенә, күзенә, муенына, кул-аякларына кан сауган. Болар каты физик көч кулланып кыйнау билгеләре. Аңарда чиктәш тыш арыганлык билгеләре дә бар. Больницага урнаштырырга кирәк. Врач Габдрахманов. 25 август. 10 сәг. 15 мин.»

— Аңлашыла, — диде Камалиев үзалдына. Һәм шунда ук Соловьевка мөрәҗәгать итте. — Бүлмәдә ике пунәтәйне генә калдырыгыз, капитан. Башкалар чыгып торсын. Игнатюкны алып керегез.

Игнатюкны тикшерүче янына Соловьев култыклап алып керде. Камалиев кассирга урындык тәкъдим итте:

— Рәхим итеп, утырыгыз... Борчуыбыз өчен гафу итегез, — диде ул, Нинага мөмкин кадәр илтифатлы булырга тырышып.

Кассирның сары бөдрә чәчләре тузгыган, кан сауган күз тирәләре күгәреп шешенгән. Ачык тезләре өстендә яткан ап-ак куллары, урыны-урыны белән күгәреп, шәмәхә төскә кергән. Озын бармаклары җиңелчә калтырый. Битендәге яшь эзләре кибеп тә өлгермәгән, иреннәре сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп тора.

— Нишләп мине больницага озатмыйсыз? — Игнатюк тагы елый башлады.

— Минем сезнең белән беренче очрашуым, — дип башлады сүзен Камалиев ягымлы тавыш белән. Аннары кем икәнлеген әйтте. — Бу җинаять эше миңа тапшырылды...

— Миңа ашыгыч ярдәм кирәк!.. — дип, Игнатюк тикшерүченең сүзен бүлдерде.

— Яхшы, хәзер озатырбыз. Әмма, Нина Николаевна, без дә сезнең ярдәмгә мохтаҗ бит.

— Ярдәм? — Кассир җанлана төште, башын күтәреп Камалиевка карады һәм күз яшьләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды. — Нинди ярдәм?

— Әйе, ярдәм! Кассага кайчан, нинди кешеләр һөҗүм иткәнен сөйләсәгез, хәзергә шул җиткән.

— Милициягә сөйләдем бит инде, — Игнатюк Зәйнуллага ымлады. Капитан кулындагы сорау алу беркетмәсен тикшерүчегә бирде.

«Барысына да кай арада өлгерә соң бу Соловьев?» — дип уйлады Камалиев, ләкин булып узган хәлләрнең бердәнбер шаһиты да, зыян күрүчесе дә булган Игнатюкның үзеннән ишетәсе, кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы килә иде аның. Больница шартларында очрашу да, Игнатюк белән күзгә-күз карап сөйләшү дә кыенлашачагы аңа ап-ачык.

— Яхшы, Нина Николаевна, яхшы.

Тикшерүче бу юлы да карышмады, гадәтенчә, Игнатюк белән бәхәскә кермәде. Аңа бирелгән соңгы характеристикада: «Камалиев кеше белән тупас сөйләшмәс, шаһитларны урынсыз сүз әйтеп, эшкә кагылышы булмаган сорау биреп рәнҗетмәс. Тикшерүченең, кырысланган булып, явызланып-усалланып тавыш күтәрүен дә урынсыз саный. Үз-үзен тотышы

итагатьле», — дип юкка гына язылмаган. Әллә тикшерүченең ипле сөйләшүе тәэсир иттеме, әллә кәефе яхшыра башладымы, Игнатюк тынычлангандай булды. Үзгәрешне тикшерүче дә сизеп алды.

— Ярый, Нина Николаевна, капитанга сөйләгәннәрегез өчен рәхмәт. Сезгә ышанычыбыз зур безнең. Тик минем бернәрсәне генә ачыклыйсым килә, хәтерләгез әле, һөҗүм итүчеләр ничәү иде?

— Хәтерләмим бит, — диде кассир, теләр-теләмәс кенә. — Муеныма арттан китереп суккач, аңымны җуйганмын...

— Исегездә калганнары?..

— Исемдә калганымы? — Игнатюк шулай ук теләр-теләмәс кенә сүзгә керешге. Әмма тора-бара теле ачылып китте. Кассир сөйләгәннәр яңа беркетмәгә теркәлде.

Игнатюк касса бүлмәсен элекке хәленә китерергә рөхсәт сорады. Араларында ике сантиметр киңлектә сызык калдырып, тәрәзәнең ике як пәрдәсен тартып куйды. Өстәлне ишеккә якынайтты. Шулай иткәч, касса ишеге яртылаш кына ачыла икән. Ишекнең сул ягына урындык, өстәлгә исә калын кәгазьдән эшләнгән бер бәйләм касса тасмасы һәм төймәле зур счет куйды да, ике картон тартма һәм газета сорап алды:

— Кибетләрдән җыелган акчаны менә шушындый ике тартмага тутырдым, — диде. — Сыймаган акчаны, целлофан капчыкка салып, газетага төрдем. Кәгазь акчалар гына иде анда. Акчаларны, сумына карап, аерым-аерым төргәккә җыйдым. Өемнәрнең һәммәсен санап чыктым да, аерым кәгазьгә, бездә аны опись диләр, язып бардым.

Игнатюк арыды булса кирәк, сөйләвеннән туктап, бераз тынып торды. Су сорап алып эчте.

— Аннары нишләдегез?

— Барысын да сейфка бикләп, касса бүлмәсеннән чыга гына башлаган идем, нәрсә беләндер муенга китереп суктылар...

— Тартмага нинди акча тутырдыгыз?

— Өчлек, бишлек, унлык, егерме бишлек — алары ике тартмага сыйды.

— Иллелек, йөзлекләр бар идеме?

— Булмыйча. Аларны целлофан капчыкка тутырдым. Барысы да сейфта калды.

Игнатюк әйтүенчә, бу хәл җомга көнне, августның егерме дүртендә, кичке сигездән соң булган. Бу вакытта сәүдә конторында беркем дә калмый икән. Ул кичне дә коридорда тып-тын, ишек, гадәттәгечә, тышкы яктан бикле була. Касса бүлмәсендәге утны сүндереп, Игнатюк коридорга чыга. Касса бүлмәсен бикләп торганда гына тышкы яктан кинәт «шалт» иткән тавыш ишетелгән, шунда ук ишекне ачып та кергәннәр. Аннан урта яшьләрдәге ике кеше килеп керә дә, Нинаны кулыннан борып алып, кире касса бүлмәсенә төртеп кертә, резин перчатка кигәне кул сырты белән муен тамырына суга. Нина һушыннан яза. Аңына килә, авызында чүпрәк, бөтен гәүдәсе сызлый, кул-аяклары бау белән тарттырылып үзе утырган урындыгына бәйләнгән. Нина төн буе кыймылдарга куркып, калтыранып чыккан. Кассирны иртән директор Нәгыймов коткарган. Игнатюк башка берни дә хәтерләми.

— Менә монда да кул куегыз, — дип, тикшерүче бүлмәдәгеләргә икенче бер кәгазь сузды. — Монда күргән, ишеткән монда калсын. Сүзең көмеш булса да, дәшмәвең алтын чак, иптәшләр, — диде ул, йомгак ясап.

Вакыйга булган урынны җентекләп тикшергәндә дә, Игнатюкны тыңлаганда да, беркетмә язганда да Камалиевның башында буталчык җеп бәйләмнәре кебек төрледән-төрле юрамалар, тикшерү юнәлешләре барлыкка килә торды. Алар берсеннән-берсе дөрес, берсеннән-берсе җитди сыман иде. Әмма җеп бәйләмнәренең кайсына тотынырга соң? Кайсыннан сүтә башларга?

Трофимов Чаллы шәһәренең эчке эшләр бүлегендә берүзенә бер бүлмә биләп алган. Иомыкый дип юкка гына көләләр майордан. Камалиев килеп кергәндә, ул яшь кенә бер сержант белән гәпләшеп утыра иде. Сүзләре үтә җитди нәрсә хакында булгандыр күрәсең, тикшерүче кергәч тә Трофимов башланган әңгәмәне бүлдермәде, сержантны тиз генә чыгарып җибәрмәде.

Камалиев, аларга комачауламаска тырышып, шунда торган урындыкларның берсенә килеп утырды.

— Вилдан Галиевич, без хәзер тәмамлыйбыз.

Сержант чыгып киткәч Трофимов, урыныннан кузгалмыйча гына, тикшерүчегә эндәште:

— Я, кайларда булдың?.. Яңалыклар юкмы?..

— Бар шул, Иван Иванович. Шулар хакында бергәләп уйлашыйк дип килдем әле. — Тикшерүче пиджагын, галстугын салып урындык артына элде, изүен чишеп җибәрде.

— Бүлмәнең бөркүен биргәннәр үзеңә.

— Эшләргә урын булгач, ярый инде, — дип, майор кул гына селтәде. Камалиевның бөтенләй башка нәрсә турында сөйләргә җыенуын бик яхшы белеп тора ул.

— Яңалыклар юк түгел, Иван Иванович.

Тын бүлмәдә ярты сәгать буе Камалиев тавышы гына ишетелеп торды...

— Ялгышмыйсың, Вилдан Галиевич, — диде Трофимов, үзенә хас кырыслык белән. Шунда ук өстәл тартмасыннан бер бит кәгазь алды да, серле карап, аны тикшерүчегә сузды. — Мә, укып кара әле. Сержант белән шул хакта сөйләшеп утыра идек.

Камалиев ул биргән кәгазьне бер тында укып чыкты...

«...Егерме дүртенче августта милиционер Даниленко белән бергә алтынчы маршрут буйлап барганда, егерме өч сәгать кырык биш минутта Яңа шәһәрдәге икмәк кибетенең тимер элмәге йозагы-ние белән суырып алынганлыгын күрдек. Ишеге ачык иде. Бу җинаятьне эшләүдә шик төшкән кешене, эчке эшләр бүлегенә алып килеп, дежурга тапшырдык. Ул кеше Матусов Геннадий Федорович булып чыкты. 1940 елда туган, торган җире, эшләгән урыны билгесез. Без аны кибет каршында, ышык урында исерек килеш йоклап яткан җиреннән алдык. Кесәсеннән тимер ачкыч, бер пар резин перчатка һәм ике данә йөзәр сумлык кәгазь акча табылды. Акча номерлары БЧ 6495043 һәм ЛК 9691635. Уятканда тибенде, каршылык күрсәтте. Кисәтүләргә игътибар итмәде. 25 август. Чаллы шәһәре. Милиция сержанты Илһам Заһретдинов».

— Нинди ачкыч ул, Иван Иванович? — Өлкән тикшерүче рапорт кәгазен өстәлгә куйды.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул менә. — Трофимов, ниһаять, үз серләрен ача башлады. — Касса урнашкан сәүдә конторының тышкы ишегенә ярый торган ачкыч булып чыкты ул. Менә монысы үткәрелгән эксперимент нәтиҗәләре тупланган беркетмә. — Майор, тикшерүчегә икенче бер кәгазьне тоттырып, гадәтенчә шаяртып алды. — Мәгәричен дә онытмассың дип уйлыйм.

— Мәгәрич дисең инде. Онытырсың синең белән! — диде Камалиев, уены-чыны бергә кушып. — Син сөйләгәннәр Иделгә кушылган инеш бит ул... Бәйләнеш бар монда, Иван Иванович. Резин перчатка, ачкыч, ике йөз сум акча. Тикшерергә кирәк моны, иптәш майор, һичшиксез, тикшерергә...

Шулай итеп, эзләнүдә төпле бер юнәлеш хасил булды.

Паспорт бүлегеннән китертелгән картотекада фамилияләре «М» хәрефенә башланган Чаллы кешеләре мең өч йөз туксан алты булса да,

алар арасында бер генә «Матусов» та юк иде. Димәк, шикле кеше Чаллыда пропискага керми генә яшәгән. Монда кайчан килгән ул? Кайдан һәм нинди максат белән?

Матусовны чакыртырга да, сорау-җавап беркетмәсе язарга да ашыкмады Камалиев. Нигәдер икеләнә иде. Тукта әле, ни өчен ул, тикшеручe буларак, Трофимов әйткән «инеш» буйларында йөрергә ризалашты? Беренче юнәлешне ташлап, икенчесенә ябышу дөрес булырмы? Трофимов юрамасын хуплап, үзе билгеләгән юлдан читкә тайпылмыймы соң ул болай? Ләкин Трофимовның да моңарчы тикшерелгән эшләрдә ялгышканы булмады бит. Киресенчә, тапкыр планнары шактый җитди җинаятьләрне ачарга ярдәм итте. Трофимов юрамасын да игътибарсыз калдырырга ярамый...

Камалиев тикшерү планына «Матусов!» дип язып куйды. «Бу эшне Соловьевка гына тапшырыргамы икән әллә?» — дип тә фәһемләгән иде дә, соңыннан үзе тикшерүне артыграк күрде. Бөтен эшне бер иләктән үткәрү кирәк иде.



## 7

Игнатюк тынычлана төште. Камалиевның игътибарлы карашын тоеп, үзе дә аңа текәлде. Мөлдерәп торган бу караштa: «Я, тикшеручe абый, сүзеңдә торасыңмы?» — дигән үтенүле сорау чагыла иде. Камалиев кассирны кызганып куйды. Урындыкта бөрешеп утырган кечкенә Нинаны көчле куллары белән аркасыннан сөясе, «борчылма, сеңелкәш!» дип юатасы килде аның. Әмма тикшерүче моны эшли алмый иде шул.

Камалиев, галстугын тарткалап, муенын кысып торган күлмәк якасын бушатты да Соловьевка таба борылды:

— Иптәш капитан, машина әзерме?

— Әзер. Кая барабыз?

— Больницага, Игнатюк белән.

Нина әйткәнне дә көтмәде, ухылдап, урындыктан торды һәм вак-вак атлап ишеккә таба юнәлде. Камалиев белән Соловьев аңа ияределәр. Капитан эчтән бау кисәкләре төртеп торган газета төргәген кулына алды. «Менә бу ярдәмче ичмасам, — дип сөенде Камалиев, үзе белән янәшә атлаган Зәйнуллага карап куйды. — Мондый ярдәмчеләр барында хур булмассың...»

Камалиев бу өлгер офицерны Казан университеты профессоры Фәтхуллин бүлмәсендә очратуын хәтерләде. «Бездә читтән торып укучы аспирант», — дип таныштырган иде галим аларны.

Чаллы урамнары кояш нурларында коена. Аның якты шәүләсе кала буйлап йөзә. Дулкыннар өстендә алтын балыклар чума-калка уйнап тора шикелле.

Игнатюк алгы рәттә шофер белән янәшә утырган. Йокысыз үткән фаҗигале төннән соң ул исән калганына сөенеп бетә алмыйдыр, мөгаен.

Камалиев әледән-әле күршесенә карап ала. Соловьевның йөзе кырыс, җитди. «Ниләр уйлый икән бу егет?»

«Волга» больница ихатасына борылды да «Судебно-медицинская экспертиза» дигән язу эленгән ишек каршына килеп туктады. Игнатюк тикшерүчегә борылып карады. Ләкин ул тел тибрәтеп сүз әйтмәде.

Капитан Соловьевның хәстәрле булуы монда да үзен сиздерде. Экспертларның икесе дә урыннарында иде.

— Иптәшләр, таныш булыгыз, бу — Нина Игнатюк, — дип, Камалиев рәсми кәгазьне өлкән яшьләрдәге медицина белгеченә сузды. — Безнең карарда суд-медицина экспертизасы үткәрү зарурлыгы, моның сәбәпләре язылган. Сезнең төпле сүзегез кирәк.

— Нина, булган хәлне докторларга үзегез сөйләп бирерсез инде. — Камалиевның тавышы йомшак, ягымлы иде.

Игнатюк, турая төшеп, тикшерүчегә карады. Аның күзләрендә: «Тагын ни телисез инде сез миннән?» — дигән сорау күрде Камалиев.

— Сезгә чыгып торырга кирәк булыр, — диде өлкән эксперт, ирләргә карап. — Кимендә утыз-кырык минутка. — Һәм сәгатенә күз төшереп алды.

— Монда әлеге вакыйгага бәйле дәлилләр, — диде милиция капитаны, чыгар алдыннан төргәкне экспертка тоттырып. — Бау, чүпрәк ише әйберләр.

Соловьев белән Камалиев әйләнеп кергәндә, яшь эксперт кулын юа, ә өлкәне өстәл артында нидер язып утыра иде. Игнатюкны бүлмәдәге бердәнбер кәнәфигә утыртканнар. Тикшерүчеләр кергәч тә, аны: «Коридорда утырып торыгыз әле», — дип чыгарып җибәрделәр. Кыз ишекне ябуга:

— Игнатюкның тәненә берәр төрле зарар килгәнме? — дип сорады Вилдан Камалиев.

— Башында, йөзендә, муены белән күкрәгендә, кул-аякларында шеш. Тәненә кан сауган, кан тамырларына зыян тигән. Уң яктагы ике кабыргасы чатнаган булса кирәк. Тәгаен әйтү өчен рентгенда тикшерәсе бар.

— Келәп турында нәрсә әйтә аласыз?

— Келәп дигәнегез бер сатин чүпрәктән һәм ефәк кулъяулыктан гыйбарәт. Кеше авызына ничек сыйгандыр?! Ничек тончыгып үлмәгән диген.

Соловьев тикшерүчегә карады. Камалиев ризалык белдереп баш какты.

— Игнатюк больницага салуны үтенә, — диде Камалиев. — Сезнеңчә, дәвалау кирәкме?

— Кирәк, һичшиксез кирәк, — диде өлкән эксперт. — Без ул турыда үзебезнең нәтиҗәдә дәлилләп яздык.

Камалиев, ялт борылып, Соловьевка карады:

— Зәйнулла, ишеттеңме?

— Ишеттем, Вилдан Галиевич.

— Ишетсәң, яхшы. Урнаштыр...

Тикшерүченең дулкынланганы сизелеп тора иде. Экспертиза нәтиҗәләре Нина Игнатюк сөйләгәннәрне раслады бит.

Тагын бер йомгак сорау. Аны сүтми торып, тикшерүне гадел алып бару мөмкин түгел. Игнатюк җинаять турында дөрес сөйләгән, димәк, ул — зыян күрүче.

Тикшерүченең уйлары яңадан касса баскан юлбасарларга әйләнеп кайтты.

— Планыбызда бу юраманы иң мөһим юнәлеш итеп саныйк, — диде Камалиев, нәтиҗә ясап. — Җинаятьнең шимбәгә каршы төндә эшләнүе үзе үк уйландырырлык нәрсә.

— Җинаятьчеләрнең исәбе ачыкланачак түгелме соң? — дип кушылды Соловьев. — Янәсе, шимбә, якшәмбе — ял көннәре, кеше өйдә утырмый. Аларча итеп әйтсәк, тикшерү тоткарланачак.

## 8

Берәр хәвефле хәл чыкса, гадәттә, милиция җинаятьченең эзенә басканчы бик күпләрне борчырга мәҗбүр була. Чаллы милициясе, киресенчә, тынып калгандай тоелды. Ләкин бу читтән караганда гына шулай тоелырга мөмкин. Моны, барыннан да элек, аэропорт, елга порты, автовокзал хезмәткәрләре сизде. Алай гына да түгел, хәтта зур төзелеш, завод һәм төрле контора-идарә җитәкчеләре дә эшнең нидә икәнлеген тө-

шенә иде. Эзәрләүдән котылу өчен Чаллыда мөмкинлекләр җитәрлек. Җинаять эшләгән кеше моны бик яхшы белә әлбәттә. Һәм качу юлларының кайсыннан кайчан китәргә икәнен үзе хәл итә. Тик шунысы бар: кырыкмаса-кырык төрле мөмкинлекнең берсен генә куллана җинаятьче.

Эзәрләүченең хәле киресенчә: җинаятьченең качу ихтималы булган барлык юлларны исәпкә алырга, шуларның һәркайсын зур игътибар белән күзәтергә, тикшереп чыгарга тиеш ул.

Бу очракта да эзәрләүнең шулай башланганын Камалиев шәһәр прокуроры Әхмәтов кабинетында үткәрелгән киңәшмәдә ачыклады. Чаллы прокуроры белән ул инде дүрт елдан бирле таныш иде.

Прокурорның эш бүлмәсен дә ул яхшы белә. Кабинет түрендә каракучкыл төстәге, ялтырап торган ике өстәл. Кыскарагы аркылы куелган. Аның янында йомшак урындык. Өстәлнең озыны бүлмә буйлап сузылган. Кергәч тә сул якта шундый ук ялтыравыклы шифоньер. Егермеләп урындык тезелеп тора. Бер почмакта эш кәгазьләре саклана торган сейф. Бүлмә җыйнак, эшләп утыру өчен җайлы иде.

Камалиев кергәч, прокурор аның каршына чыкты, каты итеп кулын кысты.

Шимбә көннәрендә беразга гына килеп, яңалыкларны тыңлыйлар да, кирәк булса, тиз генә чарасын күреп, кире өйгә кайталар иде. Әмма бу шимбә прокуратура хезмәткәрләре өчен борчулы булды. Менә хәзер, кулдагы мәгълүматларны барлап, Казан тикшерүчеләре белән бергә уйлашырга кирәк. Чакырылган кешеләр җыйналган.

Чаллыда элек моңа охшаган җинаятьнең булганы бармы?

Беренче нәүбәттә шундый сорау куелды. Аңа җавап бирү төп юнәлешне — җинаятьчеләрне кайдан, нинди кешеләр арасыннан эзләүне билгеләячәк. Кассага һөҗүм ясаучылар кемнәр — элек җинаять эшләгән, хөкемгә тартылган кешеләр түгелме? Һәр җинаятьченең күп вакытта үзе дә белми, сизми торган үз ысулы була бит. Җинаятьчене шул билге буенча эзләүне юристлар «язу рәвеше буенча табу» дип йөртәләр.

— Моңа охшаш җинаятьнең Чаллыда исәпкә алынганы юк, — диде Соловьев, кырт кисеп.

Камалиев сорашуын дәвам итте:

— Элегрәк шундый җинаять башка шәһәрдә эшләнмәгәнме, төзәтү колониясеннән Чаллыга кайткан кеше юкмы?

— Мондый хәлнең булуы мөмкин, — диде капитан. — Әмма исәпкә алынган кешеләр арасында андый җинаять өчен утырып чыкканнар юк.

— Алайса, шундыйларның паспорт өстәлендә теркәлмичә яшәүчеләр арасында булуы мөмкин. Шулай бит? — Камалиевның бу соравы тикшерүдә катнашучыларны уйланырга мәҗбүр итте.

— Әйе, мөмкин, — диде Соловьев. — Без дә бу юраманы күздә тотабыз. Халык дружиналарына, йорт идарәләре хезмәткәрләренә, милициянең бүлек инспекторларына махсус күрсәтмә — боерык бирелде.

Соловьевның докладын тыңлый-тыңлый, Камалиев сөйләгәннәрне хәтер дәфтәренә яза барды. Кассага һөҗүмне шундый «җинаять белгече» ясаган булса, тикшерүне тиз генә төгәлләрмен дип уйлама да. Үзенең «язу рәвеше» булган «белгечнең» тәҗрибәсе дә, тәвәккәллеге дә, кайвакыт белеме дә тикшерүченекеннән ким булмый. Алар, эзләрен бутыйлар да, берни булмагандай, яшеренеп озак вакыт тыныч кына яшәп яталар... Тикшерелә торган бу җинаятьнең очраклы булуы да ихтимал. Җинаятьче бәлки бик үк тәҗрибәле дә түгелдер. Әмма бу очракта инде тикшерү мәйданы киңәя төшә, тикшерү юнәлешләре арта.

— Чаллыга көн саен ничәмә-ничә мең кеше килеп китә, — диде Камалиев. — Шулар арасында җинаятьчеләр юк дип тә раслый алмыйбыз бит.

— Әлбәттә, моны инкарь итеп булмый, — диде Соловьев. — Шуңа күрә бөтен транспорт үзәкләренә — елга портына, автовокзалга тиеш-

ле күрсәтмәләр бирелде. Җинаятьчеләрне эзәрлекләү бүлегеннән дежурлар билгеләнде. Халык дружиналары да хәлне белә. Андыйларның барысы да аякка бастырылды.

— Җинаятьчеләр Бөгелмә аша качса? — дип сорады Әхмәтов.

— Анда махсус опергруппа җибәрелде, күрше шәһәрләргә дә хәбәр ителде.

— Әгәр җинаять кылучылар кич белән үк ычкынган булса? — Прокурор шул сорау белән Соловьевка карады.

— Андый очракта, билгеле инде, эзәрләү кыенлаша. Чаллыга көн саен җиде-сигез меңнән артык кеше килеп китеп тора.

Әңгәмәгә Камалиев кушылды.

— Кача торган кеше өчен тизлек мәслихәт! Тизлек! Тикшерү җинаять эшләнгән җирдән башлана. Угрылык юлына баскан кеше моны яхшы белә. Димәк, бу урыннан тизрәк качу, акчаны тизрәк озату яисә яшерү — җинаятьче өчен ин мөһиме шул. Тизлек. Минемчә, каракның юлы, һичшиксез, аэропорт аша узар...

— Дөрес, — диде моңарчы йокымсырап утырган Трофимов, тикшерүченең фараз кылуын хуплап. — Аэропортта тикшерүне капитан Соловьев белән без үткәрдек.— Ул үз кулындагы кәгазь төргәген өстәлгә куйды. — Анда эш җиңелрәк бара, әлбәттә. Билетка да, аның корешогына да пассажирның фамилиясе языла. Аннары кассаны басу вакыты да мәгълүм. — Трофимов дөрес сөйлимме дигәндәй, Камалиевка карап куйды. — Аэропортка ярты сәгатьлек юл. Кичке тугыздан соң, иртән тикшерүче килеп житкәнче, Бигештән төрле маршрутка унжиде самолет очкан. Барлыгы биш йөз егерме кеше. Аларның исемлеге бар, — дип, Трофимов кәгазь төргәгенә күрсәтте.

— Исемлеккә Түбән Кама һәм башка күрше район кешеләре дә кергәнен онытырга ярамый, — диде Камалиев.

— Монысы да иска алынды, Вилдан Галиевич. — Соловьев сумкасыннан икенче төргәк чыгарып, анысын да өстәлгә куйды. — Бу исемлектә кичә кич, бүген иртә белән Чаллыдан командировкага киткән кешеләр. Барлыгы ике йөз сиксәннән артыграк. Бүген эшкә чыкмаганнарны да барладык. Андыйлар йөздән арта...

Камалиев, урыныннан торып, Соловьев янына килде:

— Тикшерергә өлгердегезме соң?

— Күбесенең квартирында дружиначылар, милиция хезмәткәрләре булды инде.

— Эш өчен әһәмиятле берәр нәрсә бармы?

— Бар, әлбәттә. Өеннән Казанга «Метеор» белән барырга дип ниятләп киткәннәрнең унжидесе самолетта очкан кешеләр исемлегендә. Самолетта очарга уйлаганнарның егерме икесе билет алучылар исемлегендә юк. Өйдә дә юк, аэропортта да.

— Юлга чыккан кешенең транспорт төрен, үз җаена карап, үзгәртүе дә мөмкин, әлбәттә, — диде Камалиев. — Ләкин шушындый житди тикшерү барганда, мондый үзгәрешләрнең ни өчен килеп чыгуын да, сез санап үткән юлчыларны да ачыкларга туры килә. Башка чара юк. Ашыгыч тикшерү — хәзергә төп бурыч. Аны хәл иткәч, арырак китәрбез...

— Безнең инспекторлар бу эшкә керeште инде, — дип белдерде Соловьев. — Елга портына барырга җыенган ике кеше самолетта очкан, дүртесе, киресенчә, самолетка җыенып «Метеор» белән киткән.

Камалиев беравык уйланып торды: «Игътибарга лаеклы фикер бит бу. Транспорт төрен алмаштырырга нәрсә мәҗбүр иткән аларны!..» Ул янә Соловьевка эндәште:

— Син, Зәйнулла, иптәш Трофимов белән бергәләп, исемлекләрне яңадан карап чык әле. Үзең тотып алган факт бик әһәмиятле, минемчә.

— Анысы шулай да бит... — Трофимов, уянып киткәндәй, сүзгә кушылып алды. — Өч йөз сиксән ике кешенең барысыннан да шикләнеп булмый ләбаса.

— Әлбәттә, — диде Камалиев. Ләкин тикшерүдә «җиде үлчә, бер кис!» дигән кагыйдәне барыгыз да яхшы беләсез. Пассажирларны беренче иләктән хәзер үк үткәреп карыйк. Кайчандыр хөкемгә тартылганнар. Яңа шәһәр поселогында торучылар, сәүдә конторасы белән бәйләнешле булган кешеләрне генә тикшерсәк җитәрме? Кем ничек уйлый?

— Минемчә, бу иләккә контора урнашкан дүртенче йортта торучыларны һәм аларның туган-тумачаларын да салырга кирәк, — дип тәкъдим итте капитан Соловьев. — Сәбәбен үзегез дә аңлыйсыз.

Камалиев белән Әхмәтов аның белән килешүләрен белдерделәр.

Киңәшмә шактый озакка сузылды. Аның караве, тикшерү эшенең юнәлешләре ачыграк шәйләнә башлады.

Зәйнулла Соловьев белән майор Трофимов, бүлмәдән дә чыкмыйча, исемлекләр тикшерергә керештеләр. Камалиев та алар яныннан китмәде.

Исемлекләрнең өчесен дә карап чыкканнан соң, капитан бер мәлне кәгазьләрдән аерылып, Камалиевка эндәште:

— Карагыз әле, Вилдан Галиевич, бер фамилия уйландыра бит әле. Эшкә чыкмаучылар исемлегендә дә бар. Үзе Яңа шәһәр поселогында тора, заманында сәүдә тармагында да эшләп киткән.

Өлкән тикшерүче җәһәт кенә Зәйнулла янына килеп басты.

— Кем ул?

— Зайцев. Степан Григорьевич.

— Тагын шундыйлар бармы?

— Кайберәүләр ике исемлектә дә очрый, ә өчтә — хәзергә бу берүзе.

Очраклы хәлме бу, әллә юкмы? Уйлаша торгач, тикшерүче һәм милиция офицерлары билгеле бер карарга килеп, төрлесе төрле якка юл тоттылар.

## 9

Матусовны өлкән тикшерүче янына алып килделәр.

Кайберәүләр тимер рәшәткәле, кеп-кечкенә тәрәзәле камерада аз гына вакыт утырса да, сыгылып төшә. Әмма Матусов, күрәсең, андыйлардан түгел. Үзе тәбәнәк кенә буйлы. Күптән инде тарак-кайчы күрмәгән, чуалган чәчләре башын иләмсез зур итеп күрсәтә. Аның лавсан пинжәге җәйнең бар тузанын үзенә җыйган диярсең, төсенең яшел икәнен чак-чак кына аерырлык. Ишектән керүгә үк, Матусов, сержантны артта калдырып, житез генә өстәлгә якынлашты һәм, күптәнге танышын очраткандай, уң кулын Камалиевка сузды. Әйтерсең, боларның берсе — җинаятьче, икенчесе — тикшерүче түгел, гүя озак еллар буе бер-берсен күрергә зарыккан туганнар гына.

Камалиев үзенә таба сузылган кулны алмады. Көлемсерәп кенә Матусовка карады да:

— Утырыгыз, — диде.

Тегесе өстәл янындагы урындыкны аягы белән генә тибәреп, тикшерүчегә якынрак куйды да, лып итеп килеп утырды. Калын аскы ирене авыраеп салынып төште.

— Сезне нәрсә кызыксындыра, гражданин начальник? Матусов мин. Исемем Геннадий, әтием Федор булган. Сугыш башланганда миңа төптөгәл бер яшь булган икән, әнкәй әйткән иде моны, үзем хәтерләмим, билгеле. Туган җирем — башкала! — Матусов баш бармагын тыр-

пайтып күрсәтте. — Во, гражданин начальник! Мәскәүнеке мин. Өйләнергә әле өлгермәдем, бала-чагам юк.

— Мин сезгә начальник түгел, Геннадий Федорович, — диде Камалиев, Матусовны сүзеннән бүлдереп. — Таныш булыйк: прокуратура тикшерүчесе Камалиев Вилдан Галиевич.

Ләкин Матусовка моның берниндн тәэсире булмады. Барыбер, сүз саен «начальник»ны тәкърарлады.

— Гражданин начальник, безнеңчә ничек була инде ул, исемегезне әйтәм.

Тикшерүче әүвәлгечә сабырлык белән аңлатып бирүне мәслихәт күрде.

— Безнеңчә сум, сезнеңчә рубль була, тиен — копейка, — ул җавабын Матусовча шаяртып башлады һәм һәр сүзе истә калырлык итеп, басым ясап әйтте. — Исемем сезнеңчә дә Вилдан, этиемнеке Гали була. Кешенең исем-шәрифләре тәрҗемә ителми, ул акча түгел. Аның бәһасе юк, сатып алып та булмый.

— Гафу итегез, гражданин начальник, — дип, кабат кул бирмәкче булып, Матусов урыныннан купты. — Гражданин начальник, зинһар, мине дөрес аңлагыз, гаепләштән булмасын. Үземнең исемем генә түгел, җаным-тәнем дә сатылган шул инде. И-и, ул башкалада үткән бала чаклар... — Матусов, хисләргә бирелеп, ихлас күңелдән офтанып куйды.

Сизелеп тора, Матусов алда торган җитди сөйләшүләрдән, төп мәсьәләдән тайпылмакчы, димәк, дилбегәне кулга алырга вакыт җиткән.

— Кайда эшлисез, башкалада туган егет?

Тикшерүченең ирониясен сизде Матусов, әмма сер бирмәде, аңламаганга салышты.

— Гражданин начальник, мин Чаллыга эш эзләп килдем.

— Урнаштыгызмы соң?

Сорауны тыңлап бетерер-бетермәс борын Матусов шартлатып җавабын кайтара. Атна буе репетиция үткәргән диярсең.

— Кая ул, гражданин начальник! Якын да китермиләр: хөкем ителгәнсез, имеш.

— Нинди акчага яшисез соң?

— Кая ул акча, гражданин начальник! Кесәләрдә җил уйный минем! — дип, азрак уйланып торды да, Матусов элеккечә җиңел генә дәвам итте. — Вак-төяк эш майтарам шунда.

— Мәсәлән?

— Соңгы атнаны икмәк кибетендә эшләп үткәрдем.

— Нинди эштә?

— «Ух та һоп!» инде безнең хезмәт, гражданин начальник... Төяүбушату, ишегалды себерү. Лафа, кыскасы! — дип, Матусов кулын селтәп куйды.

— Ничек түләделәр соң?

— Эш — миннән, ашату-эчерү — кибетчеләрдән.

— Шул гынамы? — дип сорады Камалиев, гаҗәпләнеп.

— Ак башлыны җәлләмәделәр, гражданин начальник.

— Аның бер шешәсе дә дүрт сум унике тиен бит! — Матусов телен шартлатып куйды.

— Сәүдә оешмасында ничә мәртәбә булдыгыз?

— Миңа анда нәрсә калган?

— Шулай да контораның кайда икәнен беләсезме?

— Тукта, тукта, гражданин... — Матусов нәрсәдер хәтерләргә тырышты. — Бер мәртәбә генә, үтеп барышлый. Өчәү уздык: кибет ди-

ректоры, мин, шофер. Ул чакта салмыш идем, әмма контораның Яңа шәһәрдә, бер торак йортта икәне хәтеремдә.

Бу тикшерүче өчен бик мөһим яңалык иде.

— Анда кемнәрне беләсез?

— Кызганыч, беркемне дә белмим, гражданин начальник, иртәрәк утырттылар бит. — Матусов шаярта ук башлады.

— Нина Игнатюкны, мәсәлән?

— Чибәр мени, гражданин начальник? Кызганыч, белми калдым шул.

— Паспортыгызда билге-мазар юк, Чаллыга килгәнче кайда тордыгыз?

— Ай чамасы Мәскәүдә булдым.

— Ни өчен паспортыгыз Мәскәүдә теркәлмәгән?

— И, гражданин начальник, анда минем кебекләрне язмыйлар шул.

— Нишләп?

— Сездән яшерен-батырын түгел, гражданин начальник. Бер тотынгач, әйтсәм дә, әйтмәсәм дә, барыбер энәсеннән җебенә кадәр беләчәксез. Бүген булмаса, иртәгә бөтенесен әйләндереп чыгарачаксыз. Нигә ул артык эш сезнең кебек ягымлы начальникка? Минем шикелле дүрт мәртәбә утырып чыкканнарга башкалада прописка да, эш тә юк.

— Хөкемгә нәрсә өчен тарттылар?

— Яшь вакытта мин, гражданин начальник, бик яхшы кесә карагы идем. Ни ултара, ни пултара түгел, оста, танылган карак!

— Юкәдә икән чикләвек. Сезнеңчә, кесә чистарту кәсеп кенә түгел, профессия дә инде алайса?

— Ломброзо турында ишеткәнегез бармы?.. Бар, кәнишне. Ул әйткән: җинаятьченең бар бозыклыгы тумыштан килә, дигән.

— Караклыкны сез теоретик яктан да исбатлап, акламакчы буласыз, күрәм. Барып чыкмас бит, Матусов.

— Юк, гражданин начальник, мин үзем дә нәкъ шуны әйтмәкче булам. Юләр сата ул Ломброзо дигәннәре. Әйтик, миндә тумыштан нинди бозыклык булырга мөмкин? Әби-бабаларны, әти-әниләрне алыйк. Әни гомер буе һаман бер урында, — аяк киемнәре фабрикасында эшли. Әтине сугышта үлгән диләр.

— Ничек итеп мондый хәвефле сукмакка бастыгыз соң?

— Бу бик катлаулы мәсьәлә, гражданин начальник! — дип, Матусов, терсәкләре белән өстәлгә таянып, уйга калды. — Әни эштә, мин бала чагымнан ук бер ялгызым... Сөйләп кенә бетерерлек түгел.

— Сез миңа Ломброзоны телгә алдыгыз, мин сезгә бик борынгы Мисыр язмаларында ташка чокып калдырылган бер киңәшне әйтмәкче булам. «Корабы баткан кеше турында әкият» дип атала ул язма...

«Корабы баткан кеше» дигәнне Матусов үзенчә аңлады. Каптың, янәсе! Колакларын торгызды, тикшерүченең авызына керердәй булып, аңа табарак иелде.

— Борынгылар болай дигән, Матусов: «Тиешенчә җавап бир, тотлыкма, чөнки котылуың — телеңдә». Төшенәсезме?

Матусов, җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды:

— Аңлашыла, гражданин начальник. Мондыена гына баш житә, аллага шөкер...

Камалиев дәфтәренә нәрсәдер язып куйды.

— Кызык... Утыз өчне тутыргач, профессия алыштырдыгызмы?

Матусов, сары тешләрен күрсәтеп, елмайган булды. Ул үзенең элекке кыяфәтенә керә башлады.

— Ачыклавыгызны үтенәм, гражданин начальник. Соравыгыз томанлы.

— Ярар, алайса. Сезне милиция патруле тоттымы?

— Тоткан, мин исерек идем.

— Егерме дүртенче августта, төнге унбер сәгать кырык биш минуттамы?

Бу сорауга да Матусов артык игътибар итмәде:

— Шулай да булсын, ди.

Тикшерүче торак йортлардагы гади стандарт йозак ачкычын тартмадан алып өстәлгә куйды.

— Кесәгездә шушы ачкыч идеме? Кемнеке ул?

— Беренче күрүем.

Өстәлгә ачкыч белән янәшә бер пар резин перчатка да куелды.

— Мин бер нәрсә дә аңламыйм.

— Ике йөз сум акча да таптылармы?

Бу сорау Матусовка бөтенләй сәер тоелды:

— Нәрсә, нәрсә дисез?

— Кызык бу кеше дигәнең. Йөзәр сумлык ике кәгазь акча, дим.

Тикшерүченең уң кулындагы өр-яңа йөзәрлекләр кыштырдап тора иде. Җинаятьченең күзләре ялтырап алды да сүнде.

— Мондый акчаларны төшемдә дә күрмим хәзер, гражданин следователь. Исергәнмен, кибетчеләр юмартланып киткән, артыграк сыйлаганнар. Белмим, кайсы юмарты шулай мул итеп бирде икән акчаны?

— Законны беләсезме? — дип сорады тикшерүче.

— Закон!.. Нинди закон?

Тикшерүче, иелеп, портфеленнән җинаять кодексын алды.

— Менә шушы китапта язылган законны әйтәм. Исерек хәлдә җинаять кылган кеше хөкем җаваплылыгыннан азат ителми, диелгән. Уникенче статья. Миңа ышанмасагыз, үзегез укыгыз, — дип, Камалиев кодексны Матусовка сузды. — Сигезенче биттә.

— Кирәк түгел! Сезгә ышанам. Прокурорларга ихтирамым зур минем. Сезгә ышанам да... — Матусов нәрсәнедер әйтеп бетермәде.

— Кемгә ышанмыйсыз соң?

— Тентү беркетмәсендә язылганнарга. Исерек килеш кибет янында табулары хак та булсын ди. Каршылык күрсәтүең дә, тибенүләрнең дә булуы ихтимал. Исереклек! Ләкин, гражданин начальник, минем кесәдә андый акчаның да, перчатканың да булганы юк. Алар минеке түгел. — Матусовның күңелен шөбһә корты кимерә башлады. Камалиев җинаятьчедәге үзгәрешне шунда ук сизеп алды.

— Ишек элмәген суырып кибет басу кем эше?

— Менә шушы урында тотып атсалар да, берни әйтә алмыйм.

— Белмәгәнегезне милиционерлар, пүнәтәйләр әйтер. Күзгә-күз очраштырам үзегезне.

Милиционерлар да, тентүдә катнашкан пүнәтәйләр дә, шаһит буларак, Матусов белән күзгә-күз очраштырып сорау алганда бер үк сүзне кабатладылар. Матусовның каршы торырлыгы калмады. Өстендәге пинжәгенең сул як кесәсеннән торак йортларның стандарт ачкычы табылган. Бер пар резин перчатка белән ике йөз сум акча чыккан.

— Кибет ишеген дә бергә карадык. Лом белән каерылган иде, — диде пүнәтәйләр беравыздан.

Милиция сержанты каерылган ишекне фотога төшереп алган. Рәсеме тикшерүче кулында. Камалиев җинаятьчегә анысын да күрсәтте.

— Я, Матусов, ишеттегезме инде?

— Ишеттем, гражданин начальник. Әмма ни әйтергә дә белмим. Хет әллә нәрсә эшләтегез, ышанмыйм мин ул милиция кешеләренә. Ышанмыйм, аңлыйсызмы?! — Матусов ярсый ук башлады. — Алар үзләре оештырганнар моны. Аңлыйсызмы, үзләре оештырганнар!.. Соң, үзегез уйлап карагыз, гражданин начальник. Бик шома килеп чыга бит бу. Милиционерлар дежурда, димәк, һәр җинаять өчен алар җаваплы. Кинәт алларында таланган кибет күрәләр. Сорау туа: милиция кайда

булган, нәрсә караган? Моның өчен дежурдагы патрульләр җавап бирергә тиеш. Ә җавап бирү җиңел булмаячак. Тирә-якка карасалар, алларында гына — һушсыз яткан исерек. Яшь милиционер «бәракалла!» ди, ходайга меӊ рәхмәтләр укып, аны милициягә сөйри. Җинаятьче кибеттә ташлап калдырган перчатканы, ачкычны, кибеттәге ике йөзлекне исерек кесәсенә салу — чүп тә түгел. Тик моны аңларга гына кирәк, гражданин начальник.

— Аңлашып утырабыз түгелме соң, Матусов? — диде өлкән тикшерүче. — Тик сезгә әкиятче буласы калган. Фантазиягез тискәре якка шәп суктыра. Бер нәрсәне генә искә алып бетермисез: сез әйткән ул кибеттә товар һәм акча җитмәүчелеге сигез сум да унҗиде тиенлек кенә бит. Ә сезнең кесәдән ике йөз сум чыккан.

Моны ишеткәч, гаепләнүче көрсенеп куйды.

## 10

Камалиев җиңел машинада Яңа шәһәр буйлап бара. Күңелен исәпсез-сансыз сораулар бимазалый. Кем ул Зайцев? Аның өч исемлектә дә булуы очраклымы, әллә җинаятьнең очы барып тоташа торган кешеме ул? Зайцев уникенче йортта тора, ә таланган касса — шул ук урамдагы дүртенче йортта. Халкы ике йөз меңнән арткан шәһәрдә мондый гына туры килүләр бер дә гаҗәп түгел. Зайцев шимбә көнне эшкә чыкмаган. Шулай да булсын ди. Исемлектә андый кешеләр йөздән артык. «Юк, Вилдан, фикерең нигезле түгел, дәлилләнмәгән», — диде ул үз-үзенә. Ләкин әлеге шикне тикшерү уеннан кайтмады. Нинди генә булып тоелса да, тикшерү дәверендә туган бер фикерне дә ярты юлда, ачыкламыйча калдырырга ярамый. Шулай итмәсәң, башка тикшерү юнәлешенең дөреслеген каян беләсең дә, шик астындагы кешеләрнең гаепле яисә гаепсез икәнен ничек ачыклыйсың? Әмма моның Зайцев яши торган уникенче йортта гына ачылуы ихтимал.

Уникенче йорт Яңа шәһәрдәге башка торак биналардан берни белән дә аерылып тормый. Кирпечтән салынган, биш катлы. Шундый ук чәчәкле-гөлле балконнар. Йорт янында гына балалар мәйданчыгы.

Машинадан төшкәнче үк, Соловьев өченче каттагы челтәр пәрдә эленгән тәрәзәгә күрсәтте:

— Зайцев квартирасы, Вилдан Галиевич.

Тикшерүче, бүлмә эчендәге нәрсәләрне дә күрергә теләгәндәй, тәрәзәгә бик дикъкать белән карады. Шоферга, бу йорт яныннан үтеп, почмакка борылгач кына туктарга кушты.

Кыска җиңле җәйге күлмәк, бик пөхтә итеп үтүкләнгән соры чалбар кигән капитан Соловьев, җил-җил атлап, алдан китте.

— Башта дворникка керәбез.

Ишекне алтмыш-алтмыш бишләр тирәсендәге карт ачты:

— Әйдүк, Зәйнулла туган!..

Соловьевның монда үз кеше булуы әллә каян күренеп тора. Карт белән ул бик иркен сөйләшә башлады.

— Без утырып торган арада Тәхәвиев, Зайцев, Спиридоновларга кереп белешегез әле: өйдәме хуҗалар, юкмы? Булмасалар, нинди җил кая алып китте икән үзләрен? Берәр йомыш табыгыз шунда. Милиция кызыксынганын белмәсеннәр.

— Аңлашыла. Булдырабыз аны! — Картның тавышы көр иде. — Алардан коридор җыештырган өчен акча аласы бар иде, менә бит, сәбәбе чыгып тора.

Камалиев дворник карт артыннан карап калды. Карт таныш булса да, Соловьев бөтенләй үк ачылып бетмәде. Милициянең чынлыкта кем

белән кызыксынуын ул да белмәячәк. Өч кешене сораштты бит капитан. Зайцев фамилиясен башкалар арасына кертте дә, пөхтә генә итеп «төреп» куйды.

Дворник озак көттермәде, әйләнеп тә керде.

— Тәхәвиев туган якларына киткән, — диде карт. — Минзәлә районына. Ә Зайцевлар бүлмәсе бикле. Спиридонов балыкта икән.

— Җәмәгатьләре өйдәме соң? — дип сорады Соловьев.

— Спиридоновның хатыны өйдә, Тәхәвиевләр парлашып киткән, Зайцева мәктәптә. Укытучы ул.

Зәйнулланы бу мәгълүматлар гына канәгатьләндермәде, билгеле. Ул һаман төпченүендә булды.

— Бала-чагалары кайда икән, белмисезме?

— Белмәскә! — диде карт. — Әнә, — дворник тәрәзәгә килеп, урамга күрсәтте. — Зайцевларның малае туп тибә. Башкаларныкы күренми.

Камалиев шунда гына Соловьевның ниятен аңлады. Зәйнулла аңа мәгънәле караш ташлады: «Күрдеңме, эзләгәнне табабыз бит, болай булгач», — дигән ишарә иде бу.

— И шайтан алгыры, бар иде безнең дә туп типкән чаклар! — дип, капитан тәрәзә янына килде, малайларның уйнавын сокланып та, кызыгып та күзәтә башлады.

Карт аңа мәйданчыкта җилдәй җилдергән чандыр гына малайны күрсәтте.

— Кара чәчлесе түгел, Зайцевларныкы — сары чәчле, исеме, атасыныкы шикелле, Степан.

— Ярый, Николай Иванович, сау булыгыз. Рәхмәт! — Капитан дворник картка кулын сузды.

Ишегалдына чыгу белән, Соловьевны алмаштырып куйдылармыни— ул гамьсез бер егет кыяфәтенә кереп алды. Ул, сызгыра-сызгыра, малайларга таба атлады. Яннарына житәрәк, туктап, сары чәчлесен читкәрәк чакырып алды да:

— Зайцевларның кайда торганын беләсеңме? — дип сорады.

Чая булырга охшый малай — чатнатып җавап бирде:

— Без ул!

«Сөйләшә белә капитан, — дип уйлады Камалиев. — Карт белән сөйләшкәндә дә аны-моны сиздермәде, малай янында да гаҗәп оста сайрый».

— Әтиең өйдәме? — дип сорады Зәйнулла, белмәмешкә салышып.

— Юк, кичә Казанга очтылар.

— Нигә миңа әйтмәде икән? Кем белән очты?

— Апаның аягы авырта, операция ясатырга кирәк, диде.

— Кай вакыттарак китте соң әтиең?

— Кичке тугызларда.

Зәйнулла беравык тынып торды. Гел-гел сорашып кына торсаң, малайны шикләндерүең бар. Ә сорашырга кирәк. Әһә, чынлап торып еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга ди, бар икән ләбаса җае.

— Үз машинам белән озата да алмадым, ичмасам, — дип, Зәйнулла офтанып куйды. — Әйберләре дә авыр булгандыр инде, өстәвенә авыру кыз. Килеп житә алмадым шул, эш тыгыз булды.

Каршысында басып торган олы кешенең борчылуын күреп, малай аны җәлләгәндәй әйтә куйды:

— Нинди әйбер ди ул чаклы! Икесенә бер портфель!

— Нишләп мине көтмәде икән, шайтан алгыры?

— Самолетка ашыкты ул.

— Нәрсә белән китте соң?

— Күрше Җиһаншин абый илтеп куйды, машина белән.

Камалиев, малайга сиздерми генә, Зәйнулла ягына карап алды. Хә-

зер инде өлкән тикшерүче үзе дә аның планын ахырынача ачыкларга өлгергән, кирәк була калса, сүзгә катнашырга әзер иде.

Соловьев сорашуын дәвам иттерде:

— Җиһаншин абыеның машинасы нинди, энекәш?

— «Волга».

— Минеке дә «Волга», тик менә ватылып китте әле, төзәтәсе бар,— дип, тагын офтанды Соловьев.

— Бәлки, Җиһаншин ярдәм итәр.— Камалиевның сүзгә кушылуы шундый табигый килеп чыкты, бала-чага түгел, гомер иткән агаең да аны «артистлана» димәс иде. Зәйнулла аңа елмаеп җавап кайтарды:

— Әйе шул,— үзе белән сөйләшеп карарга кирәк әле алайса.

Уйламаган-көтмәгән җирдән икесенең дә уенда яңа план өлгерде. Җиһаншинны тыңлап карарга кирәк. Нинди адәм икән ул? Җеп очы аңа да тоташмаганмы?

— Кара әле, энекәш! — Камалиев малайга якынрак килде.— Кайда тора ул Җиһаншин абыең?

— Әйдәгез, күрсәтәм.— Малай аларны урам аркылы алып чыкты да биш катлы йорт каршында ялтырап торган көрән «Волга»га күрсәтте.— Җиһаншин абый «Волга»сы.

Машина эчендә биш-алты яшьлек кызчык уйнап утыра иде.

— Әтиеңне чакырып чыкмассыңмы, кызым? — диде аңа Камалиев.— Безгә бик кирәк иде ул.

— Хәзер, абый.— Кызчык, машинадан төште дә, ишекне ябып, подъездга таба йөгерде. Шунда ук аның әтисе — урта буйлы, тулы гәүдәле, утыз-утыз бишләр чамасындагы ир кеше чыкты.

Исәнләшкәннән соң, ир-атлар Зайцевны эзләп килгәннәрен әйттеләр.

— Үзегез кайдан буласыз? — дип кызыксынды Җиһаншин, җавап биргәнче.— Торак конторасыннанмы, әллә сәүдәгәрләрме?

Кеше дигәнең төбенә тоз коючан шул. «Волга» хуҗасы тиз генә ачылып китәр дип уйларга да ярамый. Бу сиңа йорт алдында туп тибеп йөрүче малай түгел. Җаен тапмасаң, аның белән сүз башламавың хәерлерәк. Җиһаншинның соравы аларга шуны искәртте. Бу юлы Зәйнулла җавап бирергә ашыкмады. Камалиев моның сәбәбен тиз аңлады. Чаллы кешесенең Зәйнулланы тануы ихтимал. Монда аңа артистланырга да, артык күп сөйләшергә дә ярамый. Димәк, «сәхнәгә» Камалиев чыгарга тиеш.

— Сизгер кеше икәнсең,— диде Вилдан, югалып калмады.— Әйе, мин сәүдәгәр. Җитез юртаклар белән эш итәм. Күрше шәһәрдән. Исемем — «Син сорама — мин әйтмим».

— Анысы аңлашыла, май чүлмәге тышыннан билгеле ул,— диде Җиһаншин, көлемсерәп.— Степан Григорьевич үзе дә чын сәүдәгәр, дуслары да менә дигән.— Һәм, кинәт җитдиләнеп, сорауны кабыргасы белән куйды: — Ни йомыш?

— Без эш хакында сөйләшкән идек,— диде Камалиев.

— Ә-ә-ә?! — дип сузды Җиһаншин.— Тик ул Казанда бит.

— Кара аны имансызны.— Камалиев гамьсез елмайган булды.— «Килегез, көтәрмен»,— дигән иде. Китеп барган бит.

— Бик ашыгыч китте ич ул,— дип, Җиһаншин дустын якларга тотынды.— Унбиш яшьлек кызы, бәлки, белә дә торгансыздыр, Маша, аягын имгәткән. Кичә кич шәһәрдән үзем озаттым.

— Чаллыгыз бөтенләй корыган икән, аяк имгәтү белән Казанга бар, имеш.

— Үзем дә әйттем анысын,— дип, Җиһаншин Камалиев белән килеште.— Юк, тыңламады бит. Озат та озат.

— Туктале, тукта!..— дип, Камалиев Соловьевка борылды.—

— Ялга каршы нинди поликлиника эшләсен ди! Чынлап торып баксаң, минем дус берәр җирдә кәеф-сафа корып утырадыр әле!

Җиһаншин каршы төште.

— Кызык та кеше сез! Аэропортка үзем илтеп куйдым ләбаса. Самолетлары очканчы сөйләшеп утырдык. Сумкасын да, портфелен дә үзем илтештем. Очкан вакытына кадәр хәтеремдә: егерме сәгать кырык минут.

Камалиевның «кәфе кырылды»:

— Сагынып кил дә, авыз чылатмый да кит инде...

— Әйдә, миңа рәхим итегез, — дип, Җиһаншин кыстый ук башлады. — Кунак булып китәрсез, бәлки, төнгә, сүзендә торса, Степан үзе дә кайтып җитәр.

Зәйнулла, барысы да күрсеннәр дигәндәй, сәгатенә карап алды. Бу «таярга вакыт» дигәнне аңлата иде.

— Бик рәхмәт, — диде Вилдан, елмаеп. Җиһаншинга кул сузды. — Үзегез дә каядыр җыенгансыз бит.

— Җыенса ни! Өлгерермен. Сез әйткән җитез аргамак үзебезнең кулда ич.

— Рәхмәт! Юл кешесенең юлда булуы яхшы, — диде Камалиев, аның көрәктәй зур кулын кысып.

Алар, пошаманга бирелгән кешеләр сыман, урамга таба атладылар. Җиһаншин машинасы янында басып калды.

— Я, нәтиҗә нинди? — дип, Соловьев, сабырсызланып, Камалиевның беләгенә орынды.

— Бу турыда сүз монда түгел, аэропортта, билет алучылар исемлеген тикшергәч булыр.

Никадәр тикшерсәләр дә, Зайцев үзе дә, кызы да аэропорттан алынган биш йөз егерме пассажир исемлегендә юк иде.

— Җиһаншин үз исеменә алып бирмәдеме икән?

Әмма исемлектә Җиһаншин фамилиясе дә табылмады.

## II

Матусовны тикшерүче бүлмәсенә кабат алып керделәр. Бу юлы да ул өстәл кырындагы урындыкка гамьсез генә килеп утырды. Кулларын тез өстенә куйды.

— Яңа сораулар тудымыни, гражданин начальник? — дип, Матусов соргылт күзләрен Камалиевка төбәде.

— Искеләренә дә җавап бирмәдегез бит әле.

— Нindиләренә?

— Кибет ишеген ничек каердыгыз?

— Юк, юк, гражданин начальник. Минем эш түгел бу. Әйттем ич, сезгә мәгълүм булганча, минем һөнәрем — кесә карагы.

— Кесә капшап кына яшәп булмый шул хәзер.

— Анысы хак, кесәчеләргә ход калмады. Шулай да кибет басу — минем эш түгел. Кесә карагы мин. Мелкая сошка.

— Кесә карагы, имеш. Анысына кайда өйрәндегез соң?

— Кечкенәдән, гражданин начальник, кечкенәдән. — Тикшерүченең кызыксынуын күреп, Матусов ачылып китте. — Федор белән Ольга дигән ике бәндәне гомердә онытасым юк, сволочьларны! Ирле-хатынлы. Безнең күршедә тордылар. Балалары юк иде. Мине үзләренә алып керәләр, сыйлыйлар. Бездә ашау ягы такы-токы. Бер сыйладылар, ике. Күнегә башладым. Федор — төнге каравылчы, хатыны бер җирдә дә эшләми, өйдә ята. Юк, өйдә тормыйлар иде алар үзе, көне буе югалып йөриләр иде. Сумка тотып, иртүк чыгып китәләр, соң гына кайталар.

Сумкалары тулы ризык була, шуннан миңа да өлеш чыга. Байларча тордылар, кыскасы. Парлап чөмерәләр, берсе дә исерми, чаманы беләләр. Вакыт-вакыт мине дә ияртеп чыгалар, үз балалары итеп йөртәләр, «улым» дип кенә эндәшәләр. Апрель азагында онытылмас бер вакыйга булды. Халык бәйрәм каршыларга әзерләнә. Без өчәүләп вокзалга төштек. Бөтен җирдә халык шыгрым. Федор белән Ольга бераз караштырып йөрделәр дә, мине кулларына алып, халык арасына кереп кысылдылар. Имеш, балалы кешеләр, чиратсыз гына кермәкчеләр. «Баламны үтерәсез!» — дип, Ольга мине кочаклаган килеш этешә дә төртешә. Күзем Федорга төште. Ул Ольга белән янәшә торган бер ачыгавызның кесәсеннән бумажнигын алды да, вокзалдан чыгып китте. Ике-өч минуттан Ольга белән без дә аны куып җиттек. Шул чагында әнигә әйтмәвемә үкендем үкенүен, әмма соң иде инде. Шулай йөри торгач, мин шомарып беттем — Ольга белән Федор мактап туймыйлар иде. Тотмадылар түгел, тоттылар, әмма минем авыздан күршеләрнең исеме чыкмады. Федор да, судка эләксә-нитсә, үзен генә белде. Ольга белән мине телгә алмады, төрмәгә өстерәмәде. Бу минем өчен мәктәпне дә, академияне дә алыштырды. Нәрсә ул җиде класслы мәктәп? Менә шулай, кадерле начальник, мин — профессиональ кесә карагы.

— Дөрес аңлагыз, Матусов, мин сезгә җинаять такмыйм, булган хәлне сөйлим. Гаепле булмасагыз, үз-үзегезне яклагыз.

Матусовның күңелендә өмет чаткысы кабынды. Җылы сүз әйтте бит тикшерүче, «үз-үзегезне яклагыз» диде.

— Барыбер монда ниндидер этлек бар, гражданин начальник, — дип, Матусов кодексны үзе сорап алды. — Кемдер минем исереклектән файдаланган. Әмма бу сигез сумлык урлауны, сез кирәк дип тапсагыз, черт с ним, мин үз өстемә алам. Димәк, миңа 95 статьяның икенче бүлеге, — диде ул, кодексны актара-актара.

Тукта, тукта, нишләп Матусов ул статьяга ябышты соң әле?

Бүлмә тынып калды. Матусов элекке хәленә кайтты —үзен иркен тота башлады. «Статья ачыкланды, җәза билгеле, нигә артык кайгырырга», — диде бугай ул эченнән генә. Әмма аның тыныч уйларын тикшерүче бүлде:

— Кызык кеше сез, Матусов. Җиңел генә котылмакчы буласыз

— Законда ике елга кадәр ирektән мәхрүм итү каралган, гражданин начальник. Сигез сум өчен моны җиңел җәза дип ялгышмыйсызмы?

— Монысы икенче нәрсә. Ачкыч та, перчатка да сездәге. Дөресме?

— Әйе, ышандым, алар минем кесәдән табылган, — дип, Матусов монысына да ансат кына күнде.

— Ул ачкыч белән сәүдә конторасы ачылган, кассасы таланган. Талаучы кулында да, зыян күрүче кассир әйтүенчә, сезнең кесәдәгегә охшаган ак резин перчатка булган. Бу аңлашыламы?

Матусов сискәнеп китте, әмма үз хәлен сиздермәскә тырышты. Дорфа гына җавап бирде:

— Аңлашыла, аңлашыла. Монысын да миңа такмакчы буласыз икән. Чаллыда әлегә кадәр ачылмаган күпме урлашу, кеше талау? Әйтсәгез, мин барысын да үз өстемә алам. Исәпкә алынган җинаятьләрнең барысын да ачкансыз дип мактарлар. Медаль биреп куюлары да ихтимал. Әмма, гражданин начальник, сезнең алда утыручы Матусов — карт чыпчык, аны кибәк белән генә алдый алмассыз.

— Ышанмыйсызмыни?

— Әйе, хәзер сезгә дә ышанмыйм. Нишләп сез миннән уңай җавап кына көтәсез? Бәлки кайбер нәрсәләргә мин үзем дә төшенеп бетми торганмындыр. Кыек-мыек сөйләшеп, үземне генә түгел, башкаларны

да әллә нинди бәла-казаларга дучар итүем бар бит. Тикшерү эшендәге дәлилләрне карап чыгарга рөхсәт итсәгез, икенче нәрсә.

— Рәхим итегез, — дип, тикшерүче делоны, тәвәккәлләп, Матусов алдына этәрде.

Матусов папкадагы кәгазьләрнең бар битен ашыкмый гына укып чыкты. Папканы ябып куйды да кул сырты белән маңгаен сөртте.

— Я, Матусов?

— Вакыйгалар чын, гражданин начальник, рәсми кәгазьләр бар, дәлилләр дә күп, димәк, дөрес.

Матусов башын күтәрде дә, тикшерүчегә гамьсез, салкын караш ташлады. Бу караш: — «Теләсәгез нишләтегез, миңа барыбер»,— дигәнне аңлата иде.

Тикшерү барганда, шулай инде: эш мәйданы тарая дип өметләнеп торганда, ул үзеннән-үзе киңәя башлый, бер тикшерелгән юрама урынына ике-өч яңасы калкып чыга.

Камалиев, кәгазьләрен актара-актара, Матусов турында уйланды. Бик сәер адәм бу. Үзе дүрт мәртәбә хөкем алдында булган, унбер елга ирегеннән мәхрүм ителгән кеше. Рецидивист рәтенә керә торганнардан. «Карт чыпчык», үзе әйтмешли. Белеме дә бар. Аның ишеләр җинаятькә алдан ук җентекләп әзерләнә, бер алга атлаганчы, ике кат артка карый. Җинаять эзләрен оста яшерә белә, шомалыгы, үткенлеге белән хәтта милицияне гаҗәпкә калдыра.

— Дөрес, дисез. Ярый... — Тикшерүче һам...н уйлана иде әле. — Сәламәтлегегез ничек сезнең? — дип куйды Камалиев кинәт кенә.

— Ходайга шөкер. Чибәр апалардан җалу-мазар бармы әллә?

— Сәламәт булсагыз, үткәннәрне хәтерләгез, сөйләгез, бәхәсләшегез. Кеше ләбаса сез, кеше! Игътибар иткәнегез бармы, чебен дә җилгә каршы оча ала! Ә сез?.. Үз-үзен саклый һәм яклый алмаган зат — кеше мени ул!

Тикшерүче сүзләреннән Матусовның миенә электр тогы йөгергәндәй булды, тәннәре чымырдап китте. Көчсезгә, меескенгә калдырды бит аны тикшерүче, ә бу, чыннан да, шулай, ахрысы.

— Нишлим соң, гражданин начальник? Хәтерем буш, исерек идем бит, — дип, башын аска иде, калтыранып куйды.

Кинәт кенә тышта көчәеп киткән төнге җил дә тәрәзәләргә бәрелә, сызгыра, улый башлады. Җил тавышы Матусовның үксү авазларын күмеп китә иде.

## 12

Урманның эченәрәк кергән саен коры-сары күбрәк дигәндәй, тикшерү мәйданы киңәйгән саен сөрле төеннәр арта барды.

Капитан Соловьевка шул төеннәрнең берсен — Зайцев тирәсен «капшау» йөкләтелде. Чаллыда ачыкларга мөмкин булганнарны озакка сузмадылар — ачыкладылар. Ләкин шуннан соңгысы кыенлаша төште. Зайцевның нинди адәм булуын тәгаенләү шактый четерекле эш булып чыкты.

Зайцевның эш урынында булды Соловьев, аның шәхси делосын карады, фотоларын кулга төшерде. Аларны зурайтып, күпләп бастырып алды. Читләтеп кенә булса да, таныш-белешләреннән сораштырды, сынын-кыяфәтен, кием-салымын, гадәтләрен ачыклады.

Юлга чыгар алдыннан, милиция формасын салып, штатский костюм кигән арада, Зайцев турында бөтен белгәннәрен барлап чыкты.

Степан Григорьевич Зайцев Воронежда туып үскән, утыз сигез яшьтә. 1965 елда Казанга килгән, авиация техникумына кергән, анда

дүртенче курска кадәр укыган. Техникумнан авиация институтына күчкән, ләкин вузны тәмамламаган — икенче курстан соң укуын ташлап киткән. Чаллыда икенче елын яши. Гаиләсе бар, хатыны Вера — педагог, өченче класста укыта. Маша исемле кызлары үндүрттә, уллары Степа апасыннан дүрт яшькә кече. Чаллыга килгәч, Зайцев магазин директоры булып эшли башлый. Яңгын чыгып, ике йөз мең сумлык зарар китергәне өчен, хезмәтеннән азат ителә. Шуннан соң коммуналь торак идарәсенә начальник урынбасары булып урнаша. Казанның Гагарин урамында хатынының әнисе белән бертуган энесе яши. Таныш-белешләре дә буа буарлык. Белүчеләрнең әйтүенә караганда, Зайцев тиз аралашучан, шактый үткен, җор телле кеше. Тәмәке тартмый, хәмерне дә артык өнәми...

Казанга сәфәр чыкканда, шик куләгәсе төшкән Зайцев турында Соловьевның белгәннәре шуннан гыйбарәт иде. «Ниләр генә майтарып булыр икән соң бу багаж белән?» — дигән уйлар башыннан үтсә дә, Зәйнулла төшенкелеккә бирелмәде.

Плащ алырга кергән Зәйнулла Казан аэропортында самолеттан төшкән чакта гына искәрде. Онытылган бит тәки, урындык артына эленгән килеш калган. Ә монда яңгыр коя.

Самолеттан төшүенә, аны башкала милициясе хезмәткәрләре каршылады. Картлар әйтмешли, рәхмәт төшкере затлар, үз өстенә үлчәп тегелгәндәй таман плащ та алып килгәннәр. «Иртәнге ашны да ашамый чыккандыр бу»,— дип, термос тутырып кайнар кофе да, сыр кисәге куелган, май ягылган хуш исле икмәк телемнәрен дә әзерләп куйганнар. Зәйнулла машина шәһәргә элдергән арада тиз-тиз генә капкалап алды.

Казан милициясе дә кайбер нәрсәләрне ачыкларга өлгергән булып чыкты. Авиация техникумыннан, институттан, Зайцев эшләгән Казан оешмаларыннан шәхси делолары алынган, кирәкле мәгълүматлар җыйналган, төрле фоторәсемнәрнең нөсхәләре әзерләнгән иде инде. Милиция хезмәткәрләренә бер-берен аңлау кыен булмады. Һәр ике як та, үз планнары белән таныштырып, уртак фикергә килделәр. Машинадагы рация аша министрлык җитәкчеләре белән элемтәгә кереп, ризалык алынды.

— Зайцевларның элекке квартирасыннан башлыйбыз, алайса, — диде Зәйнулла, эшкә керешергә әзерләнеп.

Шофер белән мыеклы инспектор машинада калды. Соловьев, коңгырт чәчле егет белән кереп, Зайцевлар яшәгән квартираның ишеген шакыды. Ишекне кабаланмыйча гына ачтылар. Бусагада алтмышлар тирәсендәге карчык тора иде.

— Рәхим итегез. Кем буласыз? — дип сорады карчык.

«Вераның әнисе шулдыр, мөгаен», — дип уйлады Зәйнулла. Хуҗа әбигә исә:

— Без Чаллыдан, әбекәй. Степан Григорьевич эшләгән җирдән, — диде, соңгы сүзләренә басым ясап.

— Керегез, әйдә үтегез! Кияү эш белән чыгып киткән иде, озакламый кайтыр.

Бер бүлмәле квартира әллә ни иркеннән түгел иде. Кухнядан үсмер кыз да килеп чыкты. Зәйнулла аны күрүгә:

— И-и, Степан Григорьевичка охшаган, әллә кызы Маша инде? — дип, аңа кулын сузды. — Таныш булыйк, сеңелкәш, Соловьев абыең булам мин.

Әби кеткелдәп алды:

— Минем оныгым, Маша.

— Сез, Маша, бездән җитезрәк булып чыктыгыз бит әле, алданрак килеп җиткәнсез. Әллә «Метеор»да җилдердегез инде?

— Юк, без кичә самолет белән килдек, — диде кыз.

— Аэропортта да күренмәдегез, югыйсә. Мин кичә билетка чират торып караган идем дә, тәтемәде.

— Билетны бер абый алып бирде безгә, үзебез аны машинада көтеп утырдык.

— Аягың авыртa дип ишеткән идем, әйберләрегез дә авыр булгандыр инде. — Капитан аның хәленә кергәндәй итте. — Бергә килсәк, күтәрешкән булыр идек, шуңа гына әйтүем.

— Күн портфельне әти тотты, минем кулда җиңел сумка гына иде.

Капитанның хәтеренә кылт итеп Җиһаншин сөйләгәннәр килеп төште. «Әйе... ул да шулай диган иде: күн портфель белән хуҗалык сумкасы. Кайда булыр икән соң ул портфель дигәннәре, шайтан алгыры?»

Зәйнулла, кесәсеннән шырпы кабы алып, уч төбенә суккалап утырды.

— Тартыгыз, тарт! — диде хуҗа әби. — Тәмәкечеләр хәлен беләм мин.

— Рәхмәт инде! — Папирос кабызырга маташкан Соловьевның кулыннан шырпы кабы төшеп китте. Иелеп алам дигәндә генә аяк очы тиеп, шырпы тартмасы диван астына ук олакты. Зәйнулла үзенең «тотмас кулын» тирги-тирги, шырпы кабын эзләргә керешге. Идәнгә сузылып, диван астына карады — күн портфель юк иде. Тәмәке тартырга дип туалет бүлмәсенә керде, ләкин эзләгәне анда да күренми иде. Кухняда бер стакан суны бик тәмләп озакка сузып эчте Зәйнулла — күзләре белән бөтен нәрсәне актарып-айкап чыкты, әмма шикләнерлек берни таба алмады.

— Нишләп кайтмый инде бу Степан Григорьевич? — дигән булып, балкон янындагы тәрәзә янына да килеп басты. Юк, күн портфель балконда да юк иде. Үзе белән алды микән әллә?» — Соловьев башына шундый уй килде. Зәйнулланың бүлмәдән тизрәк чыгып йөгерәсе, Зайцевны эзәрлекләүне казанлылар тәкъдим иткәнчә дәвам иттерәсе килде. Тик ниндидер эчке тойгы аны ашыкмаска, сабыр итәргә өнди иде. Хуҗа әби аның түземсезләнүен бик яхшы аңлый, хәленә керергә тырыша:

— Йомышыгыз ашыгыч булгач, көтегез инде, хәзер кайтып җитәр ул, — дип тәкрарлый тора. — Таныш врачларын эзләп кенә китте ул. Машабызны дәвалыйсы бар бит. Кайтыр, кайтыр. Аңарчы чәй кайнатып алыйк.

Кухняда савыт-саба белән мәш килгән әбинең тавышы ишетелде:

— Машенька, кибеткә чыгып кер әле, кызым!

Хуҗа карчык үзе дә бүлмәгә чыкты. Бәләкәй генә өстәл тартмасын ачып, аннан акча алды. Соловьевның чәчләре үрә торды: онигын кумәч алырга җибәрергә җыенган әбинең кулында шыгырдап торган йөзлек иде.

— Синең вак акчаң юкмы, кызым?

— Хәзер карыйм, әби, — Маша кул сумкасын шартлатып ачты да кыштырдата-кыштырдата кәгазь акчалар актара башлады. Соловьевның күзенә иллелекләр чагылып киткән сыман булды. — Юк икән шул, әбием...

— Бәлки, сез ваклап бирерсез? — Кулына йөзлек акча тоткан карчык кунакларга мөрәҗәгать итте.

Соловьев аның кулындагы акчадан күзен алмыйча, дикъкать белән кесәләрен актарды. Әмма ваклардык сумма таба алмады.

Мыексыз инспекторның да кесәләре такыр булып чыкты.

— Үземнекеләр дә шактый эредән шул, әбекәй. Командировкага вак-төяк акча белән чыкмый инде ул ир-ат.

— И, безнең Степан кияү дә шулай, — диде карчык. — Эш хакын мулдан ала, ходайга шөкер.

Зәйнулла үзе әбине тыңлый, ә уйлары бөтенләй икенче нәрсә турында: «Хуҗа карчык кулында — йөзлек!.. Матусов кесәсендә дә шундый ук зур акча табылган. Нәрсә бу — сәер бер очраклыкмы әллә бер үк җинаятьнең тармакларымы?»

Озак уйлап торырга вакыты юк бит аның. Зәйнулла кесәсеннән бер өчлек, бер берлек алып, өстәлгә куйды:

— Шулар җитеп торыр, әбекәй.

Маша кибеткә дә чыгып керде. Сөтле чәйдән дә авыз иттеләр, тик Степан Зайцев кайтмады да кайтмады. Кунаклар, аны очрата алмауларына бик офтанып, чыгып китәргә мәҗбүр булдылар.

Капитан Рәшит исемле инспекторны шул тирәдә Зайцев кайнанасының фатирын күзәтеп торырга калдырды. Үзе Эчке эшләр министрлыгына шалтыратып, Гагарин урамына ярдәмгә тиз генә кеше җибәрергә кушты. Аэропорт, тимер юл вокзалында, елга портында күзәтү турында да сөйләшенде.

Эзәрлекләүнең вак-төяк булып күренгән мәшәкатьләрен очлап чыккач, капитан янындагы инспекторга, шаяртып:

— Киттек куян куарга, Коля! Эзләре ярылып ята, үзе генә юк, шайтан алгыры, кай тарафларга сызды икән? — диде.

Эзләр, чыннан да, ярылып ята, — капитанның кесәсендә уннан артык адрес бар иде. Зайцевның туган-тумачасы, дус-ишләре, танышбелешләре гаҗәп күп икән. Степан Григорьевич аларның һәркайсында кунып чыга ала, атна-ун көн дә ята ала. Димәк, аның Чаллыга яки кайнанасының Казандагы квартирасына кайтуын көтеп торырга ярамый. Эзләргә, һич югында, кесәдәге адреслар буенча китәргә кирәк.

Ул көнне Эчке эшләр министрлыгының бер машинасы Соловьев карамагына бирелде. Җилдереп тә карады соң капитан! Кайларда гына булмады ул!

Өченче адрес белән баргач, аңа болай диделәр:

— Әйе, ишеттем, Степан Григорьевич Казанда. Как же, иске дуслар! Үзе күренмәде, телефоннан гына шалтыратты. Кызы белән врачка килгән. Кермәде, «вакыт тар, дустым», диде...

## 13

Ямь-яшел каеннар үсеп утырган ишегалдына килеп кергәч, капитан белән көнгырт чәчле инспектор да, беравык туктап тордылар. Юлдашы тирә-яктагы хозурлыкны күзәткән арада, капитан бер сәгатенә, бер күккә карап, уйланып алды. Җиденче кырык минут иде инде. Көн озын та киткән ләбаса. Кояш баер вакыт та җитеп килә.

Инспектор тирә-якны караштырып йөргән арада капитан кирәкле подъездга таба атлады. Ишеккә җиткәч, звонок төймәсенә басты. Әмма эчтән шылт иткән тавыш та ишетелмәде.

«Әллә адресны бутадыкмы?» — дип, капитан эчке кесәсендәге исемлекне алып карады. Юк, алар дөрес килгәннәр иде. Аннары капитан үз хәтеренә нык ышана. Кирәк икән, бу квартирада кемнәр торганын хәзер үк санап чыга ала. Сораша-нитә калсалар, гаилә башлыгының Головин Илларион Зотович икәнен әйтер. Биология фәннәре кандидаты икәнен, фәнни-тикшеренү институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләвен өстәр. Хатыны Вера Семеновна — теш врачы. Бердәнбер кызлары Карина алтынчы класста укый.

Зайцевның монда кызын дәвалату өчен килеп чыгуы бик мөмкин.

Капитан төймәгә кабат үрелде. Бу юлы катырак басылды, ахрысы, хәтта баш бармагы авыртып китте.

Ниһаять, ишек ачылды, аннан мәһабәт гәүдәле ир килеп чыкты һәм кырыс кына:

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады.

— Исәнмесез! — Зәйнулла Соловьев хуҗага таба атлады. — Мөгаен, сез Илларион Зотовичтыр. Зинһар гафу итегез безне, Чаллы сәфәрчеләрен.

Хуҗаны кинәт алыштырып куйдылар диярсең.

— Шәһәрегез белән куптыгызмы әллә? Тынычлап эшләргә дә ирек бирмисез, имансызлар, — дип көлемсерәде ул. — Берсен озатырга өлгермисең, икенчесе ишек шакый. Я, Головин булсам, ни йомыш?

Башка берәү булса, бу сүзләрне, мөгаен, авырга алыр, галим монда килүне өнәп бетермәде, ахрысы, дип уйлар һәм ялгышмас иде. Ә капитанны хуҗаның шулай каршылавы сөендерде.

— Сизеп торам, Степан Григорьевич булган сездә, — диде Зәйнулла, җанланып. — Кәрәм диган иде шул.

Головин моңа һич тә гаҗәпләнмәде.

— Әйе, аның чыгып киткәненә... — хуҗа кул сәгатенә карап алды, — төп-төгәл егерме җиде минут.

«Касса талануга да тиздән төп-төгәл ике тәүлек тула», — дип уйлады капитан өзгәләнеп. Хуҗага исә:

— Илларион Зотович, ул безгә бик кирәк иде! Шуның өчен махсус килдек тә. Берәр сүз әйтмәдеме, язу-мазар калдырмадымы? — диде.

— Юк, андый сөйләшү булмады, — диде галим, кабат җитдиләнеп. — Ә сез, әйдәгез, әчкә үтегез. Ике сәгатьтән кайтырмын диган иде ул.

«Чаллы егетләре», бусагадан атлап керү белән, туфлиләрен ишек төбендә калдырып, бүлмәгә уздылар. Хуҗа, мөлаем елмаеп, зәңгәрсу обойлы стена буенда торган урындыкларга күрсәтеп, утырырга кушты. Егетләр, рәхмәт әйтеп, утырыштылар.

— Тартасызмы? Юк? Бик әйбәт, үзем дә бик өнәп бетермим тәмәке дигәннәрен. Менә газета-журналлар карый торыгыз.

Галим егетләр алдына бер өем газета-журнал китереп куйды.

— Я, танышып җибәрик, үзегез кем буласыз?

— Чаллыдан без, Степан Григорьевич белән бер оешмадан. Иптәшем инженер, мин юрист, — дип, капитан үзенең исемен әйтте, кинәт ачылырга туры килсә дип, һөнәрен дә яшермәде.

— Менә сиңа мә! Минем каенеш тә юрист бит! Свердловскида юридик институт тәмамлады. Сигезенче ел инде Төмәндә эшли. — Әңгәмә торган саен җанлана барды.

— Сез, егетләр, юлда килеп талчыккансыздыр инде, — диде кунакчыл хуҗа. — Чәй өлгертимме, әллә берәр рюмка тотабызмы? Миңа да ял булыр, Зәйнулла Салихович, нишлибез?

— Рәхмәт, Илларион Зотович, борчылмагыз, берни дә кирәкми. Без күнеккән инде. — Капитан журнал битләрен актарырга тотынды. — Юл кешесен беләсез бит: ашык та пошык.

— Белми ни. Алҗыган инде ул командировкаларда йөреп.

— Без комачаулыдык бугай сезгә. Степа гына кайтсын да, үз юлыбызда булырбыз.

— Кайтыр, Степа төгәл кеше ул, — диде хуҗа, борчылмаска өндәп.

— Төгәл дисең дә бит, берәр ресторанга юлыкса, — Зәйнулла, сул күзен кысып, телен шартлатып куйды,— күтә-күтә күзләрең күгәрер.

— Зайцевны белмисез икән әле сез, — дип элеп алды хуҗа. Зәйнулла исә үзен: «Бетте баш!» дип шелтәләргә тотынды. Тик хуҗа сүзен һич көтмәгәнчә дәвам итте: — Биш бармагым шикелле беләм мин дустыгызны. Заманында Степа белән без дә ахири дуслар идек. Степа Казанда күңеленә ятышлы эш тапмады бит тәки, Чаллыга күчеп китте. Күрәсең, шәһәрегез ошады Степага, тынычлана төште. Килсә кермичә китми.

— Илларион Зотович, сез хәзер дә үзәк яклаучыдан ким түгел, яшьлек дустыгызга бераерсе тел-теш тидереп карасын, ишетер көтмәгәннәрен...

— Яклаучы дигәч тә, Зәйнулла Салихович... Степа үзе дә төшеп калганнардан түгел ул. Үзсүзле егет. Үзен утә ярата торганнардан. Хәер, кайсыбызда гына юк икән инде андый чир? Степа беренчелекне бирмәс өчен җанын фида кылыр. Модадан да калышмас. Баш бар, сәләт бар егеттә. Чаллыда ниләр майтара соң? Анда да шулаймы?

Яшь егетнең сүзгә кушылмавын күргәч, хуҗа бу юлы туп-туры Зәйнуллага мөрәҗәгать итте. Зәйнулла үзен ут белән су арасында калган кеше кебек хис итсә дә, сорауны җавапсыз калдырырга базмады:

— Чаллы ни дә, Казан ни, Илларион Зотович, кеше характерын шәһәр генә үзгәртә ала микән?

— Юк, әлбәттә.

— Сез «бишле»гә укучы студент иде дип мактыйсыз да бит, Зайцев безгә авиация институтын ташлап киттем дип шапырынды.

— Менә, менә, нәкъ өстенә бастыгыз, иптәш Соловьев, — Головин күзгә күренеп җанланып китте. Урыныннан торып, арлы-бирле йөренеп алды. — Ике ел укыды да, кәҗәләнде бит, тәки ташлап китте.

Хуҗа читкә борылган арада «Коля, арымадыңмы әле,» — дип, Зәйнулла инспекторны мавыктыргыч журналдан аерды. Аннары хуҗа да ишетерлек итеп әйтте: — Кайтып килсә ярый да бит.

Галимнең йөзе яктырып китте:

— Кайта, кайта ул. Кайтмаска, барлык кәгазь-мәгазьләрен монда калдырып китте бит ул.

Бу сүз Зәйнуллага корыч пружинаның кинәт шартлап сынуыдай тәэсир итте.

— Портфеле-ние беләнме?! — Капитан түземлеген җуйды, ахрысы, тавышы үзгәреп, калтыранып чыкты.

— Әйе, портфеле белән, — фатир хуҗасы күзлеген төзәтеп куйды.

Житте, капитан, бүтән артистланып маташма, уеннан уймак чыгуы бар, хуҗага эшне ачып салыр вакыт житте.

— Кадерле Илларион Зотович, зинһар өчен, гафу итегез. Мин милициядән бит, капитан Соловьев булам. Менә таныклыгым, рәхим итегез, — дип, аны хуҗа алдына өстәлгә куйды.

Головинның йөзе кинәт агарынып китте. Кызыл тышлы таныклыкка текәлгән килеш, бераз шаккатып торгач кына телгә килде:

— Милициядән? Гаҗәп! Ә алдан ук әйтсәгез ни булган?!

— Илларион Зотович, каенегез, милиция майоры буларак, безне дөрес аңлар иде. Әйтми торуыбызның сәбәбе бар. Сезгә ышанмаудан түгел бу, Илларион Зотович, сез, галимнәр дә, ниндидер фәнни ачыш алдында торганда сабырлык саклыйсыз, гипотезаны аксиома, дип шапырынмыйсыз.

Зәйнулла көлемсерәп, кулын Головинга сузды:

— Бирегез бишне, танышуыбыз дәвамлы булсын.

Киеренкелек, ничек кинәт туган булса, шулай тиз һәм эзсез үтеп тә китте.

— Я, егетләр, йомышыгыз нидән гыйбарәт? — дип сорады хуҗа ягымлы тавыш белән.

— Йомышыбыз житди, Илларион Зотович. Кем генә булмасын, килгән кешегә ишекне сез ачарсыз. Бусы — бер. Телефоннан шалтыратучыга да сез эндәшерсез, безнең турыда һичкемгә ләм-мим. Зайцевка да! Ике булды. Бирeдә бераз рәсми тикшерү үткәрәсе булганлыктан, сезне борчырга мәҗбүрбез. Монысы — өч. Безгә телефоныгыздан шалтыратырга да рөхсәт итсәгез, хәзергә шул житкән.

— Рәсми хезмәт куша икән, мин ничек карышыйм ди, Зәйнулла Салихович? — дип хуҗа капитанның өстәлдә яткан таныклыгын укып чыкты. Башта фоторәсемгә, аннары Соловьевка карап алды. Таныклыкны иясенә кайтарып биргәч, сул стенадагы ишек янына терәтеп куелган шифоньерга ымлады: — Портфелен шифоньерга куйган иде, кирәк булса, алыгыз, — диде. — Хуҗаның тавышында гаҗәпләнү төсмере бетеп җитмәгән иде әле.

— Илларион Зотович, без икебез дә милиция офицерлары, аны алырга да, карарга да хәзер безнең хакыбыз юк. — Соловьев телефон янына килде, кирәкле номерны җыеп, министрлыкка шалтыратты.

Экспертлар килеп кергәндә, пунәтәйләр бүлмәдә иде инде.

— Чакырылган кешеләр җыелды, магнитофон көйләнде,— дип, инспектор беркетмә язарга әзер булуын белдерде.

— Ярый, алайса, — диде Соловьев һәм эшкә кереште.

— Иптәш Головин, Зайцев Степан Григорьевич калдырган портфель кайда?

— Әнә шунда — дип, хуҗа кулы белән шифоньерга төртеп күрсәтте.— Алып биримме?

— Рәхмәт, Илларион Зотович, — дип, капитан аны туктатты. — Ашыкмагыз. Шифоньер ишекләрен соңгы мәртәбә кем ачканын, кем япканын әйтегез.

— Зайцев үзе ачты, портфелен куйды да, үзе үк япты.

— Аннан соң шифоньерга кагылучы булмадымы?

— Юк, әлбәттә.

— Яхшы, — капитан, коралларын әзерләп торучы белгечкә борылып: — Иптәш эксперт, шифоньер ишегенең тышкы һәм эчке ягындагы эзләрне, бигрәк тә бармак эзләрен барлагыз. Булса, фоторәсемгә төшереп, ябыштыргыч тасмага күчерерсез.

Шифоньер ишегендәге эзләрне тикшергәч, экспертлар бик озак портфельне карадылар. Ниһаять, өлкән эксперт телгә килде:

— Портфельнең тышында, каешында, тоткасында — барлыгы биш урында кул һәм бармак эзләре бар, әмма алар тоньк, экспертиза үткәрү өчен яраксыз. Тимер йозакларында ике эз табылды, бармак очыныкы. Чагыштыру үткәрү өчен яраклы булганлыктан, ул эзләр ябыштыргыч тасмага күчереп алынды.

— Рәхмәт. Хәзер портфельне ачабыз, — капитан, түземсезләнеп, портфель каршына килеп басты. — Перчатка кияргә онытмагыз.

Венгриядә эшләнгән өр-яңа, зур портфельнең ике йозагы да бикле иде. Моңа экспертларның исе китмәде, махсус чемоданнан төрле-төрле ачкычлар бәйләме алып портфельне ачып җибәрделәр. Соловьев сабый балаларча кычкырып җибәрде:

— Менә кайда ул югалган хәзинә!

Иң өстә үтә күренмәле целлофан капчык, капчыкта яшел иллелекләр, кызгылт йөзлекләр. Аның астында дыңгычлап акча тутырылган ике катыргы тартма. Нәкъ Нина Игнатюк сөйләгәнчә!

Стена кырыена этәреп куелган телефон трубкасы Зәйнулла кулына күчте:

— Подполковник Җарьянов! Капитан Соловьев бу. Акча табылды. Ярдәмгә кеше, алып китәргә кассир җибәрегез. Чаллыга шалтыратып, Камалиевка да әйтеп куегыз.

Акча табылганнан соң ыгы-зыгы тагы да көчәя китте. Фотоаппарат ялкыннары яшьнәде, целлофан капчыктан тартмалардагы акчалар бушатылды. Головинның ике тумбалы язу өстәлендәге өемнәрдән акча санау, һәммәсенең сериясен, номерларын язып чыгу ярдәмгә җибәрелгән өлкән сержант белән кассир һәм пунәтәйләр җилкәсенә төште.

Капитан нишләргә белми бер читтә басып торган бүлмә хуҗасына:

— Илларион Зотович, чәй яңартып алсак та ярар иде, — дип куйды.

Головин аны аңлап, кухняга кереп китте, Зәйнулла аңа ияpде.

Головин үзен утта янгандай, бөтен дөньясы актарылып ташлангандай сизә иде. Ул — Зайцевның күптәнге иптәше. Унтугыз ел элек спорт мәйданында танышканнар иде алар. Элек ул Зайцевны футболчы студент игеп белә иде. Ә бүген нәрсә белә ул аның хакында? Җор сүзле, күпне белә торган, физик һәм рухи көче ташып торган Степан Зайцев белән һәр очрашу шатлык һәм илһам өсти торган истәлекле минутлар бүләк итә иде, ә менә монысы... Нинди каһәрле портфель булды соң әле бу? Моның берәр хикмәте бардыр мөгаен...

Милиция капитаны исә, һичбер гаме юк кеше шикелле, тәрәзәдән нидер күзәтеп тора. Әмма Головин алай ук озак түзә алмый, күңелен бушатырга тиеш ул.

— Зәйнулла Салихович, нәрсә булып чыга соң инде бу?

— Белмәгәннең беләге авыртмый димәкче буласыз инде, алайса.— Капитан борылып, хуҗага текәлде. — Мондый малны кешенең, сез әйткәнчә, җиңел генә ташлап йөрүе икеле. Кайтып керсә, Зайцев эчке кесәсеннән распискагызны тартып чыгарса, нәрсә диярсез?

— Нинди расписка ди ул! Керде, исәнләште, үзе сул яңагын тоткан, тешем сызлый дип, мышьяк сорады. Юк, дидем. Поликлиника адресын бирү белән, чыкты да йөгерде. Син күр дә, мин күр. «Ике сәгатьтән көт», —дигән сүзләре генә ишетелеп калды. Шуның белән вәссәлам. Портфеле, ничек куйды, шулай шифоньерда калды.

— Мышьяк сорады дисезме?

— Хафаланып чыгып китүенә шул сәбәп булды да инде. Теше сызлаган кешенең хәле билгеле миңа.

— Ничек кенә булмасын, ахири дус шулай эшләми инде.

— Алай димәгез, Зәйнулла Салихович, кешенең төрле вакыты була, — Головин капитан белән килешмәде. — Ә мин, гамьсез җан, сезне Зайцевның хезмәттәшләре, аның йомышын йомышлаучы якыннары дип кабул иттем. Милиция кешесе икәнегезне белгәч тә, Степан Григорьевичка ниндидер куркыныч, фаҗига яный, ә сез аны шул бәладән коткармакчы, дип уйладым.

Шул вакыт кухня ишеген шакыдылар.

— Акчаны санап бетердек,— диде инспектор.— Кырык ике мең йөз туксан бер сум!

Иптәшләре беркетмәне рәсмиләштереп торган арада Зәйнулла күзе белән күргәнне зиһене аша үткәрде. Бу хәтле акчага ия булу өчен хезмәт кешесенә ничәмә-ничә дистә еллар буе чуен, корыч эретү, ташкүмер чыгару, мал үрчетү — никадәр тир түгү кирәк! Ә Зайцев ише әрәмтамакларга исә бер талпыну, бер селтәнү җитә... Коточкыч җинаять бит бу! Аныкларга! Калган 5200 сумның да тиененә кадәр табарга!..»

Капитан, министрлыкка шалтыратып, яңалыкларны әйтте, алдагы эшләргә икәне турында киңәште.

Телефонны куйгач, Зәйнулла тикшерүдә катнашучыларга рәхмәт әйтеп, акча белән бергә аларны министрлыкка озатып калды. Ә пунәтәйләрнең икесенә дә сабыр итәргә кушты һәм, Головинга туп-туры карап:

— Менә, күрдегезме инде, Илларион Зотович! — диде. — Моның нинди акча икәнен һәм аны кем биргәнен белү өчен безгә бирелә Зайцев кайтканны көтәргә туры килер, — дип, сәгатенә карады. — Хәзер сәгать сигезенче илле ике минут, ул кайтырга егерме бер минут вакыт калды. Илларион Зотович, сез каршы килмәссез бит?

Головин, иңбашларын җыерып, теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Моңарчы таныш-белешне милиция белән каршылаган юк иде югыйн. Кирәк булган, ни...

Засада оештыру турындагы карарга килгәндә, Зәйнулла гади логикага таянып фикер йөртте. Зайцев мондый сумманы билгесезлектә яткырмаячак, бу вакытлы яшерү генә. Әгәр Головин портфель эчендәге барын чыннан да белми икән, ул чагында Степан Григорьевич акчаны яшерү өчен тагын да ышанычлырак урын эзләячәк. Ә биргә килүе дә, портфельне калдырып торуы да вакытлыча гына. Хәзергә каракның берсе Матусов, икенчесе Зайцев дип фараз кылыйк. Беренчесе капкында утыра, ә икенчесе... Тотылмаган — бур түгел, ди мәкаль.

Тып-тын бүлмәдә кинәт телефон шалтыраудан Головин сискәнеп китте, шунда ук трубкага килеп ябышты:

— Әйе, мин, Степа, мин.

Капитан мәче тизлеге белән тавыш тынсыз гына хуҗа янына килеп җитте, магнитофон төймәсенә сак кына басты. Өстәлдәге кәгазьне алып, язарга әзерләнде.

— Тыңлыйм, Степа... Юк, үзгәреш-мазар юк. Портфелеңне калдырасыңмы? Анысы синең ихтыярда, Степа. Бозыла торган әйбер юкмы соң? Булмагач, торсын әйдә. Вера белән Карина да көньякта, кагылучы-нитүче булмас. Ничә көнгә? Ике-өч атнага? Миңа димәгәе, хет ике-өч ел торсын.

Капитан, аягүрә килеш, кәгазьгә «Кайдан шалтырата?» — дип язды да, аны сөйләшү белән мавыккан хуҗага күрсәтте. Әмма соң иде инде. Головин аны-моны сораштыру түгел, гадәтенчә, «Гуд бай, картлач!» дип саубуллаша да алмады. Башланган шикелле үк, сөйләшү кинәт кенә өзелеп тә куйды. Хуҗа өнсез калган трубканы кире урынына куймакчы булып борылган гына иде, капитан:

— Анда куймагыз! — дип, кисәтеп өлгерде. — Күршеләрегезнең кайсында телефон бар?

— Уникенче квартирада.

— Телефонга кагылмагыз! — дип, капитан капыл чыгып китте һәм уникенче бүлмәдән министрлыкка шалтыратып, ашыгыч йомышын тапшырды, үзе, җавап көтеп, телефон янында утырды, буталчык уйлар йомгагын сүтә башлады.

Зайцев төгәл кеше булып чыкты. Кайтмаса да, нәкъ әйткән вакытында шалтыратты. Хәзер аның Головиннарга килмәячәге көн кебек ачык. Нишләп шулай килеп чыкты соң әле бу? Әллә берәр ялгышлык ычкындырып, өркеттеләрме үзен? Их, шайтан алгыры, белсәң иде Зайцевны нинди корт чакканын!

Бу кадәресен министрлыктан шалтыраткан подполковник Зарьянов та әйтә алмады.

— Йомышыңны үтәдек, — диде ул җитди генә. — Каян шалтыратканнарын белеп булмады. Автомат телефон. Совет районыннан булуы мөмкин. Димәк, аэропорт ягыннан. Бусы бер. Аннары лейтенант Шәрипов шалтыратты. — Капитан сүзнең Гагарин урамында калдырылган Рәшит исемле инспектор турында барганын аңлады. — Кайткан бит тәки. Каенанасына кермәгән Зайцев. Подъезд каршына килеп җиткәч, нәрсәсендер оныткандай, беравык таптанып торган. Фотога төшергәннәр үзен. Аннары, кире борылып, Гагарин һәм Декабристлар урамы чатындагы аэрофлот кассасына кергән. Расписание укып торганда, билет тотып чыгучы ир-атны туктатып исәнләшкән. Иске танышын очраткан булса кирәк, үзара сөйләшү өч минутка сузылган. Сүз Чаллыдагы сәүдә хәлләре һәм Машаның авыруы турында барган. Зайцев күрәләтә үзгәргән. Күңеле күтәрелгән егетнең. Каенанасына керәсе урынга, беренче троллейбуска утырып, шәһәр үзәгенә җилдергән. Шәрипов, үтеп баручы «Москвичны» туктатып, аның артыннан юнәлгән. Куйбышев мәйданында троллейбустан төшкәнен күреп калган калуын да... машинадан төшкәнче күздән ычкындырган. Бу унөч минут элек булган. Лейтенантка аэропортка барырга кушылды. Ярдәмчесе Гагарин

урамында. Монысы ике булды. Хәзер яңа боерыкны тыңла! Головин белән хәзергә элемтәне өз. Барысын да законда күрсәткәнчә рәсмиләштер. Безнең телефоннарны язып калдыр үзенә, ул-бу була калса, туптуры безгә шалтыратсын. Унбиш-егерме минуттан яныңдагы инспектор белән аэропортта булыгыз. Очрашу урыны — ресторан. Машина синә билгеле тыкрыкта көтә. Кирәк тапсаң, машинадагы рация аша элемтәгә керерсең.

Иске аэропортка килеп җиткәч, капитан Соловьевны һәм аның юлдашын ресторанның арткы ишеге аша тар гына бер бүлмәгә озаттылар. Министрлыкның бүлек начальнигы аягүрә торып каршы алды үзләрен. Инспекторларның икесенә дә таныш полковник иде ул. Исәнләшеп, кул юарга өлгермәделәр, җитез официантка өстәлгә аш-су китереп куйды. Подполковник Зарьяновның ашыктыруы сәбәпсез түгел икәнен, вакытларының минутлап исәпләнгәнен төшенде Зәйнулла. Иптәшләре ашаган арада полковник җайлап кына кайбер нечкәлекләр турында сораштырды, алдагы эш планын билгеләде. Җинаять сирәк очрый торганнардан, әмма бик куркынычлы. Анда катнашучыларның һәммәсе дә фаш ителергә тиеш. Шуннан чыгып, Зайцевка сиздермичә генә, яшерен күзәтүне дәвам итәргә булдылар.

Чәй эчеп утырганда ишек шакыдылар.

— Миңа бу! — дип, полковник җитез генә барып ишекне ачты.

Кыска буйлы, киң җилкәле, очучы киеме кигән таза бер егет килеп керде. Полковникның колагына нәрсәдер пышылдады да, борылып, чыгып та китте. Полковник кул астында эшли торган милиция лейтенанты Сазонов иде ул.

— Лейтенант Шәрипов Зайцевның эзенә төшкән, яшерен күзәтү алып бара, — диде аз сүзле полковник. — Шушы бинада. Регистратура белән элемтә бүлекчәсе тирәсендә бөтерелә, диләр. Кирәге чыкса-нитсә, билет табу, сезне озату Сазоновка йөкләтелде. Аны икенче катта табарсыз.

— Аңлашылды, — дип, Зәйнулла урыныннан купты.

— Кечкенә генә искәрмә, Зәйнулла Салихович: Чаллы кешесе икәнеңне онытма, Зайцев танымасын, дим. Аз булса да кыяфәтеңне үзгәрт, — дип, полковник капитанга кечкенә генә бер төргәк тоттырды һәм, уңыш теләп, саубуллашты.

Официант кызга рәхмәт әйтеп, милиция әһелләре берәм-берәм залдан чыгып киттеләр.

Чуар кепка, кара пыялалы күзлек кигән Зәйнулла аэропортның иске, соры таш бинасын уратып, арткы ишектән залга килеп керде. Туп-туры элемтә бүлекчәсенә барып, кәгазь, конверт сатып алды. Стенага беркетелгән тар гына өстәл кырына килеп, «хат язарга» кереште. Иелеп ике-өч сүз яза да, башын күтәреп, «уйга бата», халык ыгы-зыгы килгән залга гамьсез генә күз ташлап алгалый. Коляны бик тиз күреп алды ул. Егет регистратурага чиратка барып баскан, алдындагы ике ир-ат белән гәпләшеп тора иде. Рәшит Шәрипов та яшерен күзәтү юлын тапкан: буфет ишегенә сөялгән дә, дөньясын оныткан кешедәй, мороженое кимереп маташа. Коляның да, Рәшитнең дә күз карашы бер ноктага төбәлгән иде. Почтага каршы стенага Степан Зайцев сөялгән, регистратура алдындагы чиратны ваемсыз гына күзәтеп тора.

...Чиратка җан керә башлады: кичке ун тулырга егерме минутта Бигешкә оча торган самолетка билет теркәү турында игълан иттеләр.

Зайцевны алыштырып куйдылар диярсең! Чемоданын тотып, тиз генә чират янына килде, билетларын теркәп, утыру өчен талон тотып чыккан кешеләрне туктатып, нәрсәдер сораштыра башлады. Әйләнә торгач, җаен тапты бит. Озын чәчле бер егетнең озата төшкән кызын кочаклавын күреп алды. «Бер кечкә генә булса да кал инде», — дип ялвара иде тегесе. Зайцев ялт итеп болар янына килеп басты.

— Коткара күр, туганкай! — дип утлы күзләрен пумала башка текәп, тышкы күкрәк кесәсеннән бер егерме бишлек алды да аптырашка калган егеткә тоттырды. — Сат билетыңны! Сдача кирәкми! Әни үлем хәлендә минем! Ишетәсеңме, әни!..

Ул арада, фокусчы җитезлеге белән, әллә кесәсеннән, әллә чемоданыннан ярты литр аракы да алып өлгерде.

— Мәгез, мә! Әнием саулыгы өчен эчәрсез! — дип берсенә дә авыз ачарга ирек бирмичә, сигез сумлык билет белән талонны тузгак баштан тартып алды да юкка да чыкты. Кыз шатлыгыннан үлә язып егетенен бит очыннан үбеп алды. Егет исә, «беткән баш беткән» дигәндәй, тәвәккәлләп, кулын селтәде дә, җанашының нечкә биленнән тотты.

Шатлыгы ташып торган Зайцев халык арасында лейтенант Шәриповның күләгәдәй үз артыннан ияреп барганын күрә алмады, әлбәттә.

Читтән күзәтеп торган Зәйнулла аптырап калды.

«И-и-их, билеты-ние белән эләктереп аласы, бөтен сорауларны чишәсе иде дә бит... Ярамый, шайтан алгыры!» — дип, капитан үзалдына ярсынды ярсынуын, хәлбуки, Сазонов белән элемтәгә керәсен онытмады.

Биш-алты минуттан соң Сазонов килеп җитте.

— Бер самолетта очасыз, — дип, ул Зәйнуллага билет белән талон сузды. — Сезнең арткы рәттә утырып баруыгыз мәслихәт. Коляга Зайцев тирәсендәрәк булырга кушылды, ул Шәриповны алмаштырырга чыкты. Рәшит биредә кала.

— Монысы аңлашылды, — диде капитан, аннары өстәп әйтте: — Карагыз аны, билетыннан колак каккан тузгак баштан сорау алу сезнең өстә. Егерме бишлек белән аракы шешәсендәге бармак эзләрен ачыкларга онытмагыз.

— Тиешле чара күрелде, — диде Сазонов, барысын да яшерен рәвештә кино тасмасына төшергәннәрен әйтте.

Зайцев җирдә көтә торган эшләре өчен хәл җыйгандай, уйга чумып, кыймшанмый-нитми утырып барды. Бигешкә килеп җитү белән, кабат җанланып китте. Пассажирлар урыннарыннан торырга да өлгермәде, аларны этә-төртә ишеккә ыргылды, беренчеләрдән булып аэропорт каршындагы мәйданчыкка ашыкты. Бүген дөньяда иң бәхетле кешеләрнең берсе ул иде.

«Эш эшләнде, — диде Зайцев, канәгатьләнеп. — Гап-гади бер Варонеж малае, бүгеннән иң мөстәкыйль, иң ирекле кеше». Шундый исерткеч, татлы уйлар дәрьясында гизгән килеш автобус янына барып басуын сизми дә калды. Әмма аңа башкалар белән бергә гап-гади бер автобуста утырып бару һич килешмәс төсле тоелды, җиңел машина эзли башлады. Бер почмакта «яшел күзле» такси пассажирлар көтеп тора иде. Түрәләргә генә хас бер кыланыш белән Зайцев:

— Чаллыга, үзәк шифаханәгә! — дип әмер бирде.

Әмма таксист егет ашыкмады.

— Тагы өч кеше утыртам әле. Простой өчен үз кесәмнән чыгарып түләргә мин буржуй түгел, — дип гамьсез генә утыра бирде.

Зайцев, уйланырга урын калдырмыйча, кырыс кына:

— Беркем дә кирәкми! — диде. Кесәсеннән тиз генә егерме бишлекне тартып алып, таксистка төртте. — Мә, тот, монысы аванс! Шәп җилдерсәң, тагын өстәрмен.

Шулкадәр акчаны күргәч, таксист та йомшарып киткәндәй булды.

Шыгырдап торган акчаны бумажнигына салып, кесәсенә тыкты да ялагайлана ук башлады:

— Баш өсте, әфәнде! Чаллыга, димәк, үзәк больницага! Кемегез ята? — дип сорарга җөрьәт итте таксист, олы юлга чыккач.

— Әнием.

— Шулаймыни... — диде шофер, пассажирның хәленә кереп.
Пассажирның сүзне озайту теләге булмаса да, таксист егетнең «теле кычытып торган» чак туры килдеме, әүвәлгечә ваемсыз гына сорашуын дәвам иттерде:
— Сезгә кем дип дәшик инде?
— Михаил Евграфович,— диде пассажир, күз кырые белән генә карап, көлемсерәп торды да,— Салтыков-Щедрин турында ишеткәнең бармы? Хәтерләсәң, минем исемне онытмассың.
— Патша заманындагы генералны әйтәсезме?
— Ха-ха-ха!.. — Пассажир үз-үзен тыя алмыйча, шаркылдап көлеп җибәрде.
— Уку тәтемәде миңа, — дип башлады таксист офтанып. — Дүрт классны уку дисәң инде... Ятим үстем мин. Мал көттем. Аннары — хөкем. Үсмерләр колониясе. Рульборгаларга шунда өйрәнгән идем. Әй, мин күргәннәр! Хәзерге пижоннарның төшенә дә керми алар.
— Колониягә эләгерлек нишләдең ул кадәр? Кем, ә-ә, Мансур?
— Юләр чак. Авыл кибетен баскан идек. Онытылып бетте дигәндә генә тоттылар да яптылар.
Гәпләшеп бара торгач, озын юлның үткәне сизелми дә калды. Таксист «Волга»сын ишегалдына кертеп туктатты да, пассажирына таба борылып:
— Михаил Евграфович, үзәк больница шушы була, — диде. — Миңа нишләргә?
— Нишләргә икәнен чыккач әйтермен, Мансур. Көтеп тор!
— Озакмы?
— Алдан әйтүе кыен.
Чемодан тоткан пассажирның пыяла ишектән кереп китүе булды, таксист машинасын шифаханә бинасының артына ук чигерде дә, рация трубкасын кулына алып, сөйләшә башлады:
— Тыңлыйсызмы? Яздырып барасызмы? Яхшы. Полковник Хәернасов белән тоташтырыгыз әле... Иптәш полковник, кече лейтенант Шаһинуров бу. Сез дә тыңладыгызмыни? Рәхмәт, иптәш полковник. Өстәмә боерык булырмы? Яхшы. Рацияне әзер тотармын.
Шаһинуровның пассажиры илле ике минуттан әйләнеп чыкты. Кулында шул ук чемодан иде. Тиз-тиз генә машинага кереп утырды да, ишекне япмас борын ук, арттан куып җитмәсеннәр дигәндәй, ашыктыра башлады:
— Аэропортка!
— Бигешкәме? — дип тавышын кечәйтеп сорады.
— Бигешкә булмый, кая булсын! — дип, пассажир кәефе кырылганын сиздерде.
— Бездән Бөгелмә белән Минзәлә аэропортына да йөриләр,— диде таксист беркатлыланып.
— Бөгелмә, имеш, — дип мыгырданды пассажир, — шайтаныма кирәкмени ул миңа. Төнлә үк миңа Казанда булырга, иртә белән Мәскәүгә очарга кирәк. Аңлыйсыңмы син шуны, Мансур?! Мәскәүгә!
— Айн момент, Михаил Евграфович, — дип таксист тизлекне арттыргандай кыланды, әмма машинасын бормалы тыкрыклар аша бормәбер озын юлдан алып китте. Монысын хезмәттәшләре аэропортка алданрак барып җитсеннәр, әзер торсыннар өчен эшләде ул.
Аэропорт мәйданына килеп туктагач, пассажир, урыныннан кузгалмыйча, кесәсеннән тагын бер егерме бишлек тартып алды да таксистка сузды:
— Мансур, Казанга нәүбәттәге рейска билет алып чык әле, — диде мөлаем гына.
— Кадерле Михаил Евграфович, безгә дәүләт машинасын калдырып йөрү тыела. Катгый рәвештә тыела!

— И-и, каһәр суккыры, шул тәртипләрен! — дип, кәефе кырылган пассажир аэропортка табан атлады.— Көтеп тор!

Урындыктагы чемоданны күргәч, шофер:

— Әйберегез калды, Михаил Евграфович,— дип аны туктатмакчы булды.

— Беләм, беләм, — диде пассажир, борылып карамыйча гына. — Көт диделәр бит сиңа!

Бу юлы да рация яхшы эшләгән булып чыкты.

Үзен «Михаил Евграфович» дип таныштырып пассажир төнге икенче яртыда оча торган самолетка кулдан билет алып чыкканчы милициянең эше җайланган иде инде.

Бигештән Казанга оча торган самолетка менмәкче булып аягын трапның беренче баскычына сузуы булды, таксист егет озатып калган озын буйлы пассажирны кинәт ике яктан култыклап алдылар. Таксист егетне шул арада җир йоткан диярсең. Типсә тимер өзәрдәй бу ир-атлар да, артында басып торучы милиция сержанты белән аэропорт хезмәткәре дә аңа ят иде.

— Нишлисез сез? Мин исерек түгел ич! — дип ярсый башлады пассажир.

— Мин милиция капитаны Соловьев! Сез бу самолеттан калдырыласыз!

— Ни өчен? Нишләгән мин ул кадәр!

— Кеше билетын кулланган өчен,— диде аңа капитан сабыр гына.— Билетны өч-дүрт бәягә артык түләп, «спекуляция»гә ярдәм иткәнегез өчен!

— Ничек түләсәм дә, үз акчам!

— Нишләп самолетка яшереп чемодан алып керәсез? Эчендәге әйберләрен махсус караучыларга күрсәтү дә юк!

Пассажир тешен шыгырдатып:

— Чемодан, имеш! Минеке түгел ул! — дип, аны чөеп кенә җибәрмәкче булган иде, барып чыкмады. Коля чемоданны үз кулына алды.

— Ярый, Зайцев! — дип, Зәйнулла беренче мәртәбә пассажирга үз фамилиясе белән эндәште. — Бу турыда, Степан Григорьевич, түкмичәчми тикшерүчегә сөйләп бирерсез.

Җәнҗал куптарган пассажир басыла төште, артык карышмый гына кызыл билле милиция машинасына кереп утырды.

— Зайцевны кертегез! Чакыртылган кешеләр әзер торсын.

Бер минут та үтмәде, Зайцевны алып килделәр. Зәһәр күзләрен тикшерүчегә кадады ул. Камалиев исә үзенең кем икәнен, сорау алу өчен чакыртканын, сөйләшүнең магнитлы тасмага язылачагын аңлатып, беркетмәгә Зайцевның имзасын куйдыртты. Зайцевның кулга алынгандагы ярсулары басылган иде инде. Шуңа күрә сөйләшеп китүе кыен булмады.

Камалиев, өстәл тартмасыннан Бигештә сатылган яшькелт авиабилет алып, Зайцевка күрсәтте:

— Бу сездән алындымы?

— Әйе.

— Нишләп ул Зиновьев исеменә язылган?

— Кулдан сатып алдым.

— Ничә сумга?

— Үз бәясенә инде, сигез сумга.

Звонок төймәсенә басып, тикшерүче Зиновьевны чакыртты:

— Бу кешене беләсезме?

— Белмини! Билетымны саттым мин аңа. Бик ялварып сорагач.
— Күпмегә?
— Егерме бишлек тоттырды да, үзе чыгып шылды. Акча милициядә. Шаһитка чыгып торырга кушылды.
— Степан Григорьевич, сезгә бер киңәш: авызыгыз кыек булса да, сүзегез туры булсын.
— Зиһенем таркалган, оныткanмын.
— Нишләп һава транспортыннан файдалану кагыйдәләрен бозасыз?
— Кызым Казан больницасында ята, хәле авыр, ашыктым.
Тикшерүче кабат звонок төймәсенә үрелде.
Зайцевның кызы Казаннан кайтартылган, аннан тиешле сорау алынган иде инде. Камалиев бу очракта аны бер генә җавап ишетер өчен чакыртты:
— Маша, синең больницада ятканың бармы?
— Ю-у-ук,— диде кыз сузып, үзе бер әтисенә, бер Камалиевка карап алды.
Зайцев кызарынып-бүртенеп урыныннан сикереп тормакчы булган иде, тикшерүче, уң кулын күтәреп, кузгалмаска ишарә ясады.
— Бердәнбер билет өчен бөтен гаиләне пыран-заран китермәсәгез... — дип мыгырданды Зайцев.
Звонок төймәсе хәрәкәткә килде. Казанда билетыннан колак каккан тузгак баш ишектән атылып керде.
Зайцевның йөзе кинәт үзгәреп китсә дә, ул үзен тиз кулга алды.
— Билетыгызны кемгә саттыгыз?
— Шушы пижон суырып алды, — дип, тузгак баш Зайцевка төртеп күрсәтте.
— Ничә сум түләде?
— Егерме биш, өстәп тагын бер ярты.
Тикшерүче туктаусыз һөҗүм итә торды.
— Бу кем чемоданы?
Зайцев йөзен чытты:
— Белмим.
— Пижонныкы! Аракыны шуннан алып бирде, — диде тузгак баш теш арасыннан.
— Исәнмесез, Михаил Евграфович! Бу чемодан сезнеке бит, әйеме? Әйбәт чемодан! — диде «таксист» Шаһинуров иске танышын очратканга куанган кебек итеп.
— Больницага кергәндә бу кеше кулында нәкъ шушы чемодан иде, — диде шифаханәнең төнге дежуры.
— Чемоданның дүрт җирендә сезнең бармак эзләре табылды, менә, укыгыз, — дип, тикшерүче фоторәсемнәре-ниләре белән экспертиза нәтиҗәсен сузды.
— Нәрсәгә ул миңа! — диде Зайцев дорфа гына, — Чемодан йөрткән өчен дә хөкем бармыни хәзер?
— Чемоданда мышьяк кушылган коньяк йөрткән өчен бар! Җинаять кодексы, 224 нче статья.
Зайцев корт чаккандай сикереп торды. Күзен акайтып:
— Ялган бу! Белеп сөйләшегез! — дип акырынырга тотынды.
Зайцев бераз тына төшкәч, Камалиев уң яктагы тартмадан печать сугылган рәсми заключение алып селкеде:
— Фәнни-химик экспертиза нәтиҗәсе булыр бу, Зайцев. «Кешене үтерү өчен егерме-утыз грамм мышьяк җитә»,— диелгән монда.— Менә экспертизаның икенчесе! Агулы коньяк шешәсе белән бөкесендә дә сезнең бармак эзләре ярылып ята.
— Чепуха! Бар да юк сүз! — дип, Зайцев күкрәк киереп бәхәскә

керде, зур-зур йодрыклы кулларын селтәп: — Шаһитыгыз кая? Шаһит, дим, шаһит!... — дип кычкырынырга тотынды.

Тикшерүче шуны гына көтеп тора иде.

...Күренеп яисә аңлашылып торган куркынычка караганда билгесезлек авыррак кичерелә. Кеше нәрсәдән сакланырга, нәрсәдән курыкмаска кирәген алдан белмәсә, гадәттә, иң начарын күздә тота. Әгәр нинди куркыныч янаганы билгеле булса, каршы тору яки яраклашу юлларын эзли. Билгесезлек аны тынычсызлый, ул булачакны алдан төшенергә тели, шуның аркасында хәлне дөрес бәяләү сәләтен югалта.

Теләсә, теләмәсә дә Зайцев үз-үзен шундый язмышка дучар итте.

— Шаһит та булыр, — диде Камалиев кырыс кына, бу юлы төймәне батырыбрак басты.

Ишектән Головин килеп керде. Өстәл каршында тукталып, иске дустына сәлам бирде. Зайцев, аптыравыннан нишләргә белмичә, күзләрен уып алды.

— Илларион Зотович, сез бу кешене беләсезме? — дип сорады Камалиев.

— Белмәскә, заманында бер үк футбол командасында иң шәп уенчылар идек без, ул авиация институтыннан, мин университеттан. Ул — һөҗүмче, үзәк бомбардир иде. Җитезрәк тә, көчлерәк тә, хәйләгә дә бик бай иде Степа. Кушаматы да «Ярканат» бит аның.

Камалиев кинәт агарып чыккан Зайцевка карады, өскә таба очланыбрак, тырпаеп торган зур колаклары аны чыннан да ярканатка охшата иде.

Камалиевның соравына каршы Головин:

— Әйе, ул көнне Степа миннән мышьяк сораган иде шул, бик ялынгач теш поликлиникасы адресын биргән идем, — диде галим.

— Бутыйсың, картлач! Узган ел булган хәлне сөйлисең, — дип, Зайцев дустын бүлдермәкче булды.

Бу юлы инде Головин аптырашта калды.

Тикшерүче шуны гына көткән кебек, алдан хәстәрләп куелган техник җайланманы тоташтырды. Бер-ике секунд шытырдап торганнан соң, магнитофон телгә килде. «Иля, синме бу! Үзгәрешләр бармы?.. Портфельне сездә калдырып торам... Юк, бозылырлык әйбер юк... Ике-өч атнадан киләсем бар, шул чагында алырмын...»

— Илларион Зотович, үз тавышыгызны танудыгызмы?

— Әйе, танудым, Степан белән телефоннан сөйләшкән идек.

— Кайчан булды ул сөйләшү?

— Быел, 26 августта...

Головин сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, теш арасыннан гына әйтелгән сүзләр ишетелде:

— Их, җүләр баш, кемгә ышанганмын бит, ә?! Камалиев, әйтегез әле, вак-төяк сорау белән газаплаудан хәзер ни мәгънә! Барысын да беләсез икән бит! Нишләп баштан ук кулга алмадыгыз? — дип өзгәләнергә тотынды Зайцев. — Их, җүләр баш, нишләп элегрәк сизмәдем икән мин бу тозакны? Барын да сөйләп бирдемени инде ул тинтәк?..

«Матусовмы?» дигән сорау тел очында эленеп торса да, тикшерүче эндәшмәде. Сүзең көмеш булса да, дәшмәвең — алтын чак иде бу. Зайцев түзмәде:

— Саткан икән дура! — дип чалт итеп идәнгә төкереп куйды.

Камалиев ялгызы гына калгач, Зәйнулла Казаннан алып кайткан беркетмәне укырга тотынды. Анда энциклопедиядән күчерелгән юллар да бар иде.

«Мышьяк — кайбер минераллар составына керә торган химик элемент, көчле агулы матдә. Шул матдәдән ясалган препарат медицинада һәм техникада кулланыла...»

«Кайсы тешең сызлады икән синең, Зайцев? Алгысымы, уртымы? Әллә акыл тешеңме?..» — дигән уй үтте Камалиев күңеленнән.

«Ярканат — имезүчеләр классына керә торган җәнлек. Очуга бик яхшы җайлашкан, ауга караңгыда чыга. Көндез, аулак урыннарга яшеренә, аяклары белән ябышып, баштүбән асылынган хәлдә йоклый...»

Зайцевка укыганда ук «Ярканат» кушаматы takканнар. Гади бер шуклык кынамы бу, әллә моның берәр хикмәте бармы?



## 15

Нина йокыга китә алмыйча төнне борчылып үткәрде. Тик палатадагыларга берни дә сиздермәскә тырышты. Мендәренә капланып елап алды. Аннары кәгазь, конверт, авторучка сорап алып, әнисенә хат язарга утырды.

Нәкъ менә шушы вакытта милиция бүлегендә Камалиев белән майор Трофимов Нина хакында сүз алып бара иде.

— Аның һәр адымы күзәтү астында, Вилдан Галиевич, — диде Трофимов. — Бу ягы тәртиптә. Тик мине борчыган бер нәрсә бар: әгәр дә ул гаепле булмаса?

— Хискә бирелмик әле, майор, — диде Камалиев. — Капитан кайтуга, мин дә берәр яңалык ачармын, шәт.

— Аңлашылды, — диде майор. — Сез үзегезнең девизга турылыклы инде: «җиде үлчәгән — ялгышмас».

— Теләсә нинди ялгышны гафу итсәләр дә, мин үз ялгышымны гафу итә алмыйм. Безнең эштә ялгышу — кеше язмышын чәлпәрәмә китерү бит ул.

Нина, хатын тәмамлап, конвертка салды. Адрес язып, аны мендәр астына тыкты. Бераз уйланып ятты да, кабат балавыз сыгарга тотынды. «Мондый хатны алса, әнинең йөрәге ярылып үлә бит инде», — дигән фикергә килде ул. Хатны, конверты-ние белән ертып, коридорга чүп савытына ташлады да, туалет бүлмәсенә юынырга кереп китте.

Күп тә үтмәде, Нина Игнатюкның вак кына хәрефләр белән язылган хат кыйпылчыклары тоташ бер биткә ябыштырылып Трофимовка китерелде. Майор аны укып чыкты да Камалиевка юллады.

«Әни, кадерлем! Кичә үзеңне төштә күрдем: кара шәл ябынгансың. Мин хәтерләмим дә инде, андый шәлең бар идеме икән? Нигәдер эчем пошулы, күңелем тынычсыз. Монда озак яши алмам шикелле. Ник дисәң, тирә-ягымда адәм рәтле дусларым да юк. Эшләгән җирем — ялганчылар оясы! Үзем дә шул ялган упкыны кырында торам хәзер. Бу хатымда мин барлык туганнарым белән хушлашам. Хушыгыз, мине яман-начар итеп искә төшермәгез!»

Камалиев уйга калды. «Тирә-ягымда адәм рәтле дусларым да юк» — нигә өметсезләнә бу кыз? «Эшләгән җирем — ялганчылар оясы!» — нәрсәгә ишарәле Нина Игнатюк?

Якшәмбе көнне кичкә табан Игнатюкны врач бүлмәсенә сорау алырга чакырдылар. Камалиев аңарчы сатучылардан, инкассаторлардан сорау алган иде. Ниһаять, нәүбәттәге сорау Нинага бирелде:

— Инкассаторларга гадәттә күпме акча тапшыра идегез?

— Документлардан карый аласыз бит, төрле чакта төрлечә була инде ул.

— Кассада күпме акча кала торган иде?

— Зиһенем таралган, ни сөйләгәнемне дә аңлап җитмим, ахрысы. Кассада, гадәттә, ун-унбиш меңнән артык калмый иде.

— Ә шимбәгә каршы төндә кырык җиде меңнән артык калган, — диде тикшерүче.— Каракның бүресен улаткансыз!..

Нина Игнатюк белән төпле сөйләшү дәвалану тәгәлләнгәннән соң булды. Үзенә күрсәтелгән өч фоторәсем арасыннан Игнатюк Матусовны танымады. Тикшерүче Матусовны чакыртырга мәҗбүр булды. Нина башта бик текәлеп аңа карап торды да, җирәнгәндәй, иреннәрен бөрештерде. Өстәлнең икенче ягында, үзенә каршы утырган ир-атның кәяфәте чыннан да хатын-кызда уңай тәэсир калдырырлык түгел иде шул. Битен сакал-мыек баскан, өстендәге киемнәре керләнеп-майланып каткан. Кулларына сабын тимәгәнгә биш былтырдыр.

— Юк, күргәнем юк бу өрәкне! — диде Нина.

Камалиев аны кисәтергә мәҗбүр булды:

— Кимсетү сүзләрен онытып торырга киңәш итәм, Игнатюк. Бу бүлмәдә сез икегез дә бер дәрәҗәдә. Нина Матусовка яны беләнрәк борылып утырды. Тегесенең, киресенчә, каршысында чибәр хатын-кыз күргәч, күңеле күтәрелеп киткәндәй булды.

— Кызганыч, мондый асыл кош белән танышырга туры килмәде, гражданин начальник, — диде Матусов.

— Очратмавыгызга шөкер итегез, — диде Камалиев.

Матусовны озатканнан соң, Камалиев, ике пүнәтәй чакыртып, өстәлгә кабат өч фото куйды.

— Ашыкмыйча карагыз! Кайсын күргәнегез бар? — диде ул Игнатюкка.

— Мин белгән, күргән кеше юк болар арасында! — диде Нина кырт кисеп.

Камалиев звонок төймәсенә басты.

Кабинетка Нинаның бүлмәдәше Лиза керде. Сорау янә башланды.

— Бу кешене яхшы беләм, — диде Лиза, фоторәсемнең берсенә текәлеп. — Зайцев Степан Григорьевич, торак идарәсе начальнигы.

— Каян беләсез?

— Белмәскә! Нина янына килеп йөрде. Кунып та киткәләде. Өчдүрт тапкыр. Өйләнешергә дә озак калмаган иде инде.

— Рәхмәт, Лиза, чыгып торыгыз.

Лизаның чыгып китүе булды, Игнатюк телгә килде:

— Ышанмагыз! Көндәшем ул минем. Яла бу!

Үзәк больница врачы да:

— Менә монысын күргәнем бар, — дип, Зайцев фоторәсемен кулына алды. — 26 августта мин төнге дежурда чагында чемодан тотып керде, Нина Игнатюк белән очрашырга рөхсәт сорады, илле сум акча бирмәкче булды. Алмадым, әлбәттә. Артына тибеп чыгарырга иде дә, тешемне кысып булса да түздем. Хәернасов сүзен тыңладым инде. Кем икәнен әйтми-нитми мыштым гына кереп китмәкче булган иде дә бит, барып чыкмады. Төн уртасында больницага ят кеше кертү уен эш түгел! Документларын тикшереп, энәсеннән җебенә кадәр журналга теркәп куйдым. Зайцев аның фамилиясе, Степан Григорьевич, инженер булса кирәк. Шулай диде.

— Мин Зайцевны белмим! — диде Игнатюк, врач сүзләренә каршы.

Нинаның больницадагы бүлмәдәше дә шуны ук раслады.

— Белә ул, шушы рәсемдәге Зайцевны белә Нина! — диде. — Якшәмбе иде. Төнлә килеп керде, аптырап калдым. Башта ут яктысында, аннары сүндереп дә пышылдаштылар.Ниләр генә кыланмадылар! Степушка да Степушка! Нинуся да Нинуся! Назлану дисеңме, коньяк чыгарып эчәргә маташу дисеңме — берсе дә калмады.

— Коньяк?! Нинди коньяк? — дип бүлдерде Камалиев.

— Биш йолдызлы, грузинский.

— Шушы түгелме? — дип, тикшерүче сейфтан өстәлгә бер шешә коньяк алып утыртты.

— Нәкъ үзе! — диде Маша. — Эчәргә ирек кенә бирмәдем. Врач чакырмакчы булып урынымнан торгач кына, Зайцев стакандагы коньякны кире шешәгә салырга мәҗбүр булды.

— Бәхетегез, эчмәгәнсез! — диде тикшерүче. — Зайцев чемоданыннан мышьяк кушылган шушы коньяк табылды. Кешене үтерү өчен утыз граммы җитә.

— Маша, нәрсә сөйлисең син! Болар бар да ялган бит! — дип кычкырды Игнатюк.

— Нишләп ялган булсын? — диде Камалиев сабыр гына, өстәл тартмасыннан кәгазьләр алып. — Менә тентү беркетмәсе. Болары чемоданында табылган әйберләр, акча, фоторәсемнәр. Монысы химик экспертиза нәтиҗәсе. Рәхим итеп танышыгыз.

Маша өстәлдәге кәгазьләр өеменнән күзен алмыйча, нәрсәдер хәтерләп торды да:

— Юк, Нина, алай дип авызны томалама! Ул егетеңнең акча биреп калдырганын да ялган диген тагын!

— Нинди акча? — Тикшерүче аягүрә басты.

— Зайцев калдырган акчаны әйтәм мин, — дип кабатлады Маша. Телефонны алып, Камалиев дежурный аша хатын-кыз милиция офицерын һәм тагын пүнәтәйлеккә ике хатын-кыз чакыртты. Аларга Маша күз алдында тентү үткәрергә кушты, үзе, ир-ат пүнәтәйләр белән, чыгып торды.

Күп тә үтмәде, Камалиевны чакырып керттеләр. Нина Игнатюкның эчке кием астыннан унсигез данә йөзлек акча табылган икән.

— Игнатюк, нинди акча бу? — дип сорады аннан тикшерүче, өстәлдәге акчага күрсәтеп.

— Сахалиннан кайткан акча! — диде Игнатюк.

— Нишләп яшереп йөртәсез?

— Акчага мин хуҗа! Ничек телим, шулай йөртәм.

Тикшерүче:

— Җинаятьченең икенчесен кертегез! — диде.

Степан Зайцевны майор Трофимов алып керде. Камалиев каршында утырган хатынга бер генә сорау бирде:

— Игнатюк, сез бу кешене беләсезме?

Нина беравык телдән калгандай эндәшми торса да, элеккечә үк нык иде әле:

— Беренче күрүем.

— Ә сез, Зайцев?

Степан иелгән башын бераз турайта төште. Аның юка, каны качкан иреннәрендә зәгыйфь елмаю чагылды.

— Әйе, беләм, — дигән тоныктавыш ишетелде. — Нина Игнатюк бу.

Кыз күз аллары караңгылануын тойды. Барсы да чәлпәрәмә килде. Шулай да ул тел тибрәтерлек көч тапты:

— Су бирегез әле.

Вилдан Камалиев сузган стакан Нина кулына күчте. Тикшерүче аның озынча, нәфис бармакларына игътибар итте. Стаканның кыры Игнатюкның уймактай авызы янында тукталганын, терекөмештәй су тамчыларының сизелер-сизелмәс кенә кыймылдаган сусыл иреннәр арасында югалуын дикъкать белән карап торган Вилдан чибәр, каһәр, дип уйлады кыз турында!

— Ә сез, Игнатюк, хәтерләдегезме инде?

— Мин аны ир кеше дип торам тагын! — Нина аягүрә басты, башын арткарак чөеп,— Алтын дип йөргәнем бакыр бер тиен икән. Күгәргән бакыр! — диде тәкәббер тавыш белән.

Кулга элэгү Зайцевка эллэ ни тээсир итмэгэн кебек. Карашы чая, үзен интеллигентларча тотарга тырыша. Эмма ул үзенең кечсез икэнен аңлый, хэзер инде кулыннан берни дэ килмэгэнен яхшы белэ. Ул бүген таудан түбэн шуып баручы боз кисэген хэтерлэтэ. Аны экренэйтү дэ, туктату да мөмкин түгел! Зайцев күрсэтелгэн урынга утыргач, тикшерүче Матусовка сорау бирде:

— Бу кешене белэсезме?

Матусовның болай да тар маңгае, җыерылып, тагын да тарая төште, күзлэрендэ дэ, үзе эйтмешли, «ниндидер этлектэн» шиклэнү чагылып үтте:

— Белмим, гражданин начальник, үтерсэгез дэ белмим. Гомеремдэ беренче күрэм мондый ыспай джентельменны, моңарчы аралашырга туры килгэн кеше түгел.

— Э сез? — Камалиев, кисэк борылып, Зайцевка эндэште.

Степан көлемсерэде, Матусовка карап торды, аннары Камалиевка төбэлеп:

— Кайдадыр күргэнем бар төсле, гражданин следователь. Тик хэтерлэп бетерэ алмыйм. Томан эчендэге кулэгэ шикелле генэ, — диде.

— Яхшылабрак уйлагыз. — Тикшерүче өстэл тартмасыннан акча чыгарып, папка өстенэ куйды. Матусов кесэсеннэн алынган йөзлеклэр иде алар. Аларны күрү белэн Зайцев кычкырып җибэрде:

— Э-э, кибет янында яткан исерекбаш!.. Хэтерлим, хэтерлим. Пиджагы таныш.

Матусов коелып төшкэндэй булды, ялварулы карашын тикшерүчегэ төбэде:

— Аралагыз бу нахак бэладэн, гражданин начальник. Мин аны белмим лэбаса, ул мине каян белсен ди?

— Менэ шуны ачыклыйбыз да инде, — диде Камалиев. — Сез, Матусов, камерага кайтыгыз, кирэк булсагыз, чакыртырмын.

Моны нэрсэгэ дэ юрарга белмэгэн Матусов, артына борылып карыйкарый, бүлмэдэн чыгып китте.

— Я, сөйлэгез, Зайцев.—Камалиев папка өстендэ яткан акчаны алды.—Болары шушы кеше кесэсеннэн табылган йөзлеклэр. Нинди акча бу?

— Касса басуда ул катнашмады.

— Э резин перчатка? — Камалиев аны да, өстэл тартмасыннан алып, акча янына куйды.

— Бумы?.. Юл уңаеннан ясалган эксперимент кына ул! Эврика! — дип елмайган булды Зайцев. — Бирим дигэн колына, чыгарып куяр юлына, дигэннэр... кул астына үзе килеп керде бу сакалбай.

Камалиев, урындыкка утырып, магнитофон төймэсенэ басты.

— Бер нэрсэ дэ инкарь итэргэ җыенмыйм, гражданин следователь. Рөхсэт итсэгез, ашыкмыйча, эчемдэгенең барысын да чыгарып салыр идем.

Магнитофон тасмасы ике сэгать буе эйлэнеп торды.

— 1965 елда мин Казанда яши идем. Язмыш җиллэре ул калага безне кырык икенче елның көзендэ илтеп ташлады. Мин кечкенэ идем эле. Үсеп житкэч, Горбунов исемендэге заводта эшлэдем. Кичлэрен авиация техникумында укып та йөрдем. Бу җэһэттэн язмышыма үпкэлэрлегем юк иде, эмма торак ягыннан соңгы елларга кадэр игелек күрэ алмадым. Гаилэм белэн бер бүлмэдэ тордык — аны квартира диярга тел бармый, өч бүлмэле квартираның бер өлеше. Олы якта хатынның энисе яшэде. Аның буй җиткэн улы Валерий «төшерергэ» бик тэ ярата торган иде. Ничэ ел яшэдек — аек көнен хэтерлэмим. Кайтып керэ дэ, бөтен квартираның астын өскэ китерэ: шаулый-сүгенэ, савытсабаны кыра, эйберлэрне вата-җимерэ. Өченче бүлмэдэ тагын бер күр-

ше — Надежда Куклова яшәде. Монысының кыланышлары Валерийныкыннан да хәтәррәк иде. Көне-төне типтерә. «Бер утыруда бер литрны эчеп бетерер — исе дә китмәс!» — дип сөйлиләр иде аны. Кыскасы, өч бүлмәнең икесендә дә бәйрәм: көн дә мәҗлес, көн дә туй, ә безгә — кайгы-хәсрәте, тынычсызлыгы. Мин формулалар ятлап утырам, күрше бүлмәдә урындыклар оча, стеналар селкенә, тәрәзәләр чылтырый, икенчесендә «Камаринский»га типтерәләр. Аннары улыбыз туды. Исерек гаугасына түзеп торырлык хәл калмады. Алтмыш тугызынчы елның сентябрь аенда, ахрысы, хатыным үзе эшли торган мәктәпнең директорына гариза язып, фатир алуда булышуны үтенде. Директор аңа:

— Әгәр ирегез сезгә квартира бирерлек оешмада эшләмәсә, без булыша алыр идек, — дигән.

Мәктәп директорының һавадагы торнасына ышанып... хезмәт урынымны ташладым. Фатир фонды булмаган оешма эзләргә керештем. Сәүдә челтәре нәкъ шундый урын булып чыкты. Бер базага директор урынбасары итеп билгеләделәр. Озак та үтми, сәүдә министрлыгы каршында кибет директорлары әзерләү курсы ачылды. Мине шунда җибәрделәр. Өч айдан аны бик яхшы тәмамлап чыктым. Яңа урынга — магазин директоры урынбасары итеп күчерделәр. Эш ягыннан зарлана алмыйм — барысы да әйбәт иде, әмма квартира шартлары һаман искечә кала бирде. Балаларның күзенә исерек башларның кыланышларын күрсәтмәс өчен әллә ниләр бирер идем мин шул чакта. Хатын белән киңәштек тә, Түбән Кама, Чаллы якларына киттек. Түбән Камада инде төзелеш тәмамланып килә, ә Чаллыда әле яңа башланган гына иде. Мин соңгысында төпләнергә ниятләдем.

Холкым белән мин оптимист кеше, тормышны яратам. Дөньядагы һәр бөҗәк миңа дус, берсен дә рәнҗетмим, берсенә дә кул күтәрмим. Җәй көне елгада колач салып йөзүләр, урманда җиләк, гөмбә җыюлар, кошлар сайравын тыңлап утырулар — бөтенесе җанга якын, күңелгә юаныч. Мактанып әйтүем түгел, «бу дөньяда миңа да урын бирелгән бит, кояш миңа да нурын сибә!» — дип сөенә беләм мин. Кеше булып тууыма, яшәвемә шатланам. Кием-салымга табынмыйм, анысын да әйтим, ләкин үтүкләнмәгән чалбар, щетка белән чистартылмаган пиджак кигәнем юк. Кешеләрнең миңа карата нинди мөнәсәбәттә булуы мине кызыксындырмый да, борчымый да иде. Һәркемнең үз күзе, үз колагы — ничек күрә, шулай күрсен, ни ишетә, шуны ишетсен, моңа мыегым да селкенми. Тик бер уй баштан чыкмады: ничек квартиралы булырга? Өйле булу миңа бәхетнең иң олысы булып күренде. Хыялларның очы-кырые юк иде: эштән син туп-туры үз өеңә кайтасың, анда хатының, балаларың көтеп тора. Исерекләр жыры колагыңны ертмый, талаш-сүгенү дә ишетелми. Сигез ел буена шуларның барын да күреп-ишетеп торган күңел тынлыкка сусаган, уңайлылык эзли иде.

Сәүдә оешмасының кадрлар бүлегендә мине бик яхшы кабул иттеләр. Документларым белән танышкач, бер заводтагы сәүдә челтәре директорының урынбасары итеп эшкә алдылар. Сөенеп туймадым. Вәгъдә иткәч — бирерләр дип, квартира алудан да өмет өзмәдем. Заводтагы сәүдә челтәрен икегә бүлгәч, берсенең директоры итеп мине куйдылар. Анда 1972 елга кадәр эшләдем. «Бәхетсезгә — вакытсыз» дигән сүз хактыр — март аенда кибетләрнең берсендә янгын чыкты, мине эштән сөрделәр. Шулай да көенечем озакка сузылмады. Май аенда квартира алдык. Күптәнге хыялым!.. Анысы булгач, кайда эшләсәм дә мин бәхетле, шат! Сәүдә челтәреннән киткәч тә, эшкә төзү-монтаж идарәсенә кердем. Җитмеш өченче елның июль аенда коммуналь-торак идарәсе начальнигының урынбасары булып күчтем.

Сәүдә берләшмәсе директоры Нәгыймов белән моннан дүрт-биш ел элек танышкан идем. Башта без аның белән эшләдек: ул — беренче сәүдә оешмасының директоры, мин — икенчесендә башлык. Кибет ян-

ганнан соң директорлыктан ычкынсам да, мөнәсәбәтләр үзгәрмәде. Мин аның конторасында еш була идем. Товароведлары белән сөйләшәм, сатучыларга киңәшләр биргәлим — шулай йөрдем.

Игнатюкны беренче тапкыр горпромторг складында очраттым. Аның кем булып эшләвен дә, кайда торуын да белми идем әле. Житмеш өченче елның июлендә, директор янына кергән чакта, Нинаның өлкән кассир булып эшләвен белдем. Шулай бер вакыт аның кайда торуы да ачыкланды. Әбәткә кайтып бара идем, дүртенче каттагы бер квартира тәрәзәсеннән иске танышым Лизаны күреп алдым. Кыз да мине таныды, кул изәде. Вакытым бар иде, дүртенче катка күтәрелдем.

— Ни эшлисең монда, Лиза? — дим.

— Биредә яшим ич мин, — шушы бүлмәдә. Нина исемле кыз белән торабыз.

Нина дигәне шул Игнатюк икән. Тагын берничә көннән мин аларның икесен бергә очраттым. Йортлары яныннан торак конторасына хәтле озата бардым үзләрен. Лиза өйгә кереп китте, без Нина белән урамда калдык.

— Ашыкма, Нина, — дидем мин. — Кичкә табан, сәгать алтыларда безнең конторага сугылып чыга алмассыңмы?

— Нишләрбез анда?

— Сиңа гына сөйлисе сүзләрем бар, — дим.

Нина, бик ягымлы елмаеп, керергә вәгъдә итте.

Нәкъ менә шул вакытта мин Нина белән кассадан акча эләктерү турында сөйләшергә ниятләдем дә инде.

Төштән соң, кичке алтыга кадәр, төрлесен уйлап йөрдем. Ниңага бу тәкъдимне ничек әйтергә? Баш тартса, чигенү юлы бармы? Шаяртуга борып булырмы? Уйлап түгел, уйнап әйттем диярмен. Әгәр Нина риза булса, без ни эшләргә тиеш? Әлбәттә, жылы диңгез буена барып типтереп ятарга да ярый...

Уй-фикерләрем өермәдәй бөтерелә. Игнатюк ризалашмаса дип, шуңа әзерләнеп куйдым. Тик эчтә ниндидер шайтан котырта: нишләп риза булмасын, ди? Ул да бер генә тапкыр яши ич дөньяда!.. Кармакны шул яктан салып сөйләшергә булдым. Үзенә күрә бер психологик алым да иде бу. Чибәр кызга сүзем үтәрме? Аны күпләп акча юнәтү юлына этәрә алырмынмы? Ул чакта мине жинаять өчен жәза биреләчәген уйлаудан бигрәк шундый кызыксыну хисе биләде. Үзем дә аңлый алмаган тойгылар өермәсенең уртасында калдым мин, буранда адашкан кеше кебегрәк. Юлны күрмисең, ә үзең барасың да барасың. Мин әле үзем генә дә түгел, Нинаны да ияртергә жыенам...

Конторага әйтелгән вакыттан ун минутка алданрак кереп утырдым. Озакламый Нина да килеп житте. Дөресен әйтим, аның башында бөтенләй икенче нәрсә булган.

— Йә, сөйлә инде серләреңне, — дип сәер генә көлә, хыялына бирелеп, яңалык көтә.

Мин сүзне әйләнечтән башладым. Кызның дөньяга карашын ачыклыйсым килде. Мәхәббәте дә, көндәшлек темалары да — берсе дә калмады. Күбрәк мин сөйләдем. Сизеп торам: битләрем ут кебек яна, ләкин Нина моны күрми. Кичке эңгер-меңгер чак, мин электрны юри кабызмадым. Сөйлим дә сөйлим, сорашам да төпченәм: кайда туган, кайларда эшләгән? Киләчәк тормышын күз алдына ничек китерә? Ул, ихтимал, мәхәббәт сүзләре дә көткәндер миннән, шуңа өметләнеп килгәндер дә, бәлки. Тик мин андый сүз әйтергә ашыкмадым. Бервакыт ул бөтенләй күңелсезләнде. Кассадан акча алу турында сүз чыккач икеләнеп:

— Юк, юк, булдыра алмам мин моны, — диде.

Нина, минемчә, тәвәккәл кеше. Ләкин аның киреләнүе дә минем мәхәббәт сүзләренә саран булуым аркасында килеп чыкты булса кирәк.

Шунлыктан мин аны эшнең без дигәнчә тәмамланасына, алда мәхәббәт көткәненә ышандырырга тырыштым:

— Икеләнеп торасы юк, Нинуся, — дидем мин, аны кочаклап. — Бер селтәнүдә умырып алабыз да, мин — синеке, син — минеке! Анна-ры, карарбыз тагын. — Шулай аңа вәгъдә бирүемне абайламый да калдым. Кыз йомшара төште.

Без шулай бер-беребезгә сыенып озак утырдык. Нина минем җайга-рак тора башлады. Шунда мин аның кассадан акча эләктерүгә каршы килмәячәген аңладым. Бу мине тагын да кыздыра төште. Инкассатор-ның кассага кай вакытта килүен сорадым. Игнатюк төгәл сәгатен әйтте. Акчаны эш көне бетәр алдыннан килеп алалар икән.

— Ә кассада күпме кала?

— Ун мең, унбиш мең. Күбрәк калдырырга да мөмкин.

Шушы кадәресен ачыклагач, мин инде тартынып тормадым, читлә-теп сөйләүне дә кирәксенмәдем — турыдан ярып салдым.

— Акчалы булабыз, алайса, — дидем. — Бер көнлекне генә кулга төшерсәк тә...

Кочагымдагы Нинаның «Их!» — дип бер көрсенүе миңа җитә калды.

— Кай вакытларда кереп чыгу җайлырак булыр икән?

— Иң уңайлы, тыныч вакыт алтынчы яртыдан алтыга кадәр, — диде ул.

Бу вакытта касса бүлмәсендә Нина берүзе утыра икән. Акча тап-шыручылар инде китеп беткән, инкассаторлар әле килеп җитмәгән була. Аларга тапшыру өчен әзерләнгән сумканы тиз генә эләктерәм дә, табанны ялтыратам. Нина берара шау-шу күтәрми тора, соңыннан разбой салса да ярый.

Августның егермесе. Нинаның гадәттәгечә эш көне. Билгеләнгән вакытта конторага кердем. Әмма коридорда кешеләр күренгәли иде. Игнатюк үз бүлмәсендә утырса да, мин анда кермәдем, туп-туры ди-ректор кабинетына уздым. Анысы да бикле иде.

Пәнҗешәмбе көнне кич белән, касса урнашкан йорт янында йөрер-гә чыктым. Игътибар итмәсеннәр өчен эт тә иярттем. Озак йөрдем. Касса бүлмәсе һаман ап-якты. Сигез тулып, унбиш минут үткәч кенә ут сүнде. Мин Нина чыгасы подъездга якынлаштым. Бераздан ул як-ягына карана-карана килеп чыкты да тулай торакка табан атлады. Этемне ияртеп, мин дә шул тарафка юнәлдем. Шактый ара узгач, кыз-ның каршысына килеп чыктым, аны озата киттем. Караңгы төшә баш-лаган иде инде — безне күрүче-белүче булмады.

Ниләр сөйләштек — хәтерләмим. Мине ул чакта бер генә уй билә-де: «Әлеге коридорда кеше юк чагын ничек туры китерергә, кайсы ва-кытны сайларга соң?»

Тулай торак янында хәерле төн теләп саубуллашканда Нина сүз арасында гына әйтеп куйды:

— Бүген кассада кырык мең калды.

Мин сызгырып җибәрдем. Кырык мең!.. Ул йортта бернинди кара-вылчы юк ич! Касса бүлмәсенең биге ничек ачылганын да сынап ка-рарга өлгергән идем инде. Дөрес, акча сейфта ята, ләкин кулы тимер тота белгән кешегә әллә ни кыен булмас аны ачуы...

— Могҗиза! — дидем мин, шуларны уйлап.

Нина гаҗәпләнеп миңа карады:

— Нинди могҗиза турында әйтәсең?

— Моңарчы кассагызга беранең дә кермәвен, акчаның исән-имин ятуын әйтәм.

— Исең киткән икән! — сәер елмаеп, Нина подъездга кереп китте.

— Сабыр ит, кызый... — Кире чакырып чыгардым үзем. — Әйдә, тагын бер урап килик әле.

Мин аңа планны үзгәртергә туры киләчәген сөйләдем.

— Шулай хәл итәбез, Ниночка: кичке тугыздан соң, унынчы яртыда мин кассага «һөҗүм» итәчәкмен, белеп тор, — дидем. Ул баш кагып, минем ниятемне хуплавын белдерде. Коридор ишегенә ярый торган ачкыч минем кесәмдә иде инде. Аны Нина күрерлек итеп учымда уйнатып-сикерткәләп тә тордым. Игнатюк ишарәмне аңлады, ләкин авыз ачып сүз әйтмәде. Хәтерлим, кисәтеп тә куйдым әле:

— Акчаны гадәттәгедән артык җыйма! Бик аз да калмасын. Күлгә ятьмә салып, артны юешләтеп, балыксыз кайтырлык та булмасын.

— Борчылма, Степушка, балыксыз калмассың. Хәерле төн! — Нина сүз озайтып тормады, кырт борылып, тулай торак ягына юнәлде.

Иртәгесен, 24 августта, җомга көнне, кызым йокыдан сыкранып уянды. Аягы сызлый башлаган. Минем уйлар һаман бер якка каера иде, баланың сыкрануын да шул максатта файдалану шәп булыр дип фараз кылдым. Чыннан да, җае чыгып торуын кара. Кызны Казанга алып барам, больницага салырга була. Юл уңаенда, узып барышлый гына, кассаны да бушатып китәм, акчаны Казанда яшерәм. Кая баруымны Нинага әйтмим, ә өйдәгеләргә, күрше-күләнгә ашыгыч китүемнең сәбәбе бар: Машаны дәваларга илтәм. Моннан да уңайлырак вакытны юри көтеп тә таба алмассың!

Көндез үк юл хәстәрен күрә башладым. Җиһаншин белән сөйләштем, аэропортка илтеп куюын үтендем. Игелекле кеше ул, сүзне аяк аска салмады. «Күрше хакы — алла хакы», диде. Транспорт ягы шулай җиңел генә хәл ителде.

Нина белән очрашуга да әзерләндем. Өч кисәк бау, зур гына чүпрәк әзерләдем, газетага кара борыч төреп куйдым. Исәп итүемчә, алар барысы да кирәк булачак иде.

Көнем тынгысыз үтте, кичне җиткерә алмыйча интектем. Ары сугылдым, бире сугылдым, — ә эч поша, нәрсәгәдер ашкына. Ул мине үзенә тартып, ярсытып, ашкындырып торган билгесезлек, һаман ераклаша гына бара кебек. Кичке сигезләр тирәсендә Җиһаншиннарга кабат кердем. Ишекне хатыны ачты. Үзе гаражда булып чыкты.

Өйгә кайтып, «Язның унҗиде мизгеле» дигән картинаның уникенче сериясен карап утырдым әле. Менә кайда ул кыюлык, хәтәр романтика!

Кино беткәч, чама белән тугызынчы яртылар тирәсендә, кызыма юлга әзерләнеп торырга куштым да, йорт артыннан урап, касса каршыннан уздым. Нина күрсен дип. Шулай сөйләшкән идек. Касса бүлмәсендә ут янмый, урамдагы лампочкалар гына тоныкнур сирпи. Тәрәзәгә эленгән пәрдәләр арасында тар гына ярык калдырылган, шуннан Игнатюкның күренгәнен көттем. Ул ялт кына карап алды да, мине искәреп, артка чигенде. Мин, күкрәгемдә таулар актарырдай көч сизеп, атылып подъездга кердем. Нина коридор ишеген ачып ук куйган— әзерләгән ачкычымның кирәге дә булмады. Туп-туры кассага атладым. Йөрәк дөпелди, мин гүя йөгерешчеләр ярышында катнашам, беренчелекне бирмәскә теләп, алга ашкынам. Кинәт бөтен тәнем яна башлаганын тойдым, маңгайга тир бәреп чыкты...

## 17

Сорау алуны бүлдерделәр — телефон шалтырады. Зайцевны чыгарып торырга туры килде.

Сөйләшкәннән соң трубканы элеп, Камалиев, нидер исенә төшеп, Трофимовка мөрәҗәгать итте:

— Кара әле, майор, теге кара сакалны Кама буена алып төшәргә кушмыйбызмы? Матусовны әйтәм. Көннәр дә җылы тора, судан чыкмый ята торган көн... Бер кисәк исле сабын биреп, югыйсә, кызлар

кырын карый үзенә. Бая Нина Игнатюк аңа яны белән борылып утырды. Өрәк, ди.

— Җинаятьчеләрнең бер-беренә кушамат тагуы яңалык түгел инде ул.

— Анысы шулай, — тикшерүче майор янына килеп басты. — Хикмәт шунда, бу җинаятьттә Матусов катнашмаган. Минемчә, эшкә урнаштырырга кирәк үзен. Бер җиргә дә алмыйлар ди бит. Берәр идарә белән сөйләшәсеңме әллә? Аңарчы әйбәтләп юынсын.

— Аңлашылды! Монысын эшләрбез, Вилдан Галиевич. Тик елга буена ничек соң, конвой белән җибәртикме?

— Анысы кирәкмәстер... Болай итик: син аңа өч сәгать вакыт бир. Прокуратура тикшерүчесе юынып кайтырга кушты диген. Прокурорларга гына ышана ул, — дип көлде Камалиев.

Бераздан бусагада Матусов күренде. Күзләре уттай яна, борчылган да, ярсыган да шикелле.

— Гражданин прокурор, — бу юлы «прокурор» дип эндәште, — әйттем бит милиция миңа этлек эшли дип. Күрәсезме, нәрсә тәкъдим итәләр: Кама буена барып, рәхәтләнеп су кер, имеш. Бер уңайдан юынырсың да, янәсе. Качты дип, тагы статья чәпәрләр иде бугай. Чәпәми торсыннар әле!..

— Болай атлыгып керүең ошый миңа, — диде Камалиев. — Үзең өчен көрәшә башладың, димәк.

— Булмый бит ансыз, гражданин прокурор.

— Мин тикшерүче, прокуратура тикшерүчесе, — дип төзәтте аны Камалиев. — Нәрсә, Камада колач салып бер йөзәргә риза түгелмени син? Милиция дә рөхсәт биргәч, юынып килергә ярый, Матусов. Аннан кайткач, ирләрчә тагын сөйләшеп утырырбыз. Ризамы?

— Сез әйткәч, риза, — диде Матусов. — Мин бит тагын этлек эшлиләр дип торам.

— Ташла әле шул сүзеңне, Матусов! Бар, кайнар башыңны Кама суында сафландырып кайт.

...Тикшерүче магнитофон төймәсенә басты да, сөйләвен дәвам иттерергә кушып, Зайцевка ымлады.

— Без кассага кердек. Бүлмәдә ут янмаса да, урамнан төшкән уттан бөтенесе ачык күренеп тора. Нина сейфтан ике төргәк алып, миңа сузды. Аларны сумкага салып куйдым.

— Күпме?

— Кырык җиде мең! — дип пышылдады Нина.

Шундый зур сумма! Барып чыкмас бит, кире куяргамы әллә? Тик бу фикер шундук юкка чыкты. Башлаган эшне ярты юлда калдыру— егетлек түгел! Төргәкләр салынган сумканы өстәлгә куйдым да Нинага пышылдадым:

— Кулларыңны артка куй, бәйләп калдырам!

Ул карышмады. Игнатюкның кулларына бау урый-урый, тагын пышылдадым:

— Болай күп итеп калдырырга кирәкмәс иде, Нина.

— Суга кергәч, юешләнүдән шурләмиләр, Степан.

Аның сүзләре хурландырды: куркакка саный лабаса бу кыз мине! Тик шундук фикеремне үзгәрттем. Хатын-кыз башы белән ул шундый кыю булгач, мин сынатырга тиешмени инде? Юк, тәвәккәлгә дәрт өстәр өчен әйткәндер Нина. Баксаң, аның күңелендә комсызлык хисе дөрләгән икән. Ул минутларда мин моны аңларлык хәлдә түгел идем. Игнатюк үзенә тиясе өлешнең дә зуррак булуын теләгән, шуңа тырышкан. Мин усалланып эшкә тотындым. Нина Игнатюкның кулларын кат-кат урап бәйләгәч, бауларга борыч сиптем — эт эз алырлык булмасын! Кул-аяклары бәйләнгән кассирны бау белән урындыкка бәйләп куйдым, авызы-

на чүпрәк тыктым. Бушрак булып тоелды, кесәмнән ефәк кулъяулык алып, аны да өстәдем.

Алдан сөйләшү буенча, Игнатюкка сугарга тотындым. Кулым авырткапчы кыйнадым да касса ишеген сак кына яптым. Коридор ишегеннән чыкканда йөрәгем ярыла дип торам: күкрәк читлеген авырттырып ук тибә! Кисәтә сыман мин тинтәкне: «Кайт!.. Кайт!.. Кайт!..» Мин үземне азмы-күпме беләм: нервларым корычтай булмаса да, юк-бардан эреп китәрдәй балавыз да түгел. Мондый халәтем куркудан булмавын да беләм. Эшнең болай тиз пешүе таң калдырды, көтелмәгән җиңеллек калтыратты.

Коридор ишеген бикләгән ачкыч тавышы, пистолеттан аткандай, мине сискәндереп җибәрде. Як-ягыма ялт-йолт карандым. Коридорда кеше-кара күренми иде. Тып-тын. Ишекне дә бикләгәч, тынычланып, подъезддан чыгып киттем. Сәгатькә күз салсам, нибары биш минут узган! Тәүлектән дә озын булып тоелган минутлар...

Өйгә мин, яңа йортка нигез салу өчен казылган тирән чокыр аша узып, икмәк кибете яныннан урап кайттым. Ни күзләрем белән күрим — кибет янында бер исерек йоклап ята. Ни эшләгәнемне үзем дә аңышып җитмәстән, резин перчатканы аның кесәсенә салып куйдым. Берни сизмәде йокы капчыгы. Миңа шул гына кирәк тә. Касса коридорын ачарга яраклы ачкычны да кесәсенә тыктым. Китәргә дип борылганда гына башыма уй төште: «Милицияне ышандырырлык булсын өчен, моңа акча да төртергә кирәк ләбаса!..» Сумкадагы төргәкнең почмагын ерттым да ике йөзлекне ачкыч янына төрттем.

Калтырауларым басылды, тынычланып киткәндәй булдым. Кызык хәл: үз йортыбызга табан мин: эштән кайтучы кеше сыман, гамьсез генә кыяфәт белән, кулымдагы сумканы селти-селти атладым. Кем очраса да — курыкмыйм, янәсе.

Өйгә кайткач, сумкадагы тартмаларны, төргәкләрне сары портфельгә яшердем. Кассага киеп барган чүәкләрне дә газетага төреп шунда тыккан идем. Хәзер инде юлга чыгу өчен киенә башларга да була. Плащымны, кызымның киемнәрен хуҗалык сумкасына тутырдык. Нәкъ кирәк чагында гына Җиһаншин да, ишек шакып, килеп керде.

— Китәсе булсаң, әйдә, машина әзер, — диде ул.

Шәһәрдән чыгып барганда, милиция машинасы очрады, йөрәгем жу итеп китте. «Әллә сизеп тә өлгергәннәрме инде?» — дип уйладым. Ләкин кызыл билле, зәңгәр лампалы машина безнең яннан выжылдап кына узды. Миңа җан керде. Сәгатемә карадым, ун тулмаган иде әле. Унбер тулганда без самолетка утырдык. Кыскасы, төнге беренче яртыда Казан таксисты безне Гагарин урамына китереп җиткерде. Унлык бирдем үзенә. Менә кайда ул рәхәт тормыш! Акча дигәнең кешене үзгәртә икән, билләһи. Машинадан эре генә чыгып:

— Сдача кирәкми, — дип кул гына селтәдем.

Шулай итеп, егерме бишенче августта, шимбәгә каршы төндә мин үземнең җинаятьтә катнаша алмавымны расларлык эшләр башладым, шикелле. Үземчә, алиби инде бу. Минутына кадәр кеше күз алдында, барысы да исәпләнгән. Шул чакта мин кассага кереп, акча алып чыгу һәм урамдагы исерек кесәсенә резин перчатка белән ачкыч салу вакытын да хисапладым. Нибары сигез минут! Гаҗәп кыска арада эшләнде бу, ә сумкада нинди зур калҗа! Тик аны кая урнаштырырга?..

Төннең калган өлешен каенанам квартирасында күз дә йоммый үткәрдем. Барысы да йоклап беткәч, балконнан портфельне алып кердем, ванна бүлмәсендәге киштәгә күзгә бәрелеп тормаслык итеп урнаштырдым. Биш мең ике йөз сум акчаны алып, кесәләремә тутырдым. Тагын бер тапкыр рәхәтлек кичердем: күпме алсам да акча тиз генә бетәрлек түгел! Их, гел шулай яшәсәң икән ул!

Шимбә көнне иртән иртүк, каенанам белән кызыма зур-зур акча-

лар бирдем, күзләре шардай булды. Урамда хәрәкәт башлануга, туганнарыбызга киттем. Алар өйдә булмады. Күрше хатын миңа:

— Кичтән дачаларына киттеләр, бүген кайтулары икеле, — диде.

Көтеп торырга вакытым юк, таныш-белешләрне эзләргә ашыктым. Алиби кирәк! Кызны больницага саласы бар. Врачлар белән сөйләшергә кирәк. Йомышларым тавык чүпләп бетерерлек түгел. Иң зурысы — сары портфель! Кайда урнаштырырга?

Машаны дәваларга салуны бер танышым үз өстенә алды. Туганнарыма килеп төшкәндә, төшке ашлары өлгергән иде инде.

Яхшы гына сыйлангач, су буйларын сайран кылыйм дип чыктым. Менә хәзер елга буенда йөрсәң дә була. Җайлы урын табып, чүәкне, газетаны, төрлесен төрле төшкә, суга ташладым.

Күңелне тырнап торган әйберләрдән котылгач, туганнарыбыз белән рәхәтләнеп кәеф-сафа кордык. Ничек йокыга чумганымны, күпме шулай ятканымны белмим. Мин уянганда яңа көннең — якшәмбенең яртысы диярлек узган иде инде. Ашап-эчкәч, электричкага утырып, Казанга кайтырга чыктым. Күңелемдә борчылу хисе көчәйде. Акчаны кулга төшергән чакта мине очындырып йөрткән дәрт сүрелде, җанны тынгысызлык корты кимерә башлады. «Барыбер табачаклар бит!.. Табачаклар!..» Әйтерсең, вагон тәгәрмәчләре дә шул сүзне минем колак төбендә яңгыратып бара: «Та-ба-чак-лар!.. Та-ба-чак-лар!..»

Самолетка билет алырга кергән җирдә, Чаллы сәүдә оешмасыннан килгән бер иске танышка юлыктым. Аны-моны сиздермәдем, гадәттәгечә, ерактан ук сәлам биреп күрештек. Тик ул, очлы күз, каян сизгәндер, сорап куймасынмы?

— Борчылуың йөзеңә чыккан, Степан, берәр күңелсезлек бармы әллә?

— Кызым чирләп китте әле, — дим. — Үзеңдә ниләр бар? Сөйләшә-сөйләшә, ике урам аша уздык. Ул миңа касса таланганын әйтте. Мин, кызыксыну күрсәтмәсәм дә, ул кассирның үзәк больницада ятуын, үлем хәлендә булуын сөйләде. Аннары, үз итеп кенә:

— Монда, һичшиксез, тәҗрибәле юлбасар кулы уйнаган, — диде.— Берсе кулга алынды инде. Матусов дигән карак диләр. Дүртме-бишме тапкыр утырып та чыккан бер бәдбәхет. Кесәсеннән акча, резин перчатка, касса ачкычлары чыккан. Эшли дә соң бу милиция! Кайдан белә?

Тәннәрем чымырдап китте. Нинадан сорашып-төпченеп бөтенесен ачыкларлар да миңа килеп җитәрләр сыман тоелды. Тынычлыгым бөтенләй җуелды. Һәр кешедән шикләнәм, мине һәр адымда эзәрлекләп киләләр сыман. «Каракның бүреге яна» дигән сүзнең чын мәгънәсенә мин әнә шул көннәрдә бик яхшы төшендем.

Вакыйгаларың соңгысы сезгә инде мәгълүм».

— Зайцев, сезне касса басуга нәрсә мәҗбүр итте? — Мохтаҗлыкмы? Җиңел яшәргә омтылумы? Я, нәрсә?

Зайцев уйга калды. Мондый сорауны бирәселәрен ул, әлбәттә, көткән, ләкин аңа җавап әзерләп өлгермәгән иде сыман.

— Мохтаҗлыктан түгел, гражданин следователь. Эш хакларыбыз да аз түгел, хатынымныкы да, үземнеке дә яшәргә җитә. Квартира да әйбәт. Акчаны күбрәк эләктерергә омтылыш кайсы вакытта туганын мин яздым, ә сәбәбен үзем дә аңлап җитә алмыйм. Җан гадәттән тыш хәлгә сусаган, күрәсең. Башкача аңлата алмыйм.

— Янган кибетне искә төшерик, — диде тикшерүче, үзалдына сөйләнгәндәй, үзе Зайцевка туры карады. — Сез ут сүндереп йөрмәгәнсез, Зайцев, бәлкем, шактый симез калҗа эләктереп, шуның эзләрен яндыргансыздыр. Тикшерү җиңел юлдан киткән, сез шома гына котылгансыз...

— Ялгыш фараз! — диде Степан, тавышы калтырап чыкты. — Ул вакыйга үз вакытында тикшерелде, энә күзеннән үткәрелде.

— Тынычланыгыз, мин сезгә ул эш өчен дә статья билгеләргә җыенмыйм. Күрәсез ич, беркетмә дә язмыйм. Хәерле булсын, калган эшкә кар яуган. Әйтергә теләгәнем сезнең аппетитка кагыла. Магазин ялкыны итәгегезне көйдермәгәч, сез кыюланып киткәнсез. Сусаган җаныгызга азыкны башка җирдән түгел бит, сәүдә оешмасыннан, касса тирәсеннән эзләгәнсез. Нина Игнатюкка юлыгуыгыз очраклы түгел, ул — сез озак вакыт буе әзерләнеп килгән максат.

— Нахак! — диде Зайцев. — Шулай да сүзегездә логика бар, тик ул тормыштагы вакыйгаларга нигезләнми.

— Алайса, әйтегез: Нина Игнатюкның мәхәббәт хисләре белән нигә уйнадыгыз?

— Безнең арада ул хакта сүз булмады.

— Син — минеке, мин — синеке, дигән сүзләр... Яше үтеп барган кызга мондый вәгъдәнең тәэсирен үзегез дә беләсез.

— Минем аңлавымча, җинаять эшенә кагылмый бу мәсьәлә, гражданин следователь.

— Мин дә җинаять эше турында сөйләмим, җинаятьченең рухи дөньясына гына күз салам. Безнең күзлектән ул шактый вак җанлы кеше булып күренә.

— Мине хәзер бер фикер дә кызыксындырмый.

— Кызганыч!

Зайцев кылган җинаятьләренең бөтенесен дә икърар кылды. Артка чигенмәс өчен, әшәкелек юлындагы күперләрне яндыргандай булды.

Камалиев беркетмәгә кул куйдырды да, аны хөкем папкасына салды.

— Эшегез судка тапшырылачак, Зайцев. — Камалиев төймәгә басып, милиционерны чакыртты һәм җинаятьчене камерага озатырга боерды.

Тикшерүче телефоннан Матусовны кертергә кушты.

Матусов бусагадан ук кычкырып керде:

— Сез эндәштегезме, гражданин начальник?..

Кәефе әйбәткә охшаган. Кыяфәте дә баягы кебек түгел инде: юынган, чәчләрен тарап җибәргән. Бөтенләй икенче кеше.

— Мин чакырттым, — диде Камалиев. — Я, Кама суы җылымы?

Матусовның авызы колагына җитте.

— Оҗмах, гражданин начальник. Чыннан да минем муеннар каешланып беткән булган икән, бер кисәк сабын гына җитмәде.

— Шәп булган, Матусов! Тәндәге пычракны юып була, ә күңелдәге караны нишләтәбез?

— Соң... — Матусов күзләрен чет-чет йомгалады. — Соң, сез мине утыртып куясыздыр бит инде...

— Утыртмыйбыз шул, Матусов, иреккә чыгарабыз.

— Эшкә урнашып булса, билләһи, болай йөрмим, — дип кычкырып җибәрде. — Нихәл итим соң, бер җиргә дә алмыйлар бит!.. Бәлки, сез булышырсыз, гражданин начальник, ә?..

Нәкъ шул сүзне көткән иде Камалиев. Матусовның үз авызыннан эш турында сүз ишетергә кирәк иде аңа. Мәҗбүр итәләр диярлек булмасын, аз гына булса да ялыныбрак алсын ул эшкә җибәрү кәгазен.

— Эш турында син яратып бетермәгән милиция кайгыртты, Матусов, — диде Камалиев. — Менә сиңа кәгазь. Төзелеш идарәсендә иртәнге сигездә көтәләр үзеңне. Кичекми бар! Кичеккәнне тормыш кичерми.

## Абай Конанбаев

●

Кыран бөркет нәрсә генә алмас аулап?
Берәүләр йөри тилгән, козгын асрап,
Кыран очса, алар да җибәрәләр
Үзләренең ике кошын ике яклап.
Каркылдап козгын калмый арттан оча,
Ә тилгән өстән канат кага лап-лап,
Ауламыйлар, аулатмыйлар бөркеткә дә,
Ияләре атта, тузан китә каплап.
Соңра алар куаналар кошларына
Тотышмыйча, йөргән өчен комачаулап.
Ни файда мондый аудан диючә юк,
Йөри бирә һәрбере үз кошын мактап.
Моннан юк ни тәнгә, ни җанга азык,
Хәйран илем шулай яши үзен алдап...

●

Киң илем, казагым — ай, хәйран йортым,
Чәчтәраш юк, авызыңа төште мортың [1],
Яхшы белән яманны аералмадың,
Бере канда, бере майда ике ортың.
Эчтән келәч чыраең шундый әйбәт,
Кайдан гына бозылды соң болай сыртың?
Аңламыйсың үз сүзеңнән башка сүзне,
Авыз белән урак уру — бар да кыртың [2].
Үземнеке дия алмый үз малыңны
Көндез келкең качты йөздән, төнлә — йокың.
Күрсә-кызар [3] килә күзен бәйләмичә,
Тегеләй-болай итә, баса алмый кортың,
Бер-бер артлы биге менә гел вак-төяк,
Менә шул да ала инде илнең котын.
Тезәләр дип икеләнми әйтәлмыймын
Үз кулыңнан киткәчтен иркең, йортың.

Агай-эне кабарта юкка сыртын,
Аның да бозды, ахры, ходай холкын.
Берлек юк, бәрәкәт юк, эш сөю юк,

[1] Морт — мыек.
[2] Кыртың — буш сүз, күп сүз.
[3] Күрсә-кызар — бу урында кеше малына кызыгучы, барымтачы — мал талаучы.

Буталды бар байлыгың, баккан елкың.
Башта ми, кулда малга талаш ачкан,
Көч сынашкан көндәшлегең боза йортың.
Төзәлми эчтә йөрсә ачу, үпкә —
Ачылмас беркайчан да чырай-күркең.
Тыянаксыз, бәйсез пошыну дигәне дә
Файдасыз шул буш көлке дә, байгош йортым.
Сүз аңларлык бер кешегә туры килсәң,
Ул да пыш-пыш итә, шикле һәм астыртын.

●

Яңа карда бәркетчеләр чыга ауга,
Таудан төлке табыла аулаганда.
Бер ганимәт була шәп ат, яхшы юлдаш,
Өс-башың да килеп торса бик таманга.
Үзән буйлап киекнең юлын табып,
Яр башыннан канат җәеп эз алганда,
Бәркетче тау өстендә, бәркет аста, —
Күзәтү ансат болай аулаганда.
Томагасын[1] алу белән, ерактан ук,
Кыран бәркет үз корбанын сайлаганда,
Түбән очсам төлке тауга качар, диеп,
Канлы күз менсә үрләп һаваларга,
Туктап кала кинәт качып барган төлке,
Котылмасын белеп, табалмагач чара,
Әзерләнә талашырга тешен кайрап, —
Башкача әмәл калмый чебен-җанга,
Тамашаны күреп кәефле аучылар
Чаба атта, карамыйча егылганга.
Кырык пычак тешен ыржайтса да төлке
Була алмый карулашыр яу кыранга.
Аякларда сигез сөңге[2] хәрәкәттә —
Бәркет батыр тырнак җәйгән, калмый таңга.
Канат, койрыклар сызгыра һава кисеп
Кыран күктән шарлавыктай атылганда.
Айкашалар икесе ялт-йолт килеп,
Чыккандай ике батыр кан-мәйданга.
Берсе күк, икенчесе җир ерткычы.
Кеше өчен батышалар алар канга.
Кар ап-ак, бәркет кара, төлке кызыл, —
Шуңа охшаш сылу түшәккә ауганда:
Кара чәче дулкынланып, ике терсәк
Шулай кагына иреннәрдән суырганда.
Ап-ак тән, кып-кызыл бит, яп-ялангач,
Кара чәчләр сибелеп, күзләр йомылганда
Охшый сылу бәркет баскан шул төлкегә
Кияү белән тар түшәккә сыенганга.
Төлкенең дә уйный калак сөякләре
Кыран бәркет аска ботарлап салганда.
Бәркетә дә, хуҗасы да кукраеша
Җитмеш төрле хәйлә остасын алганда.
«Өере белән өч тугыз»[3] дип, шаян көлеп
Агасы мал бәйләсә тагын янга, —

[1] Томага — ау кошының күзләрен каплый торган күн маска.
[2] Бәркетнең тырнаклары.
[3] Өере белән өч тугыз — елкы (ат) бүләк иткәндә әйтелә. Өерең өч тугызга артсын дигән сүз.

Томакны[1] кыңгыр киеп насыбайны[2]
Бер атасың шулай кәеф килгән җайга.
Таудан җиләк җыйгандай күп киек алсаң
Шуннан да зур бәхет бармы икән ауда!
Күкрәгеңдә һичбер яман нияттең юк,
Тик ау гына була уйда кош салганда.
Бер кемгә дә бер зыян юк мондый эштән,
Бу бер күңел ачып йөрү сунарларда.
Җаны сизгер, күңеле хуш фикерлегә
Барысы да бик ачык бит уйланганда.
Күз алдына китерәлмассың ләкин тыңлап,
Ауга чыгып син үз күзең белән бер бак.
Хәер, оста сүзне мавыгып тыңлый бәндә,
Кызу көндә ял иткәндәй күләгәдә.
Шулай да аучы укысын моны, дуслар, —
Аңлашылмас сунар тәмен белмәгәнгә.

●

Җилсез төндә якты ай,
Шәүләсе суда дерелди.
Авыл арты — тирән сай[3],
Ташыган инеш гөрелди.

Агачларның яфрагы
Шыбырдаша, серләшә.
Күренми җирнең туфрагы, —
Үлән үскән тезгәчә.

Тау яңратып җыр чалып
Эт өрдереп як-якта,
Йөрмәдекме юл алып
Очрашырга аулакта?

Истәме оялганың,
Бер туңып, бер янганың,
Йотлыгып тын алганың,
Юкка каушап калганың?..

Сүз әйтәлмый тәелеп,
Каккан чакта йөрәгең,
Тормадыңмы сөенеп,
Муенга батып нягең?

●

Сызлана җаным,
Синсез күңелсез көнем.
Бетте бар хәлем,
Тәкъдирдән килде золым,
Әмер иткәч мәүля —
Ниләр күрми бәндә?

Сайрый бир, телем,
Сыкрап, сулып салкыннан.
Бегелде билем,
Ярым тангач антыннан.
Күңелдә гел сагыш,
Нигә мондый язмыш?

Сагындым сине,
Күрмәдем бит күп гомер.
Кеше дип мине
Хат та язмадың бит бер.
Бик кыйналды күңелем, —
Язмышыма күндем...

Әгәр бу зарым
Барып җитсә янына,
Сагыш-уйларым
Им булмасмы ярыма:
Уятмасмы аңын,
Эретмәсме җанын?

Казакъчадан НУРИ АРСЛАНОВ
тәрҗемәләре.

[1] Томак — бүрек.
[2] Насыбай ату — авыз тәмәкесе кабу.
[3] Сай — үзән.

## Газинур Моратов



*... Күңел түрендәге өметләрне, хыял-теләкләрне шигырь итеп кәгазьгә төшерәсе иде...*

*Үзем — Кукмара якларыннан. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыйм.*

*Миңа — 20 яшь.*

### Сабан туй

Мәйдан уртасында — ирләр, —
Алып батыр уллары.
Көрәшче халыкныкы ул —
Язгы сабан туйлары!

Бабайлардан калган йола
Бүген безне җилкетә...
Әнә мәйдан тын да алмый
Көрәш батырын көтә.

Я кем ул батыр көрәшче —
Ил йөзен акларлыкмы?
Туган җирен тирле залим
Затлардан сакларлыкмы?

Рухы нықмы, түзәрлекме,
Әзерме зур алышка?
Ныклы дәвам булырмы ул
Халкым улы Алыпка?

Бу көрәштә беркемгә дә
Юк бернинди ташлама.
... Татарның сабан туйлары
Алыплардан башлана.

●

Ничәнче төн тынгы бирми,
Нинди моң бу? Кайдан килә?
Әбкәм сүзе: былбыл түгел,
Җил дә моңлы туган илдә.

Читкә китеп тыңлап кара,
Ишетелер сагыш кына.
Халкыңа бак! Карама син
Мәнсез затлар ялгышына.

Ни кылмас ул «дальтониклар»,
Зәңгәр моңнар ни аларга?
Җирдә һәркем «халкым» диеп,
Тиеш ләса бер янарга.

Салкын кышта былбыл эзләп,
Туган җирен ташлаганнар,
Язлар җиткәч уйлар әле,
Уйлар да һәм бер көн аңлар.

Аңлар алар җилләр моңын,
Аңлар алар шагыйрь җанын.
Җиргә кадәр иелеп тә,
Сынмаганын горур талның
Аңлар алар.

...Ничәнче төн тынгы бирми,
Нинди моң бу? Кайдан килә?
Сәер хәлдер: әрнүләр дә
Шифа икән туган илдә.

●

Безне әле җилләр генә назлый,
Давыллары аның алда әле.
Омтылышлар, куәт, әйтер сүзләр
Җанда яна, бары җанда әле.

Учак булып яна һәммәсе дә.
Төрлебездән төрле җылы кала.
... Давылда тик олы учак кына
Дөрләп китә, үрләп китә ала.

●

Әй, балачак хыяллары,
Татлы көньяк җимеше.
Сине ашап койдык ич без
Сабыйлыкның сөт тешен.

Тәүге адым ясау белән
Омтылдык без ирлеккә.
Агач атны бәреп ваттык
Калсын диеп иректә.

Хыял-атта җилдердек без
Замананың каршына.
Буйлар бәләкәй булса да,
Рухи үстек аршынлап...

Кем ул анда шәрран яра
Уйдырма дип хыялың?
Йолкып өзәргә маташа
Хыял-атның ак ялын?

Кем оныткан Моабитның
Чөеп атылган чагын?..
Ак хыяллар саклады бит
Вөжданны — ирләр җанын.

Хыял-атта җилдердек без
Замананың каршына.
... Сабан туй күк гүли дөнья
Тояклар тавышыннан.

# Мөхәммәт Шәйхи



*Яшьлек шәһәре — Түбән Камада яшим. Шигырьләрем эштә, ял вакытында һәм «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә кызу бәхәсләр, шигърият турында сөйләшүләр вакытында туалар.*

*Язасы, халкыбызның үткәннәрен, бүгенгесен йөрәктән кичереп, киләчәк турында горур уйлар белән, зур шигъриятебезгә лаек образлар, сүзләр табып язасы килә.*

## Әйтеләсе уйлар...

Мин җир буйлап барам...
Авазлардан
бөтен дөнья тора яңгырап...

Әйтеләсе уйлар
тынгы бирми
талпыналар һаман сүз сорап...

Ирек сорый уйлар,
мәйдан сорый,
тарсыналар күңелем читлеген.

Башка уйлар ачкан
бу киң галәм
алар өчен генә чит мени?!

Башкаларга
хас сыйфатлар бары да —
Сөю, Яну, Нәфрәт, Борчылу.

Ә тарлыкка
Сыеша алмый икән, —
Уйларымның, димәк, ул чыны!..

## Сабыр уй

Кырпак төшкән болын буйлап атлыйм,
Ерак әле таңга.
Күктә чекерәйгән йолдызлардан
Салкын коела җанга.

Һава салкын. Әле юкса бары
Кышның башы гына.
Моңга чума торган бу тугайлар
Күптән йоклый сыман.

Изрәп ята болын тынлык сарган
Төннең кочагында.
Их, бер янган гашыйк гармун уйнап
Чыкса шул чагында,

Җырлар идек икәү ярсый-ярсый,
Бу тынлыкны тетеп...
Бар әле, бар йоклый алмаучылар
Безнең моңны көтеп.

## Давыллы уй

...Күтәрелде давыл,
Тыныч елга
Танымаслык булып үзгәрде,
Ярда көймә көткән кешеләрнең
Болыт сыман сары йөзләре...

Актарылды елга,
Ярсып-ташып
Тал-тамырлы ярын кыйнады...
Чишеп салган кебек үпкә-зарның,
Ачуларның эчкә җыйганын.

Көймәләрне чөйде әллә кая,
Кешеләрне куды ярыннан.
Әйтерсең лә алар комачаулый
Бер чишелеп-бушап алырга...

... Килгән кебек үтеп китте давыл,
Әйтерсең лә берни булмады.
Гаепледәй ярын килеп үбә
Вак дулкыны нәни елганың, —
Мыштым гына калып элеккечә
Акланырга сәбәп эзләве.
...Ярда көймә көткән кешеләрнең
Кояш сыман балкый йөзләре.

## Риваятьле уй

Урманнарга керсәм, чыга алмыйм,
Чакыра үлән баскан юллары —
Җәя керешен тартып чыгар төсле
Тугызак әбекәйнең уллары.

Шундадыр дим, урман ешлыгында
Канкай егетләре ял итә...
Сызгырам да, тик кайтаваз гына
Ераклярга яңгырап гел китә...

Зәңгәр шәлле Мәйсәрәсен алып
Булат чыгар төсле каршыма.
Бәреләсугыла куркып очып китә
Мине күргәч арык карчыга.

**Риза Ишморат**

# ЗАМАНДАШЫМ

ОЧЕРК



Дөньяның иң матур почмагын бер күреп кайтыйм әле дип, Актаныш якларына килеп чыксаң, ашаган нигъмәтләреңне әзерләүче колхозлар хәле белән дә бераз кызыксынсаң: «Районда иң алдынгы колхоз кайсысы?» — дип сора син, дустым, теләсә кемне туктатып сора. Ул бераз уйланып торыр да (чөнки алдынгылар әз түгел):

— «Коммунизмга» колхозы, — дияр.

— Ә иң алдынгы колхозның председателе кем?

— Ул колхозның җитәкчесе Гарипов Кәрам.— Тулырак булсын өчен, Гариф улы дип тә өстәп куяр, җитәкчеләрдән сорасаң, алар да шул сүзне әйтер.

Кәрам Гариповның исеме бөтен Татарстанга билгеле.

Ул Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары кавалеры, партиябезнең XXV съездында делегат, Актаныш райкомы бюросы члены. Кыскасы, җәмәгать эшлеклесе.

Яшьтән үк Кәрам Мәскәүдә һөнәр училищесын тәмамлый. Авиация заводында токарь булып эшли. Гитлерчы козгыннар изге башкалабызны бомбага тота башлагач, яндыргыч бомбаларны сагалап өй түбәләрендә йөри.

1942 елны үзенең туган авылы Иске Кормашка, балалык көннәре үткән кырлар кочагына кайта. Ике ел кырчылык бригадиры булып эшли. 1947—1961 елларда ул — Актаныш РТСында токарь. Оста һәм бик яхшы токарь. Тимер, корыч кырдыруның бөтен нечкәлекләрен белә. Аңардан тәм, ләззәт табып эшли.

Ләкин токарь станогыннан да бигрәк аны киң кырлар үзенә тарта. Күкрәп уңган арыш, солы, бодай басулары. Аларның үзләренә генә хас хуш ис аңкытып, күңеленниндидер шатлык чорнавы... Язгы чәчү вакытындагы тургайлар җыры, моңлы кәккүк тавышы... Биек булып үскән яшел уҗымнарның салмак кына искән җилләрдә дулкын-дулкын булып тирбәнүләре сихерли аны... Күкрәп уңган иген басуы — кешеләргә шатлык алып килүче басу белән дөньяда нинди матурлык тиңләшә ала?

Кәрам оста токарь гына түгел, ул моторны да яхшы белә. Комбайн йөртергә дә сәләте бар, һәм ул, көннәрнең берендә, РТС директорына килеп, берәр колхозга комбайнчы итеп җибәрүләрен үтенә. Гәрчә ул мастерскойда бик кирәкле кеше булса да, аның үтенечен кире какмыйлар. Рөхсәт итәләр. Һәм ул беренче елны ук, «Кызыл көч» колхозында оста комбайнчылар белән ярышып эшләп, зур уңышка ирешә. Сигез мең центнер ашлык суктыра. Бу аны куандыра, дәртләндерә, рухи ләззәт бирә. Икенче елның урак вакыты җиткәч, ул тагын кырда. Инде унике мең центнер уруга ирешә. 1960 елда урак өстендә исә рекорд куя — 15 мең центнер ашлык суктыра. Иген игү эшенә, оештыру эшенә, кешеләр белән эшләүгә сәләтле, авыл хуҗалыгы техникасын

яхшы белгән коммунист Кәрам Гариповны «Маяк» колхозына председатель итеп тәкъдим итәләр. Бу тынгысыз коммунистны колхозчылар бертавыштан сайлыйлар. Игеннәрнең уңышы күтәрелә, байлык артканнан арта, колхозчыларның көнкүреше яхшырганнан яхшыра бара.

Районда Кәрам иң оста председательләрнең берсе булып исәпләнә башлый. «Зур корабльгә зур диңгез кирәк», — диләр дә, аны иң зур колхозларның берсенә — «Коммунизмга» колхозына күчәргә тәкъдим итәләр. Ул риза була. Алга, бәхетле дөньяга туп-туры юл тоткан кешеләр осталыгы белән дан алган капитанны үз корабльләренә шатланып кабул итсәләр дә, «Маяк»лылар элекке җитәкчеләреннән аерылуга нык көенәләр. Каршы килергә дә тырышып карыйлар, шау-шу күтәрергә дә исәпләре булмый түгел.

Кәрам Гарипов — 1969 ел башыннан «Коммунизмга» колхозында председатель. Үзенә нинди җаваплы эш йөкләнгәнен, нинди ышаныч белән караганнарын бөтен тирәнлеге белән аңлый. Аңлый, ләкин шул ышанычны аклый алырмы? Абынмасмы? Зур корабльне зур юлдан алып бара алырмы? Тау-тау дулкыннар, давыллар булганда, билгесез рифларга очраганда, серле тынлык, штильләр вакытында, эссе кояш кыздырганда зур корабльгә дөрес юнәлеш биреп, алга баруны дәвам иттерә алырмы? Эштә яхшы ук сыналган, зур гына тәҗрибә туплаган председатель булса да, ул уйланмый булдыра алмады. Күп уйланды. Иске һәм Яңа Богады, кечкенә урман артына посыбрак утырган Югары Богады, Яңа Дияш, Солтангол авылларын берләштергән «Коммунизмга» колхозының җәйрәп яткан кара туфраклы җирләрен хуҗаларча карап, кайбер урыннарга махсус тукталып, кара туфракны учына алды. Аны иң затлы нәрсәләрдән дә затлырак, кадерлерәк күреп, бармаклары белән капшап карады. Күзләрен текәп, аның яңа сыйфатларын күрергә тырышты. Кат-кат иснәп тә куйды. Бу минутларда аның күңелен нииндидер шатлык биләде.

Фермаларга, авылның матур гына булып төзелә башлаган яңа өйләренә, тиздән авам дип торган шыксызракларына да күз салып чыкты да, машинадан төшкәч, авыр гына сулап куйды.

— Җирләр күп. Чәчүлек җирләре генә дә 6550 гектар. Табигый печәнлек — 67, көтүлекләр — 628... Бу саннарны ул күңеленнән белә. Байлык җитәрлек. Мал-туар да күп. Каян башларга? Бер нәрсә ачык. Барын да тик кешеләр хәл итә. Тәҗрибәле, белемле, намуслы белгечләр. Җитәкче, алтын акыллы булса да, ялгызы көчсез. Ул партбюро һәм авыл Советы белән уртак тел табып эшләүне үзенең иң әһәмиятле бурычы итеп куйды. Колхозның баш агрономы, намуслы хезмәт белән мактаулы исем алган Мөхәммәтнур Исламов, аның беренче ярдәмчеләреннән булды.

Яшьтән үк хыялларга бай, ашкын күңелле Кәрамның хыяллары зур иде. Райком аңа ышанып зур эш тапшырды: «Коммунизмга»ны шундый итеп күтәр син, — ул, чыннан да, үз исеменә лаек булсын, башкаларга һәрьяктан үрнәк булсын», диделәр.

«Коммунизмга» колхозының җитәкчесе булып билгеләнгәннән соң ул иген уңдыру мәсьәләләренә бәйле төрле журналлар, популяр китаплар, шулай ук фәнни проблемаларны чагылдырган әсәрләр укып уйга калды. Зур һәм чиксез галәмдә Җир дип аталган гаҗәеп планетаның серләре уйландырмаслык хәл мени? Аеруча җирнең өске катлавы, без, кешеләр басып йөри торган туфрак сере уйландырды аны. Чыннан да, уйланып, таң калмаслык мыни? Җир шарының диаметры унике мең километрдан артык, ә туфрак, кешеләрне икмәк, ит, май, сөт, җиләк-җимеш, яшелчә, гөлләр, чәчәкләр, мәһабәт сынлы, куе яфраклы агачлар, урман үстерә торган туфрак ни бары утыз, кырык, күп булса, илле сантиметр. Аннан соң инде кызыл балчык, ком, таш, таш, таш... Ул да өч-дүрт, күп булса, берничә дистә километр, аннан соң магма, ут, ут...

Бодай, арыш безнең басуларда нибары уртача 15—20 центнер уңыш бирә.

Уңдыра белеп уңдырганда, туфракны фән нигезенә куеп эшкәрткәндә аның 25 тән 60 центнерга кадәр бирүе мөмкин. Тимирязев җир 100 центнер уңыш бирә ала дип исәпләгән. Ул гынамы, шул сүзне аңа кадәр үк әле бөек галим, шагыйрь Ломоносов та әйткән. Әгәр дә әнә шул туфракның бөтен серенә төшенеп, аны кирәгенчә кадерләсәң, шуның өстенә безнең бүгенге техниканы да кулланып эш итсәң, нигә безнең җирләрдән дә... Юк, йөз дип әйтергә батырлыгы җитмәде Кәрамның, әлегә минем гомердә уртача 50—60 центнер булса ярар дип куйды.

Алдына куйган югары максаты булмаса, шуңа ирешү өчен бар көче белән көрәш-

мәсә, кеше биеккә, югарыга күтәрелә алмый. Бу хакыйкатьне дә белә иде Кәрам.

Үзенең зур хыялларын гамәлгә ашыруда кем беренче ярдәмчесе булыр, иген уңышын күтәрүдә кемгә таянып эш итәр ул? Билгеле инде, колхозның баш агрономы Мөхәммәтнур Исламовка. Моңарчы җиде ел эшләгән тәҗрибәле белгеч. Артык үзсүзле диделәр. Ләкин үзсүзле булу кире сыйфат түгел, дип уйлады Кәрам. Үз сүзе, үз фикере булмаган кеше начар.

Колхозга килеп эшли башлаганның икенче көнендә үк аның белән сөйләште. Яше белән үзеннән күп аерылмаса да, Кәрам аңа абзый дип, хөрмәт күрсәтеп дәште. Мөхәммәтнур исә «абзый» сүзен бөтенләй игътибарсыз калдырды.

Һәр эштә төгәллекне ярата торган Мөхәммәтнур сөйләшенгән вакытка, нәкъ сәгать алтыда, председатель бүлмәсенә килеп кергән иде. Председатель хәл-әхвәл белешкәннән соң, җитди төстә сүз башлап:

— Үзең дә беләсеңдер, безнең алда, аеруча синең белән минем алда, бик зур бурычлар тора. Бөртеклеләрне, әйтик, якын елларда 25—26 центнерга күтәрсәк, бәлки ун-унбиш елда 30—35 ләргә үрмәләсәк...— Кәрам үзенең хыялларын ача, җәелдерә барып, 50—60 дип тә әйтмәкче, Тимирязев белән Ломоносовны да телгә алмакчы иде, әмма Мөхәммәтнурның йөзенә чыккан үзгәрешне, аның сәер генә елмаюын күреп, сүзне бөтенләй икенче якка, мал азыгына күчерде. — Терлек-туар азыгы уңдырышын да күтәрергә, моның өчен дә барлык чараларны күрергә...

— Дөрес инде, иптәш председатель, — диде баш агроном, Кәрамның сүзен тыңлап та бетермичә. — Болар әллә кайчангы бурычлар ич инде. Тырышмадык түгел, без дә тырыштык.

— Беләм, — дип куйды Кәрам, яхшы ук кырыс кәяфәт ала башлаган Мөхәммәтнурның озынчарак йөзенә һәм эчке бер мәгънә белән янып торган күзенә карап.

Юк, бик үк белеп бетермисең икән шул әле дигәндәй, һәр сүзенә басым ясап, шулай да мөмкин кадәр сак һәм тыныч булырга тырышып, Мөхәммәтнур:

— Мин эшли башлаган елларда уртача 13—14 центнер ала торган идек. Хәзер егермене. Беләсеңдер инде, — диде.

— Беләм, — диде Кәрам тагын.

— Ничек ирештегез дигәндә, анысын да әйтәм. Иң башта басуларны өйрәнеп чыктык. Кайсысы, нинди культура өчен яхшы. Чәчү әйләнешен билгеләдек. Кайсы җирне ничек ашлау... Күбрәк үзебезнең ашлама белән ашладык. Ерак барырга көч җитми иде. Хәзер минералын да байтак кайтартабыз. Әлегә уртача 20 центнерга җиттек, тора-бара егерме ике, егерме бишне дә алырбыз.

— Ә Тимирязев...

— Теге... Йөз центнер дигәнен әйтәсеңме?

— Юкка әйтелмәгән ләбаса.

— Кайчандыр без дә ирешербез аңа, әмма дә ләкин әлегә бу хыял гына... Матур хыял.

— Хыял?! Бик дөрес, хыял! — Кәрам, зәһәрле ачуны, нәфрәтме, әллә югыйсә ярсулы бер сокланумы икәнен әйтү кыен булган бер тойгы белән Мөхәммәтнурга күз ташлап алды да, урыныннан сикереп торып, тәрәзә янына килеп басты. Йөзендә, күзләрендә сәер генә елмаю. Башында аннан да сәеррәк уйлар агышы. Буталчык һәм берсен-берсе басып килә, юкка чыгара торган агыш... Мөхәммәтнур? Менә нинди кеше икән бит ул. Зур белемле, олы хыяллар белән яшәүче, эшчән, алга карап яши торган белгеч... Миңа чын мәгънәсендә таяныч. Ышанычлы таяныч. Таянычмы соң? Ышанычлымы? Әллә куркыныч көндәшме? Бәлки ул шундый канатлы хыяллар белән яшәп бара-тора зур уңышлар яулап, данга ирешергә теләгәндер? Бәлки мин аның хыялларын тормышка ашыруда киртә булганмындыр? Бәлки әле ул председатель булу турында да хыяллангандыр? Бәлки ул мыштым гына туфракның искиткеч серләре турында гыйльми әсәрләр язган атаклы галим Василий Докучаевның әсәрләрен җентекләп укып, өйрәнеп утыра торгандыр. Кәрамның йөрәген сыздырып, ниндидер көнчелек хисе уятып, менә шушындый уй чагылып киткән иде. Ул ялт итеп Мөхәммәтнурга күз төшереп алды. Аның нәкъ шушы шашкын минутта өстәл янына утырып, күзләрен каядыр бер ноктага текәп, тыныч кына утырганын күреп, аптырап калды. Әйтерсең баш агроном вазифасын үтәп барган кешенең башында бер уй да, бер гамь дә юк. Шулаймы соң? Юк, билгеле алай түгел. Хәзергә кадәр намус белән көн-төн эшләгән

баш агрономга, сугышка кадәр үк инде «Хезмәттә батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән һәм Ватан сугышы елларында батырларча сугышып Чехословакиягә кадәр барып җиткән ветеранга яңа председательнең шикләнебрәк, ышанмыйчарак каравы (һәрхәлдә, бу аның үзенә шулай тоелды) кимсетте аны, борчыды, күңелендә утлар өерде. Ләкин үзе ничек тә сиздермәскә тырышты.

— Синең белән минем уйлар, хыяллар уртак булып чыга болай булгач, иптәш баш агроном, — дип ачык йөз белән елмаеп, ул Мөхәммәтнур янындагы буш урындыкка килеп утырды.

— Шулай булса, мин бик шат, ә эшләргә дисәң... — дип әйтеп җиткермәде Мөхәммәтнур. Ә Кәрам яхшы аңлады аны.

Аларның күңелләрендә бер-беренә карата ямьсез уйлар булмады диярсең. Ай, бу кеше күңеленең серлелеге! Бер начар сүз аның җанын айкап, упкынга ыргытса, бер җылы сүз җанын эретеп, күкләргә күтәрә. Мөхәммәтнурның да күңеле эреде. Һәм ул эшләде: пионерларча җитезлек белән, ашкынып, дәртләнеп эшләде. Иген уңышы, мал азыгы уңышын күтәрү өчен күрелгән чараларда ул Кәрамның иң якын ярдәмчесе булды. Беренче көннәрдә булган шикләнүләр бөтенләй бетте диярлек. Чөнки Кәрам аның башлаган яңалыкларын хуплады гына түгел, үзе әледән-әле яңалыклар өстәп торды.

Колхозның үсешен һәр тармакта да күтәрергә дип зур дәрт белән килгән Кәрам, иген уңышы турында уйлау белән бергә, терлек-туар, колхозның барлык төзелешләре турында да һәм, билгеле инде, барлык эшләрнең иң җаваплы өлешен үз җилкәләрендә алып бара торган механизаторлар, шулай ук инженер, техник, зоотехник, электротехниклар турында да кайгыртты — берсе дә аның игътибарыннан читтә калмады.

Мәктәп, уку-укыту эшләре, культура сарае, анда җәеп җибәрелгән эшләр, үзешчән сәнгать, яшьләрне шунда тарту кебек эшләрнең барысына да колачы җитте председатель Кәрамның. Нәтиҗәдә колхоз күзгә күренеп күтәрелде һәм күтәрелә бара. Барган юл елдан-ел, көннән-көн киңәя, яктыра, төп максат якыная бара. Кәрамның хыяллары тормышка аша бара. Уңыш! Уңышлар... Зурлар алар.

Мөхәммәтнур гына түгел, һәркайсы үз өлкәсендә яхшы үрнәк күрсәткән белгечләр — баш инженер Риф Заһертдинов, экономист Зөфәр Исламов, баш зоотехник Фикат Гаянов, төзүче-техник Фәнил Туктаров, элек баш бухгалтер, соңгы елда колхозның партбюро секретаре эшен алып барган Фаяз Фәйзуллинның да Кәрамның ныклы таянычлары булганын әйтергә кирәк.

Ә колхозда иң җаваплы эш алып барган, колхозчыларны хезмәткә оештырып чыгарган бригадирлар? Беренче бригаданың бригадиры Вәсил Сафиуллин, икенче бригаданың Сәгыйдулла Төхфәтуллин, өченченең Гыйльмебаян Әшрапов, чәчү орлыкларын әзерләп, тикшереп чәчтерүче Таһирҗан Әхмаев? Юк, алардан башка колхозда рәтле эш баруы мөмкин түгел. Кәрам урта звеноның бу җаваплы командирларына тулысынча ышанып, үз эшен дәвам иттерде. Соңгы елларда иген уңышын хәл итүче, язгы-көзге чәчүдә дә, игеннәр өлгереп аларны урып-җыйганда да төп рольне уйнаган механизаторлар — тракторчы, комбайнчы, шулай ук шоферлар — Татарстанның атказанган механизаторлары Мәсәлим Хәйдәров, Рөстәм Гарипов, Шәйхенур Зарипов, Иҗат Мөхәммәтов, Фаил Мөхәммәтов, Даниф Заһретдинов... Алар гына да түгел, колхозның йөз илледән артык механизаторы, терлекчеләре, төзүчеләре һәм башка тармакта эшләүчеләр...

Һәрвакыт халык белән бергә булганга, үз булганга өлкән командирлар да, урта звено командирлары да, гади колхозчылар да яратты Кәрамны. Бары да үзләрен хуҗа итеп хис итте, эшен дәртләнеп, бирелеп эшләде.

...Богады, Яңа Дияш авыллары. Яшүсмер чаклар. Авылыбызда Кара Җирек дип йөртелгән җыен үтү белән, бу яклар көтеп ала торган Бикә җыенына килә идек. Иске Богады янәшәсендә генә урнашкан Яңа Дияштә (ул елларда Каратал авылы диләр иде) безнең якын кардәшләребез — Әхмәткирам абыйлар яши. Без аларга килә идек. Ярлы иде алар. Салам түбәле кечкенә генә өй, аннан-моннан гына киртәләп алынган ишегалды. Җил капка. Түрдә лапас, абзар, кара мунча. Кыш ягар өчен зур кирпечләр итеп сугылып куелган тизәк. Бер ат, бер сыер, берничә баш сарык. Кыскасы, күршеләрнеке шикелле үк, ярлы, шыксыз хуҗалык. Шулай да Кирам абзыйларның хәтердә уелып калган зур байлыгы бар. Ул — якты чырай, киң күңел, юмартлык, кунакчыллык.

Халкыбызга хас булган гүзәл сыйфат. Әхмәткирам абзый һәм аның хатыны Фәхрия җиңги, әниләре минем карт әнкәйнең бертуган сеңлесе Фәхриҗамал әби, Зыя абый белән мине, кыш көне мәктәптә укып кайткан шәкертләрне, аеруча ачык йөз күрсәтеп каршы алалар иде. Җыенга һәр елны бер сарык суела. Кыр ягында ул аеруча симез. Шулпасы тәмле. Чәй янында ару азык кушып пешергән юача ипи. Сөтле чәй. Елда бер генә килә торган бәйрәм — сабан туе булгач, аз-маз булса да, шикәр куела. Һи-и, шикәрле чәйдә мени хикмәт! Безгә җыен, сабан туе кыйммәт. Ә ул авыл башында шаулый-гөрли. Иң затлы күлмәкләрен киеп, чигүле алъяпкычлар бәйләп чыккан яшь кызлар, яшь киленнәр... Түбәтәйләрен кыңгыр салып, пар ат җигелгән тарантаска өелеп утырган егетләр гармунга кушылып җырлыйлар, сызгыралар, кычкыралар. Аларга кушылып, дугага тагылган җиз кыңгыраулары да зың-зың итеп җырлый... Әй-й...

Әйттер җаный, әйттер җаный,
Әйттергәннәрең калыр;
Без алмасак; башка алыр,
Безнең сөйгәннәр калыр.

— На-а! Бахбай!

Әйттерәләр дә егетләр, сиптерәләр дә. Сабан туе көнне дөнья аларныкы. Җыр, бию, көрәш, йөгерешү, ат чаптырулар көнозын бара. Шаулап тора дөнья! Авыр тормышта яшәгән авыл, берничә көн генә булса да, аяк тибеп бәйрәм итә. Ләкин шунысы үкенеч — тиз үтеп китә бу бәйрәм көннәре. Шулай да күңел түрендә сагынып сөйләрлек матур истәлеге кала. Каратал, Богады, Солтангол авылларын безнең Идел буе авылларында яшәүчеләр кыр яклары дип йөртәләр. Урмансыз, болынсыз, сусыз яклар... Утын ягып түгел, тирес ягып көн итәләр. Басулары да киртә белән түгел, ур казып, балчык өеме белән генә уратып алынган. Авылга килеп керсәң, үзенә хас бер ис. Тизәк, төтен исе. Җәен дә, кышын да шул ис һич китми бу авыллардан. Без яшь чакларда шушы кыр якларында яшәүчеләр гомер буе тирес ягып, шундый төтен исе сулап ничек яшиләр икән дип аптырый идек. Гомер буе балык заты күрмиләр, хуш ис аңкытып торган болыннары да юк, дип кызгана идек. Өйләре дә күбрәк салам түбәле. Үзләре ачык чырайлы, киң күңелле булып, көн-төн эшләсәләр дә, ай-яй, авыр тормышта яшиләр икән ди идек.

Алайга китсә, безнең авыллардагы тормыш та ал-гөл түгел иде түгелен. Авыр тормыш, ярлы тормыш. Шулай да, Идел буе. Үзе зур юаныч.

Ә бүгенге Богады?

Кадерле кунак сыйфатында зур хөрмәтләр күреп, Кәрам белән озак кына сөйләшеп утыргач, аңа:

— Авылларыгызны, басуларыгызны күреп бер әйләнеп кайтасым килә, — дигән теләгемне белдердем.

— Рәхим ит, машина әзер, ләкин шунысы кызганыч, үзем бара алмыйм. Кичектермичә эшләргә кирәк ашыгыч эшләрем бар. Менә партия оешмабызның яңа секретаре Фаяз Фәйзуллин. Син элегрәк килгән чорда Ә. Халиков секретарь иде. Ул укытучы булып мәктәпкә китәм дигәч, аның теләгенә каршы килмәдек, риза булдык. Хәзер инде бөтен эшне Фаяз алып бара. Ул сине безнең кырлар белән дә, кешеләр һәм авыллар белән дә таныштырыр, дигәч, мин, билгеле, шатланып риза булдым.

Озак юанып тормадык. Фаязның зәңгәр төстәге «Жигули» машинасына утырып, юлга чыктык. Сөйләшә-сөйләшә барабыз. Без Богады, Яңа Дияш, Солтангол басуларында. Я-а! Булса да булыр икән бер могҗиза! Җәйрәп яткан бодай, арыш, арпа... алар шундый каерылып уңган... Әле яңа гына туя башлаган булсалар да, шундый зур, тере башак... Алар әкрен генә искән җилдә дулкын-дулкын булып тирбәләләр... Күңелгә аерым бер ләззәт бирә торган шундый соклангыч алар... Бу рәхәтне, ләззәтне бөтен тулылыгы белән тояр өчен тәгаен авылда, буразналар ярып, җир тырмалап үскән малай булу кирәктер. Барлык басулардагы, барлык культуралар да шундый уңган. Яңа чәчәк ата башлаган борчакны кара инде син. Уңышы белән дә, яме белән дә синең исеңне китәрерлек. Барыннан да мине гаҗәпкә калдырганы печән, Уразайның Иске авыл, Чәйле күл буйларындагы сугарып үстерелә торган кындырак үләне, бигрәк тә аның тагын да калынрак, уңганрак булып үсүе. Менә сиңа кыр ягы! Бәй, Идел буй-

ларындагыга караганда күп уңганрак түгелме соң бу? Әйе, уңганрак. Монда тик бары Чәйле күлдәге кебек балыклар гына юк.

— Юк?!. Дошман сүзе бу, — диде Фаяз, шаяра-көлә генә. Кечкенә елгачыгыбызны буып, махсус ясалган күлдә Идел балыкларына биргесез менә диган карп һәм табан балыклары үсә. Әлегә кадәр без балык дип Идел буе авылларына, Уразайга, Илчебайга бара идек. Хәзер үз елгабызда үзебез үстерәбез дип, горур гына миңа карап куйды. Менә бит ул әкият кебек гаҗәеп дөнья. Кыр якларына балык үрмәләп менгән, печән каерылып уңган, игеннәр нинди.

Алай гынамы? Түгел, билгеле. Мине сокландырганы «Коммунизмга» колхозындагы авылларда берсеннән-берсе матуррак, зуррак, мәһабәтрәк итеп салынган өйләр булды. Алар тирәсендә үсеп утырган агачлар, чәчәкләрен балкытып, биек булып үскән чын агачлар. Өй һәм болдыр тәрәзәләреннән карап, аллы-гөлле чәчәкләрен җәеп, елмаеп утырган гөлләр... Әйтерсең чын-чынлап әкият дөньясында мин. Берничә секундка гына элекке салам түбәле, җиргә иңеп торган Богады, Каратал авылларындагы өйләрне күз алдына китердем. И-и... Бар иде бит заманнар... Халкыбызның бөтен язмышын аллага тапшырып, байларга, патшага баш орып, тезләнеп, хәерчелектә яшәгән чак исемә төшеп, тәнем чымырдап китте.

Киртәләр, читәннәр, җил капкалар берсе дә юк хәзер. Алар урынына сырлап эшләнгән рәшәткәләр, төрлечә сырландырып, күзнең явын алырлык итеп матурлап, бизәкләп эшләнгән капкалар... Шуларны күреп, ничек сокланмыйсың да, ничек горурланмыйсың. Болар бит асылда партиябезнең эше. Гариф улы Кәрам Гарипов партиябезнең алдынгы вәкилләреннән берсе. Бүген бирсдә ул командир. Аның җитәкчелегендә төзелә бу матур дөнья. Шул җитәкчеләрнең берсе мине «Коммунизмга»ның матурлыклары белән таныштырырга алып чыккан Фаяз Фәйзуллин. Яңарак салынган бер бик матур өй яныннан үткәндә Фаяздан:

— Кем өе бу? — дип сорыйм.

— Колхозның алдынгы хезмәт батырлары Дәбир Фазлыев белән Миңлегөл Фазлыевалар өе, — ди миңа Фаяз. — Дәбир алдынгы тракторчы, тугызынчы бишьеллык батыры, Миңлегөл — III Дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнгән тырыш хатын — дуңгыз караучы, авыл Советы депутаты, партия члены. Әгәр теләсәң, әйдә, өйләренең эчен дә күреп чык, өйдә булсалар, үзләре белән дә танышырсың.

— Бик яхшы, әйдә, карап чыгыйк.

Баһадирларга хас мәһабәт сынлы Дәбир Фазлыев үзе каршы алды.

— У-у, кунаклар килә икән, рәхим итегез, — диде ул, ачык йөз белән. — Бик мактап йөрисез икән. Әнкәй тәплекәй пешергән иде, сезгә дә насыйп икән, әйдәгез, өстәл янына рәхим итегез.

Фаяз Дәбирне минем белән таныштырды.

— Без ашыгабыз, барасы җирләребез күп, — дисәк тә, тәплекәйне, тәплекәйне генә дә түгел, күз ачып йомганчы өстәл тулып киткән мул ризыкны, сый-хөрмәтне ташлап китәргә, бигрәк тә хуҗаларның хәтерен калдырырга батырчылыгыбыз җитмәде. Утырдык. Миңлегөл эштә иде. Ул да кайтып җитте. Өстәл янындагы мул сыйдан бигрәк'тә минем күңелемә гаҗәеп бер зәвык белән җиһазланган өйнең эче аерым рәхәтлек бирде. Шәһәрнең культуралы тормыш белән яши торган гаиләләренә хас бай җиһаз, мул тормыш.

Тәплекәй дә, сөтләп ясалган куе чәй дә, башкасы да күңелебезгә бик хуш килде. Ләкин аеруча хуш килгәне, сокландырганы ачык йөзле, юмарт, хезмәттә батырлык үрнәкләре күрсәткән хуҗалар үзләре — Дәбир, Миңлегөл, тәплекәйне тәмле итеп пешергән алтын куллы, мөлаем чырайлы әнкәләре иде.

— Бу үрнәк гаилә, бирсдә тәрбияле балалар үсә, — дип куйды Фаяз.

Без үзебезгә күрсәтелгән сый-хөрмәткә зур рәхмәтләр белдереп, киләчәктә дә аларга бәхетле тормыш теләп, саубуллашып урамга чыктык, машинабызга утырып, юлыбызны дәвам иттердек.

Югары Богадыга да күтәрелдек. Урман артына кунаклаган кечкенә авыл. Нибары егерме-утыз йорт. Ләкин кешеләре тырыш, шундый ук киң күңелле. Күп еллар тракторда һәм комбайнда эшләп, районда зур дан алган Ленин ордены кавалеры, шулай ук башка медальләр белән дә бүләкләнгән коммунист Шәйхенур Заһитов шушы

авылда туып үскән. Колхозны үстерүдә зур хезмәтләр күрсәткән бу хөрмәтле кеше белән дә танышып, аның бүгенге хәл-әхвәлләрен дә сораштык.

Бу кечкенә авылның зур хөрмәткә лаек кешеләре ул гына түгел, билгеле. Аларның берсе — шушы авылда туып, бәләкәй чагында яхшы ук шаян, үзсүзлерәк малай булса да, соңыннан тырышып укып, районның зур кешесе, җитәкчесе булып өлгергән, Актаныш район башкарма комитетының председателе Баязит Шәймәрдән улы Мөхәммәтев.

— Әйбәт җитәкче, акыллы җитәкче биргәнсез районга, рәхмәт, — дим мин Шәйхенур Заһитовна.

— Әтиләре Шәймәрдән карт үзе дә бик акыллы кеше иде. Укырга илткәч, малае: «Укулары бик кыен, укымаем», дип, өйгә кире кайтып та караган иде, кая!.. Шәймәрдән карт ирек бирәме соң, бирмәде! «Бар, укы, акыл җый, кеше бул! Югыйсә син миңа малай түгел, мин сиңа ата түгел», — ди. Кире куып җибәрде. Шулай булгач, нишләсен Баязит? Укыды. Акыл җыйды. Кеше булды. Әнә ул ел инде хәзер районны шул җыйган акылы белән әйбәт кенә җитәкләп бара. Игенче малае булгач, игенчелекне дә, башкасын да яхшы белә.

«Коммунизмга» колхозына караган авылларның атаклы кешеләрен, зур техникасын, байлыгын саный китсәң, аңа саннар да җитмәс, вакыт та җитмәс. Әдәби әсәрдә саннарның күп булуын укучылар да бик яратмый. Шулай да бер сан турында әйтми мөмкин түгел. Табигать шартлары бик авыр килгән 1978 ел (яңгыр, рәхмәт төшкере, яуды да яуды) яхшы булып уңган игенне җыеп алырга нык комачаулады. Күп районнар, күп авылларда байтак иген урылмыйча кар астында калды. Ә менә барлык эшне зур осталык белән оештырып, ипатовлылар ысулын дөрес кулланып эш иткән «Коммунизмга» колхозы бу елны да сынатмады. Алдынгылыкны бирмәде. Районда иң зур уңыш алган колхоз «Коммунизмга» колхозы булды. Алар бу елны уртача һәр гектарга 30 центнердан бик әз генә ким уңыш алдылар.

Әйтеп үтелгән зур уңышларга тиңләрлек уңышы, аларга тиң шатлыгы, бәхете бармы тагын Кәрамның? дип сорарсыз бәлки.

Бар гынамы соң, бик бар, бөтен уңышларына торырлык олы уңышы, шатлыгы, бөтен бәхетләренә торырлык бәхете, олы горурлыгы бар аның. Ул аның сөеп алган кадерле яры, матур һәм уңган хатыны сөйкемле Мөстәфидәсе.

Мөстәфидәгә гашыйк булып, беренче мәхәббәт утлары кабынган чорларда нинди генә ашкынулы минутлар кичермәде бит ул. Аңа атап нинди генә мәхәббәт җырлары җырланмады. Ул көннәрдә тавышы да көррәк, моңлырак иде, ахры. Һәрхәлдә, назлы кыз Мөстәфидәнең күңелен ауларга, аны сихерләп үзенә карату өчен җитә иде.

Алар өйләнеште. Туй әллә ни шау-шулы булмады. Еллары шундый иде. Авыррак еллар. Ләкин олы мәхәббәт өчен, киләчәктә гаилә матур, тату яшәсен, бәхетле булсын өчен туйның шау-шулы булуы, өстәлнең бай эчемлекләргә мул булуы им мени? Юк! Бокаллар тутырып әйтелгән матур теләкләр дә, яшьләргә бәхет теләп тыпырдаган аякларның бәясе дә, халык әйтмешли, сукыр бер тиен. Яшьләрнең киләчәктә бәхетле булулары өчен аларның бары тик үз акыллары, үз бәхетләренә, киләчәк язмышларына үзләренең җаваплы караулары кирәк. Яхшы теләк теләгән дусларның чын дус булып калуы да гаилә бәхете өчен яхшы терәк. Кәрамның зур хыялларын тормышка ашыруда ышанычлы ярдәмче, төп таянычы булды Мөстәфидә. Арыган чакта ял иттерү, күңеле төшкән чакларда күңелен күтәрү генә түгел, алдында торган хыялларын киңәйтә төшү, аңа ялкынлы дәрт өстәүдә дә булышты ул. Гаиләнең олы шатлыгы, тиңсез бәхете итеп, Кәрамга берсеннән-берсе сөйкемле балалар бүләк итте.

Иң беренче кадерле бүләк булып, «Үә-үә!..» дип яхшы ук әче тавыш белән кычкырып, искиткеч мөлаем бала — Хәршидә килде дөньяга. Ул тәпи басарга өлгермәде, мин дә апамнан калышырга теләмим дигәндәй, Гөлсинә туды. Дөресен әйтик, Хәршидә белән Гөлсинәнең кулы-аягы җиңел булды: бер-бер артлы Ләлә белән Ләйсән дөньяга килде. Дүрт апасына үпкә белдергәндәй, нигә мине үзегездән калдырып киттегез дигән сыман, елый-елый Рәмзия туды.

Ата белән ана шатлыгының иге-чиге булмады. Шулай булмый: берсеннән-берсе

чибәр биш кыз үссен әле бер өйдә!.. Алар аякка басып кул астына керә башлагач, менә дигән булышчы булачак түгел мени?

Тик тизрәк үссеннәр генә... Дөрес, аларны тәрбия итү әнигә дә, әти булган кешегә дә бик җиңелгә килмәде. Борчулары җитәрлек иде аларның. Чыр-чу, үзара көрмәкләшү. Биш кыз бала шау-шуына түзеп кара әле син! Алар түзде. Хәер, кыз балалар бик шаулашып, әти-әниләрен артык борчымадылар. Әтиләренең җаваплы зур эш алып баруын аңлагандай, аның алдына басып: «Әттә!» — дип елмайдылар, көлделәр. Бераз үсә төшкәч, җырлап, биеп тә күрсәттеләр. Аларның шат йөзләрен, сөйкемле кыланышларын күреп, Мөстәфидә белән Кәрамның сөенүләрен сөйләп тә, язып та бетерә торган түгел. Кызларының нәзакәтле кыланышларын күргән минутларда ата-ана шатлыгының зурлыгын үлчәү өчен бер төрле үлчәү дә юк дөньяда. Шундый бәхетле, шатлыклы бер минут — үзе бер гомер... «Дөнья бәясе тора», — ди безнең халык аларны бәһаләү өчен бернинди үлчәү дә, сан да таба алмагач.

Шулай да Кәрамның күңел түрендә бер ризасызлык бар иде. Ничектер... бәхете тулы түгел кебек иде. Мөстәфидәнең күңелен төшермәс өчен ул кайчак үз эченнән генә: «Их, шушы биш кыз янына тагын бер малай да булса, нур өстенә нур булыр, бәхетебез тагын да тулырак булыр иде», — дип куя иде.

Сизгер һәм киң күңелле Мөстәфидә Кәрамның бу уйларын, бу урын теләкләрен дә сизде. Дөресен генә әйткәндә, бу аның үзенең дә теләге иде. Шуңа күрә яраткан иренә тагын бер бала, ир малай бүләк итте. Шулай итеп, аларның уртак теләге, уртак шатлыгы булып, малайларга хас көр тавыш белән гөрелдәп, дөньяга Наил килде. «Энебез булды, энебез!» — дип, апалары шатланды. Ләлә белән Ләйсәнне әйткән дә юк анысы.

— Наил апаемны мин сөям, мин тилбәтәм, — диде Ләйсән, чыгар-чыкмас сакау теле белән.

Наилнең дөньяга килүенә әле бер яше яңа тулып узган Рәмзия генә шатланмады, ахрысы. «Әннә мине әз сөяр, бөтен күңелен бәләкәй апаема — Наилгә бирер», дип көнләште сыман. Ләкин ялгышты, бик ялгышты нәни Рәмзия. Әнисенең балаларына карата булган бетмәс-төкәнмәс мәхәббәте Наилгә дә җитте, Рәмзиягә дә җитте, апаларына да җитте. Ана — ана шул инде. Ул балаларының барын да бер тигез ярата. Аның игътибары барсына да бер үк. Ә менә әтиләре Кәрам... Юк, атаның мәхәббәте балаларның кайсына булса да күбрәк, я кимрәк булгандыр дип уйлый күрмәгез тагын. Һич юк! Тик шулай да Наил... Ир бала... аның иң олы куанычы, горурлыгы иде. Кызыклы һәм гаҗәеп бер тылсымлы ашкын уйлар, хыяллар килеп китте аның башына. «Китте» дигән сүз бик дөрес түгел бу очракта. Килде, әмма ул хыяллар китмәде, һаман үсә, киңәя, барган саен тирәнрәк булып тамыр җәя барды. Нинди хыял ул дисезме? Туры гына әйткәндә, үземә алмашка килде бу малай, дөньяга бер яңа игенче, иген эшен миңа караганда яхшырак белергә тиеш булган, мин тормышка ашыра алмаган хыялларны тормышка ашырачак егет килде, дип хыялланды ул. Һәм аңа шул юнәлештә тәрбия бирергә, кече яшьтән үк хезмәткә мәхәббәт, авылга, җиргә мәхәббәт тәрбияләргә тырышты.

Тәрбия, балаларга тәрбия бирү...

Бу аларны югары белемле итү генә түгел. Бу — безнең бүгенге чорыбыз өчен иң әһәмиятлесе — хезмәт сөючән, тырыш, тәүфикълы, гадел, югары әхлаклы, кешеләргә игътибарлы, җәмгыятебезгә, идеалыбызга, Ватаныбызга турылыклы булган чын кеше итеп үстерү.

Шушы изге бурычны бөтен тирәнлеге белән аңлаган Кәрам һәм Мөстәфидә балаларның барын да тигез күреп, әнә шул таләпләргә җавап бирерлек итеп тәрбияләргә тырыштылар. Кызларның барысы да югары белем алды һәм намус белән хезмәт итәләр.

Хәршидә, Ләлә, Ләйсән, Рәмзия — врачлар, медицина хезмәткәрләре, Гөлсинә — агроном, Наил дә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап килә. Кәрам Гарипов үзе дә, читтән торып укып, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады, диплом алды. Иң җаваплы хезмәт — колхоз председателе вазифасын алып бару белән бергә, укырга да, балалар тәрбия итәргә дә өлгерде. Соңгысы — балалар — аның дөньяга биргән, киләчәк елларга, киләчәк буынга калдырган иң кыйммәтле һәм иң кадерле бүләге. Шуңа күрә ул бүген күкрәк киереп горур атлый да. Яхшы председатель булганы, акыллы һәм ин-

сафлы булганы өчен генә түгел, җәмгыятебезгә югары белемле һәм тәрбияле балалар үстергәне өчен дә аны һәр җирдә хөрмәт белән каршы алалар.

Иң мөһиме — киләчәк дөнья, киләчәк буын турында кайгырту...

Еллар үтәр...

Ул җан сөйгән хатыны, сикәлтәле авыр юлларда иң ышанычлы таянычы булган юлдашы Мөстәфидә белән бергәләп, ике меңенче елның могҗизалы капкасын ачып кереп (Кәрам әле ул чакта нибары 75 яшьлек ир-егет, Мөстәфидә җитмеш өчтәге яшь ханым), берничә көннәр һәм берничә йөз километр җир үткәч үк XXI йөзнең егерме, егерме биш яшьлек егетләре, кызлары, профессор, академик һәм сәнгать осталары сорар алардан:

— Безнең яңа гасыр, яңа мең еллыкка нинди бүләкләр белән килдегез, үткән юлларыгызны нинди уңышлар белән бизәп киттегез? — диярләр.

Кәрам әйтер:

— Кырлардагы, гомумән, колхоздагы уңышым шундый да шундый, — дияр. — Аларны санап тормыйм, тик бөртекләләр турында гына әйтәм, уртача уңыш гектарга 70—75 центнер, ә инде иң зур бүләгебез турында әнә әниләре әйтер, — дип, инде чәчләренә бераз ак куна башлаган булса да, элеккеге нәфислеген, мөләемлыгын югалтмаган Мөстәфидәсен күрсәтер.

Тыйнаклыкны бар нәрсәгә караганда да кыйммәтле хәзинә дип санаган Мөстәфидә тыныч кына:

— Зур байлык дигәнебез — биш кыз, бер егет. Аларның балалары, ягъни безнең оныкларыбыз. Үзебезнең исәп буенча, алар барысы да бүген коммунизм җәмгыятенә ныклап аяк баса башлаган чорыбыз өчен лаеклылар, — дияр идем.

— Ни өчен шулай бик нык ышанып әйтәсез бу сүзне? — дип сорар әлеге акыл иясе.

— Чөнки без, — дияр Кәрам, Мөстәфидәсенең сүзен куәтләп, — үткән гасырыбызның соңгы чирегендә, техника һәм материаль байлык үсешебезгә генә түгел (алар капиталистларда да җитәрлек), балаларыбызны, гомуми җәмгыятебездәге барлык кешеләребезне дә әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар, хәлиткеч игътибар бирдек. Исерек башлар, ялганчылар, ялагайлар, караклар һәм бюрократлар, хезмәт яратмаган әрәмтамакларның берсен дә яңа гасыр, яңа мең еллыкка алып керәсебез килмәде.

— Алайса, сез безнең гасырга тулысынча лаек кешеләр, барыгыз да рәхим итегез! — дип, Кәрам Гариповның өч дистәдән ашкан олы гаиләсен алга уздырыр.

— Чү! Безне алга уздыручы, әлеге әхлак сагында торучы яшь профессор Актаныш ягы егете түгел идеме соң?

— Булыр, булыр. Актаныш ягы да булыр, Арча, Буа якларыннан да булуы мөмкин, Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Уфа, Алма-Ата — барысы да үзебезнең як бүген, — дияр кара чәчле, кап-кара һәм куе кара кашлы Кәрам. Ул бу чорда әле һаман батыр йөрәкле ир-егет булып исәпләнсә дә, үтелгән озын, авыр юлы, яшьләрнең дә саны басу аркасында, элекке җитезлеге бераз кимегәнгә күрә, салмаграк атлый атлавын, шулай да җаны тыныч, күңеле көр, һәр яктан сәламәт ул.

Кәрам һәм Мөстәфидәләр гаиләсе — сокландыргыч гаилә. Киләчәк буын сорау бирә калса, сорау бирүченең күзенә туп-туры карап җавап бирергә әзер алар.

# КамАЗ КЕШЕСЕ: КЕМ УЛ?

*Социолог язмалары*

Минем нык ышануымча, еллар үткәч тә барлык совет кешеләре Камадагы хезмәт батырлыгын горурланып искә алырлар.

*Л. И. Брежнев.*

КамАЗ турында төрле жанрларда һәм бик күп язылган. Киләчәктә аның хакында тагын да матуррак әдәби әсәрләр һәм тирән эчтәлекле фәнни трактатлар иҗат ителер. Бәлки бүген КамАЗга бәйләнешле катлаулы процессларга тирәнтен тикшерү ясарга, аларга катгый бәя бирергә иртәрәктер әле. Алай да, төзелеш башланганнан бирле ун елдан артык вакыт үткәч, аның кайбер этапларын һәм байтак социаль хәлләрне тикшереп-карап үтүнең зур әһәмияте бар. Автогигант төзелеше республикабыз тормышында гына түгел, ил тормышында да байтак яңалыклар китереп чыгарды. Кама ярлары буена җыелган кешеләр эшчәнлегенең кыйммәтле тәҗрибәсе гомумиләштерелергә, аңа бәя бирелергә һәм киң массаларга җиткерелергә тиеш. Һичшиксез, ул заманча социалистик производствоны идарә итү фәнен һәм практикасын баетачак.

Баһадир — баһадир инде ул. Нык үскән социализмның куәтен бөтен дөньяга чагылдырып, ул чынбарлыкка әверелде. Әле кайчан гына чит ил белгечләрен КамАЗ проекты гаҗәпләндерә иде, хәзер исә аларны бу проектның тормышка ашу факты таңга калдыра, «Форд Моторс» компаниясе президенты Форд әфәнде (кечесе) 1972 елда: «Кушма Штатларда һәм Көнбатыш Европада моңа охшаш предприятие төзү беркемнең дә хәленнән килми. Без бу очракта көндәшлек итә алмыйбыз», — дигән иде. ГФРдан «Даймлер-Бенц» фирмасы президенты да, Америка бизнесмены фикерен куәтләп: «Мондый масштаблар безнең өчен ачылмаган яңа җиргә тиң. Сезнең бу комплексны төзү планыгыз, барысын бергә алганда да, Көнбатыш Германиянең барлык зур йөк машиналары заводларыннан өстен. АКШта да моңа охшаш бернәрсә дә юк», — дип белдерде.

Чит ил вәкилләренең әйткән сүзләре арасыннан безнең экономика һәм казанышлар турында гына түгел, совет кешеләре турында да куанычлы фикерләр табарга мөмкин. Француз коммунистларының «Юманите» газетасы корреспонденты С. Лейрак, Чаллыда булгач: «Татарстанның бу ягында кыю, батыр, үз эшен белүче кешеләр формалаша. Соңгысы аеруча мөһим. Палатка шәһәрләр романтикасы турындагы сүзләр үлде. Ләкин бу гомумән романтикага хөкем карары чыгаруны белдерми. Алгы планга, шушы максатта һаман саен заманчарак техникадан файдаланып, катлаулы бурычларны хәл итә белү осталыгы чыга. СССР үсте. Кәрәк һәм кәйлә романтикасы машиналар романтикасына юл бирде», — дип язды.

Машиналар романтикасы... Бу саф һәм яңача яңгырый торган сүз генә түгел. Бу сүзләрдә КамАЗга хас күренешләр чагылыш таба.

## КамАЗның баш продукциясе

КамАЗның баш продукциясе — автомобиль түгел. Машиналар аның төп продукциясе. КамАЗның баш продукциясе — Кеше. Мин моңа ышанам һәм шуны исбатларга җыенам.

Автогигантта үзебезнең һәм чит илләрдән алынган заманча җиһазлар урнаштырылган. Ә фән-техника казанышлары кулланылышы һәм хезмәт җитештерүчәнлеге

буенча автомобиль заводлары төзелеше практикасында аңа тиңнәр юк. Кешенең җитештерү көчен һәм производство культурасын чагыштыргысыз күтәрергә булышлык итә торган санлы һәм программалы идарә станоклары, яңа технологик процесслар, электрон-хисаплау машиналары, автоматлаштырылган идарә системасы — менә шуларның барысы бергә яңа сыйфатлы башкаручы — заман югарылыгындагы аңлы эшче һәм производство оештыручысы зарурлыгы таләпләрен куя.

Бер генә эшче дә, махсус әзерлеге булмый торып, мондый җиһазга якын китерелми. Төрле машина төзелеше предприятиеләреннән бирегә килүче югары квалификацияле белгечләр КамАЗда еш кына түбәнкерәк разряд белән эшкә урнашалар.

Социаль-производство бурычларын хәл итүгә комплекслы якын килү эшчеләрнең һөнәр осталыгы дәрәҗәсен КамАЗ производствосы таләпләре югарылыгына күтәрергә һәм аларның күпчелеген планлы рәвештә өйрәтергә мөмкинлек бирде. Алар илебезнең заманча җиһазландырылган предприятиеләрендә, шулай ук чит ил фирмалары заводларында күнегү үттеләр. Әммә аларның төп өлеше КамАЗның үзендә оештырылган укыту-өйрәтү системасында төрле һөнәр үзләштерде һәм бу эш әле хәзер дә дәвам иттерелә.

Менә шундый җентекле әзерлеккә дә карамастан, биредәге эшчеләрнең 11—13 проценты катлаулы җиһазлар белән идарә итү серенә төшенеп җитә алмый әле.

Шулай да аларның күпчелеге КамАЗ производствосының яхшы сыйфатлы, кыйммәтле һәм сирәк очрый торган һөнәр ияләренә әвереләләр һәм автогигант эшчеләр сыйныфының алтын фондын тәшкил итәләр. Алар, кем әйтмешли, дөнья бәясе кешеләр, аларның берсен югалту да — җитди экономик зыян. Әйтик, аерым технология процесслары, технология линияләрен көйләү зур теория белемнәре таләп итә. Биредәге эшчеләр — махсус урта һәм югары техник белемле кешеләр. Эшче һәм хезмәткәрнең КамАЗ шартларына күнегүе дәвамында кешедә яңа сыйфатлар барлыкка килә. Шуңа күрә КамАЗны күпләр өчен һөнәр осталыгы мәктәбе генә түгел, шулай ук аны социаль өлгергәнлек университеты дип тә атарга була.

Мәгълүм булганча, җитештерүче көчләрнең үсеш дәрәҗәсе, җитештерү характеры хезмәтне оештыруның тиешле алымнарын, кешене хезмәткә иләштерүнең яңа формаларын табу һәм файдалануны таләп итә. КамАЗның оештыру структурасын төзү белән махсус проект һәм фәнни-тикшеренү институтлары шөгыльләнде. Алар проекты белән биредә бер эшчегә 33 мең сумлыктан артык эш башкару каралган. Бу — тармактагы иң зур күрсәткеч. Чагыштыру өчен әйтеп үтик: ВАЗда әлеге күрсәткеч 25 мең сум чамасы тәшкил итә, ә иске заводларда шактый түбәнрәк.

Табигый, мондый дәрәҗәдәге җитештерүчәнлеккә (хәтта заманның иң югары җитештерүчән җиһазларында да) хезмәтне һәм производствоны идарә итүне тәгәл оештырганда гына ирешергә мөмкин. Шуңа күрә, ВАЗдан үрнәк алып, биредә бөтенләй яңа оештыру принциплары кертелә. Башлангыч производство коллективларыннан башлап, ул тулаем промышленность берләшмәсе белән идарә итүне дә үз эченә ала. Производство берәмлекләренә тәгәл экономик һәм технологик нигезләнгән наряд-заданиеләр булдыру — шушы эшчәнлекнең күзгә ин чагылып торырдай үзенчәлеге. Бу очракта заданиене арттырып үтәү — абсурд; аларны бер процентка арттырып үтәү дә наряд-заданиенең дөрес исәпләнелмәгән булуы турында сөйли. Эшсез торуларны бөтенләй булдырмау, җиһазлар һәм кешеләрнең мөмкинлекләрен мөмкин кадәр күбрәк файдалану, ритм, нибары ритм — менә шулар гына хезмәт җитештерүчәнлегенең югары, продукциянең сыйфаты яхшы булуына, үзкыйммәтнең соң чиккәчә кимүенә китерә ала. Хезмәтне шулай оештырганда аерым эшчегә яисә хезмәткәргә матди стимул бирү турыдан-туры барлык башлангыч коллективларның уңышына бәйле. Бу исә, һичшиксез, нык тупланганлыкка, оешканлыкка, коллективизм хисен үстерүгә китерәчәк. Болай эшләгәндә шулай ук аерым кешенең җитештерү көченә һәрьяклап якын килү шартларына да нигез салына. (Әйтик, һөнәр осталыгы өчен өстәмә түләү һ. б. да исәпкә алына.)

Әлбәттә, яңалыкны кертү җиңел түгел. Эш башкаручыларның гына түгел, кайбер җитәкчеләрнең дә иске гадәтләре, әүвәлге, консерватив карашлары авырлык белән җиңелә. КамАЗга кешеләрнең күбесе нигездә эш башыннан һәм сәгатьләп түләнә торган предприятиеләрдән килә. Бу традицион нормалар кешеләрнең психологиясенә

шулкадәр нык урнашкан ки, алар яңача түләү формасына тиз генә күнегә алмады, бу исә башта кадрларның тиз алышынып торуына да китерде. Фәнни әдәбиятта ВАЗ системасы дип аталган яңача түләү формасы, бераз үзгәртелгән формада, КамАЗда уңышлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

КамАЗдагы эшчәнлекнең производство-технологик һәм социаль-экономик үзенчәлеге кешеләр аңында, коллективтагы мөнәсәбәтләр культурасында, алардагы социаль-психология торышында чагыль.ш тапмый калмый. Шушы зур һәм җаваплы эшкә үзләренең дә катнашы булу хисе аларда горурлык уята; бер үк вакытта һәркайсы кыләчәк техникасы һәм производствосы белән идарә итүнең авырлыгын яхшы аңлый.

Минем производство участоклары һәм цех башлыклары белән КамАЗдагы коллективлар үсешенә бәйле мәсьәләләр турында фикер алышканым бар. Аерым алганда, түбәндәге мәсьәләләр тикшерелде: камазлыларның башка күпчелек заводлар вәкилләреннән аерырлык конкрет билгеләре, сыйфатлары бармы? КамАЗ производствосының үзенчәлеге кешеләрдә шушы шартларга яраклы профессиональ һәм социаль сыйфатлар барлыкка китерәме? Һәр сөйләшүдә дә әлеге темаларга карата кызыклы уйлар ишетергә туры килде. КамАЗ белгечләре һәм ветераннары әйтүенчә, бу сыйфатлар — акыл эзләнүе, иң катлаулы инженерлык бурычларын хәл итәргә һәрвакыт омтылып тору. Болар — КамАЗдагы заманча җиһазлар тәэсиренең турыдан-туры нәтиҗәсе. Яңалыкны тою, техник һәм оештыру бурычларын кыю хәл итү. Эшче кешенең тыйнаклыгы һәм гадилеге, бер үк вакытта үзендә эчке ышаныч һәм үз дәрәҗәсен сизү, холык-фигыльләрендә масаю һәм тәкәбберлек булмау. Гүзәл сыйфатларның бу кушылмасы, беренчедән, кешеләрнең техниканың гаять зур мөмкинлекләрен һәм көчен тануы; икенчедән, техниканың куәтле булуына карамастан, аның белән кеше акылы идарә итүен һәм бу техниканың кешелек даһие иҗат итүен аңлавы белән аңлатыла.

Кызыклы бер мисал: берничә дистә яшь инженер һәм техник хезмәткәр ярты ел дәвамында Мәскәүдәге Лихачев исемендәге автозавод цехларында күнегү үтә. Күнегүләре тәгәлләнер алдыннан, аларның барысына да ЗИЛда эшкә калырга тәкъдим итәләр, шәһәрдә калу мөмкинлеге бирелә. Ләкин аларның берсе дә Мәскәүдә калмый, барысы да КамАЗга әйләнеп кайта. Мин аларның кайберләренә: «Сез кайсы ягыгыз белән ЗИЛ эшчеләреннән өстенрәк идегез соң? — дигән сорау бирдем. — Завод җитәкчелеге нигә сезгә игътибар итте?» «Камазлылар, инженер буларак, көчлерәк, ә кеше буларак, гадирәк булгангадыр», — дигән җавап бирделәр алар.

Өч заводта — двигательләр, кою һәм ремонт-инструмент заводларында үткәрелгән тикшерүләр (1976 ел) эшчеләрнең 50 процентының үз һөнәре осталыгын КамАЗда, ә белемнәрен техникумнарның кичке һәм читтән торып уку бүлекләрендә күтәрү теләкләре барлыгын күрсәтте. Эшчеләрнең күпчелеге башка социаль төркемгә, ягъни эшчеләрдән инженер-техник хезмәткәрләр һәм интеллигенция төркемнәренә күчәргә җыенмый. Моны нигездә КамАЗдагы эшче һөнәрләренең абруйлыгы һәм эчтәлеклелеге белән аңлатырга мөмкин.

Техник югары уку йорты тәмамлаган яшь белгечләргә КамАЗга эләгүе җиңел түгел: теләүчеләр күп. Шуңа күрә бик яхшы укучыларга, инженерлык фикерләве төпле һәм өметле булган яшьләргә өстенлек бирелә. Проект оешмаларында, конструкторлык, технология бүлекләрендә, производство участокларында без әнә шундый белгечләрне күп очраттык. КамАЗ шартлары үзе дә икенче югары уку йортына тиң. Биредә берничә ел эшләгән яшь белгеч чын мәгънәсендә чәчәк ата — ул алдынгы техника үсешен киң һәм тирәнтен күрергә өйрәнә. Алар бирелгән техникага ихтирам белән генә түгел, ә сакчыл, кыйммәтен белеп тә карый, заман техникасыннан искечә файдалануга тәнкыйтьчел каршы чыга. Мин яңа җиһазлардан нәтиҗәле файдалануны оештыру өчен кирәкле яңа службалар булдыру өчен җаны-тәне белән көрәшеп йөргән байтак энтузиаст инженерны беләм.

КамАЗда барлыкка килгән яңа сыйфатлар совет эшчесенең әүвәлтеннән килгән гореф-гадәтләрендәге кыйммәтле сыйфатларның әһәмиятен һич тә киметми. Чыдамлык, тапшырылган эш өчен үзендә зур җаваплылык хисе, кирәк чагында үз-үзеңне аямыйча эшләү — аларга һәрвакыт менә шундый күркәм сыйфатлар хас булды. Аларның КамАЗдагы фидакарьлеген бик күп мисаллар белән расларга мөмкин.

Хәзер КамАЗда җаваплы һәм киеренке бурычларны үтәп чыгарга сәләтле күп меңле коллектив бар. Шулай булуга да карамастан, кадрлар мәсьәләсе берләшмәнең төп проблемаларыннан берсе булып кала.

Соңгы өч елда кадрлар килү кимеде, коллективларның берегү һәм ныгуы башланды. Әмма үсеш дәвам итә, КамАЗның сафка басачак икенче чиратына тагын шактый кеше кирәк булачак.

Кадрларны шулай тиз туплауга махсус һәм җитди чаралар күрү нәтиҗәсендә ирешелде. Билгеле, элекке зур төзелешләрнең бай тәҗрибәсеннән файдаланылды, күбесен яңадан уйлап табарга туры килде. Хәтта ВАЗның яңа тәҗрибәсе дә тәнкыйть күзлегеннән үткәрелеп файдаланылды.

Яңа эре промышленность үзәкләрен төзү һәм аларның коллективларын формалаштыруда бөтен ил катнаша. ВАЗда да бу шулай булды. Хөкүмәтебезнең махсус карарлары нигезендә, бирегә гамәлдәге машина төзү предприятиеләреннән оешкан төстә күп санлы белгечләр җибәрелде. Заводның алдынгы техника белән җиһазланган булуы һәм производствоны оештыруның алдынгы ысуллары бик күп талантлы белгечләрне үзенә тартты Бу исә куәтләрне интенсив төстә үзләштерергә һәм продукция җитештерүне тизләтергә мөмкинлек бирде. КамАЗ ВАЗдан соңрак төзелде һәм шуңа күрә бирегә килүче сәләтле белгечләр ташкыны азрак булды. Автомобиль промышленносте министрлыгының гамәлдәге предприятиеләре җитәкчеләре үз белгечләрен югалтырга теләмиләр иде инде. Шуңа күрә КамАЗда үз кадрларын өйрәтү һәм тәрбияләүгә игътибар ителде. Укыту-өйрәтү системасын эшләү һәм булдыру зарурлыгы шуннан килеп чыкты.

Производство әзер булганчы ук, кадрлар туплау Чаллыда сыналган икенче алым булды. Булачак КамАЗ предприятиеләренә эшкә алынган кешеләр вакытлыча төзелеш оешмаларына бирелде. Бу исә промышленность объектлары һәм шәһәр төзелешен тизләтергә мөмкинлек бирде, ләкин килгән кешеләрнең кире китүләрен булдырмау, төзелеш оешмаларында камазлыларның структура берәмлеген саклау кыенлыкларын китереп чыгарды. Кешеләр заводта үз белгечлекләре юнәлешендә эшләргә килгән иде бит. Ә аларга бер-ике, хәтта кайберләренә өч ел төзелештә эшләп торырга туры киләчәк. Монда, әлбәттә, риза булып бетмәүчеләр дә табылды, кадрлар еш алышынуы килеп чыкты. Төзелешкә вакытлыча гына киткән кешеләрнең бер өлеше, яңа шартларга күнегеп, заводка әйләнеп кайтмадылар, төзүчеләргә әверелделәр. Югалтулар шулкадәр зур булды ки, уртача еллык үсеш эшкә кабул ителүчеләрнең яртысы өлешен генә тәшкил итте.

Бу катлаулы һәм җентекле эш кешенең социаль асылы һәм аның табигать ихтыяҗларын, миграция процессларын, кадрлар алышынуның сәбәпләрен һәм башка шуңа охшаш мәсьәләләрне ныклап өйрәнүне таләп итте. Аларны өйрәнү шушы процесслар белән нәтиҗәле һәм максатчан идарә итү чаралары һәм рекомендацияләр эшләү өчен кирәк иде. КамАЗдагы социологик тикшеренүләр бүлегенә тупланган социологлар алдына кадрларның еш алышынуының төп сәбәпләрен ачыклау һәм кадрларны ныгытуга, коллективларны берегәйтү һәм ныгытуга юнәлдерелгән җитди чаралар тәкъдим итү бурычы куелды.

Моның өчен байтак сорауларга җавап бирергә кирәк иде. Әйтик, «Кеше КамАЗдан ни өчен китә?» Моңа төпле һәм тулы җавап бирү өчен үзара бәйләнеше булган бик күп факторларны өйрәнү сорала. «Ул ни өчен китә?» дигән сорауга КамАЗдан нинди кешенең китүе мәсьәләсен анализламыйча җавап табып булмый. Димәк, биредәге шартлардан канәгать булмаган кешеләрнең яшен, һөнәрен, женесен, гаилә хәлен һәм башкаларны ачыклау зарур. Аларны нәрсә канәгатьләндерми? Производство шартларымы? Шәһәрме? Климат шартларымы? Әллә коллективтагы мөнәсәбәтләрме? Әгәр дә без «КамАЗга кем һәм ни өчен килә?» — дигән сорауга җавап бирмәсәк, алдагыларына да җавап табуы кыен.

Берләшмә подразделениеләрендә үткәрелгән байтак социологик тикшеренүләр ныгып, оешып килгән гаять зур коллективның тотрыклырак тенденцияләрен ачыкларга мөмкинлек бирде. Табигый, аерым бер кешенең тормыш юлы уртача ста-

тистик биографиядәгечә үк түгел. Әмма бу очракта социаль организмның аякка басуындагы төп билгеләрне ачыкларга кирәк иде. Әйтик, кешенең яшәү урыны итеп КамАЗны сайлавының төп сәбәпләре нидән гыйбарәт?

1975 елда ВЛКСМ Үзәк Комитетының Югары комсомол мәктәбе аспиранты Н. Лукашевич катнашында үткәрелгән тикшеренүләр — 36 яшьләр бригадасын өйрәнү (800 кеше) менә мондый күренешне ачыкларга ярдәм иткән. Аларның 14 проценты КамАЗга удар төзелеш романтикасы хисе китерүен әйтте. Мондыйлар — 23 тулмаган яшьләр. 6,7 проценты яңа һөнәр алырга исәплап, 5,3 проценты эшкә бирегә билгеләнүе сәбәпле, 4,5 проценты зуррак эш хакын күздә тотып, ә күпчелеге — 54 проценты тизрәк квартир алу исәбе белән килгән.

Күренгәнчә, КамАЗга күпчелек үзенең көнкүреш шартларын яхшырту максаты белән килә. Ике елдан соң үткәрелгән яңа тикшерү СССР Министрлар Советы карары нигезендә КамАЗга җибәрелүчеләрнең инде 86 процентының торак таләбен күздә тотуын күрсәтте.

Әйе, фактлар белән исәпләшергә, аларның табигатен өйрәнергә, җаваплы карарларны фактларны исәпкә алып кабул итәргә туры килә. Югыйсә, идарәнең сыйфаты түбән булачак, идарәче вакыйгалардан артта калачак.

Мәгълүм булганча, яңа шәһәр бөек төзелешләр тарихында беренче мәртәбә барак һәм палаткалардан башланмады. Барлык уңайлыклары булган квартирлар — күп төрле хезмәт ияләрен бирегә тартучы төп көч булды. Билгеле, башка сәбәпләрне дә читләтеп үтәргә ярамый. Алар кешеләрне КамАЗ һәм Чаллыга җәлеп итүгә төрлечә һәм төрле бәйләнештә тәэсир итәләр.

Моның үз диалектикасы бар. Мәсәлән, Ленинград социологларының 1967 елда чыккан «Кеше һәм аның эше» дигән хезмәтендә ясалган нәтиҗәдән күренгәнчә, яшьләр үз күңеленә ошаган эшне хезмәт хакыннан өстенрәк күрә. Әлбәттә, бу шулай. КамАЗдагы социаль тикшеренүләр андагы идеяләрне үстерергә дә мөмкинлек бирде. Безнең 1975 елгы тикшеренүләрдә кешенең яшәү ихтыяҗы бер халдә генә тормавын, бәлки кешенең яшенә, гаилә хәленә, шулай ук башка шартларга бәйле рәвештә үзгәрүен күрсәтте. һәм аның нәтиҗәләре бу фикеребезнең дөреслеген икърар итте. Мәсәлән, «торак» сәбәбе яшь буенча төрлечә бүленә. Тикшеренү үткәрелгән кешеләр арасында 22—25 яшьтәгеләрнең 44,2 проценты, 26—28 дәгеләрнең — 60, ә инде 29—30 яшьтәгеләрнең 86,4 проценты КамАЗга тизрәк квартир алу максаты белән килгән. Табигый, кеше үзенең төрле чорында тормыш мәсьәләләрен төрлечә хәл итә. Егерме ике яшькә кадәрге буйдакка һөнәр сайлау, квалификация алу әһәмиятле; эш хакы, торак мәсьәләсе аны артык кызыксындырмый. Өйләнгәч яисә кияүгә чыккач, кешеләр торак ээли башлый, башка мәсьәләләрнең арткарак чигенүе дә ихтимал. Беренче бала туу яшь ата-ананы балалар бакчасында урын эзләргә мәҗбүр итә. Әйтеп үтик, идарә коллективына бу динамиканы да искә алып эш итәргә кирәк була.

Хәзер инде «Кеше КамАЗдан ни өчен китә?» дигән соравыбызга әйләнеп кайтыйк. Бүген моңа җавап бирүе җиңелрәк, чөнки бирегә кемнең ни өчен килүе шактый ачыклана төште. Ә боларны белмичә, коллективны формалаштыру белән нәтиҗәле идарә итү, производство участокларында тиешле мөнәсәбәтләр урнаштыру мөмкин түгел. Безгә барлык төп категория кешеләр һәм аларга характеристикалар билгеле булырга тиеш. Без шулар нигезендә генә киләсе көнебезне, алдагы елларны, бишьеллыкларны планлаштыра алачакбыз. Әгәр без моны белмәсәк һәм аңламасак, килеп чыккан һәр вакыйга, һәр ситуация саен аптырашта калачакбыз.

Кешенең производстводан китүенә, кагыйдә буларак, бер генә фактор түгел, ә **«факторлар төене»** тәэсир итә. Әгәр кеше Чаллыга бер генә проблеманы — эш хакы яисә торак, яисә уңышсыз өйләнешүдән соң тормыш иптәше табу мәсьәләсен җайга салу максатын гына күздә тотып килгән икән, ул коллектив өчен тотрыклы эшче була алмый. Әгәр аның ихтыяҗы вакытында канәгатьләндерелмәсә, ул кире китә яисә башка эшкә күчә. 1974—1978 елларда КамАЗдан киткән андый кешеләрнең биредәге уртача эш стажы ярты ел чамасы тәшкил итә.

Бер генә түгел, ә берничә фактор — завод масштаблары, яңа производство, шәһәр, табигать һәм башкалар җәлеп итүе нәтиҗәсендә килгән кешеләр, социолог күзләгеннән караганда, завод һәм шәһәрнең тотрыклырак өлешен тәшкил итә. Андый

кешеләр башлыча үз максатларына ирешсәләр һәм ирешмәсәләр дә, бер урында озакка төпләнеп калалар. Аларны өйрәтергә, үстерергә, аларга таянырга кирәк.

Әлбәттә, кимчелекләр «төене» — җитди нәрсә. Аларны булдырмау һәм кешеләргә начар тәэсир итмәве өчен тырышырга кирәк. Мәсәлән, кеше ике ел квартира көтәргә һәм гаиләсеннән аерым яшәргә диган фикер белән килеште ди; килгәч, хатынының үз белгечлеге белән эшләмәве белән дә килешүе ихтимал. Шулай итеп, ике факттан «төен» барлыкка килде. Ә менә балалар бакчасында урын юк, начальнигы белән мөнәсәбәтләре яхшы түгел. Шик юк, бу төеннәр инде кешенең эштән китүенә һәм, бәлки, кыйммәтле белгечне югалтуга китерә.

Бүген хуҗалык җитәкчеләре предприятие коллективларын оештырганда хатын-кыз хезмәтеннән файдалану мәсьәләсен һаман саен ешрак хәл итәргә мәҗбүр. Хатын-кызлар — әлегә җитәрлек файдаланылмый торган эшче көч. Ни өчен? Аларның бер «кимчелекләре» — балалары бар. Хуҗалык җитәкчеләре өчен бу өстәмә мәшәкать — балалар бакчалары һәм яслеләр төзергә һәм аларны карап тотарга кирәк.

Кадрлар алышынуы предприятиеләрнең балалар учреждениеләре белән ничек тәэмин ителүенә турыдан-туры бәйле. Мәгълүм булганча, бала ышанычлы кулларда һәм уңайлы шартларда булганда гына хатын-кыз тулы көченә һәм тыныч эшли. Һәм ул баласы өчен шундый шартлар булган урынга гына эшкә керә. Андый шартлар булмаса, эшеннән китәргә мәҗбүр була.

Яшь ата да баласын куярга урын булмаган производствода төпләнеп калмый. Чөнки хатыны бала белән өйдә утырса, гаилә бюджетына зыян килә. Шунысы да бар, яхшы белгечлеге һәм квалификациясе булган хатын-кызның бала карап өйдә утырырга да теләге юк.

КамАЗ бик яхшы балалар комбинатлары төзи. Шулай да балалар учреждениеләренә булган ихтыяҗ бик зур әле. Кадрларның еш алышынуы менә шуннан да килеп чыга.

Сүз уңаеннан әйтеп үтик, шәһәрнең башка оешмалары һәм предприятиеләре балалар учреждениеләре белән КамАЗга караганда начаррак тәэмин ителгән. Шуңа күрә анда хатын-кызлар шактый күп. Алар балалары хакына бередә теләсә нинди эшкә урнашалар.

Балалар учреждениеләре төзү коллективлар үсеше темпларына туры килергә тиеш. Ә кайбер объектив сәбәпләр — төзү оешмаларының куәте җитмәү, аларның эшчеләр белән тиешенчә тулыландырылмаган булуы балалар комбинатларын төзү һәм сафка кертүне тоткарлый.

Күңелне борчый торган субъектив сәбәпләр дә бар. Кайберәүләр фикеренчә, балалар учреждениеләрен интенсив төзү КамАЗ өчен файдалы түгел, чөнки аларның киләчәктә бушап калулары ихтимал. Мондый заман кайчан килер икән соң? Бу карашның исәп-хисапка нигезләнгән ныклы җирлеге юк. Бу — тар, ведомстволы караш. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре мәсьәләләре, социаль-культура-көнкүрешнең башка проблемалары кебек үк, шәһәр үсеше дәвамында хәл ителергә тиеш.

КамАЗ коллективының оешуына йогынты ясый торган тагын бер факторга тукталып үтик. Бу — милли структура. Автогигант подразделениеләрендә дистәләрчә милләт вәкилләре эшли. Алар арасында бернинди «кытыршылыклар», ягъни «милли мәсьәлә» юк. Процент ягыннан алганда, күпчелеге — руслар. Икенче урында — татарлар. Аларның безнең республикадан гына түгел, Ульяновск, Куйбышев өлкәләреннән, Башкортстаннан, Урал, Себердән һәм башка бик күп урыннардан килгәннәре дә байтак. Чуваш, удмурт, украин, белорус, грузин, әрмән, әзербәйҗан һәм башка милләт вәкилләре дә күп.

Аларның КамАЗда төпләнүләре төрлечә, сан ягыннан һаман үзгәреп торалар. Коллективның гомуми структурасында татарларның сан ягыннан үсеш динамикасы игътибарны җәлеп итә. Мәгълүматларга караганда, 1977 елда татарлар бередәге халыкның 17 процентын тәшкил итсә, 1980 елның февраленә алар ике мәртәбә артты — 34 процентына якынын тәшкил итте. Бу — тотрыклы тенденция, КамАЗ коллективында татарлар саны үсә барачак. Җирле халык һәрвакыт тотрыклырак була, чөнки, ни әйтсәң дә, туган як, туган табигать, ата-бабалар, туганнар җире... КамАЗ

профессиясен үзләштергән һәм заман производствосының социаль сыйфатларына ия булган татарларның бередә төп милли катламга әверелүе бик мөмкин. Җәмгыятьтәге фән-техника һәм социаль-экономик прогресска үз өлешеңне кертү — безнең халык өчен зур дәрәҗә һәм гаять җаваплы миссия.

Автогигант коллективы. КамАЗның беренче чираты сафка басканда ук аның генеральный директоры Л. Б. Васильев: «Безнең бу гигантны эшләтү өчен ышанычлы коллективыбыз бар»,— дигән иде. Ул коллектив оештыруда башкарылган эшкә югары бәя бирде. Хәзер бу коллективта берничә дистә мең кеше исәпләнә, ә аның яңа подразделениеләрен тулыландыру дәвам итә. Даими үсештәге катлаулы социаль организм сыйфати үзгәрешләрнең яңа баскычларын үтә.

Бүгенге көндә коллективның төп структурасы оешты, ягъни башлангыч подразделениеләрдә коллективларның үзәге, активлары, җитәкчеләре, әйдәп баручылары формалашты, үз нормалары, традицияләре барлыкка килде, социаль-психология халәненең тотрыклы билгеләре күренә башлады.

КамАЗның нигез ташы салынган көннәрдә үк бирегә килүчеләр иң хөрмәтле кешеләр булып саналалар. Алар — төзелештәге иң авыр чорны бередә үткән, юлсыз чакта пычрак изгән, гел булып торган шимбә һәм якшәмбе өмәләрендә катнашкан, көйләү-җибәрү эшләрен башкарган, авырлыкларны үз җилкәләрендә кичергән кешеләр.

Каманың борынгы ярлары... Кайчандыр үзләрен болгарлар дип атаган кешеләр өчен изге җир. Бу җир күпне күргән. Ул Көнчыгыш цивилизациянең чәчәк аткан чорын да хәтерли. Кыргый кабиләләр көтүе тарафыннан да тапталган, вәхшиләр тарафыннан җимертелгән һәм яндырылган...

Бүген бу елганың ярлары кешелек акылы һәм хезмәте ялкыны белән яктыртылды. Тиңе булмаган завод-баһадир, гүзәл яңа кала төзелде. Бередә яңа кеше — КамАЗ кешесе туып килә.

Совет Татарстаны КамАЗ һәм Чаллыны күтәргәндә гаять зур авырлыкларны горурлык белән җиңеп чыкты. Шик юк, алда торган җаваплы бурычлар да уңышлы рәвештә тормышка ашырылачак.

Нариман ФӘТХУЛЛИН,
философия фәннәре кандидаты.

*Ахыры бар.*

Азат Әхмәдуллин

# ЧЫН КЕШЕ БУЛЫП ЯШӘҮНЕҢ СЕРЛӘРЕ

*Туфан Миңнуллин иҗатына бер караш*

Бүгенге милли сәхнәбезне тотып торучы драматурглар арасында Туфан Миңнуллин алдагы урыннарның берсенә чыкты. Аның үзенчәлекле һәм өлгергән, халыкчан һәм партияле иҗаты аерым алып өйрәнүгә, уртага салып сөйләшүгә һәм махсус язылган хезмәтләргә лаек. Кай яклары белән ул хәзерге тамашачыга якын һәм кирәкле, ни өчен режиссерлар аның пьесаларына ялтып алыналар һәм, һәрвакыт дип әйтерлек, уңышка ирешәләр? Ниһаять, драматургия һәм театр тарихында бу иҗатның урыны кай тирәдәрәк?

Шундый мәкалә язарга дигән редакция тәкъдимен кабул иткәч, гадәтемчә, хат конвертларыннан гыйбарәт булган пакетлар тартып чыгардым. Аларда аерым драматургларга кагылышлы материаллар — кәгазь кисәкләренә теркәлгән фикерләр, чыганак-карточкалар, спектакльләрнең премьералары, пьесаның кайда беренче басылуы турындагы һ. б. мәгълүматлар тупланган. Эшкә керешеп китү өчен бик кирәкле «чимал». Ләкин ни гаҗәп, бу юлы конвертлар арасыннан мин тышына «Т. Миңнуллин» дип билгеләп-язып куелганын табып, тартып алу хаҗәтен күрмәдем. Т. Миңнуллин иҗаты тулаем хәтердә икән бит! Менә алда аның 6—7 китабы — пьесалар һәм хикәяләр җыентыклары ята. Аларга кергән әсәрләрнең кайчан язылганы, кайсы елны һәм кайда сәхнәдә куелганы, тагын да кайсы театрларда уйналганы, кайсыларына нинди бүләкләр бирелгәне, аларга нинди рецензияләр һәм мәкаләләр язылганы — барысы да хәтер шүрлегендә рәт-рәт булып тезелгән. Сәбәбе нидә? Иң беренче, шунда, күрәсең — Т. Миңнуллин иҗаты соңгы 10—12 ел эчендә чәчәк атты. Бөтенесе күз алдында. Шуның янына бу авторның әсәрләре минем үземә, әдәбиятка һәм сәнгатькә булган карашларыма һәм зәвыкларыма якынлыгын, шәхес буларак аңар карата битараф булып кала алмавымны, тагын да төгәлрәк әйткәндә, язучы һәм кеше буларак аңа соклануымны да китереп кушсаң, бу иҗатның хәтердә ни өчен аерым бер урын алуын аңлау артык кыен булмас. Әлбәттә, мәсьәлә һич тә моның белән генә чикләнә алмый әле. Төп сәбәп Т. Миңнуллин пьесаларының гаҗәеп тормышчанлыгында һәм художество ягыннан оригинальлегендә, заманыбызның өлгергән мәсьәләләрен сәнгатьчә төгәл итеп, җыйнак һәм үткен төстә хәл итә белүендә. Сине һәм мине бердәй борчыган мөһим сорауларга вакытында һәм дөрес, кызыклы һәм тулы итеп бирелгән җавап хәтергә тирән уелып кала. Чын сәнгать нәкъ менә шуның белән көчле дә инде.

## 1

Драматургия, мәгълүм булганча, асылда әдәби жанр. Шуның белән бергә ул әдәбият кысаларында гына да калмый. Пьеса спектакльнең инсценировкасы ролен уйный, ягъни үзендә театр драматургиясенең төп сыйфатларын йөртә. Драматургиядән башка театр да, кино да була алмый. Димәк, аны бары тик сүз сәнгатенә генә кайтарып калдырып булмый. Аның тәэсир итү чикләре киңрәк һәм үзенчәлеклерәк. Драматургия — сәнгатьнең күп төрләре арасында ята торган художество формасы. Әдәбиятның башка жанрларына куела торган таләпләр драма өчен ярап бетмәскә дә мөмкин. Мөстәкыйль алып караганда, драма жанры сүз сәнгатенең иң шартлы төрләреннән берсе. Бөек Пушкин юкка гына «барлык төр әсәрләр арасында драматик әсәрләр — дөрескә иң охшамаганнары» дип әйтмәгән, күрәсең. Шуның белән бергә драматургия чынбарлыкны сәнгатьтәге югары нокталарга күтәреп сурәтләп бирергә ярдәм итә торган иң уңай, тормышны үз формаларында чагылдыруның күп төрле чараларына бай булган формалардан берсе. Моның өчен жанрның эчке мөмкинчелекләрен, үзенчәлекләрен, ягъни

серләрен яхшы үзләштерергә һәм белергә кирәк.

Шул хәл элек-электән драматургларның тормыш биографиясендә дә үзенә бер үзенчәлекле төстә чагыла килә. Бездә драматургиягә театр аркылы килү очраклары байтак. Классик драматурглар Кәрим Тинчурин һәм Таҗи Гыйззәт мисалын алыйк. Беренчесе танылган артист һәм режиссер, татар совет театрының нигезен салышкан күренекле сәхнә эшлеклесе. Икенчесе шулай ук язучылыкка актерлык юлы аша килә. Галиәсгар Камал татар театрын оештыручы, аның «атасы», ул сәхнәдә үзе дә шактый ук уйнаган кеше. Гафур Коләхметов эне һәм сеңелләрен спектакльләргә тарта, беренче театр постановкаларын оештыруда актив катнаша, үзе дә спектакльләрдә уйный. Мирхәйдәр Фәйзи үзешчәннәр белән пьесалар сәхнәләштерә, аларның режиссеры һәм артист та була. Фәтхи Бурнаш иҗат юлын Г. Кариев труппасы өчен пьесалар тәрҗемә итүдән башлый, ә егерменче еллар ахырларында Татар дәүләт академия театрында директор булып эшли. Риза Ишморат — режиссерлыктан, Хәй Вахит — җырчы артистлыктан үсеп, алга таба драматургия өлкәсендә иҗат итә башлаган язучылар. Инде килеп Т. Миңнуллин — шул үзенчәлекле традицияне дәвам итә, ул театрдан әдәбиятка килде. Аннан яшьрәк буын драматурглар арасында да кичәге актерлар бар: Роберт Батулла, Юныс Сафиуллин... һәм аларның пьесалары, иң әүвәл, сәхнә серләрен тирән белеп иҗат ителгән булулары белән, сәхнә сәнгатенең тамашачыга тәэсир итү мөмкинлекләрен исәпкә алган булулары белән аерылып тора.

Шулай, Т. Миңнуллин — сәхнәдән драматургиягә килгән кеше, театр эчендә кайнап, аның һавасын сулап, махсус белем алып та, актерлык тәҗрибәсе туплап та җитлеккән каләм иясе. Менә шуның өчен дә булса кирәк, аның пьесалары куюө өчен режиссерларга, уйнар өчен артистларга уңай, карар өчен тамашачыга кызыклы.

Аның биографиясе алай артык катлаулылардан түгел. Балачагы авыр сугыш елларына туры килгән (Туфан 1935 елда туган). Ул яшьли шул данлы да, газаплы да чорның кайгы-хәсрәтләрен, михнәт-авырлыкларын чумырып эчкән һәм татыган. Шул еллардагы барлык авыл малай-кызлары өлешенә чыккан крестьян хезмәте, ямаулы күлмәк-бишмәттән укырга йөрүләр... Ватан сугышыннан соңгы беренче унъеллыклар да тормыш көтү өчен җиңел түгел иде. Балалар өлешенә тигән авырлык еш кына укудан аерылып калуга, мәктәпне ташлауга китерә иде. Бәхеткә каршы, Туфан белән мондый хәл булмады. Мәрхәмәтле гаилә ничек итсә иткән, малайны укыткан, ул үзе дә тырыш булган. Аннан урта мәктәп белеме белән генә дә канәгатьләнми, Мәскәүдәге махсус театр институтына укырга керә, аны тәмамлый.

Дөресен әйтергә кирәк, артист Т. Миңнуллин сәхнәдә артык эз калдырмады. Студент елларында ук кагылган «язучылык җене» аңар уен сәнгате белән чын-чыннан шөгыльләнергә ирек бирми, кирәсең. Шулай да нәкъ менә театр студиясендә уку һәм Академия театрында эшләү еллары Т. Миңнуллинны әдәбиятның иң авыр төрләреннән булган драматургияне үзләштерү өчен әзерләп җиткерәләр. Яшь егет журналистикага күчә, «Чаян» журналында эшләгән елларында аңардагы юмор таланты ачылып китә. Ул шактый санда көлкеле һәм «камчылы» хикәяләр яза, кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре иҗат итә. Болар һәм 1968 елда аерым китап төсендә дөнья күргән «Азат», «Айга сәяхәт» дип аталган әкият-пьесалары яшь иҗатчының өйрәнчек чорын тәшкил итә. Бу чор чагыштырмача кыска, Туфан аны бик тиз узды. Шуңа күрә дә аның олы сәхнәгә килеп чыгуы тамашачы өчен дә, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчеләре өчен дә көтелмәгәндәрәк булды. 1968 елда берьюлы ике олы сәхнәдә — Татар дәүләт академия театрында һәм Республика татар дәүләт күчмә театрында (хәзерге Республика драма һәм комедия театры) аның «Миләүшәнең туган көне» драмасы һәм «Нигез ташлары» комедиясе уйнала башлады. Шулай итеп, Туфан Миңнуллин дигән яңа автор милли сәхнә түренә үтте. Аның бу «тәкәллефсезлеген» тамашачы,— театр тәнкыйте турында инде әйтеп тә торасы юк!— хуплап һәм сөенеп каршылады. Тиз арада бу драматургиянең үз режиссерлары ачыкланды, актерлары билгеләнде, аудиториясе тупланды. Бүген афишалар — Академия театраныкыны ул, Минзәләнекеме, Әлмәтнекеме, Драма һәм комедия театрыныкымы — аның әсәрләре исеменнән башка басылмыйлар һәм эленмиләр.

Укучы өчен (ә безнең халык драманы карарга гына түгел, укырга да бик ярата) драматург Т. Миңнуллин исеме 1969 елда басылып чыккан «Бәхетле кияү» исемле бер әр пәрдәлек пьесалар җыентыгы белән танылды. Җыентыкка кергән әсәрләр, бигрәк тә «Бәхетле кияү», «Бакча каравылчысы» дип аталган комедияләр һәм «Чакыру билеты» дигән скетч талантлы кулдагы җитлеккән каләм белән язылган. Болар — авторның, яшьлеге яисә тәҗрибәсезлеге дигән кебек, һичнинди ташламалар сорамый торган югары сәнгать әсәрләре иде. «Миләүшәнең туган көне», «Нигез ташлары» пьесалары, «Бәхетле кияү» җыентыгына кергән кече күләмле әсәрләре белән Т. Миңнуллин олы әдәбиятка һәм сәхнә сәнгатенә җитди заявка ясады. Шуннан бирле узган кыска вакыт эчендә аның язучылык таланты формалашты, иҗади йөзе билгеләнде һәм ачыкланды. Хәзер Т. Миңнуллин иҗаты 20 гә якын тулы күләмле пьесалар, дистәләгән кыска күләмле сәхнә әсәрләре белән, күп санлы кечкенә хикәяләр һәм юморескалар, публицистик мәкалә һәм чыгышлар белән билгеләнә. Драматургның иҗатын аның иҗтимагый эшчәнлегеннән башка бәяләп булмый: менә ничә еллар инде ул — Татарстан Язучылар союзының партоешма секретаре. Халык депутатларының Казан шәһәр Советы әгъзасы буларак та ул зур һәм җаваплы вазифалар башкара.



*Якташлар Ибраһ Гази һәм Туфан Миңнуллин. 1970 ел.*

Тормышта Туфан шаян кеше, җор һәм тапкыр фикердәш. Аны һәрчак кеше уратып алган булыр, ул булган җирдә һәрвакыт шаян сүз яңгырар, күтәренке кәеф өстенлек итәр. Аның фикерләве җәһәт, теле үткен, ул һәрнәрсәдә кызык һәм тәм таба белә. Андый кешегә яшәве күңелле, аның белән башкаларга да һәрчак җиңел. Аның чыгышларын каләмдәш дуслары көтеп алалар һәм кайда да яратып тыңлыйлар. Ләкин бу һич тә Миңнуллин — ерык авыз, артык җиңел яисә җилбәзәк диган сүз түгел. Киресенчә. Кирәк җирендә һәм вакытында ул бик сабыр һәм уйчан, аек акыллы һәм тирән фикерле, җитди кеше. Драматург характерындагы мондый сыйфатлар ул язган әсәрләргә дә үзенчәлекле эз сала. Гомумән алганда, аның пьесалары тормышның нәкъ үзе кебек — якты һәм күтәренке, аларның үзәгендә оптимизм ята. Нәкъ менә чынбарлыктагыча, аларда җитдилек һәм күңеллелек, шаян рух һәм мәгънә тирәнлеге аралашып, үзара тыгыз үрелеп килә. Бу яктан аның әсәрләрен башка берәүнең дә пьесалары белән буташтырып булмый.

2

Т. Миңнуллин драматургиясе темасы һәм проблематикасы ягыннан бай һәм күп тармаклы. Драматург билгеле бер темага, тормыш материалына яки бер сыйфаттагы геройларга гына ябышып ятмый. Дөрес, берчакны автор үзе Актерлар йортында барган сөйләшү вакытында: мин — авыл малае, авылны чагыштырмача яхшы беләм, шуңар күрә миннән, әйтик, эшчеләр, нефтьчеләр турында әсәрләр бик үк көтмәгез, диган сыманрак сүзләр әйткән иде. Әмма аның иҗат практикасы моның киресен раслый. Ул шулай булырга тиештер дә инде. Чөнки чын талант бертөрлелек корбаны була алмый. Ул өзлексез эзләнүдә. Шуңа күрә дә Т. Миңнуллин кебек агымдагы тормыш белән нык бәйләнеш тоткан актив иҗатчының тематик төрлелеккә һәм образлар байлыгына омтылуы бер дә гаҗәп түгел. Киресенчә булса сәер тоелыр иде. Жанрлар ягыннан караганда да драматургның иҗаты күп төрле: психологик драма һәм комедиянең төрле төре дә, водевиль һәм әкият-пьеса да, тарихи драма да...

Т. Миңнуллин материалны асылда бүгенге көннән ала, аның пьесаларының күпчелеге безнең көннәрне чагылдыра. Тарихи үткәнгә караган пьеса әлегә бары берәү генә. Димәк, Т. Миңнуллинны чын мәгънәсендә бүгенге көн язучысы дип атарга мөмкин. Көндәлек тормышны, күз алдында бара торган вакыйгаларны, бүген туган һәм кичекмәстән хәл итүне сораган мәсьәләләрне чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрү, замандашыбызны художество югарылыгына бастырып күрсәтү гаять авыр эш. Шуның белән бергә шул дәрәҗәдәге үк мактаулы да! Сәхнә әдәбиятыбыз заман сорауларына электән үк аерата игътибарлы булган. Шул җәһәттән Т. Миңнуллин иҗаты белән иң алдынгы һәм күренекле традицияләр дәвам иттерелә.

Туфан Миңнуллин драма өчен материалны тормышның төрле өлкәләреннән таба белә, яңадан-яңа фикерләр күтәрә, пьесаларында куелган проблемалар күпчелек очракта мөһим һәм оригиналь, тамашачының игътибарын билэп ала торган була. Менә шул төрлелек арасында да Т. Миңнуллин иҗатына хас булган өч юнәлешне аерып күрсәтергә мөмкин. Алар драматург талантының һәм эшчәнлегенең колачын билгелиләр, иҗади эзләнүләрнең мөһим якларын туплап чагылдыралар.

Беренче юнәлешне «Миләүшәнең туган көне», «Күрше кызы», «Уйланыр чак», «Китәр юлың еракмы?», «Дуслар җыелган җирдә», «Адәм баласына ял кирәк» дип аталган пьесалар тәшкил итә. Аларны бүген Бөтенсоюз драматургиясендә көчәйгән тенденция — интеллектуаль-фәлсәфи башлангычка омтылуны ачык чагылдырган әсәрләр дип карарга кирәк. Боларда авторның төп игътибары мораль-этика мәсьәләләренә юнәлгән. Җитлеккән социализм җәмгыяте шартларында нинди әхлак принциплары өстенлек итә? Кешеләр арасындагы, кеше белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрнең нигезен нинәрсәләр билгели? Бу нормалар ни күләмдә тормышчан һәм ни дәрәҗәдә тотрыклы? Менә шул сорауларга җавап эзләү төп проблематиканың әһәмиятен күтәрә. Коммунизм иң югары мораль принципларга нигезләнгән җәмгыять булачак, бу җәһәттән аның белән үткәндәге бернинди җәмгыять тә тиңләшә алмый. Димәк, коммунизмны бары тик югары әхлакка ия булган кешеләр генә төзи ала. Шулай булгач мораль-әхлаки проблемалар торган саен үзләренең әһәмиятләрен арттыра гына баралар. Әдәбиятның һәм сәнгатьнең барлык төрләре кебек үк, драматургия

һәм театр да шул процессны чагылдыралар. Т. Миңнуллинның югарыда саналган пьесалары аның шул процесс үзәгендә торуын күрсәтә.

Бигрәк тә «Миләүшәнең туган көне» һәм «Дуслар җыелган җирдә» драмалары характерлы. Алынган проблемалары белән дә, персонажлары бер үк булу ягыннан да алар бер-берсенең дәвамын тәшкил итә. Драмаларда кешенең тормышта үз урынын дөрес билгеләргә тиешлеге мәсьәләсе куела. Ул «Миләүшәнең туган көне»ндәге кичәге студентлар, бүген олы тормышта әле беренче адымнарын гына атлаучы яшьләр өчен бик җитди һәм катлаулы. Инде тормыш юлының уртасына җитеп килүче шул ук геройлар «Дуслар җыелган җирдә» пьесасында мәсьәләнең (әлбәттә, башка төрле яклырының) әле дә үзләре өчен актуаль булып калуын, хәл ителмәгән булуын күреп беркадәр аптырашта калалар, тирән кичерелешләргә төшәләр. Шулай, үз тормышыңны мәгънәле итеп, җәмгыятькә һәм халыкка файдалы төстә кору җиңел эш түгел. Тормыш катлаулы булып кала бирә, дөрес итеп яшәү кагыйдәләре кешене һәрвакыт, бөтен гомере буе сыныйлар һәм чыныктыралар. Әле яшь вакытларында ук Шәһит кебек формалист иптәшләренә каршы чыккан, аның яшәү фәлсәфәсен фаш иткән Миләүшә, Нурислам, Фәһим, Рәфисләр («Миләүшәнең туган көне»), олыгая төшкәч, үзләренең дә каядыр икенче якка авышып баруларын төшенеп алалар («Дуслар җыелган җирдә»). Инде хезмәт баскычында ниндидер урын биләнгән, дәрәҗәләре дә ирешелгән: Фәһим — композитор, Рәфис — докторлык диссертациясе яклау алдында тора, Гайнулла, аларның яңа иптәшләре, химик, шулай ук фәннәр кандидаты. Уңайлы квартира, очрашканда коньяк һәм шампанское кебек затлы эчемлекләр генә эчәргә мөмкинлек бирә торган хезмәт хакы... һәм менә шулар янәшәсендә каядыр күңел китеклеге, канәгатьсезлек...

Т. Миңнуллин катлаулы, җанлы һәм тормышчан характерларны оста сурәтли белә. Образлар күпкырлы, шуның белән аңлаешлы һәм якын да. Сүз бара торган ике драма бу яктан татар сәхнәсендәге күренекле әсәрләрдән саналырга хаклы. Мәгълүм булганча, заманында театрда шактый көчле тамырлар җибәргән схематизм һәм ясалмалык, декларативлык урынына хәзер чынлыкка ирешү, дөреслеккә омтылу алмашка килде. Бүгенге татар театры ирешкән бу уңышта Т. Миңнуллинның өлеше зур.

Кеше — табигатьнең иң гүзәл баласы. Аны бер генә схема эченә утыртып, иҗтимагый законнар тарафыннан билгеләнгән кысага сыйдырып бетереп булмый, аның эш-хәрәкәтләрен, акыл-фигылен туры сызык белән генә билгеләп куя алмыйсың. Бүгенге сәхнә шуларны истә тотып эш йөртергә омтыла. Кеше — иң катлаулы җан иясе. Каршылыклар аның табигатенә салынган, каршылыклар белән көрәшү сәләте аның акылында оеткы булып ята. Беренче карашка гади генә күренгән курку хисен генә алыйк. Курку — кешенең яшәү табигатендә аерылмас бер юлдаш, ул каяндыр читтән килеп кергән ят нәрсә түгел. Гомереӊ өчен курку, якыннарың, дусларың өчен курку. Шуңа күрә дә «мин курыкмыйм!» дип хәрәкәт иттерелә торган сәхнә геройлары — автор бармакларына җепләр белән бәйләп куелган курчаклар алар. Ләкин үзең өчен генә курку бар, Ватан иминлеге, халык һәм ил язмышы өчен курку һәм җаваплылык хисе бар.

Беренче хис инстинктка салынган, икенчесе — акыл үсеше һәм әхлак дәрәҗәсе белән бәйле. Әгәр дә инде беренче хис икенчесе, олы һәм тирән хис алдында чигенә, үзенең әһәмиятен югалта икән, кеше шул икенче изге хис хакына үзен корбан итә алуга да бара икән, ул хис бөтенләй башкача — «батырлык» дип атала. Бөек диалектика, шулай итеп, монда да үз сүзен әйтә. Сәхнәдә характер җанлылыгына да шундый типтагы мәңнәрчә мәсьәләләрне хәл итеп кенә, шуларны күрсәтеп кенә ирешеп була. Соңгы вакытта көчәйгәннән-көчәя барган интеллектуаль драма шуларны куя, чишә, тамашачыга аларның асылын аңлата. Икенче сүзләр белән әйткәндә, яшәү фәлсәфәсен өйрәнә һәм өйрәтә. Бу, тулаем алганда, тормыш дөреслегенә торган саен якынай барган сәнгать дөреслегенә ирешү дигән сүз. һәм ул драматургның талант зурлыгына, гражданлык хисенең олылыгына бәйле.

Т. Миңнуллин үз пьесаларында, бигрәк тә «Дуслар җыелган җирдә» драмасында геройларында яңа төр мещанлыкка үсеп баручы тискәре сыйфатларны табып күрсәтте. Дуслык дигән изге хисне Рәфис һәм Фәһим, Нурислам һәм Гайнуллалар бер-берсенә кунакка йөрү, бер-берсен мактәшу дип кенә кузаллый башлаганнар. Җәмгыятьтән аванска күп алынган, әмма тагын да күбрәк кайтарып бирергә кирәклек турында, моның өчен үзеңдәге бөтен көч-сәләтне эшкә җигү зарурлыгы хакында бераү дә уйламаска күнеккән. Драматург үз яшьтәшләрен, алар аркылы үз буынын югары идеаллар белән янып яшәргә чакыра. Тынчу тынлык сөю, иҗади талантны ваклау һәм әрәм-шәрәм итү, үз вөҗданың алдында да, бүтәннәр каршында да, кирәкмәгән ташламаларга бару — яңа төр мещанлыкны тудыра да инде, кешене шәхес булудан туктата. Мондый тискәреләкләрне автор «пәриләр»гә охшата. Урман уртасында җомга көнне «чәршәмбе, чәршәмбе!» дип кычкырышып туй ясап ятудан тәм тапкан пәриләр белән бөкре егет уртак тел таба, шуның аркасында бөкресеннән котыла. Икенче бер бөкре егет исә, бу өергә каршы барып, дөреслекне әйткәне: бүген чәршәмбе түгел, ә җомга булуын раслаганы өчен тагын да бер бөкре ала, ике бөкреле гарипкә әйләнә. Олы дөреслеккә тугрылык аның канына сеңгән, аның эчке хасиятен, кешелеген билгели. Үз табигатенә каршы килә алмау аркасында икенче егет пәриләр туе алдында курку хисен җиңә. Беренче егет кебек ташлама ясауга, күз йомуга барса,

килешү юлына басса, ул пәриләр белән уртак тел табар, тар бәхетенә ирешер иде. Ләкин аңардагы чын кешелек, намус хисе моңар юл куймый.

Бу әсәрләр белән драматургиябез тарихында бер яңалык туып килә. «Миләүшәнең туган көне» һәм «Дуслар җыелган җирдә» пьесаларының бер-берсен дәвам итүләре турында әйтелде инде. Вакыйгаларда бер үк геройлар катнаша. Шунысы аерата кызыклы, әдәби геройлары белән бергә драматург үзе дә олыгая бара. Ягъни, әгәр дә беренче әсәрдәге образлар системасы ярдәмендә әле яшь Туфан дөньяга шундый ук яшь буын күзлегеннән караса, инде икенче әсәр авторының бай тәҗрибәсе, гражданлык җитлеккәнлеге, белем тирәнлеге белән сугарылган. Драматург үз буыны кешеләренең гомернең төрле баскычындагы яшәү үзенчәлекләрен, фикерләү рәвешен чагылдыра, шулар аша җәмгыятьтә бара торган тарихи үсешне гәүдәләндерә. Алга таба драматург моның белән генә калмас, без инде яратып өлгергән,— эчке каршылыклары, ялгышу-хаталанулары, сөрлегүләре без кабул иткән,— геройларын тагын да бер кат сәхнәгә чыгарыр дип ышанабыз һәм шуны телибез. Тик бу юлы инде алар тагын да олыгайган булырлар, аларны бүтән һәм яңарак мәсьәләләр борчыр, тормышларында һәм характерларында да яңа төсмерләр барлыкка килер. Шунысын шикләнми әйтергә була: Нурислам һәм Миләүшә, Фәһим һәм Рәфисләр һаман да мөһим мәсьәләләрнең үзәгендә кайнарлар, олы идеалларга омтылган кешеләр булып гәүдәләнерләр, аларның эзләнүләре һәм кичерешләре тамашачы өчен кызыклы һәм гыйбрәтле булыр. Шулай итеп, бөтен бер буынның тормыш биографиясен, алай гына да түгел, шул буынны кызыксындырган сорауларны һәм әзерләкләгән кичерешләр байлыгын үзендә туплаган үзенчәлекле бер трилогия барлыкка килер. Проблематикасы ягыннан алып караганда, «Адәм баласына ял кирәк» драмасы белән автор андый әсәрнең бер эскизын бирде инде. Әмма әлегә ул бары тик эскиз гына булып кала...

3

Т. Миңнуллин хикәяче буларак нигездә юмористик планда яза. Ә драматургиядә исә ул бай художестволы чаралар арсеналы белән эш итәргә омтыла. Бу омтылышы һәм тынгысыз эзләнүләре аңар бер-бер артлы уңыш китерә. Бүгенге татар драматургиясенең идея һәм сәнгатьчә ачышларын билгеләүдә Т. Миңнуллин иҗаты җитди роль уйный.

«Нигез ташлары»нда, мәсәлән, вакыйгалар эзлекле ага. Гарифулла карт, авырыйм дигән булып, дүрт малаена телеграмма суктыра, тегеләре бер-бер артлы кайтып төшәләр. Бергә җыйналгач, төп мәсьәлә хәл ителә, — малайларындагы кайбер чатаклыкларны, килешмәгән гадәтләрне карт катгы тәнкыйть итә. «Ир-егетләр»дә Мәрван очраклы төстә фронтташ дусты белән очраша, исереклек юлына кереп киткән Әхтәмне авылына алып кайта, инде аңар үз тормышы турында, алга таба ничек яшәргә тиешлеге хакында уйланырга ирек бирә. Әхтәм характерындагы тискәрелекләр берьюлы гына юкка чыкмый. Әмма шартлар, Мәрваннең үз үрнәге, кызы Сайраның самими мөнәсәбәте һ. б. факторлар электәге сәләтле архитекторга иҗади тормышка кайтырга ярдәм итә. Бөтенесе дә табигый агышта ачыла, тормыш чынлыгы нык саклана.

Драматург икенче төр алымнардан да файдалана. «Дуслар җыелган җирдә» пьесасы, мәсәлән, чынлыкка һич тә хыянәт итмәстән, кайбер композицион шартлы алымнарга да актив мөрәҗәгать итеп язылган. Вакыйгалар агышы кинәт бер ноктада өзелә, аннан соң шул ук ноктадан икенче бер җирдә, вакыт ягыннан шул туктап калган мизгелдән башлап я Рәфисләр өендә, я Фәһимнәрдә, яисә Нурислам фатирында дәвам иттерелә.

Монысы — күбрәк сәхнә шартлылыгы гына әле. Вакыт һәм пространство өзгәләнсә дә, монда реальлек бозылмый, тормыш үз формаларында гәүдәләндерелә.

Ә инде тагын да бер төр әсәрләрендә Т. Миңнуллин әдәби художество алымы буларак шартлылыкка тагын да зуррак бурыч йөкли, аннан тагын да киңрәк файдалана. «Әлдермештән Әлмәндәр» комедиясендә һәм «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасында тормыш күбрәк үз формасында түгел, ә шартлы формада сурәтләнә.

Художестволы сурәтләү алымнары төрле-төрле булган, шул җәһәттән бер-берсеннән нык үк аерылып торган бу пьесаларны бер нәрсә үзара бик тә якынайта һәм аларны Т. Миңнуллин иҗатындагы өченче юнәлешкә кертеп карарга мөмкинлек бирә. Ул — әйдәп баручы замандаш образына төп игътибарны юнәлтү, аны иҗтимагый тормышта үз урынын тапкан, үз вазифаларын һәм бурычын яхшы аңлаган кеше итеп сурәтләү. «Ир-егетләр», «Үзебез сайлаган язмыш», «Йөрәк янар өчен бирелгән», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесаларының үзәгенә уңай герой образы куелган. Беренчелек,— хронологик яктан бигрәк, сәнгать бөрәмлеге буларак эрелеге ягыннан,— күрәсең, «Ир-егетләр» (1971 ел) драмасына, андагы Мәрван образына бирелергә тиеш. Колхозны алга үстерү өчен алып барган фидакарь хезмәте дә, кешеләргә чиксез ышанычы да (монысы, иң әүвәл, аның Әхтәмгә мөнәсәбәтендә чагыла) аны уңай яктан характерлый.

Моннан соң 1973 елда язылган «Үзебез сайлаган язмыш» драмасы белән Т. Миңнуллин бу өлкәдә алга таба бер адым ясады. Пьеса халык мәгарифе өлкәсендәге алдынгы тенденцияләрне гәүдәләндерүче көчләргә тирән хөрмәт белән сугарылган. Вакыйгалар үзәгенә омтылышлары һәм яшәү принциплары һәркемгә аңлаешлы булган, олы идеал хакына көрәшкә ташланган герой образы куелган. Ул — мәктәп директоры Илгиз Туктаров. Аерым



*1979 елның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары: Туфан Миңнуллин, (уңнан), җырчы Ринат Ибраһимов, Әлмәт татар дәүләт драма театры артисткасы Дамира Кузаева, театрның баш режиссеры Гали Хөсәенов.*

намуслы укытучылар ярдәмендә директор бу мәктәптә ныклы гына тамыр җибәреп өлгергән иске тәртипләргә каршы сугыш ача. Ләкин күнегелгән гадәтләр һәм искелек шактый көчле, аларны яклаучылар да көчсез түгел. Завуч Мөнирә кебекләргә шулай яшәве дә, эшләве дә җиңел, күнегелгән. Укытуның сыйфатын төшерү исәбенә өлгереш процентын югары итеп күрсәтеп, мәктәп моңарчы районда алдынгылар исәбендә йөргән. Яңа директор менә шуңар каршы чыга. Көрәш юлында Илгиз Туктаров алдына шактый санда киртәләр корыла. Аны баштарак хәтта Нариман кебек намуслы һәм тәҗрибәле карт укытучы да аңламый. Яшь директорны эшеннән алалар, ул моннан күчеп китәргә мәҗбүр була. Шулай да мораль җиңү аның ягында кала. Һәм ул үзенең уңай нәтиҗәләрен дә бирә башлый: Фасил кебек, һәрвакыт битараф булып яшәү ягын каерган кешеләр дә йокыларыннан уяна, активлык даирәсенә тартып кертелә, искелеккә каты удар ясала. Ә. Шәйхаттаров кебек бик тә үзенчәлекле, әмма кешеләр өчен яшәүче колхоз председателенең Туктаровны ачыктан-ачык яклау позициясенә басуы, аны кире кайтару өчен эш йөртә башлавы — шул көрәш процессының иҗтимагый эчтәлеген арттыра. «Үзебез сайлаган язмыш» авторның җитди уңышы булды, бу әсәре өчен Т. Миңнуллинга Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе бирелде.

Драматург сынмас рухлы һәм нык иманлы образлар иҗат итү юнәлешендәге эзләнүләрендә яңа уңышларга иреште. Шуларның берсе — «Ай булмаса, йолдыз бар» дип исемләнгән драматик хикәя. Әлмәт дәүләт театрында куелган бу әсәре өчен Т. Миңнуллинга, спектакльнең режиссеры Гали Хөсәеновка һәм баш рольдә уйнаган артистка Д. Кузаевага Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Драматургия тарихында авторның персонаж төсендә вакыйгаларга катнашып китүе инде кулланылган алым. Еш кына вакыйгаларны яисә аерым герой характерын комментарияли. Т. Миңнуллин бу пьесасында шушы алымны бүтәнчә куллана. Персонажлаштырылган автор үзе уйлап чыгарган герой белән тартыш алып бара. Автор пьесасын мелодрама рухында язарга омтыла. Ләкин гаҗәп хәл туа: әсәрнең үзәк персонажы Мәдинә Сафина автор теләгенә буйсынмый, еламый, күз яшен күрсәтми, авырлыклар алдында сыгылып төшми, сынмый. Автор аның алдына авыр сынауларны бер-бер артлы куеп кына тора. Көйсез сукыр әнисенә ярап тору дисеңме, яраткан һәм нык ышанган иренең хыянәтеме, бердәнбере булган кызының бәхетсезлеккә юлыгуымы, соңыннан үзенең дә сукыраюы дисеңме — берсе дә калмый. Ләкин Мәдинә бирешми. «Яраткан кешемнән, кызымнан, күзләремнән мәхрүм итеп кешене җиңеп була дип уйласагыз, ялгышасыз,— ди Мәдинә.— Зур-рак кайгыларга түзгән, кеше булып кал-

ган кешеләрне беләм мин... Минем юлымда сез миңа кайгы китергән кешеләрне, котелмәгән бәхетсезлекләр очраттыгыз. Әмма белегез, кеше кешеләр арасында яши. Берәүсе этеп екса, унысы тартып торгыза. Кешедәге көч ул үзе уйлаганнан күбрәк». Кешедәге көчнең чиксез булуын, ихтыяр көчен сындырып булмый торган кешеләрнең җир өстендәге урынын күреп сокланган автор бәхәсне оттыра, бу хатынның тимер ихтыяры алдында баш иярга мәҗбүр була. Шул рәвешчә, Мәдинә үз язмышына үзе хуҗа була алган совет кешесенең җыелма образы төсендә гәүдәләнә.

Әйе, автор һәм персонаж бәхәсе — оригиналь һәм отышлы форма, ул уңышлы хәл ителгән. Үзәк идеяне тулырак ачу максаты белән шартлылыктан болай оста файдалану әсәрнең художество дәрәҗәсен бермә-бер арттыра. Сәхнәбездә романтиклаштыруның, метафорадан киң файдалануның җитешмәвен, шартлылыкның да бик сирәк кунак булуын исәпкә алсак, бу пьесаның бүгенге драматургия һәм театрыбыз өчен булган әһәмияте тагын да күтәреләчәк. Шул яклары белән, һәм әлбәттә, үзәк уңай герое белән «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы Бөтенсоюз драматургиясе югарылыгында булып чыкты. Аның русчага тәрҗемә ителеп, үзәк органы булган «Театр» журналында басылып чыгуы (1979 ел, 6 сан) шул хакта сөйли.

Реаль образлар иҗат итүдә сәхнә үзенчәлекләреннән һәм художество алымнарыннан киң һәм белеп файдалануның әйбәт нәтиҗәләрен «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясендә дә күрергә мөмкин. 1977 елда сәхнәдә куелган бу әсәр соңгы еллар драматургиясендә күренекле бер вакыйгага төсен алды. 1980 елны шушы пьеса буенча куелган спектакль өчен әсәрнең авторы Т. Миңнуллинга, режиссеры М. Сәлимҗановка һәм төп рольдә уйнаган Ш. Биктимеровка РСФСРның Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Бу — татар театры яулап алган иң зур үрләрне чагылдыручы мисал.

Тарихи планда алып караганда да, бүгенгесе турында сүз алып барганда да татар драматургиясе комедиягә бай булуны билгеләп үтәргә туры килә. Милли сәхнәбезнең үзенчәлекләреннән берсе дә шунда. Шулай да, ничек кенә гаҗәп тоелмасын, сәхнәдә үзенең идея-эстетик кыйммәте белән тулы бер вакыйгага булырлык комик һәм сатирик характерлар әллә ни күп тә түгел. Ә инде комедиянең төп билгеләмәсе һәм асыл бурычы кимчелекләрне фаш итү һәм алардан көлү булганлыктан, эре планлы уңай характерны үзәккә куйган комедияләр тагын да азрак иде һәм бүгенге көндә дә бармак белән генә санарлык. Мәсәлән, Н. Исәнбәт иҗат иткән Хуҗа Насретдин образы шундыйлардан. Сәхнәдә вакыйгаларны әйдәп бара алган, халкыбызның рухи көчен һәм акыл үткенлеген үзендә туплаган заман герое образы тудыру кирәк иде. Ниһаять, Әлмәндәр карт чыкты.

Драматург иҗатында бу образга юл күптән салына башлаган иде. Халыкчанлык сыйфатларын без «Миләүшәнең туган көне»ндәге Харис образында ук күреп калдык. Бигрәк тә «Нигез ташлары» комедиясендәге Гарифулла карт образы бу юлдагы җитди табышлардан булды. Бу образның драматургиябез өчен яңалыгы — элек-электән пьесаларда сурәтләнеп килгән ил карты тибын төрләндерүдән гыйбарәт. Акыллы, сабыр холыклы һәм мәһабәт кыяфәтле традицион аксакал урынына автор монда тынгысыз һәм килешмәүчән рухлы, төртмәле телле, шуның белән үз тирәсендәгеләрне һәрвакыт бимазалап торган, шул рәвешле хаклык өчен көрәшкән картны бирде. «Үзебез сайлаган язмыш» пьесасындагы Нариман образында да халыкчанлыкның аерым сыйфатлары әйбәт чагылдырыла. Драматургның бу юлдагы уңышларын күреп алган әдәби тәнкыйть үз вакытында «инде Т. Миңнуллин алга таба халыкчан характерга хас булган тормышчан нигезләрне бүгенгенең каһарманнары образларында органик кушарга омтылырга тиеш» дигән бер киңәш биргән иде. Ягъни, аның әсәрләрендәге үзәк уңай геройларны халыкчан характер дәрәҗәсенә күтәрелгән, шундый ук эрелә штерелгән хәлгә җиткереп сурәтләнгән рәвештә күрәсе килә иде. Әлмәндәр шундый образлардан.

Бөтенсоюз күләмендә яңгыраган һәм танылган бу пьесаның иң уңышлы яклары нан берсе Әлмәндәр образы белән бәйләнгән. Ярым комик планда хәл ителгән үзәк драматик конфликт шулай ук асылда Әлмәндәр образы белән билгеләнә. Дөрес, сәхнәдә тартыш 91 яшьлек карт белән Әҗәл арасында бара һәм конфликтка кергән көчләр һәрберсе мөстәкыйль рәвештә күзаллана кебек. Ләкин, төптәнрәк уйлап карасаң, мифик образ Әҗәл — шул ук Әлмәндәр картның үз табигатенә бәйле, персонажлаштырылган бер көч ул. Билгеле бер яшькә җиткәч кешенең үлүе котылгысыз, бу процесс табигать законнары белән билгеләнә. Димәк, һәркемнең әҗәле үзенеке, нииндидер гомум әҗәл юк һәм була да алмый. Без шуны, тамашачы буларак, бик яхшы тоешенәбез. Шулай була торып та Әлмәндәрнең үз әҗәле белән көрәш-тартышын чынлык планында кабул итәбез, шул көрәштә кешелекне кызыксындыра торган сорауларга җаваплар табабыз.

Татар драматургиясендә үзәк идеяне тулырак ачу өчен аллегорик образларга мөрәҗәгать итү тарихи түрдән үк килә. Аның беренче оригиналь кулланылышын Гафур Коләхметов биргән иде. «Ике фикер» драмасындагы аллегорик Кызыл һәм Кара фикерләр көрәшен сурәтләү ярдәмендә ул татар әдәбиятында пролетар фикерләр үткәрде, идея эчтәлеге ягыннан да, художество формасы җәһәтеннән дә зур яңалык кертте. Кызыл фикер һәм Кара фикер үзара нинди генә каты бәхәсбәрелешне дә үзләренең беренчел нигезләре булган Даут янында уздыралар, аннан аерылып китмиләр, китә алмыйлар. Ягъни, шартлы-метафорик форма шуннан



*Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Канкай углы Бәхтияр» драмасын укып тикшерү вакыты*

да узып китәргә юл куймый, аның бурычы шундый.

«Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә исә Т. Миңнуллин бу алымның киңрәк мөмкинлекләрен тапкан. Әҗәл вакыт-вакыт үзенең беренчел нигезеннән аерылып-аерылып китә, мөстәкыйль эш йөртә, мөстәкыйль «яши» башлый. Ләкин автор һәрвакыт аның нәкъ менә реаль җирлеккә һәм кешегә бәйле булуын нечкә генә билгеләр, детальләр ярдәмендә сиздереп тора. Шуңа күрә без Әҗәлнең миссиясе бик тә реаль булган кебек үк, аның үзенең дә аллегорик образ булуын яхшы төшенеп кабул итәбез. Реаль һәм мифик образларның мөнәсәбәте гаять җентекләп һәм оста язылган булганга күрә дә, гәрчә мөмкинлекләре зур булса да, Әҗәл һич тә картның үз атрибутына әверелми. Ул үзенең үлемсезлегеннән һәм вазифасыннан туйганда, җир кешеләренең яшәвенә кызыккан вакытларында мөстәкыйль эчтәлек ала. Әмма бу урыннар гаять сизгер эшләнгән, картның үз үлеме белән көрәшенә яңа төсмер һәм мәгънә бизәкләре бирерлек итеп уйланылган. Шуңа күрә дә бу шартлылык җитди теманың тормышчан фәлсәфи нигезләрен тулырак һәм тамашачыга авыр тәэсир итмәслек төстә ачарга ярдәм итә.

Дини-мифик образлардан Газраил, Әҗәл, Фәрештәләрнең ярым комик фон тудырып, әсәрнең нигезендә яткан җитди теманы кабул итүне ансатлаштыруда рольләре зур. Яшәү һәм үлем проблемасының әсәрне җитди планга тартып кертү куркынычын автор көлкеле хәлләр һәм репликалар ярдәмендә юкка чыгара белә. Мисал өчен Газраилнең «окаянный» сүзен татарчалаштырып-бозып әйтүен, Фәрештәнең аны төзәтеп куюын яисә Әҗәлнең Әлмәндәр лексикондагы сүзләр белән сөйләшә башлавы кебек урыннарны алырга була. Ләкин төп хикмәт, әлбәттә, үзәк геройда — Әлмәндәрдә, аның тормышчан нигезләрендә, аның оригинальлегендә. Әлмәндәр — чын халыкчан характер. Ул оста телле, тапкыр акыллы. Картны корыга теленә салынучы дип әйтеп булмый. Күп хәлләрне башыннан кичергән булуы, ил һәм халык өчен иң җаваплы чорларда вакыйгаларның үзәгендә кайнаган булуы аны халык трибуны дәрәҗәсенә күтәрә. Аның иң матур сыйфатлары сәхнәдә эш белән аклана бара, ул үзе таяна торган гүзәл мораль-этика нормаларын, күркәм гадәт-йолаларны эш белән исбат итә килгән. Зур һәм кечкенә мәсьәләләрне ул ил һәм кешеләр күзеннән торып бәяли, шуннан чыгып фикер йөртә һәм эш итә. Шуңа күрә дә аның гайре табигыйлеге дә — инде яшен яшәгән, ашын ашаган картның яңадан өйләнергә йөрүе, җир өстеннән, яраткан кешеләреннән һәм сөйгән шөгыльләреннән аерылып китәргә һич кенә дә риза булмавы — кешелекнең гомум сыйфаты, яшәүгә булган тыелгысыз омтылышның, оптимизмның чагылышы дип кабул ителә.

Комедия төрле настроениеләргә байлыгы, мул бизәкле булуы, алынган проблемасының җитдилеге белән аерылып тора. Монда җиңел, уйнак юмор да, җитди көлү һәм сатирик үткенлек тә, лиризм һәм драматизм да үзара берләшкән бер мохит тәшкил итә. Моңсулык һәм якты оптимизмның органик кушылмасы әсәрнең иң көчле якларыннан берсе, теманы уңышлы һәм дөрес хәл итү өчен, тамашачының кәефен төшермичә генә аны мөһим сораулар белән җәлеп итүнең иң кирәкле сыйфатларыннан берсе. Пьесада төрле жанр үзенчәлекләренең, әдәби-драматик төрләрнең, сәхнә алымнарының үзара аралашып баруын, җитди комедия формасының бүтән художество чаралары белән баетылуын күрергә мөмкин. Шулар һәммәсе бергә Туфан Миңнуллинның бу әсәрен соңгы еллар драматургиясенең генә түгел, гомумән, татар совет драматургиясенең иң яхшы пьесалары рәтенә кертеп карарга мөмкинлек бирә.

Туфан Миңнуллин — табигате белән үк җор һәм тапкыр кеше, дидек. Шәхси сыйфатлары аның иҗатында да мул булып чагыла. Аерым җитди әсәрләрендә дә, көлкеле рухтагы әсәрләрендә дә драматургның тапкырлыкка, җорлык һәм юморга теләп һәм белеп мөрәҗәгать итүен күрдек. Т. Миңнуллин тулаем көлке ситуацияләргә һәм комик конфликтка корылган, юмористик һәм сатирик образларын үзәккә куйган комедия һәм водевильләрне дә шундый ук уңыш белән иҗат итә ала. Аның иҗатындагы өченче мөстәкыйль юнәлешне дә нәкъ менә юморга һәм сатирага корылган пьесалар билгели. Алар — водевиль рухындагы комедияләр: «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ак тәүбә, кара тәүбә», «Алай түгел, болай ул». Болары бүгенге кешеләрдә очрый торган кимчелекләрдән көлә, тормышыбызны ямьсезләгән хәлләрне һәм күренешләрне фаш итә. Сатирик һәм комик конфликт та төрле рухта. Әгәр дә «Диләфрүзгә дүрт кияү» хатын-кызга кимсетеп карау, хезмәттән йөз чөерү кебек кимчелекләрне сатирик үткенлек белән ачып салса, «Ак тәүбә, кара тәүбә» җитешсезлекләрне көлке ясап күрсәтеп бирә. Тулаем алганда исә, моңарчы булган иҗатыннан күренгәнчә, Т. Миңнуллин асылда йомшак юмор белән эш итәргә яратарак төшә. Сатирага караганда ул юморны өстенрәк күрә булса кирәк. Талант үзенчәлегеннән киләме бу? Әллә бу күренештә иҗтимагый сәбәпләр дә чагыламы? Тегесе дә, бусы да бар бугай.

Т. Миңнуллин үзенә кадәр булган драматурглардан бигрәк тә Кәрим Тинчуринга якын тора. Тормыш материалын иңләп алуда, кызыклы ситуацияләр таба белүдә, тапкырлык һәм шаянлыкта, кеше рухының нечкә тирбәлешләренә сизгер булуда... һәр ике автор характерлар үсешен ярымйомшак буяулар белән сурәтли, персонажны көтелмәгәнчә итеп борып куя белә, аның образ буларак табигый хәрәкәтен барлыкка китерә. К. Тинчурин кебек үк, Т. Миңнуллин да драматик хәрәкәтне салмак алып бара, кульминацион ноктага төрле яклап килә. Ләкин моңар карап пьесада сүлпәнлек юк, барлык компонентлар да төп интригага оста буйсындырылган булу сәбәпле, һәр деталь, һәр күренеш һәм реплика үзәк фикерне ачуга хезмәт итә. Нәтиҗәдә сәхнәдә тулы тормыш картинасы барлыкка килә. Ике драматургның язу стилендәге охшашлык, уртаклыкларның кайбер яклары нигездә шулардан гыйбарәт. Әлбәттә, аерымлык та бар. К. Тинчуринның төп иҗат ялкыны буржуаз тормышны тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән иде, шунлыктан аңарда сатира гаять көчле, үткен. Җәмгыять шартларының бүтән булуы һәм иҗат үзенчәлекләреннән дә килә торгандыр — Т. Миңнуллин, әйткәнебезчә, йомшак юмор белән күбрәк эш йөртә. Ул бүгенгенең уңай якларын раслауның үтемле формаларын эзли һәм аны, еш кына хәерхаһлык белән көлүдә таба. Ягъни, юмор белән сугарылган ситуация һәм образларда күрә. Аның соңгы әсәрләре өчен хас шартлы форма һәм алымнарны да шундый ук эзләнүләрнең билгеле бер нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Алар драматургка көн кадагына эленгән мәсьәләләрне хәл итәргә, замандаш образларын югары сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләргә киң мөмкинлек бирәләр.

Художество эшләнеше ягыннан торып караганда Т. Миңнуллин пьесаларына ае-



*«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән күренеш. Искәндәр — Ирек Баһманов (сулдан), Әлмәндәр — Шәукәт Биктимеров, Өммия — Нәҗибә Ихсанова.*

руча нәрсә характерлы?— диган сорауга мин: аларны тулаем якты һәм күтәренке-оптимистик рухлы иткән мул бизәклелек, сүз-сурәтләү чараларына байлык, төсләр күплеге,— дип җавап бирер идем. Драматург оста итеп бер рухи халәттән икенчесенә, бер настроениедән бүтән төрлесенә тиз күчә. Үзенчәлекле юмор аның пьесаларына кабатланмас төс биреп кенә калмый, аларның тормышчанлыгын арттыра. Көндәлек тормышта шулай бит: кичерешләргә алмашка күңел күтәренкелеге килә, кайгы һәм көлке еш аралаша, фаҗига янәшәсендә үк мәзәк хәл яши. Тормыш шуның белән мәгънәле һәм кызык та, шаблоннан ерак һәм катлаулы да. Т. Миңнуллин пьесаларының көчле ягында тормышчан төрлелек һәм мул бизәклелек билгеле. Драматургның җитди материалга нигезләнеп язылган «Канкай углы Бәхтияр» тарихи драмасына да килеп керә ул: юморга бай күренешләр булмаса, пьеса сәнгатьчәлек ягыннан шактый ук төссезләнер иде. Пугачев гаскәрләре, билгеле инде, гел сугыш турында гына уйлап, үзләрен кыерсытучы әби патшаны һәм аның боярларын каргап кына тормаганнар. Әнә алар, сугышлар тынып торган арада, тиктормас Мортазаны алла ясап, җәннәткә кертеш уйныйлар, шаярышалар. «Ир-егетләр» драмасындагы сатирик һәм комик образлар һәм күренешләр геройларның һәм вакыйгаларның чынлыгы, ә әсәрнең сәнгатьчә дәрәҗәсен арттыра. Шундый мисалларны «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Адәм баласына ял кирәк», «Ай булмаса, йолдыз бар» h. б. пьесалардан да күпләп табарга мөмкин.

Художестволы детальләрдән Т. Миңнуллин отышлы һәм мәгънәле файдалана. Мәсәлән, шул ук «Канкай углы Бәхтияр» драмасында Пугачев алдында горур Бәхтияр басып тора, түбәтәен салмаган. Ни өчен патша алдында баш киемеңне салмыйсың!— диган шелтәгә ул «татарның түбәтәе башы белән бергә генә салына» дип җавап бирә. Ә инде бераздан Бәхтияр үзе үк түбәтәен йолкып алып, крестьяннарның бөек җитәкчесе каршында түбәнчелек белән баш ора. Чөнки ул хәзер Пугачевның ни өчен һәм кемнәр хакына көрәшүен аңлый башлаган. Гомум эшкә бирелгәнлеген ул шундый гади һәм тирән мәгънәле ишарә-деталь ярдәмендә аңлатып бирә. Кешенең кешелеген һәм эчке халәтен, рухи байлыгын сыный торган, чагылдыра торган мондый детальләр Т. Миңнуллин пьесаларын уку һәм карау өчен җанлы, кызыклы, персонажларны тулы канлы сурәтләргә ярдәм итәләр.

Танылган прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев дусты һәм фикердәшенә багышланган «Әлмәндәргә ничә яшь?» диган мәкаләсендә аның «Бәхетле кияү» исемле комедиясен үзе өчен ачкан, аның югары художество дәрәҗәсенә ия булуын матур итеп раслаган иде. «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» исемле китабымда бу әсәр турында миңа да сокланып язарга туры килгән иде. Чын талант шулай кат-кат ачыла, күрәсең. Югары художество әсәрен һәр кеше, һәр укучы һәм тамашачы үзенчә ача, үзенчә бәяли. Т. Миңнуллин иҗатында әле әдәби тәнкыйть тарафыннан да, театрлар да ачып бетерә алмаган әсәрләр тагын да бар.

Минем шуңар игътибар иткәнем бар: Туфан чыгыш ясаганда «үзегез беләсездер инде» диган гыйбарәне бик яратып һәм еш куллана. Шунда ниндидер бер мәгънә салган кебек. Драматургның булачак тамашачылары белән, укучылары белән мөнәсәбәтендәге мәгънә... Әйе, язучы һәрвакытта да яңалык ачып кына тормый, әсәр дә гел укучыга билгесез әйберләрдән генә тора алмый. Шуның белән бергә, белүнең дә үз чикләре бар. Бер укучы өчен бик мәгълүм әйбер икенче берәү өчен яңалык булып яңгырарга мөмкин. Шуңа күрә дә сәнгать мәгълүм мәзәктәге кебек «белгәннәрегез белмәгәннәрегезгә сөйләсен» дип кенә дә котыла алмый. Аның үз законнары, үз мөмкинчелекләре, үз спецификасы һәм тәэсир итү чаралары... Шулар ярдәмендә ул һәрчак сәнгать ачышы ясый. һәм монда эш талантка бәйләнгән. Шуңа күрә дә Туфанның югарыдагы сүзләре һәрчак «җәмәгать, сез аны үзегез дә беләсез, тик моның бу ягы да бар бит әле» диган мәгънәдә яңгырый һәм аның чыгышында менә шул яклар яңача ачылып китә. Драматургия иҗатында да ул шулай.

Т. Миңнуллин әдәбият һәм сәнгатьнең менә шул мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен яхшы белеп иҗат итүе белән бүгенге сәхнә әдәбиятыбызны алга таба үстерә торган дистәләрчә талантлы драматурглар арасында мактаулы урын тота.

Илдар Низамов

# ТЕЛ БАЙЛЫГЫН — МАТБУГАТ БИТЕНӘ

Туган тел ул язар өчен дә, сөйләр өчен дә, барлык жанрларга да бер үк. тик аның байлыгы, грамматик чаралары төрле урында, төрле максатта төрлечә кулланыла, ягъни «әдәби тел стильләр дип аталган төрләргә бүленә: матур әдәбият стиле, фәнни стиль, фәнни-популяр стиль, иҗтимагый-публицистик стиль, канцелярия стиле (эш кәгазьләре стиле), хатлар стиле һ. б.[1]» һәр жанр үз стиле кысасында эш итә. Аерым алганда, мәкалә, очерк, фельетон, парча, памфлет һ. б. публицистик стильгә карый. Бу төр әсәрләрнең дөнья күрү, укучыга барып җитү урыны нигездә массакүләм пропаганда һәм агитация чаралары — көндәлек матбугат, радио, телевидение. Аларның һәркайсының үз жанрлары бар. Мәсәлән, газетада — баш мәкалә, хәбәр, репортаж, интервью, рецензия, зарисовка, отчет, хат һ. б. Мондый шартларда публицистика иҗатының тагын бер төре — журналистика белән бик тыгыз аралашып китә, әйтик, газетада аларның уртак жанрлары барлыкка килә. Бу хәл телдә дә чагылмыйча калмый: хәзерге көндә телдә журналистик-публицистик стильнең тәмам формалашуы моңа дәлил.

Газета теле шушы стильнең аерым бер тармагыннан (подстиленнән) гыйбарәт, һәм ул шушы тармакка гына хас мөстәкыйль үзенчәлекләргә ия. Моны тану бик мөһим. Югыйсә, бездә әле «газета теле» термины фәнни төшенчә булудан бигрәк, тискәре, комик бер мәгънәдә йөри. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә: «газетача — публицистик стильдә, коры, «хиссез», дип кенә укыйбыз (253 б.). Кызганычка каршы, газета теленә һәм тулаем публицистик стильгә кимсетеп карау халыктан, укучылардан түгел, бәлки галимнәрнең, язучыларның үзләреннән килә, алар барлык язма әдәбиятка, шул җөмләдән, газетага да, таләпне матур әдәбият стиле кануннарына гына таянып куялар.

Ә нидән гыйбарәт соң ул газета теле?

Бу сорауны ачыкларга керешкәнче, мөһим бер нәрсәгә тукталып китү кирәк. Газета теле ул сөйләмнең бер төре, ә сөйләм ул, иҗтимагый күренеш буларак, телгә турыдан-туры бәйле булмаган күп кенә экстралингвистик мәсьәләләргә бәйле рәвештә формалаша. Чыннан да, мәсәлән, газета башкара торган функцияләрне, аның бурычларын, аңа яза торган авторларның социаль һәм психологик үзенчәлекләрен, материалларның язылу максатын, жанрларын, әдәби яктан эшкәртелү шартларын белми-ачыкламый торып, газета телен тикшерергә мөмкинме? «...Сәнгатьле сөйләм стиле матур әдәбиятның үз төзелешенә хас махсус әдәби алымнар белән берлектә, шулар белән бәйләнештә өйрәнелсә генә дөрес ачып бирелә алган»[1] кебек, журналистик-публицистик әсәрләрнең телен фәнни анализлау өчен дә аларның эчке төзелеш законнарын ачыклау зарури. Бу яктан карaганда, газета ул — «коллектив әдәби әсәр, ул әдәбиятыбыз һәм әдәби телнең гаять катлаулы бер төре, үзенчәлекле бер жанры»[2]. Ә катлаулылык менә нидән гыйбарәт: В. И. Ленин билгеләгәнчә, газета ул бер үк вакытта һәм агитатор, һәм пропагандист, һәм оештыручы әсәр. Димәк, ул төрле функция үти. Ләкин В. И. Ленин беркайчан да бу функцияләрне аерым-аерым күз алдына китермәгән. Кушмак рәвештә иҗат ителсә дә, газета ул — бер бөтен әсәр. Аңа бер бөтен итеп карау К. Маркс һәм Ф. Энгельстан ук килә, алар газетаны эшчеләр хәрәкәтенең «турыдан-туры рупоры» дип караганнар. В. И. Ле-

[1] Закиев М. З. Татар теле үсеше. Казан, 1967, 19 б.

[1] Курбатов Х. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. Казан, 1971, 45 б.

[2] Рамазанов Ш. Татар теле буенча очерклар Казан, 1954, 197 бит

нинның «җеп», «басма», «трибуна» кебек чагыштыруларында да шул үзенчәлек ярылып ята. Аннары, безнең газеталар — бер партия комитеты органы, бер редколлегия тарафыннан, айлык, кварталлык планнар нигезендә оештырыла.

Менә шушы һәм башка моментлар газетаның тел үзенчәлекләрен дә барлыкка китерәләр. «Публицистика белән художестволы һәм фәнни әдәбият арасындагы тел аерымлыклары аларның лексикасында да, сурәтләү чараларының, сөйләм алымнарының специфик кулланылышларында да, җөмлә төзелешенең үзенчәлекләрендә дә чагыла [1]».

Бүген без лексик үзенчәлекләргә генә тукталалырбыз. Мондый үзенчәлекләрнең гамәлдә булуы матбугатлы телләрнең күпчелегендә танылган инде. «Телнең башка функциональ стильләре кебек публицистик стиль дә иң беренче чиратта үзенә генә хас махсус лексикасы һәм фразеологиясе булуы белән характерлана» [2],— ди рус теле галиме А. К. Панфелов. Газета телен махсус өйрәнгән В. Костомаров, Г. Солганик, М. Кожина хезмәтләрендә дә газета лексикасының мөстәкыйльлеге ышанырлык итеп раслана, аларда «газетизм», «газета фразеологизмы» терминнарының законлаша баруы характерлы. Татар телендә без мондый закончалыкны Ш. Рамазанов, В. Хаков, Ә. Ишморатов хезмәтләрендә күрәбез.

Инде конкрет лексиканы анализлый башласак, газета теленең битараф (нейтраль) лексикадан кала, ике төрле төп лексик берәмлекләр төркеменнән торуын аңларбыз. Беренчесе — барлык жанрларга, стильләргә дә хезмәт итә торган, озак еллар буена кулланып универсаллашкан, газета стиленең үз берәмлекләренә әверелгән сүзләр, тезмә сүзләр, фразеологизмнар — **газета телендә даими (стандарт) берәмлекләр** дип атала. Икенче төркем — газетага телнең төрле стиль, катламнарыннан килеп кергән берәмлекләр. Төрле сәнгати чаралар, фразеологизмнар, архаизм, неологизмнар, хәтта диалект, профессионализмнар да, әгәр алар үз жанрында, үз урынында даими берәмлекләр белән дөрес нисбәттә аралашсалар, конкретлыкны көчәйтәләр, үтемлелекне арттыралар, шул ук вакытта газета сөйләмен катып калудан саклыйлар. Алар **вакытлы (экспрессив) берәмлекләр** дип атала.

Башта газета теленең гомумән язма әдәби телгә каравын әйтеп китәргә кирәк. Чөнки юк-юк та әле, хәтта тел галимнәре дә, матбугат телен халыкның сөйләү теленә тәңгәл итәргә өндәп куялар. Газета теле традицион рәвештә язма тел стиленә карый. Димәк, анда бу стильләргә хас лексик берәмлекләр, аерым алганда, китаби сүзләрнең күп булуы законлы күренеш.

I **Газетаның даими (стандарт) лексик берәмлекләренә** кыскача анализ ясыйк. Гадәттә, бу төр лексиканы иҗтимагый-политик терминнар дип төркемләп, өйрәнү даирәсен тарайту күзәтелә. Нигездә бу төркем **конкретлыкны, документальлекне белдерүче номинатив (атау)** лексикадан тәшкил була. Мондый сүзләрнең, тезмәләрнең күплеге газетага йөкләнгән бурычлардан, аның функцияләреннән килеп чыга. Журналистика һәм публицистика кеше аңына иң туры, иң кыска юл белән тәэсир итә, алар бары тик реаль, документаль фактлар белән генә эш итә. Конкретлык, ачыклык, тәгәллек — күңелгә тәэсир итүнең туры юллары менә шулар. Телдән дә шушы максатка ярашлы чаралар сайлап алына. Аларны менә болай классификацияләргә мөмкин: 1) документальлекне белдерүче номинатив чаралар, 2) терминнар һәм терминга тартым берәмлекләр; 3) газетизмнар (сүзләр һәм фразеологизмнар).

Безнең исәпләүләргә караганда, конкретлыкны, документальлекне белдерүче номинатив лексика барлык берәмлекләрнең 18—20 процентын тәшкил итә. Бу — район газетасының һәр санында шушындый 600 ләп сүз дигәнне аңлата. Күбесе бер сүз генә түгел, бәлки уртача 3—4 берәмлектән торган озын-озын тезмәләр. Гадәттә аларны контекстта еш кабатларга кирәк була, ялгызлык исемнәре булганлыктан, синонимнар белән алмаштыру мөмкинлеге дә юк. Менә ни сәбәпле алар текстны артык озынайталар, күп сүзлеккә, монотонлылыкка китерәләр. Шулай да эзләнгәндә мондый кыенлыктан чыгу юллары бар: 1) текст башында тулысынча алынган атама (ул нәкъ шулай алынырга тиеш тә), контекстта сүз дәвамында кыскартылырга мөмкин. **Куйбышевның авыл урта профессиональ** училищесы яңа уку елына укучылар ала... **Куйбышев училищесында** булачак механизаторны тәрбияләп чыгару өчен бөтен шартлар тудырылган... **Училище** формасын киредән тапшырган чагында Володя Митрофановның күзләрендә мөлдерәгән яшь иде (Г. Ахунов) [1]. 2) Атама контекстуаль синонимнар, шулай ук алмашлыклар белән дә аралаштырыла. Мәсәлән: «Л. И. Брежневның **«Чирәм җир» китабын** без бөтен гаилә белән укып чыктык. **Бу әсәр** миндә күп истәлекләр уятты». **«18 комбайнның** барысы да яхшылап ремонтланды. **Алар** эшкә керешергә әзер» (газеталардан).

2) Даими лексик берәмлекләрнең икенче бер зур төркеме — иҗтимагый-политик һәм фәнни-техник терминнар. Аларның вакытлы матбугатта зур урын алуларының сәбәбе, әлеге дә баягы, гомумән язма телгә караулары һәм конкретлыкны белдерүче берәмлек булулары. Үзәк һәм өлкә газеталарына күбрәк партия тормышының төрле тармакларына, хуҗалык эшчәнлегенә, дәүләт һәм җәмәгать оешмалары эшчәнлегенә караган берәмлекләр хас. Аларны куллануда, газеталарның төрләре-

---

[1] Хаков В. Тел һәм стиль мәсьәләләре. Казан, 1961, 23 бит.

[2] Панфелов А. К. Лекции по стилистике русского языка. М., 1968. 47 бит.

[1] «Социалистик Татарстан», 1979, 10 сентябрь

нә карап, шактый аерымлыклар да булуы ихтимал. Мәсәлән, безнең район газеталары күбрәк авыл хуҗалыгы терминнары белән эш итә. Өлкә газеталарыбыз иҗтимагый фәннәргә караганнарыннан нигездә педагогика, мәгариф, авыл хуҗалыгы, нефть терминнарын куллана. Соңгы елларда спорт, космос, автомобиль тематикасының активлашуы күзәтелә.

Гомумән алганда да, татарча газеталар термин ясау, аларны пропагандалау, камилләштерү юлында ифрат зур теоретик һәм практик эш башкаралар. Яңа иҗтимагый-политик терминнарның барысы да диярлек, фән-техникага караганнарының бик күбесе башлап газетада формалаша, аннан әдәби телнең башка тармак-стильләренә кереп китә. Телгә соңгы дүрт-биш елда кергән терминнарның бер өлешен генә санап китү дә шуның дәлиледер: **хуҗалыкара берләшмә, культуралы болынлык, ясалма яңгыр, хезмәт коллективы, Дәүләт сыйфат билгесе, советча яшәү рәвеше, материаль һәм мораль кызыксындыру чаралары, актив тормыш позициясе, камазчы, баш конвейер, кою заводы: чүкелүчән һәм соры корыч, этилен үткәргеч, шин производствосы һ. б.**

Матбугатта термин ясау, аларны куллану шактый катлаулы, үзенчәлекле иҗади процесс. Бу — махсус яктыртуны сорый торган үзе бер мәкалә темасы. Бу юлы исә без кайбер практик күзәтүләребезне генә уртаклашып китәбез.

Терминнарның күпчелеге, гадәттә, телдә элек-электән яшәп килгән берәмлекләрдән барлыкка килә. «Теләсә кайсы сүз, телдә ничаклы күп кулланылуына карамастан, термин була ала, терминнар алар махсус аерым сүзләр түгел, ә аерым функциядә кулланылган сүзләр»[1]. Аларны бутамас өчен хәрәкәт итү «мәйдан»нарын белү, ачыклау җитә, термин үз «мәйданында» гына термин, бирелә аның синонимы булмый, ул үзе дә башка сүзләргә синоним була алмый. Кыскасы, сүз белән терминны аера белергә кирәк, бу — газетага язучы кешегә аеруча мөһим, чөнки газетада төрле стиль, жанр материаллары аралаша, алар үз «мәйданнары», димәк, үз терминнары белән килеп керәләр. Димәк, газетаның бер битендә бер төшенчәне үк белдергән берничә термин очравы бик ихтимал (**корабль-кораб, сыер савучы-савучы-сыемчы-савынчы, кибет-магазин, ленталы конвейер-тасмалы конвейер, сварка агрегаты-эретеп ябыштыру агрегаты, станок качалка-сиртмәле станок, хәзерлек чаралары-әзерлек чаралары, инженер-техник работник-инженер-техник хезмәткәр һ. б.**). Телдә төрле стильләр, тармаклар яшәгәндә, иҗтимагый күренеш буларак, тел үзе үзгәреп, камилләшеп торганга, анда синоним терминнарының да яшәве законлы күренеш. Аларның киләчәктә кайсы активрак кулланылыр, кайсы калыр, анысын телнең хуҗасы — халык хәл итә. Бу очракта «алай дип язма, болай дип яз», дип субъектив күрсәтмәләр бирүнең бернинди файдасы юк. Әмма мондый муллык телгә талымсызлык күрсәтергә нигез бирми, бер үк авторның (газетаның) бер үк контекстта бер төшенчәне төрле терминнар белән язуын җавапсызлык дип бәяләргә тиешбез. Инде урнашып җиткән терминнарны бер контекстта төрләндереп «экспериментлар» ясау да укучыда аптырау гына тудыра, әйтергә теләгән фикернең тиз һәм төгәл барып җитүенә комачаулый: ...Урамда малайлар **шар** суга. Арада берсе куәт белән кәшәкәсен селтәп җибәргән иде, түгәрәк **алка** әллә кая очып китте[1]. ...Ул үзенең осталыгын арттырырга тырышты, белмәгәннәрен өлкән **савымчылардан** сорашты. Фермада 15—20 ел буе **сыер савучы** булып эшләгән М. Бикмуллина, Р. Галиуллина аңа эшләү серләренә төшенергә булыштылар[2]; ...Фильмнарның яртысы Казан **пленкасына** төшерелә. Бездә эшләнгән **кинотасмалар** партия, дәүләт форумнарын тарихка кертеп калдырды[3]. Мондый чуарлаулар матбугатның тәэсир көчен киметә, әлбәттә.

3) Газетаның даими лексик берәмлекләренә газетизмнар һәм газета фразеологизмнары да керә, дидек. Гадәттә стильнең, жанрның йөзен сирәк очрый, сирәк кулланыла торган «үз» сүзләре билгели. Матбугатның да үз лексикасы — газетизмнары бар, тик аларның үзенчәлеге, киресенчә, еш кулланылуларында. Газета ул, китаптан аермалы буларак, яше, белеме, һөнәре белән бик төрле кешеләр бер үк дәрәҗәдә аңларлык, кайда гына укыса да аны сүзлек-белешмәләрдән башка, төртелмичә укый торган әдәбият. Өстәвенә, ул — оператив басма (тиз языла, тиз укыла), периодик басма (көн саен басыла, көн саен укыла), димәк, лексик берәмлекләрнең еш кабатланудан калыплашкан, стандартлашкан булуы бик табигый күренеш. Ләкин шунысы мөһим, газета контекстын, фразасын телнең кайсы гына бүтән стиль, катлам контекстына кертеп куйсаң да, ул үзен «мин газетаныкы» дип торачак, үз йөзен, үз төсен югалтмаячак. Бу — телдә газетизмнар яшәвен расый торган тагын бер дәлил.

Газетизмнар туган телнең төрле мөмкинлекләреннән файдаланып ясала. Бүген без шулардан ике юлны гына ачыклап китәбез. 1) Грамматик чаралар белән газетизмнар ясау. Гадәттә газетизм төсмере традицион китаби сүзләргә кушымчалар ялганудан (камил**лек**, оста**злык**, фидакарь**лек**, актив**лашу**, җиһаз**ландыру**, житештерү**чәнлекле** һ. б. ), ярдәмче фигыль яисә башка сүз төркемнәре белән килүдән (**абруй казану, игътибар бирелү, мөмкинлек тудыру, чыгыш ясау, чара күрү, вәгъдәгә тугрылык, даими кайгыртучанлык, мөстәкыйль рәвештә, практик ярдәм, срогыннан элек үтәү, инициатива күрсәтү** һ. б.) бирелә.

---

[1] Винокур Г. О. О некоторых явлениях словообразования в русскотехнической терминологии. — Труды Московского института истории, философии и литературы. 1939, 89 бит.

---

[1] «Яшь ленинчы», 1979, 15 сентябрь.
[2] «Җиңү байрагы», 1975, 14 январь.
[3] «Социалистик Татарстан», 1979, 2 март.

Өстәмә аффикслар сүзгә китабилык, рәсмилек төсмере бирәләр һәм, аннан да бигрәк, абстракт төшенчәләрне конкретлаштыралар. **Лык-лек** кушымчалары аеруча актив. Алар белән ясалган сүзләр башка стильләргә дә үтеп керә. Тик бу очракта мондый сүзләрнең «агрессивлыгын» да онытмаска иде. Матур әдәбият стилендә аеруча сак булу сорала. Безне озата килгән дельфиннар **тиранлекка** төшеп югалалар[1].

Конкретлык төсмерен көчәйтүдә зур урын тоткан **ыш-еш-ш, ыр-ер-р** аффикслары белән ясалган газетизмнарны урынлы-урынсыз куллану очраклары да ешайды: элек тракторчы **сөрә**, комбайнчы **ура** иде, хәзер **сөрдерә**, **урдыра**. Бу шаукымга хәтта язучыларның да бирешүе күңелне борчый: «Ул... борчак **урдыручылар** янына китте», дип яза Х. Хәйруллин[2].

**Ыш-еш-ш** аффексына ябышып яту да кайвакыт мәгънәви зыян китерә: ул Гражданнар сугышында булган. Октябрь казанышларын **саклашкан**. Бөек Ватан сугышында фашистларны дөмбәсләшкән (Б. Камалов)[3].

2) Полисемия юлы белән дә газетизмнар актив ясала. «Сүзлек составында электән яшәп килгән сүзләрне яңа яки төгәлрәк мәгънәләргә беркетү дә сүзлек составы үсешен күрсәтә. Бу да — өзлексез булып тора торган процесс. Мәсәлән, ярыш, түгәрәк, йомгак, агым, оешма, кулланма, искәрмә, белем күрсәткеч йолдыз, күренеш һ. б. шуның кебек сүзләргә, иҗтимагый тормыштагы яңа күренешләрне, яңа мөнәсәбәтләрне атау өчен яңа мәгънәләр салынды һәм шул яңа мәгънәләр белән бу сүзләр тагын да активлашып киттеләр»[4].

Бу процесста вакытлы мабугат аеруча зур роль уйный. Күчерелмә мәгънәле сүзләр яңа берәмлек булып телгә кереп урнашканчы газетада камилләшү, «шомару» чоры үтәләр, ягъни газетизм булып йөриләр. Башка стильләрдә формалашкан метафорик берәмлекләрдән аермалы буларак, алар еш кабатланулары, стандартлашулары белән характерлы. Битараф сүзләрнең иҗтимагый төсмердә күчмә мәгънә алулары аеруча еш күзәтелә.

Газетада күчмә мәгънәле сүзләрнең бик күп төсмерләре ачылып китә: «Бүгенге яшь буынны хәрби патриотик рухта тәрбияләү **юлында** синниләр эшләдең? Ә бит синең гомерең, син узган **юл** — гыйбрәтле юл» (М. Мәһдиев)[5]. Шушы ук газетада солдатның «авылның такыр **юлыннан** чыгып китеп, фронтның нинди генә **юлларын** үтүе» турында дә җөмлә бар. Бик күп сүзләр менә шушындый төрлетөрле иҗтимагый мәгънәләре белән матбугат битләреннән башка стильләргә, хәтта сөйләү теленә дә кереп китәләр. Ләкин сүзләрнең барлык төсмерләре дә сүзлекләрдә билгеләнеп бетми. Менә шуңа күрә дә без газета теле сүзлеге төзергә вакыт җиткән дип саныйбыз.

Л. И. Брежневның «Чирәм җир» китабында **чирәм җирче** терминының иҗтимагый төсмер алып, яңа мәгънәдә йөри башлавы бик ачык тасвирланган иде[1]. Безнең телдә **камазчы** термины белән нәкъ шундый хәл булды.

Полисемия күренешенең матбугат телендәге үзенчәлеге тагын шул: газетизмнар күбрәк икенчел полисемия юлы белән ясалалар. Гадәттә беренче тапкыр нейтраль сүзләрдән барлыкка килгән спорт, хәрби терминнар газета сөйләмендә икенче тапкыр метафора, метонимия, синекдоха һ. б. рәвешен алалар: **биеклек**, **көрәш**, **вахта**, **эстафета**, **бил бирмәү** һ. б.

Бер сүзле газетизмнар гомумән күп түгел. Газета теле өчен төп лексик берәмлекләр булып аерым сүзләр түгел, бәлки эрерәк лексик берәмлекләр — тезмә сүзләр һәм газета фразеологизмнары характерлы. Бу да законлы күренеш: тезмә сүзләр һәм ныгыган берәмлекләр стандартлашыр өчен иң кулай «материаллар» алар. Аннары күп кенә сүзләрнең күчмә төсмерләре бары тик сүзтезмә эчендә генә күренә ала. **Тәрбия үзәге, яшел масса, олы поход, матур күрсәткеч, культура учагы** һ. б. Тезмә эчендәге берәмлекләр үзләренең мәгънәләрен югалталар, тезмә мөстәкыйль берәмлек булып катып кала: **чыгыш ясау, сәүдә челтәре, тормышка ашыру, роль уйнау, теманы күтәрү** һ. б. Газетаны даими укыган һәм аңа даими язган кеше, мәсәлән, **тормышка ашыру** тезмәсендәге берәмлекләрне аерым-аерым итеп күз алдына китерә алмый. **Уңышлы тормышка ашыру** тезмәсендә **уңышлының тормышка** гына карамыйча, бөтен тезмәгә караганлыгын шик астына куймый. Шулай да мондый стандартларны, **уңышлы төстә тормышка ашыру** дип катлауландыруларга юл куела.

Безнең исәпләүләргә караганда газетаның даими (стандарт) лексик чаралары барлык лексиканың район газеталарында 80—85 процентын, өлкә газеталарында 60—65 процентын тәшкил итә. Ләкин бу хәл газета телен коры, җансыз итәргә сәбәп була алмый. Сүзлек составының калган өлеше, әйтеп киткәнебезчә, вакытлы (экспрессив) лексик чаралардан гыйбарәт. Бу — матбугат битләрендә туган телнең барлык эчке байлык, мөмкинлекләрен тулысынча файдаланып була дигәнне аңлата. Нинди юллар белән?

**II Газетаның вакытлы (экспрессив) лексик чаралары** ифрат күп төрле, чөнки туган телдә нинди стиль катламнары, жанр төсмерләре бар, алар барысы да теге яки бу дәрәҗәдә газетада урын алалар. Ләкин тәртипсез, хаос рәвешендә түгел. Газета бер бөтен әсәр, дидек, димәк, аның тел стиле дә бер бөтен булырга тиеш. Бу — чыннан да шулай: биредә төрле стиль аерымлыклары бергә аралышып, бер-бер-

[1] Юныс М. Теләп алынган давыл. Тат. кит. нәш-ты, 1977, 94 бит.
[2] «Социалистик Татарстан», 1978, 17 август.
[3] «Социалистик Татарстан», 1977, 16 март.
[4] Зәкиев М. Татар теле үсеше. Казан, 1967, 65 бит.
[5] «Социалистик Татарстан», 1979, 1 август.

[1] Брежнев Л. И. Чирәм җир. Казан, 1978, 40 бит.

сенә нык кына тәэсир итешәләр, икенче төрле әйтсәк, бәрәңге, ярма, ит, суган, төрле тәмләткечләрдән яңа бер ризык — аш барлыкка килгән кебек, телнең төрле катламнары синтезыннан яңа функциональ стиль тармагы — газета тармагы барлыкка килә. Моны теоретик яктан да аңлатып була: газетаның функциясенә (В. И. Ленин билгеләгәнчә, газета ул миллионнар трибунасы һәм шул ук вакытта оештыручы бер үзәк) ярашлы рәвештә, анда стильләр, бер яктан, синтезланып үзенчәлекләрен югалтуга, стандартлыкка бирелергә, икенче яктан, капма-каршылыкларның көрәш һәм бердәмлек законына буйсынган хәлдә, мөстәкыйльлекләрен сакларга омтылалар. Бу омтылышны һәр яклап хупларга да газетага язганда аннан файдаланырга гына кала.

Төрле стиль үзенчәлекләренең газетада ничек «үзләшүләрен», алардан урынлы файдалану юлларын җентекләп өйрәнәсе бар әле. Монда без бер генә стильнең — газетада урын билгән матур әдәбият стиленең кайбер категорияләрен, дөресрәге, телдәге сәнгатьчә сурәтләү чараларын гына күзаллап китәрбез.

Иң башта публицистикада образ мәсьәләсен ачыклап китүне кирәк саныйбыз. Еш кына язучылар да, матур әдәбият теориясе белән шөгыльләнүче тәнкыйтьчеләр дә башка стиль әсәрләреннән, шул җөмләдән публицистикадан да, образлы сурәтләүне таләп итәләр. Образ термины әдәбият теориясендә каралган мәгънәсендә (тормышның, геройның чын үзе, реаль эш-хәрәкәте түгел, бәлки гомумиләштерелгән чагылышы) күздә тотыла икән, бу таләп — мәгънәсезлек дигән сүз бит. Чөнки бу планда матур әдәбият һәм публицистика — капма-каршы диярлек әсәрләр. Публицистика кешенең, вакыйганың образы белән түгел, турыдан-туры үзе белән эш итә. Хәтта типиклаштырган очракта да (ә бу — публицистикага да хас сыйфат) образ барлыкка килми, ә реаль тормыш күренешләренең гомумиләштерелгән суммасы бирелә. Бу гомумиләштерү образ тудыру өчен түгел, бәлки конкрет вакыйганы, ситуацияне яисә характерны чынбарлыкка тагын да якынайту өчен хезмәт итә. Документальлекне, конкретлыкны акылга гына түгел, хискә дә тәэсир итәрлек итеп җиткерү өчен публицистика телнең бөтен мөмкинлекләреннән файдаланырга тырыша. Шул максатка җигәрлек чараларны һәр стильдән ала. Бу — публицистиканың, аерым алганда, газетаның төп үзенчәлекләреннән берсе, аңа гына хас алым. Образ төшенчәсен дә ул нәкъ шушы максатта куллана. Әйткәнебезчә, образның үзен түгел, ә аның матур әдәбиятта кулланыла торган төрле чараларын. Анда да матур әдәбияттагыча түгел, үзенчә куллана.

Әйтик, бер публицистик мәкаләдә сүз ике завод арасында килеп чыккан низаг турында бара: алар үзара поставкаларны үтәмиләр, шул сәбәпле планнарын өзәләр, экономик зыян күрәләр. Бу хәлне автор эшлекле, информацион тел—саннар, термин, фактлар белән тасвирлый. Әгәр берәр тел галиме текстны аерып алып анализласа, анда бер генә дә образлы сурәтләү чарасы таба алмас иде. Ләкин бу хәл газетада образлы чаралар инкарь ителә дип ашыгыч нәтиҗә ясарга нигез була алмый. Мәкаләнең исеме «Гали Вәлигә...» дип атала. Бу очракта образлы чара (әйтем) бөтен мәкаләгә (текстка) кагыла, анда тасвирланган ситуацияне тагын да төгәлрәк, конкретрак күз алдына китереп бастырырга хезмәт итә. Өстәвенә, халыкчан үткенлек, җорлык төсмер мәкаләнең тәэсир көчен арттыра.

Мондый типтагы сурәтләү чарасы мәкаләнең исеме рәвешендә (әйтем, мәкаль, табышмак, җыр, цитатадан өзек, канатлы сүз һ. б.), шулай ук текст эчендә (эпиграф, чагыштыру, цитата һ. б.) төрле-төрле урында бирелә ала. Р. Хисмәтуллинның «Зәңгәр мәтрүшкәләр» очеркында, мәсәлән, төп геройның кешеләргә кешелекле мөнәсәбәте яшәү көче бирә торган мәтрүшкәләр белән текстның буеннан буена чагыштырып килелә [1].

Текст эчендә дә геройның аерым сыйфатлары, эш, хәрәкәтләре, вакыйганың аерым өлеш, моментлары төрле сурәтләү чаралары белән конкретлаштырып күрсәтелергә мөмкин. Матбугатта контекстуаль чагыштырулар, метафорик троплар бернинди чикләүсез кулланыла ала. Ләкин аларны куллануның төп шарты истән чыгарылмаска тиеш: алар, иң беренче чиратта, конкретлыкны, төгәллекне белдерүче, көчәйтүче чара. Фикернең аңга тизрәк барып җитүенә кечкенә генә комачаулык тудырган очракта да андый бизәкләү чараларының булуыннан булмавы артыграк.

Ә бит бездә әле матур әдәбиятка охшатыр өчен генә, рәвешенә китереп кенә «төртеп» куйган бизәкләр аз очрамый: **өрлектәй** өч малай, **җиләк кебек** бер кыз үстерделәр (Х. Хәйруллин). Язучының мондый штамп чагыштыруларыннан да, шул ук очеркындагы... **кояш бастырык бүе күтәрелде, ...әвен хәтле К-700 тракторы** кебек архаик чагыштыруларның да текст үтемлеген арттырулары бик икеле. Публицистикада чагыштыру заманча яңгырарга, иҗтимагый әчтәлекле булырга тиеш. Г. Ахунов, мәсәлән, халыкка хезмәт итүнең бөеклеген хәзер өр-яңа калага әверелгән Чупай тау белән чагыштыра [2], икенче мәкаләсендә халкыбызның культура үсешен образлы тасвирлар өчен губернатор камергеры Стрижевский белән Габдулла Тукай карашларын капма-каршы куя [3].

Публицистик чагыштыруларда авторның шәхси позициясе ярылып ята: Кәеф-сафа корганда **чебен гөмбәседәй** кызарган ул битләр чырайсыз калганнар (М. Рафиков) [4]; **Зур заводка охшаган** терлекчелек комплексы... ди Р. Вәлиев [5]; Безнең бу якларда келсу туфрак, ачы туфрак... Хатын-кызлар, бездә **гөл утыртырлык та туфрак юк,** дип сөйләргә яраталар, ди С. Хәким [6]. Бизәкләү чарасы белән конкретлыкны ачыклау, тагын да төгәлрәк итеп күрсәтү-

[1] «Социалистик Татарстан», 1979 ел, 17 апрель.
[2] «Социалистик Татарстан», 1979 ел, 1 май.
[3] Шунда ук, 1977 ел, 18 август.
[4] Шунда ук, 1979 ел, 13 октябрь.
[5] «Социалистик Татарстан», 1979, 22 август.
[6] «Социалистик Татарстан», 1978, 18 сентябрь.

нең матур бер үрнәге инде бу. Сүз уңаеннан әйтик, публицистикада чагыштыруларның җыйнак, төгәл булулары, **кебек, шикелле, охшаган** бәйлекләреннән, иярчен-комментарийлардан азат булулары хәерле.

Шулай ук метафора, метонимия, синекдоха, эпитет һ. б. сурәтләү чараларын, күп төрле фразеологизмнар куллану өчен дә вакытлы матбугатның мөмкинлекләре күп. Хәтта матур әдәбиятныкыннан да күбрәк, чөнки матур әдәбият, күп кенә стильләргә үз капкасын ачса да, стильләрнең синтезлана алуы аның үзенчәлеге түгел, бу — газетага гына хас күренеш, газета теләсә кайсы стильнең тропларын һәм башка сурәтләү чараларын иркен файдалана һәм шул ук вакытта, мөстәкыйль стиль буларак, үз тропларын, үз тел бизәкләрен дә ясый. Газетада сөйләү теленнән, хәтта аның диалектизмнарыннан алып, эш кәгазьләренең рәсми стиле әйләнмәләренә кадәр архаизмнар һәм неологизмнар да, төрле профессионализмнар һәм жаргоннар да кулланыла ала.

Шулай булуга да карамастан, көндәлек матбугатның еш чыгуы, оператив эшләнүе, яктырткан темаларының, жанрларының һәм авторлар даирәсенең чикләнгән булуы тел чараларының да еш кабатлануына китерә. Без газета телендәге штамплар, калып, клишелар турында күп сөйлибез, шулар йөзендә гомумән газета телен тискәре сыйфатларда гына күрәбез, тик бер мөһим нәрсәне искә алмыйбыз: күпләр штамп дип без алда санап киткән даими (стандарт) берәмлекләрне ягъни конкретлыкны белдерүче номинатив исемнәрне, саннарны, терминнарны, газетизмнарны атый. Юк, алар штамп түгел. Штамп, калып ул — бик еш кабатланып, кайсы авторныкы, кайсы жанрныкы икәнлеге онытылган, хәтта мәгънә төсмере дә югалып, абстрактлашкан тел бизәкләре. Әйе шул, көндәлек сүз ул төссезләнми, ә менә бизәк сүз төссезләнә. Заманында яңа булып та, авторның иҗат табышы булып күпләрне сөендергән, хәзер килеп еш кабатлануы аркасында укучының нервысына тиеп, кире тәэсир ясау хәленә төшкән метафора, эпитет, фразеологизмнарны күп, бик күп санап китәргә була.

Телдә туган кечкенә генә яңа бизәк тә зур ачыш, казаныш ул, аны төссезләндерүне кем дигәндә җавапсызлык саналырга тиеш: **кара алтын, татлы тамыр, зәңгәр экран, корыч айгыр, икенче икмәк, яшел урам, түгәрәк өстәлләребезне,** ярый инде, үзебез тапкан, үзебез ясаган тасвирлар, кадерләрен белмичә, үзебез ук шомартып, бизәкләрен коеп бетердек ди. Әмма без бит гасырлар буе халык теле җәүһәре булып саналган энҗеләрнең дә башына җитә барабыз. Мисаллар язучылар мәкаләләреннән китерелә: **җиң сызганып эшләү** (С. Шакир, Ф. Хәсни, Г. Сабитов һ. б.); **тел-теш тидермәү, бармак белән генә** санарлык, кон кебек ачык, алтын куллы оста, **кулга күп тотынып эшләү, йөзгә кызыллык китермәү,** бармак аша карау, **көнне төнгә ялгау, җиренә җиткереп** башкару, телгә алып **сөйләрлек, кулдан килгәннең** барысын да **эшләү**[1] һ. б. кебек уннарча бизәкләребезне, әйдәгез, тел сандыгыбызга кире салып куйыйк та бик сирәк кенә, бик кирәк чагында гына алыйк.

Алар урынына телнең бетмәс-төкәнмәс хәзинә сандыгыннан матбугатта моңарчы кулланылмаганнарын табып алыйк, кирәк булганда башка телләргә дә мөрәҗәгать итик, үзебез дә ясыйк. Синонимнарның төрлелеге ягыннан газета теле болай да игътибарга лаек, әмма биредә бит аларны ишәйтү мөмкинлеге чиксез. Публицистика язучының разведкасы, дибез икән, бу мөһим операцияне ул тел файдасына да куллана ала. Эзләнү, экспериментлар үткәрү, табыш, ачышларыңны укучы алдына чыгарып, сынап карау өчен газетадан да киңрәк мәйданны тагын кайдан табарсың.

Газета хәтта үзенең термин рәвешендәге даими лексик берәмлекләрен дә синонимнар белән алыштырырга тырыша [КПСС члены — коммунист — Ленин партиясе члены; колхоз — күмәк хуҗалык — артель]. Бу юнәлештә язучының эзләнүләре — газеталарга яңа резерв. Әлбәттә, газета хезмәткәре һәр яңа синонимның, иң беренче чиратта, төшенчәне югалтмыйча, конкретлыкны кеше аңына бернинди югалтуларсыз җиткерә алуын күздә тотарга тиеш: **кершәндәй югары сыйфатлы он;** кыш булуга карамастан, мелиораторлар **җир җимертеп** эшлиләр; шомыртлар ак **пәрәнҗә ябына;** Баулының нефтьле катламнары **коргаксымаган** кебек «табышларның» файдадан бигрәк зыяннары гына бардыр.

Ә инде чын табышларга килгәндә, аларга материалларны эшкәрткәндә сөенә белергә, игътибарлы булырга кирәк, энҗе бөртекләре дә бик зәвык белән, уйлап эшләнгән кашта гына матур җемелди. Шундый табышларның кайберләрен генә әйтеп үтик: Роберт Әхмәтҗанов **браконьерларны мылтыклы җанкыярлар** ди[2]. Алар шаушусыз гына, **лаф ормыйча гына...** үз эшләрен эшләп йөриләр ди Г. Ахунов[3]. Аның территориясендә 1200 баланы **кочагына алган** ике урта мәктәп бар ди Д. Зөбаерова[4].

Мондый иҗат җимешләренә карап мин сокланам, ләззәтләнәм, әмма борчылам да: берүк аларны кабатламасак иде, штампка әверелдермәсәк иде. Соклансак сокланыйк, көнләшсәк көнләшик, дәрт, илһам алыйк, тик кабатламыйк, кеше кулмәген киеп тору, кеше бизәген тагып тору — бер дә матур гадәт түгел, үзебезгә дигәннәрен эзлик. Эзлик, табыйк, шулар белән газеталарыбызны бизик, укучыларыбызны сөендерик!

---

[1] Мисаллар язучыларның 1977—1979 елларда «Социалистик Татарстан»да басылган мәкаләләреннән алынды.
[2] «Социалистик Татарстан», 1977, 25 ноябрь.
[3] «Социалистик Татарстан», 1977 ел, 1 гыйнвар.
[4] «Азат хатын», 1977 ел, 8 сан.

# ТАБЫШЛАР һӘМ ЮГАЛТУЛАР

Миргазиян Юныйның «Энҗе эзләүчеләр» исемле яңа җыентыгында язучының егерме елга якын вакыт эчендә (1961—1979) язылган повестьлары, хикәяләре, новеллалары һәм юл язмалары тупланган. Китапны авторның «Сайланма»сы дип атарга була. Шуңа күрә бу басма язучының иҗат йөзе, аның художестволы үзенчәлеге турында уйланырга шактый уңайлы форсат тудыра.

М. Юнысның «Тозлы җил» һәм «Теләп алган давыл» повестьлары уңае белән тәнкыйтьтә әйтелгән фикерне кабатлап, шуны әйтәсе килә: язучы, беренче чиратта, әдәбиятыбызның географиясен баета, аның офыкларын киңәйтә.

Чыннан да, китапның беренче битләреннән үк экзотик табигатьле ерак илләргә барып чыгасың. Кызыл, Кариб һәм Тиррен диңгезләрен, Италиядәге Генуя һәм Неаполь, Англиядәге Плимут шәһәрләрен, Везувий, Авача, Этна, Стромболи вулканнарын, Ямән, Сүрия һәм башка илләрне үз күзең белән күргән кебек буласың.

Ерак сәяхәтләр романтикасының укучыларыбыз, бигрәк тә яшьләр өчен, ни дәрәҗәдә кирәкле булуы турында сүз куертып тормыйм. Шуны гына әйтим — кайчандыр бездә сәяхәтнамәләр шактый еш чыгып торган. Соңгы вакытта исә алар бөтенләй диярлек күренми башлады. Профессиональ диңгезче булып дистәдән артык еллар буе эшләгән, бөтен дөньяны аркылыга-буйга гизгән М. Юныс иҗаты, бу яктан, бүгенге татар әдәбиятында тиңдәшсез.

Әмма чит илләрдә йөрү, туган яклардан, халкыңнан, милли телеңнән аерылу эзсез калмый. Бигрәк тә җанлы тел стихиясеннән читтә яшәү үзен ачык сиздерә. М. Юныс әсәрләренең теле ничектер корырак, ясалмарак яңгырый. Аның җөмләләре еш кына кытыршы булып чыга, стиленә матур эчке аһәң, халыкның үзендә туган моң, милли рух җитенкерәми. Аның әсәрләрендә калькалар, ягъни русчадан турыдан-туры тәрҗемә ителгән җөмлә конструкцияләре әледән-әле очрап тора.

Бер генә мисал: «Тәлинкәләрдә **тыгыз шома тәнле** алсу помидорлар... Тезелешеп торган шәраб шешәләренә **тир тамчылары кунган»** («Бәйрәм» повесте, 92 б.). Помидор турында «тыгыз шома тәнле» дип әйтеп була микән? «Тән» дигәндә, гадәттә, ниндидер җан иясе күздә тотыла бит. Ә инде җылы бүлмәгә керткәч дымланып киткән шешәләр турында «тир тамчылары кунган» дип әйтү («запотевший» сүзенең калькасы) татар теле кануннарына бөтенләй сыймый.

М. Юнысның тагын бер үзенчәлекле сыйфаты — туктаусыз уйлану, һәрбер күренешнең асылына төшәргә омтылу. Автор җирдә яшәүнең максаты, матурлыкның нәрсә икәнлеге, кеше табигатенә хас булган кайбер сәер яклар турында үз фикерләрен белгертә, адым саен диярлек лирик һәм публицистик чигенешләр ясый.

Бу сыйфат язучы иҗатының һәм уңай, һәм йомшак якларын тудыра. Бер яктан, М. Юныс гади күзәтүләрдән фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтыла, шуның белән әдәбиятыбызның географиясен генә түгел, интеллектуаль дөньясын да баета, укучыны да уйланырга өйрәтә. Икенче яктан исә, аның фәлсәфәсе кайвакытта артык гади, билгеле әйберләр тирәсендә әйләнеп, «тешкә тия» башлый («Җәяүле философ»). Әдәбиятта бармак белән төртеп күрсәтү мәҗбүри түгел бит, укучы үзе образлар тәэсирендә нәтиҗә ясаса, отышлырак булачак.

Җыентыкка төрле характердагы әсәрләр тупланган. Монда фәкать экзотикага гына корылган, күтәренке романтика, хәтта кайвакыт төче сентиментальрухта язылган әсәрләр дә очрый («Энҗе эзләүчеләр», «Хәрәрә җиле искәндә», «Җәяүле философ» һ. б.). Әлбәттә, гадәттән тыш вакыйгаларга нигезләнгән андый әсәрләрнең дә үз укучысы бар. Әмма, минем карашымча, язучының иң көчле, иң отышлы яклары аларда түгел, реалистик планда язылган әсәрләрдә тулырак ачыла. Аларның иң уңышлысы — «Табу һәм югалту» повесте шикелле.

Журналист Габдрахман кечкенә кызы Кәримә белән туган авылына кунакка кайта. Хатыны Мәрьям башта алар белән кайтырга теләми. Ир белән хатын арасында шуның аркасында сүз чыга, ара бозыла. Ләкин берничә көн үткәч, үз хатасын аңлаган Мәрьям ире белән кызы артыннан авылга кайтып төшә. Әсәр гаиләдә татулык һәм иминлек урнашуы белән тәмамлана: «Фәриха карчыкның самавары иминлек һәм гаилә татулыгы җырын көйләп утыра иде. «Менә шушыдыр инде ул

[1] М. Юныс. Энҗе эзләүчеләр. Татарстан китап нәшрияты, 1979.

чын бәхет»,— дип уйлады Габдрахман. Чыннан да, шатлык нәкъ шушы иде».

Әсәрнең төп герое Габдрахман безгә М. Юнысның «Тозлы җил» һәм «Теләп алган давыл» повестьлары буенча таныш. Аның Мәскәү университетында укып, соңыннан диңгезче булып китүен, корабльдә шактый авыр эшләр башкаруын, четерекле ситуацияләрдә калуын без инде алдагы әсәрләр буенча беләбез. Яңа повестьта Габдрахман олыгая, рухи яктан да җитлегә төшкән. Тормыш тәҗрибәсе аны дөньяны тирәнрәк аңларга өйрәткән. Ләкин характеры әллә ни үзгәреш кичермәгән. Алдыбызда шул ук тынгысыз җанлы, саф вөҗданлы, тормышның, яшәүнең мәгънәсен эзләүче Габдрахман. Соңгы елларда ул шактый дәрәҗәле урыннарда эшли — Диңгез флоты министрлыгында бүлек мөдире була, соңыннан Мәскәүдә чыга торган журналларның берсенә әдәби хезмәткәр булып күчә.

Уйлап карасаң, нинди зур үсеш! Карачарның ярлы Бәкер малае — элекке заман булса — бу турыда хыялланырга да кыймас иде. Совет власте тудырган яңа шартлар һәркемгә дә үз максатына ирешер өчен зур мөмкинлекләр бирә. Габдрахман моны яхшы аңлый. Ләкин шәһәрләшү (урбанизация) процессының кире яклары, югалтулары да юк түгел. «Иртән уяну белән, кабаланып йөгереп йөри башлыйсың, авып йокыга киткәнче туктый алмый йөгерәсең. Темпны әкренәйтеп тә, туктап та булмый, чөнки яшәү ритмы шундый. «Стресс»,— дип зарлана Габдрахман хатынына. Мәрьям дә эш урынына башта унбиш минут тынчу автобуста, аннан соң илле минут метрода һәм тагын ун минут кеше тулы троллейбуста бара. Юлда җаныңны чыгарырлык итеп кысалар. Эшкә барып җиткәнче тәмам хәлдән таеп бетә. Аерма тик шунда — Мәрьям бу тормышка инде күптән күнеккән, шулай тиеш дип карый. Габдрахман исә әледән-әле туган авылын искә төшерә: «Авылда һәркем үз көенчә йөри. Җитез кеше — җәһәт, пошмас кебе — атлар-атламас. Ожмах тормышы авылда, җәннәт». «Анда шундый рәхәт булгач, нигә башкалада интегеп яшисең?— дип каршы чыга хатыны.— Авыл тормышы миңа шулай ошаса, мин бер минут шәһәрдә тормас идем».

Бөтен бәла дә шунда шул. Шәһәрдә торып, өзлексез авылны сагынып, авылны мактап көлтә-көлтә шигырьләр язган шагыйрьләр шикелле, Габдрахман да, күпме генә зарланмасын, һаман да шәһәрдә яши бирә. Туган авылын күпме генә сагынса да, Габдрахман шәһәр тормышының җиңеллегенә күнеккән. «Эчкечә аракыга шулай күнегә. Уйнашчы хатын үзенең хыянәтенә». Шактый кызыклы күзәтү бит! Авторның бу сүзләрендә героена карата берникадәр ирония, мыскыллы көлемсерәү дә сизелә.

Әйе, Габдрахман ике арадарак калган кеше. Чын мәгънәсендәге шәһәр кешесенә әверелсә дә, ул һаман туган якларына омтылып яши. «Ниндидер көч кайтармый шәһәрдә тота, икенче бер көч авылга суыра. Икесе дә аяусыз, бер-берсе белән килешә алмый торган көчләр». Габдрахман характерындагы каршылыклар нәкъ шуның белән аңлатыла да.

Зәвыклары, дөньяга карашлары һәм башка бик күп сыйфатлары ягыннан ир белән хатын бер-берсенә күпме генә якын булмасыннар, алар арасында ниндидер, автор сүзләре белән әйткәндә, психологик киртәләр дә бар. Шәһәрдә туып үскән Мәрьям өчен (Мәскәүгә аның әтиәниләре күчеп килгән булганнар) Габдрахманның авылдашлары чит һәм ят тоелалар. Аларның телләре дә русча сөйләшеп үскән Мәрьям өчен әллә ничек ят, «инглизчә шикелле». Авыл кешесенең бер сәбәпсез үз-үзен кимсетергә тырышуында («Бед ни, бед авыл кешесе. Бед инде кая, башкала кешесе белән ярыша алмыйбыд») ул ниндидер астыртын мәкер күрә. Авылга кайткач туган-тумача, күрше-күләннең яшь киленне сынап, аның һәр хәрәкәтен, һәр сулышын тикшереп торуын җене сөйми. Авыл кешесенең яхшылыгын, сабыр холыклы, табигый булуын таныса да, шәһәр кешесенең дикъкатьсезлеген, туганнарына сүлпән каравын артыграк күрә. Авылга кайту аның өчен үзенә күрә бер газапка әйләнә. Монда ул үзенә урын таба алмый, иркенләп ял итә алмый, тәмам аптырагач үкереп елый башлый. Ә ире аны аңламый, гади психоз дип уйлый, хатынының авылга кайтырга теләмәвенә чын күңелдән рәнҗи. Минә кайда ул — ир белән хатын арасындагы каршылыкның төп сәбәбе!

Безнең әдәбиятта Мәрьям кебек шәһәрчә яшәп, шәһәрчә уйлап, авыл кешеләрен өнәп бетермәгән кире тип персонажлар очрый. Бу повестьтагы Мәрьям исә, асылда яхшы кеше — эшчән, искиткеч тырыш, саф вөҗданлы. Мәктәпне дә, институтны да ул гел бишлегә генә бетерә. Фәнни-тикшеренү институтында бергә эшләгән иптәшләре дә аны чын-чынлап яраталар, ихтирам итәләр. Ире белән дә алар яратышып, бер-берен аңлап яшиләр. Әмма «психологик киртәләр» кала бирә, аларны җиңел генә алып ташлап та, сикереп үтеп тә булмый! Туган халкыннан, аның тел, культура, әхлак чыганакларыннан ераклашу нәтиҗәсендә туган бу киртәләрне аеруча ачык итеп кичкенә Кәримә образында күрергә була.

Кәримәнең авылга беренче килүе. Габдрахман өчен изге булып тоелган нәрсәләр аның өчен чит һәм ят. Ул аларның мәгънәсен аңламый, күңеле белән кабул итә алмый. Әтисе тәмле сулы салкын чишмә турында сөйләгәч, «Әллә тау астына водопровод күмгәннәрме?»— дип сорый. Чишмә суының салкынлыгын да шунда яшерелгән холодильниктан дип уйлый. Чишмә монда символик мәгънәгә ия. Габдрахман өчен ул күңелгә азык бирә торган саф чыганак. Кәримә өчен исә — микроблы, кайнамаган су гына. «Җирдән чыккан су чиста буламыни!»

Беренче карашка, Кәримәгә бәхетле булып үсәр өчен барлык шартлар тудырылган. Ата-анасы аның өчен үлеп торалар.

Ул башкаланың балалар бакчасына йөри, аны фәннең иң соңгы казанышларына таянып тәрбиялиләр. Ә шулай да, әсәрдә күренгәнчә, Кәримәнең күңеле нәрсәдәндер китек. Анарда сабыйларга хас ваемсызлык юк. Уен-көлкене белми, күңеле һәрвакытта диярлек төшенке. Бар белгәне — әтисе белән әнисе арасындагы мөнәсәбәтләрне тикшерү. Әз генә киеренкелек туса да ул ихлас күңелдән борчылып, ут йотып йөри. «Бала мондый булмаска тиеш,— дип уйлый аның турында әтисе.— Ваемсыз, шат күңелле булырга тиеш. Уенкөлке белән, сайрар кош шикелле яшәргә тиеш бала. Бала чакта без шулай идек. Кәримә кебек чакта без табигать кочагында, әкияттәге кебек яшәдек».

Ләкин эш табигать кочагыннан аерылуда гына түгел, әлбәттә. Кечкенәдән үк туган халкыннан, милли культура байлыкларыннан аерылып үскән, татарча бер авыз сүз белми торган Кәримә (әти-әнисе дә үзара русча гына сөйләшәләр) авылдашларыч гына түгел, туган әбисен дә аңламый, аның белән сөйләшә дә, аңлаша да алмый. Бу да шактый җитди югалту түгелме? Күрәбез ки, автор бүгенге тормышка фән-техника революциясе алып килгән үзгәрешләр турында уйлана, аларның һәм уңай, һәм кире яклары билгеләп үтә. Бу яктан аның әсәре Ә. Еникинең «Туган туфрак», «Әйтелмәгән васыять» кебек хикәяләре белән аваздаш.

1979 ел башында үткәрелгән халык санын теркәү материалларына караганда, соңгы ун ел эчендә генә ил буенча авыллардан шәһәрләргә 15,6 миллион кеше күчеп килгән. Әгәр 1940 елны авылларда илебез халкының өчтән ике өлеше (67 проценты) яшәсә, хәзер исә өчтән бере генә калган (СССР буенча — 38 процент, РСФСР буенча — 31 процент). Бу объектив күренешне демографлар да, социологлар да, экономистлар да төрле яклап өйрәнә. Әдәбиятыбыз да ФТР үзе белән алып килгән бу үзгәрешләрне читләтеп узмый, аның кеше җанына, кеше психологиясенә ясаган йогынтыларын тикшерә.

М. Юныс бу процессның ике ягына аеруча басым ясый.

Беренчесе — бүгенге кеше һәм борынгыдан килә торган әхлак нормалары. Шәһәргә күчеп килүчеләрнең элеккеге элементләре өзелә, яңалары исә алай тиз барлыкка килеп өлгерми. Шул җирлектә кеше белән исәпләшмәү, мин-минлек, шәхси байлык артыннан куу һәм башка шуның ише яман чирләр тарала. М. Юныс бу чирләрнең ни кадәр куркыныч булуларын Инна Ивановна Ярославцева һәм Борис Израилевич Теодориннар мисалында күрсәтә. «Инна Ивановнаның һәр әйбере иң югары сыйфатлы: чиксез кыйммәтле күлмәге, итеге, каләме, төймәсе, ире, квартиры, эте, фәнни эш бүлешкәндә эләккән темасы — һәр нәрсәсе. Хәтта ул туалетка да чит илдә эшләнгән кәгазь белән йөри». Теодорин исә тагы да куркынычрак. «Рациональ акыл белән эш итүне» үзенә кагыйдә итеп алып, ул үз рәхәте өчен бернәрсә белән дә хисаплашмый, әхлак нормаларына көлеп кенә карый, кеше җанын пычратуны да чүп дип тә белми. Әгәр Мәрьям әлегедәй пычрак җаннарга каршы тора ала икән, монда инде аңа тәрбия бирүче, халыкның үзеннән чыккан, авылда туып үскән мәрхүмә әнисе «гаепле».

**Икенчесе** — кеше һәм табигать. Бу мәсьәлә дә соңгы елларда әдәбият битләреннән төшкәне юк (Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романын искә төшерү дә җитә). Табигатьтән ераклашкан саен кеше җаны табигатькә ныграк тартыла, чөнки «асфальт һәм таш дөньясы» кеше күңелен котылгысыз рәвештә ярлыландыра. Тормышыбыз елдан-ел алга бара, күз алдыбызда гына нинди зур үзгәрешләр булып тора. Бер Караяр авылында гына, автор күрсәтүенчә, авыл тулы техника — машина, трактор, мотоцикл, комбайн һәм тагы әллә ниндиләре. Чыбык читәннәр, кыйшаеп беткән киртәләрне бик тырышып эзләсәң дә таба алмассың. Авыл урамында алты, сигез, ун, уникеле почмаклы мәһабәт йортлар күтәрелгән. Салам түбәле йорт бөтен авылда берничә генә калган, анысы да ялгыз карчыкларда гына.

Ләкин шул ук вакытта югалтулар да бар. Кайчандыр каз үләне үскән авыл урамнарында — кантарланып беткән кара балчык. Урманнар бетә язган, инеш саеккан, чишмәләрнең күбесе кипкән. Урамда каз бәбкәләре күренми, кошлар сайравы да ишетелми. Йокыдан да кечкенә Кәримәне әтисе вәгъдә иткән әтәч түгел — трактор гөрселдәве уята.

Табышлар һәм югалтулар... Беренчеләрен тагын да үстереп, киңәйтеп, икенчеләрен бетерергә, һич югы, мөмкин кадәр киметергә иде — менә нәрсә турында уйландыра М. Юнысның яңа әсәре. Чишмә янында очраган таныш булмаган агай Габдрахманга болай ди: «Кайбер бәндәләр халыкны акчага, малга баетып кына бәхетле итмәкче,— юк, булмый. Яшәгән җирендә чылтырап чишмә агып, шаулап үскән урманнарында кәккүкләр кычкырып, сандугачлар сайрап тормаса, адәм баласының хисләре ярлылана. Чыганакларны сакларга кирәк, табигатьнекен дә, халыкныкын да».

Минемчә, «Табу һәм югалту» повестеның төп идея юнәлеше нәкъ шул сүзләрдә ачыла да.

Рафаэль **МОСТАФИН.**

# ШАГЫЙРӘНЕҢ ЯҢА АЧЫШЛАРЫ

Әсәр язарга тотынганда, кайсы шагыйрь нәрсәдән этәргеч алып китәдер, әзеп әйтүе авыр. Кемгәдер отышлы яңгыраган бер рифма гына да җитәргә мөмкин, икенче берәүнең күңелен яңа табылган образ канатландырадыр. Сәҗидә Сөләймановага исә болар гына аз, шигырь иҗат итү өчен аңарга ачыш кирәк.

Дөньяны танып-белүдә кеше берөзлексез яңадан-яңа ачышлар ясап тора. Аларның гасырлар агышына үзгәреш кертердәйләре бар, бәләкәйләре бар, шигъри җаннарга илһам бирә торганнары... Сәҗидә Сөләйманованың «Аланнарда балан»[1] исемле яңа китабында андый ачышлар күпме соң?..

Шагыйрә китапка исем булырдай шигырен,

**Аланнарда балан ак чәчәктә,—**
**яшь гомернең баллы тәлгәше.**
**Болыннарга, күңелләргә патша**
**чәчкә тажы кигән җәй башы...**

— дип алып китә дә болай тәмамлап куя:

**...Аланнарда балан тамчы-тамчы.**
**Ак чалмалы салкын кыш башы.**
**Янып тора балан, тамып тора**
**кышлау кошлар язга чыкканчы.**

Нибары дүрт строфалы шул шигырьгә С. Сөләйманова тулы гомер, яшәү мәгънәсенең асылын сыйдыра алган. Дөрес, әсәрдә ул хакта сөйләгән төшенчәләр юк, автор ишарә дә ясамый. Әмма шигырьне аңлап укыган кешенең күз алдыннан, һичшиксез, тулы гомер узар, аны җирдә яшәүнең нәтиҗәлелеге турындагы тирән фикер кызыксындыра башлар, уйга салыр.

Китапка кертелгән күпчелек шигырьләргә фәлсәфи уйланулар нәтиҗәсендә табылган яңалыклар, яңа ачылган күренеш яки хакыйкатьне тасвирлау хас. Кайбер шигырь җыентыкларында мондый табышлар бизәк сыман гына ялтырап-ялтырап китә, ул әсәрләрнең авторлары шәп яңгыраган рифма, сүз уйнату һәм купшы сурәтләүләр белән чамадан тыш мавыга кебек. Әлбәттә, андый шигырьләрнең дә үз укучысы булырга мөмкин һәм әдәбиятта алар тулы хокук белән яши бирә. Сәҗидә Сөләйманова әсәрләре исә фикер тыгызлыгы, укучы уен күңел тирәнлекләренә алып керергә сәләтле булулары белән характерлы. Вакыт-вакыт шагыйрәнең сүз сөреше, фикер йөртүе шактый катлаулана, юлларга күз йөгертеп алудан гына берни дә аңламыйсың, кабат укыйсың. Менә җөмләдән бер шигырь.

**...Үткәннәр бездән корбан сорамый,**
**хәрабәме, коралмы —**
**яд итеп, кеше баш ия.**
**Киләчәк алдында без —**
**аягүрә.**
**Ул бездән сабак ала, бәя бирә.**

Укучы моңа охшаш юлларны, шик тә юк, кат-кат укый һәм, сүз саен тукталып, тирәндәге мәгънәсенә төшенгәч, тагын бер мәртәбә кабатлап куя.

«Аланнарда балан» китабында төрле чорда, төрле шагыйрьләр кагылып узган темага багышланган шигырьләр дә юк түгел. «Әй, Айбикә», «Яр буенда», «Боз акканда, атлар чапканда», «Идел — Кама» һ. б.лар кебек ай, диңгез, яз, Идел, Җир яки аерылышу, яратышу, ата-аналар белән балалар арасындагы мөнәсәбәт турында язылган шигырьләр байтак. Тик аларның һәркайсында шагыйрә үзе булып кала, берсендә дә моңарчы әйтелгән фикер, язу формасы, сурәтләү алымнары кабатланмый. Шигърият өчен мәңгелек дип саналган темаларга кагылганда да С. Сөләйманова кайберәүләр кебек диңгезнең «зәңгәрлеге»нә, айның «яктылыгына», Иделнең «киңлеге»нә мәдхия җырлау белән чикләнми, укучыга үзе генә белгән, тойган, сиземләгән һәм ачкан яңалыкны тәкъдим итә.

**Комнан ташлар әвәли дә диңгез,**
**ташларны ком итә теләсә.**
**Ыргылалар ташлар йомарланып,**
**тәгәрәтә дөнья — куласа,**

— ди ул «Яр буенда» дип исемләнгән шигырендә. Һәм җыйнак кына шул шигъри юлларда автор дөньяда өзлексез дәвам итүче көрәшне сурәтләүгә ирешә.

**...Диңгез тиңсез —**
**комнан таш әвәли,**
**ташларны ком итә теләсә.**
**Ярлар текә — тәкәбберлек түгел,**
**җан хөрлеге өчен көрәшә.**

Китапны тоташтан күз алдына китерергә тырышсаң, аңа хас төп сыйфатны, автор алга куйган үзәк максатны тоярга

[1] Аланнарда балан. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1979 ел.

мөмкин: күпчелек шигырьләрдә, тасвирланган котылгысыз кискен көрәш, җимерелүләр һәм җиңүләр позициясеннән торып, шагыйрә шәфкатькә, тугрылыкка, матурлыкка әнди. Гади кешегә әллә ни әһәмияте сизелмәгән күренешләрдән ул яктылык эзләп таба, булып узганнарны яхшыга юрый, укучысына шуны расларга тырыша. «Нидер яна» шигырендә:

...Безне яклар өчен чыршыларның
Сөңгеләре күккә сузылган,

— ди ул. Яки

...Кешеләрнең елмаюын күреп,
яшәрәләр икән докторлар,

— дип, үзенең «Хирург» шигырендә врачлар хезмәтенең әхлакый мәгънәсен ачып бирә.

«Кар ява» шигыре С. Сөләймpraнованың дөньяны матур, кешеләрне шәфкатьле итеп күрергә теләвен аеруча тулы дәлилли.

...Бераүләргә — салкын кар бөртеге,
бераүләргә — йолдыз, энҗеләр!
Карны кар дип белгән син акыллы,
ак чәчәкләр күрәм мин җүләр.
...Уең нинди, шундый төскә буя —
Өр-яңадан дөнья агара!
Җир карасын, кыр ярасын каплап,
өметләрне аклап, кар ява.

Хәер, мондый рухта язылган шигырьләрне мисалга китереп бетерү мөмкин түгел, чөнки китапны китап иткән ул шигырьләр санаулы гына түгел. Арадан «Мин Зөһрәсе җырның», «Икмәк», «Сер алдым», «Канатланып, давылланып килде», «Сабыр канатларым», «Сау бул, язым!», «Тау тарта мине» кебек шигырьләрне һәм «Мәңгелек ут» бүлегенә кертелгән поэмаларны, аерып алып, хупларга мөмкин булыр иде. Әмма бу аеру башка шигырьләрнең кыйммәтен төшермәскә тиеш, чөнки җыентык укучы тарафыннан тоташ кабул ителә һәм инде телгә алып әйтелгән олы максатны алга сөрә, шуңа ирешә.

Шул җәһәттән чыгып фикер йөрткәндә, укучы күңеленә шик сала торган бер нәрсәне искәрми булмый. Күләме җыйнак кына шушы җыентыктагы 14 шигырь аерым кешеләргә багышланган. Дөрес, бу төр шигырьләрнең дә күбесендә автор китап алдына куелган төп бурыч юнәлешеннән тайпылмый, суратләү чараларын да сыегайтмый, фикерләрне дә саектырмый. Шулай да, кайбер багышламаларны укыганда, күңелдә моның шигърияткә әллә ни бәйләнеше юк, мондагы сүзләр фәлән-фәләневкә адресланган бит диган шикеллерәк чиклау тора.

Бар, олы шагыйрьләр иҗатында да әсәрне аерым шәхесләргә атап язу күренешләре бар. Пушкинның Кернга язган юлларын, мәсәлән, кем генә изге дога урынына ятламаган!?

...И сердце бьется в упоенье,
И для него воскресли вновь
И божество, и вдохновенье,
И жизнь, и слезы, и любовь.

Бер генә затка ишеттерергә теләгәнең дә бөтен укучыларың күңеленә хуш килә икән, аны кабул итәләр, хуплыйлар икән, багышлый бир! Китап баштанаяк гел шундый багышламалардан гына торса да, сүз әйтеп булмас иде, мөгаен. Хикмәт шигырьнең кемгә аталуында түгел, ә алардагы гомумиләштерүнең җитенкерәмәвендә. Фикерне ныгыту өчен С. Сөләймановaның арада иң уңышсыз чыккан бер багышламасын укып карыйк.

...Идеаллар белән одеяллар
буталалар, чыксаң толчокка.
Кесә караклары бар базарда,
Күп сайланып, берүк талчыкма.

Әллә авторның өзеп әйтер сүзе өлгереп җитмәгән, әллә аларны, гомумән, китапка кертүнең кирәге булмаган — багышламаларның кайберләре отышсыз. Әһәмияте артык зур булмаган бер детальне элеп алып теләсә кемгә шигырь юллау, кызганычка каршы, башка шагыйрьләребезнең дә гадәтенә кереп бара. Кирәк микән? Андый сүзләрне танышыңның үзенә генә язып тоттыру дөресрәк түгелме? Ул шигыльне һәвәскәр агитбригада репертуарын тәзүчеләргә, акыннарга калдырып тору хәерлерәк булмасмы?

Бәхеткә каршы, «Аланнарда балан» китабының яктылыгын, сәнгатьчәлеген һәм мәгънәви кыйммәтен ул берничә шигырь кимета алмый. Әдипләр дә, әдәбият сөюче меңнәрчә укучылар да китапны ярата, үз итәр, мөгаен.

**Кояш ТИМБИКОВА.**

Нияз Халитов

# КАЗАН ТАТАРЛАРЫ АРХИТЕКТУРАСЫНДА МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

„Казан — рус һәм татар үрнәге буенча төзелгән гүзәл шәһәр»,— XVI гасырда инглиз Дженкинсон әнә шулай дип язган. Европа һәм Азия чиге, борынгы татар дәүләтенең әкиятләргә кереп калган башкаласы — галимнәр һәм сәяхәтчеләр өчен Казан әнә шундый кала була. Шәрыкка да, Европага да хас сыйфатларны туплавы белән ул гади сәяхәтчеләрне генә түгел, бөек шәхесләрне дә таң калдырган. «Казан, һичшиксез, Россиянең аеруча яхшы төзелгән шәһәрләреннән берсе. Яңа зәвык таләпләренә туры китереп салынган матур биналар, борынгы чиркәүләр, төз манаралы нигытма һәм мәчетләр шәһәрне бизи һәм төрләндерә»,— дип искә ала бирегә 1833 елда булып киткән күренекле инглиз сәяхәтчесе Гельмерсен.

Революциягә кадәр шәһәр ике кисәккә — руслар һәм татарлар яши торган өлешләргә бүленгән була. Бу кисәкләр бер-берсеннән тышкы рәвешләре белән генә түгел, ә бәлки яшәүчеләренең мәдәни традицияләре белән дә аерылып торганнар. «Бирегә русларны хәтерләткән берни дә юк. Гади һәм еш кына шәрыкка тартым ысул белән салынган агач йортлар, рәт-рәт тезелеп киткән саф шәрык кибетләре. Төз, биек манаралар шәһәр күренешенә үзенә бертөрле төсмер өстиләр». Идел буе шәһәрләрен өйрәнгән Е. Беловның 1913 елда басылып чыккан юлкүрсәткечендә Татар бистәсе әнә шулай тасвирлана. Тарихчы Каюм Насыйри язып алган риваятьтән күренгәнчә, Татар бистәсе башта Кабан күле яры буйлап сузылган урамнан гыйбарәт булган. Казанның ул вакыттагы йөзе турында без аз беләбез. Бирегә XVII гасырда булып киткән голландияле атаклы сәяхәтчеләр Адам Олеарий һәм Николас Витзен гравюраларында күп санлы чиркәүләре һәм манаралары белән күзне иркәләп торган нигытманың, йортларның һәм урман каплап киткән тирә-юньнең матур иркенлекләре сурәтләнә. 1715 елда Казанда булып киткән инглиз сәяхәтчесе Джон Бэлл Татар бистәсе кешеләре «...үз диннәрен тотып байсез яшиләр һәм төрле хөрлекләрдән файдаланалар. Төркия, Персия һәм башка илләр белән сәүдә итәләр. Алар арасында бик бай яшәүчеләр дә бар»,— дип расный.

Безнең ата-бабаларыбыз ерак унҗиденче гасырда ничек яшәгәннәр соң? Татар бистәсе урамнары һәм йортлары нинди булган? Әгәр без бүгенге Татарстанның төньягындагы берәр кечерәк авылга барып кереп, үзебезне бер генә минутка дүрт гасыр артка чигенгән кешеләр дип күз алдына китерсәк, мөгаен, ялгышлык әллә ни зур булмас. Әйе, татарлар яшәгән Казанның борынгы урамнары да тәгаен гена, менә шундый булган. Хисапсыз борылышлардан торган, куе яшеллек белән капланган тар

һәм кәкре тыкрыклар. Тоташ койма һәм бүрәнә стеналар артында яшеренгән агач йортлар. Капкадан килеп кергәч без үзәктә бакча белән чолганган бер яки ике катлы агач йорт, ишегалды әйләнәсе буйлап сузылган амбарлар һәм келәтләр күрер идек. XVIII—XIX гасыр сәяхәтчеләре һәм галим-этнографлары татар бистәләрен нәкъ менә шундый сыйфатта күргәннәр. XIX гасыр башына караган татар культурасын тикшерүче күренекле галим, Казан университеты профессоры Карл Фукс та Казанда XVIII гасырдан сакланып калган борынгы йортларны шулайрак тасвирлый. Петербургтан килеп киткән архитектор ярдәмчесе топограф Яков Алексеев тарафыннан 1766 елда эшләнгән топографик күчермәдә дә Иске Татар бистәсе югарыда әйтелгәнчә сурәтләнгән.

«Татарларның өй кирәк-яракларын, нигездә, иң кирәкле әйберләр генә тәшкил итә. Аш-су әзерләү һәм ашу-эчү өчен билгеләнгән, исәбе әллә ни ишле булмаган савыт-саба, җир эшкәртү һәм һөнәрчелек кораллары, сәкегә урнаштырылган, бер үк вакытта караватны, урындык һәм өстәл хезмәтен башкаручы берничә сандык, келәмнәр, киезләр, яки чыпталар, ә кайчагында түшәкләр — аларның бөтен өй кирәк-яраклары менә шулардан гыйбарәт. Ә урындыкларны һәм өстәлләрне шәһәрдә яшәүче һәм чит ил кешеләре белән аралашучы татарлар гына тота»,— дип яза XVIII гасыр этнографы Иоганн Георги. Бу сүзләрне башка тикшеренүчеләрнең язмалары да раслый.

Татарларның ул вакыттагы торак йортлары үзләренең әлеге сыйфатлары белән шәрык мөселманнары — әзербайҗаннар, кырым татарлары, үзбәкләр, төрекләр, гарәпләр һәм башка милләт вәкилләре торакларына якын торганнар. Археологик һәм тарихи мәгълүматлар безгә Казан татарларының ата-бабалары белән әлеге халыклар арасында борынгыдан ук зур элемтәләр булуы турында сөйли. Барлык мөселман халыкларының, шул исәптән, татарларның да, тормышын һәм көнкүрешен бер көйгә салган шәригатьнең кырыс кагыйдәләре аларның культурасында һәм торак-көнкүрешендә кайбер охшаш сыйфатлар барлыкка килүгә сәбәпче булган.

Ул чорга караган йортларның хәзер, билгеле, берсе дә юк. Бүгенге көндә без Татар бистәләренең ук кебек туры урамнарында Европача салынган йортларны гына күрәбез һәм аларның берсе дә безгә XVII—XVIII гасыр галимнәре телгә алган йортларны хәтерләтми. Сәбәп нәрсәдә? Шәһәрнең татарлар яшәгән өлеше ни өчен шулай үзгәргән, соңгы 200 ел эчендә аның үсешенә нинди көчләр йогынты ясаган?

Россияне Европа державасына әверелдерергә карар биргән «данлыклы» Екатерина II реформалары Россия шәһәрләренең йөзен үзгәрткән. Инде 1767 елда ук архитектор В. Квасов Казан өчен яңа генераль план төзегән. Бу планда иске шәһәрнең урта гасырдан килгән чуалчык корылмаларын Европа стилендәге таш биналарга, тез урамнарга һәм мәйданнарга алыштыру күздә тотылган.

Әмма Урал һәм Идел буе шәһәрләре өстеннән җимергеч өермә сыман узып киткән Пугачев сугышы әлеге ниятләрне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми. Баш күтәрүчеләр Казанны алганнан соң шәһәрдән көл-күмер генә кала. Дөрес, халкы пугачевлыларны ачык йөз белән каршы алган Суконныйга һәм татар бистәләренә зыян тими. Восстание бастырылганнан соң «архитектурия поручигы» Василий Кафтырев төзегән (ул Квасов планын нигез итеп ала) яңа генераль план кабул ителә. Шушы көннән алып, Казан Европа стиленең махсус «үрнәк» проектлары буенча төзелә башларга һәм кешеләр «ышбу ниятә бернинди карусыз буйсынырга» тиеш була. Татар архитектурасының Европа дәвере әнә шулай башлана. Татар бистәләренә Европа үрнәге үтеп керү акрынлык белән, иске йортларны җимерүгә бәйле рәвештә бара. Әмма, Фукс язганча, инде XIX гасыр урталарында ук коймалар белән әйләндереп алынган борынгы утарлар бөтенләй диярлек бетерелә.

Шуны аерым билгеләп үтәргә кирәк, Казан ханлыгы җиңелгәннән соң бик мескен хәлгә килгән татар архитектурасы өчен бу үзгәртеп корулар гаять әһәмиятле була. Рус культурасы белән нык элемтәдә торып эш итү барокко һәм классицизм стилендәге, әчтәлеге белән милли һәм формасы буенча интернациональ татар архитектура корылмаларының гүзәл үрнәкләрен тудыра. Барокко стилендә төзелгән Мәрҗани һәм Апанаев мәчетләре шуңарга мисал булып торалар.

Ул чорда салынган торак йортлар әле дә саклана. Мәсәлән, Апанаев йортлары (Сафьян урамы, 5, К. Насыйри, 37), Хәсәенов йорты (Комсомольская, 42),

«Бай сәүдәгәр йортларының иң яхшы бүлмәләрендә сез Азиягә хас бернәрсә дә күрмисез,— дип яза Казан тарихын өйрәнгән күренекле белгеч М. Рыбушкин 1834 елда,— әмма аларның хатыннары яшәгән эчке бүлмәләрдә барысы да татарларның үз законнары куйган таләпләргә җавап бирә».

Кайбер йортларга хас булган тагын бер кызыклы үзенчәлекне билгеләп үтми мөмкин түгел. Бу — ишегалды ягына каратып эшләнгән һәм һавада чәй эчү өчен билгеләнгән киң иркен балконнар яки галереялар. Күп кенә шәһәр һәм авыл байлары аларны бик теләп эшләткәннәр. Мондый балконнарны күп кенә көнчыгыш халыклары — үзбәкләр, әзербайҗаннар, кырым татарлары, төрекләр, гарәпләр һәм башка милләт вәкилләре торакларында да очратырга мөмкин булган. Алар аны «айван» дип йөрткәннәр.

К. Ф. Фукс язганча, татар йортларының бүлмә стеналарын «еш кына рус осталары бизи. Алар төрле агачлар, чәчәкләр, елгалар, кораблар йөзеп йөргән диңгезләр ясыйлар, әмма биредә җәнлекләр һәм кошлар күрмисең, чөнки бу катгый тыела». Татар биналарының йөз ягында да кеше яки хайван сурәтләре булмаган (шул ук вакытта шәһәрнең руслар яшәгән өлешенә караган йортлар архитектурасында мондый рәсемнәр бик күп). Әлеге хәл ислам диненең җан ияләре сурәтен ясауны тыюы белән аңлатыла. Бу тыю архитектурага гына түгел, сәнгатьнең барлык башка өлкәләренә дә үтеп кергән.

Казанда XIX гасыр башына караган һәм хәзерге көнгә кадәр яхшы сакланган, шул чордагы татар архитектурасының бөтен милли үзенчәлекләрен чагылдырган биналар бар. Вәли бай (Комсомольская, 16/1) һәм Муллин (К. Насыйри, 11) йортлары әнә шундыйлар.

Татар бистәләренең үзенчәлеге биналарның милли сыйфатларында гына түгел, ә йортларның, бербөтен архитектур комплексларның үзенә бертөрле урнашуда күренә. Иске Татар бистәсендәге Печән базары (хәзер ул Киров урамының Париж коммунасы белән Г. Камал урамнары арасындагы өлеше) әнә шундый үзенчәлекле комплекс үрнәге.

Печән базары — XVIII—XIX гасырлардагы шәрык сәүдә үзәкләре үрнәгенә туры китереп төзелгән зур һәм катлаулы архитектур организм. 1845 елда П. Г. Песке проекты буенча салынган Олы базар мәчете тирәсендә табышлы йортлар һәм кәрвансарайлар, сәүдә һәм һөнәрчелек кибетләре, мунчалар, чәйханәләр, торак йортлар урнашкан булган.

Казандагы Печән базары кебек сәүдә майданнары ул чорда шәрыкның табигый йөзен тәшкил иткән, алар шулай ук шәһәрләрнең иҗтимагый үзәкләре ролен башкарганнар. Мондый үзәкләрдә йортларның ассортименты да бер үк төрле булган: мәчет, кәрвансарайлар, торак йортлар, мунчалар, чәйханәләр, сәүдә һәм һөнәрчелек кибетләре.

Татар архитектурасының тагын бер үзенчәлеге шунда, ул Россия империясе законнарына буйсынган хәлдә үскән, ә биналар рус архитекторлары проектлары буенча төзелгән. Әмма Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге архивларында сакланган күп санлы проектларны бу проектлар буенча эшләнгән йортларның үзләре белән чагыштырып караганда без аларның бөтенләй диярлек тәңгәл килмәвен күрәбез. Алар эчке төзелешләре буенча да, тышкы күренешләре белән дә аерылып торалар. Проект йортны төзү хокукы биргән документ булып хезмәт иткән һәм анда бинаның гомуми күренеше, аны ничек урнаштыру турында мәгълүматлар бирелгән. Әмма проектның аерым яклары, гадәттә, заказчыны канәгатьләндермәгән һәм ул төзелеш барышында үзенең төзәтмәләрен керткән. Шулай итеп, татар бистәләренең үз йөзе барлыкка килгән. Ул биредә яшәүчеләр психологиясенең һәм культурасының милли үзенчәлекләрен чагылдырган.

Ә хәзер шул чор кешеләренең истәлекләренә мөрәҗәгать итик. XIX гасырның икенче яртысында яшәгән галим Каюм Насыйри кала татарларының йортын менә ничек сурәтли: «Аларның йортлары тышкы яктан караганда урыс йортларыннан бер дә аермасы юк. Әмма өйнең эченә керсәң, өйнең эчтәге төзеклеге урыс өйләренә бер дә охшамый. Һичбер татар өендә юк урамнан керә торган ишек; булса да бик сирәк булыр. Күп вакытны татар өйләре була ике яклы, ягъни ирләр ягы, хатыннар ягы; ирләр өчен үзләренә бер ишек, хатыннар өчен үзенә бер ишек. Ха-

тыннар ирләр ягыннан йөрмәсләр... Бу эшләр мөселманның шәригатенә шулай килешә» (Сайланма әсәрләр. Т. 1, 91 бит).

Татар йортларының тышкы килеше үзгәрсә дә, эчке бизәлеше элеккечә калган. «Татар кешесенең йорты һәрвакыт келәмнәр, ачык буяулы савыт-саба белән бизәлгән өстәлләр, урындыклар, эскәмияләр очрамый диярлек: утырган җирләре келәм, йоклаганда да идәнгә күпсанлы мендәрләр салып шул келәм өстендә йоклыйлар... Зур шәһәрләрдә яшәүче кайбер татар байлары йортында гына өстәл-урындыклар, хәтта картиналар, чәчәкләр һ. б. булган бер-ике бүлмә очрый. Татарлар рус йортларында булган мебельдән бары тик савыт-саба шкафларын гына ошатканнар»,— дип яза XX гасыр башында яшәгән Россия халыклары этнографиясе белгече Е. Э. Сно.

Казан татарлары кысага утыртылган матур төсле пыяла белән әйләндерелгән иркен верандалардан, өй түбәсе маңгаенда урнаштырылган лоджийлардан элеккечә киң файдаланганнар, йортларны ачык кызыл, зәңгәр, яшел, көрән һәм башка төсләргә буяганнар. Күп кенә байлар янәшәдә торучы ике йортны үзара тоташтыручы өсте буяулы асылмалы үтеш юллары эшләткәннәр. Кайбер тикшеренүчеләр исәпләвенчә, мондый үтеш юлларын татарлар төрекләрдән күреп эшләгәннәр. Хәлле сәүдәгәрләрнең күбесе татар культурасының шәрыктан килгәнлеген күрсәтер өчен үзләренең йортларын шәрык стилендә эшләткәннәр (мисал өчен, Шакир солдат йорты. Киров урамы, 42 нче йорт), яки йортларның алгы якларын мөселман халыклары архитектурасында киң таралган элементлар белән: очлаеп торган яки көймәләп ясалган түбә, сталактит кәрнизләр, шәрык нәкышлары белән бизәгәннәр. Гәрчә бизәкләрнең күпчелеге русларның стильләштерү архитектурасында кулланылса да, Казандагы рус йортларында аларның кайберләре бөтенләй очрамый.

Җыеп кына әйткәндә, татар йортлары архитектурасында борынгы җирле урта гасыр традицияләре гомумевропа һәм рус стиле белән синтезлашкан. Моннан тыш татар йортлары архитектурасында шәрык мөселманнары торагына хас кайбер уртаклык күзәтелгән (айван галереялар, асылмалы үтеш юллары, нәкышлар, сталактитлар, очлаеп килгән яки дугалап ясалган түбәләр һ. б.). Татар йортларының милли форма һәм милли эчтәлек бердәмлеген тәшкил иткән бу үзенчәлекле сыйфатлары, тулаем алганда, интернациональ формада чагылыш тапкан, дөнья һәм Россия архитектурасының шул чордагы үсешенә җавап биргән.

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

*Идрис Туктар*

## ҖӨМЛӘЛӘР

Сызганылсын көн дә җиң, көн дә көрәш, көн дә җиң!

Соңга калып гафу үтенүләреңнән дә кәчлерәк үкенүләр була микән?

Яхшылык — дарулар даруы, яманлык — агулар агуы.

Иза чигәм нәни башыма төяп: ыгы-зыгы, ыбыр-чыбыр, вак-төяк!

Кеше булырга тырышкан һәр кеше — үзенчә матур.

Русчадан татарчага тәрҗемә итү эше азмы-күпме җайга салынган кебек, татарчадан татарчага тәрҗемә итү дә азмы-күпме җайга салынса иде.

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре докторы

# КҮРЕНЕКЛЕ ФИКЕР ИЯСЕ, ГАЛИМ ҺӘМ ӘДИП

Кешелек дөньясы Шәрыкның бөек улы, урта гасырларның күренекле фикер иясе, энциклопедист-галиме, философы һәм шагыйре Әбү Гали ибн-Синаның тууына мең ел тулуны билгеләп үтә. Аның күп кырлы бай мирасы бүген дә тирәнлеге, сафлыгы, гүзәллеге белән сокландыра, игътибарны үзенә җәлеп итә. Замандашлары ук Әбүгалисинаны зур хөрмәт белән «философлар солтаны» һәм «табиблар табибы» дип атап йөрткәннәр. Аның фәнни эшчәнлеге урта гасырлар фәненең бөтен өлкәләрен үз эченә ала, ә хезмәтләре Мәгърибтән алып Мәшрикъкача (ягъни Көнбатыштан алып Көнчыгышка кадәр) җирләрдә таныла. Ибн-Сина идеяләре һәм ачышлары, ул туплаган гыйлем-мәгълүмат алдагы чорларда фәнни-философик фикер үсешенә гаять зур тәэсир ясый.

Булачак фикер иясе 980 елда Бохарадан ерак булмаган Әфшан исемле бер төбәктә дөньяга килә. Аның әтисе — Сәманидлар дәүләтендә шактый дәрәҗәле урын биләгән Габдулла ибн-Сина үз заманының укымышлы кешесе була. Ул балаларына белем бирүгә дә акчасын-мөлкәтен кызганмый, Бохараның иң яхшы мөгаллимнәрен чакырта. Кечкенә Әбү Гали исә гаҗәп зирәк, сәләтле бала, белем алуга бик хирес шәкерт булып чыга. Ун яше тулганда инде ул гарәп теленең грамматикасын һәм стилистикасын яхшы үзләштереп өлгерә, ә Коръәнне тулысынча диярлек яттан белә. Дини хокук (шәригать) нигезләрен өйрәнгәч, Әбүгалисина математика, физика һәм логика дөньясына чума. Аның аң-белем ягыннан үсешенә борынгы грек философы Аристотель «Метафизика»сының йогынтысы аеруча көчле була. Ибн-Сина үзенең тәрҗемәи хәлендә әлеге әсәрне кырык мәртәбәләп укып чыгуы, аның күп кенә өлешләрен күңелдән белүе, ләкин әле һаман да төп мәгънәсенә төшенеп җитә алмавы турында яза. Китап базарында очраклы рәвештә кулына килеп кергән бер китап — Көнчыгышның янә бер бөек фикер иясе әл-Фәраби язган шәрех-комментарийлар гына «Метафизика»ның асылын аңларга ярдәм итә һәм Әбүгалисина алдында бөтенләй яңа дөньялар ачылып киткәндәй була.

Ибн-Синаның дөньяга карашы табигать фәннәре нигезендә формалашу аның тормышында медицинаның зур урын алып торуына китерә. Төрле авыруларны нечкәләп өйрәнү нәтиҗәсендә ул үз гасырының бөек табибына әверелә. Врач буларак Әбүгалисинаның даны бөтен Шәрык дөньясын шаулата, ә хезмәтләре медицина тарихында бик гадел рәвештә Гиппократ һәм Гален исемнәре белән янәшә куела. Медицина сукмагы аны табигать белеменең тагын да киңрәк проблемаларына алып чыга.

Унҗиде яшьлек Әбү Гали Бохара әмирен авыр чирдән дәвалап, Сәманидлар сараендагы китапханәдән файдалану хокукына ирешә. Бу бәхет озакка бармаса да, заманындагы иң бай китап хәзинәләренең берсендә гыйлем эстәү аның интеллектуаль үсешенә ифрат көчле тәэсир ясый. Тиздән чит ил яуларының һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Сәманидлар нәселе тәхеттән төшерелә, искиткеч китапханәгә ут ала, шул мәхшәр вакытында Әбү Галинең әтисе дә вафат була. Егеткә шуннан соң төньяккарак юл тотарга — чәчәк атып килүче Хәрәзм дәүләтенең башкаласы Үргәнечкә күчеп китәргә туры килә.

Хәрәзм шаһының сараенда ул чорның күренекле гыйлем ияләре җыелган була. Ун еллап биредә яшәгән Әбүгалисинага атаклы галим Әбү Рәйхан әл-Бируни белән сөйләшү һәм мөназараларның зур ярдәме тия. Ләкин Хәрәзмнең политик язмышы кыл өстендә тора. Аның көньягында Газнәвиләрнең яшь дәүләте куәт алып килә. Газнәвиләр дәүләтенең башлыгы Мәхмүднең инде төньяк-көнбатыш Һиндстанны, Иран һәм Әфганстанның зур җирләрен кулга алган, Хәрәзмгә дә нәфесен суза башлаган

чагы. Аны Үргәнечнең баш июеннән биграк, андагы шагыйрьләрне, философ һәм галимнәрне үз сараена китертү мөмкинлеге кызыктыра. Тик мондый баскынчылык Әбүгалисинага һич тә ошамый, ул, куәтле солтан теләгенә буйсынмыйча, Хәрәзмнән качып китә.

Гомеренең шуннан соңгы елларын Әбүгалисина Иранның төньяк калаларында — фарсы солтаннары сарайларында үткәрә. Биредә табиблык гыйлеме һәм осталыгы өстенә, мөселман шәригатен яхшы белгән галимнең хөкемдарлык һәм җитәкчелек сәләте ачылып китә. Хамадан әмире аны үзенең вәзире итә. Ләкин әмирлекнең эшләрен җайга салырга омтылуы белән Әбүгалисина биредәге «сугыш аллалары»ның һәм мин-минлекле түрәләрнең бугазына аркылы килгән сөяк булып чыга, нәтиҗәдә күп низагларның уртасына эләгә, хәтта бервакыт төрмәгә дә ябып куела. Бары Исфахан әмире Галәвет-даул катына килгәч кенә (1023 елдан башлап) аның тормышы чагыштырмача имин-тыныч төс ала. Философ бу идарәченең иң якын киңәшчесенә әйләнә, этрафлы һәм нәтиҗәле фәнни иҗат белән шөгыльләнә. Монда ул үзенең мөһим фәнни һәм фәлсәфи хезмәтләрен тәмамлый. 1037 елда вафат була.

Әбүгалисинаның фәнни эшчәнлеге гаять күп кырлы. Ул медицина, биология, химия, физика, математика, география, минералогия, астрономия, логика, психология, музыка һәм философия буенча өч йөздән артык хезмәт язган. Медицина буенча гына да китаплары 50 дән артык. Арадан берсе — гаять зур мөһим хезмәте «Канун фит-тыйбб» («Медицина кануннары») исемле хезмәте ибн-Синаны гасырлар буена җиһанга данга күмгән. «Канун»ны латинчага тәрҗемә кылу урта гасырларда яшәгән Европа галимнәренә Шәрык халыкларының медицина өлкәсендәге казанышларыннан хәбәрдар булу мөмкинлеге бирә. Әбүгалисина әнә шул рәвешле Көнбатыш Европа медицинасының үсешенә дә йогынты ясый. XIII—XIV гасырларда Европадагы бик күп галимнәр «Канун»ны махсус өйрәнәләр һәм шәрехлиләр.

Әбүгалисина, медицинаның киләчәктәге ачышларын алдан күреп, Пастердан сигез гасырга иртәрәк бизгәк авыруларының су белән генә түгел, һава аша да йогучы күзгә күренмәс вируслар аркасында килеп чыгуы турында фараз белдерә. Ул пульс, балаларны дөрес тукландыру турында кызыклы хезмәтләр иҗат итә, кызамык һәм чәчәк авыруларына каршы көрәш һәм аларны дәвалау юлларын таба. Әбүгалисина — физиотерапия (хәрәкәт, җылылык, су һ. б. белән дәвалау) нигезләрен салучыларның берсе, ул патология (организмда була торган авырулар, нормадан читкә тайпылышлар турындагы фән) өлкәсендә дә шактый ачышлар ясаган.

Ибн-Синаның дөньяга караш үзенчәлекләре «Китаб эш-шифа» («Шифалану китабы») дигән фәлсәфи әсәрендә һәм медицина буенча күп санлы хезмәтләрендә чагылыш таба. «Китаб эш-шифа»ның унөч кисәге дөньядагы күренешләрне, үзгәрешләрне тасвирлауга багышланган, алар шул заманның физика, химия, ботаника, зоология, геология, метеорология, астрономия, математика һәм музыка (акустика) өлкәсендәге казанышларына таяна.

Геология фәненең ачыласы катламнарын күреп, Әбүгалисина тау үзәннәре һәм тарлавыкларның барлыкка килүе, җир тетрәүләрнең сәбәбе турында кыю фаразлар белдерә. Аның бу фикерләре Җирнең яратылуы хакындагы дини карашларга капма-каршы килә һәм бүгенге фән ачыклаган мәгълүматлар белән раслана.

Әбүгалисина тел белгече һәм язучы буларак та танылa. Аның зур абруй казанган әсәрләре гарәп илләре, Иран, Әфганстан һәм Урта Азия әдәбиятлары үсешенә шифалы йогынты ясый.

Әбүгалисина хезмәтләре арасында фәлсәфи эчтәлекле трактатлар аеруча зур урын алып тора. Аның өчен философия — борынгы грекләрдагы кебек үк, фәннәр кушылмасы, ягъни гомум дөнья турындагы фән. Әбүгалисинаның фәлсәфи проблемаларның асылын аңлавы Аристотель тәэсирендә формалашкан. Аристотель мирасына әл-Фәраби күзлегеннән караса да, ибн-Сина төрлечә үзгәртүләрдән, «аңлату»лардан котылырга тырыша һәм борынгы акыл иясенең позицияләренә әл-Фәрабиларга караганда якынрак килә. Тикшеренүчеләр, ибн-Сина Аристотель философиясен Шәрык шартларында куллану юнәлешенә (Шәрык перипатитизмына) нигез салган, дип саныйлар. Ләкин буржуаз тарихчыларның аңа бары Аристотельне шәрехләүче итеп кенә карарга маташуы нигезсез. Мең ярым елдан соң, тамырдан үзгәргән социаль һәм идеологик шартларда, культура һәм фәннең бөтенләй яңа баскычында Аристотель хезмәтләренә гади аңлатмалар гына бирү мөмкин түгел. Шуңа күрә Ш. Мәрҗанинең, Ибн-Сина — борынгы грек философының «гади шәкерте генә түгел. Киресенчә, ул берничә очракта Аристотельгә каршы чыга, аның фикерләрен кире кага һәм үз позициясен яклый»,[1] дигән сүзләре күпмедер дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә.

Икенче яктан, билгеле, Әбүгалисинаның фәлсәфи проблемаларны хәл итүдә күбрәк Аристотель артыннан баруын да инкяр итәргә ярамый.

Аристотель философиясендәге материалистик элементларны үстерә барып, ибн-Сина материаль дөнья мәңгелек, ул беркем тарафыннан да барлыкка китерелмәгән һәм бөтен җисемнәр материядән тора дип саный. Ләкин бу караш капма-каршы, идеалистик рухтагы фикерләр һәм искәрмәләр белән үрелеп бара. Әбүгалисина алланың барлыгына да ышана һәм шуңа күрә яшәешнең берьюлы ике — материалистик һәм идеалистик башлангычын таный.

Үзенең фәлсәфи хезмәтләрендә ул табигатьне өйрәнүгә зур әһәмият бирә һәм логик фикерләү белән тәҗрибәнең, акыл белән экспериментның бердәмлеге принцибын яклый. Реакцион руханилар ибн-Синаны дошман күрәләр, дини тәгълиматка

[1] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 20, 89 нчы бит.

шикләнеп караганлыктан, кяферлектә гаеплиләр, аның күп санлы шәкертләрен дәһриләр (алласызлар) дип игълан итәләр.

Әбүгалисинаның фәнни ачышлары һәм заманына күрә алдынгы идеяләре Шәрык халыкларының фәлсәфи фикер үсешенә, Европа фәненең яңа офыклары ачылуга сизелерлек йогынты ясый.

Әбүгалисинаның гадәттән тыш фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында хәбәрләр башка илләргә һәм, шул исәптән, Идел буйларына да килеп җитә. Әлеге төбәк халыкларының Урта Азия, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре белән элек-электән тыгыз бәйләнештә яшәве дә моңа сәбәпче булгандыр. Шуның өстенә, Идел Болгарстаны кебек культура-идеология ягыннан нык үсеш алган дәүләтнең Шәрык мәдәниятен, фәнен һәм философик идеяләрен кабул итәрлек дәрәҗәгә ирешүен дә истә тотарга кирәк. Болгарда уку йортлары һәм китапханәләр булган, фәнни-фәлсәфи трактатлар һәм әдәби әсәрләр язылган. Тарихта Ягъкуб бин Ногман, Әбел-галә Хәмид бин Идрис, Хуҗа-Әхмәд әл-Болгари, Борһанетдин Ибраһим бин Хәзәр һ. б. галимнәрнең исемнәре сакланган. Урта гасырлар гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Әндәлүси болгар галимнәренең күк җисемнәрен өйрәнү өчен төньяк өлкәләргә баруы турында шаһитлек итә. Әбүгалисинадан һәм аның тарафдарларыннан килүче идеяләр йогынтысы урта гасырларда Идел буенда яшәгән шагыйрьләр иҗатында да ачык чагыла. XIV гасыр шагыйре Котб, мәсәлән, «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә дөньяга караш белән бәйләнешле зур проблемалар күтәрә, галәм төзелеше һәм анда кешенең урыны турында уйлана. Шул ук чорда яшәгән Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» поэмасын искә төшерик. Ул Коперниктан 150 ел элегрәк Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе хакында фикер йөртә. Күрәсең, әл-Бируни хезмәтләрендә, Әбүгалисина катнашкан фәнни даирәләрдә формалашкан бу идея үз заманында ук укымышлы кешеләр арасында киң таралган. Сәйф Сараи исә аның хаклыгына нык инанган булырга тиеш.

Әбүгалисина исемен Идел буе татарлары гасырлар буена телдән төшермиләр. Галимнең тормышы һәм эшчәнлеге турында дөрес мәгълүматлар өстенә, халык аны төрле риваятьләр каһарманы итеп тә күз алдына китерә. Шул хикәятләр һәм төрек язучысы Сәнд Яхъяның «Кәҗинә-и Хикмәт» китабы нигезендә күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри үзенең атаклы «Әбүгалисина» кыйссасын яза. К. Насыйри әсәрендә ибн-Сина мәгърифәт һәм инсафлылык нуры таратучы гаделлек хакына, хокуксызлар һәм ярлылар бәхете өчен миһербансыз патшаларга каршы көрәшүче зур гыйлем иясе итеп сурәтләнә.

XIX йөздә Идел һәм Урал татарлары арасына яңалыкка омтылучы куәтле идея ташкыны килеп керә — дин сөременә, культура һәм аң-белем ягыннан артта калганлыкка каршы юнәлгән мәгърифәтчелек хәрәкәте башлана. Милли иҗтимагый фикернең прогрессив традицияләре белән бергә, алдынгы рус фәнни-философик фикере һәм культурасы да әлеге агымның фәлсәфи һәм иҗтимагый-политик карашлары формалашуы өчен бик әһәмиятле идея чыганагы булып тора. Шул ук вакытта мәгърифәтчелек хәрәкәтенә Шәрык фикер ияләренең, бигрәк тә бөек Әбүгалисинаның яктылыкка, яңарышка чакыручы идеяләре зур йогынты ясый. Күренекле татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләре, мәсәлән, ибн-Синаны остаз буларак чиксез хөрмәт итү һәм аның фикерләре алдында баш ию рухы белән сугарылган. «Вафийәт-эл-әсляф вә тәхийәт-эл-әхляф» әсәрендә ул Әбүгалисинаны даһи шәхес, гыйлеме, зиһене белән тиңе юк талант иясе дип атый.

Әбүгалисина әсәрләре Казан Насыйри өчен дә илһам һәм иҗади эзләнүләр чыганагы була. К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә еш кына бөек галимнең фикерләренә таяна, аның образы фәнгә риясыз хезмәт итү һәм гаделлеккә омтылу мисалы итеп китерелә.

Татар мәгърифәтчеләре алланың асылы, дөнья яратылуы, язмыш, вакыт һәм яшәеш ягыннан чиксезлек мәсьәләләрендә дин әһелләре белән кискен бәхәскә керәләр. Мәгърифәтчелек хәрәкәтендә туган күп кенә идеяләр үзләренең башлангычы белән Әбүгалисина һәм Шәрыкның башка фикер ияләре калдырган фәнни-фәлсәфи мираска барып тоташа. Бу — алланы кешегә охшатып күз алдына китерүгә (антропоморфик карашларга) каршы чыгуда аеруча ачык күренә. Мәсәлән, Габденнасыйр Курсави (1776—1812) алланы сурәтләгән сыйфатларны инкяр итеп, аны абстракт төшенчәгә әверелдерә, диннең катып калган өйрәтмәләрен тәнкыйтьли.

Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889) бу карашларны дәвам иттереп, иң төп мәсьәләләрдә дин өйрәтүләренә каршы төшә, алланы дөньяның үзе кебек үк иксез-чиксез итеп күз алдына китерә. Алла табигатьтән аерылган мөстәкыйль зат түгел, ул дөньядан һәм дөнья күренешләреннән элегрәк яши, ләкин ул һәрнәрсәнең үзәгендә ятучы гомуми яшәү принцибы, дип аңлата Мәрҗани. Алланың мәңгелеге без күзәтә торган вакыйгалар агышында: ул үткәндә, бүгенге көндә һәм киләчәктә яши.

Ш. Мәрҗани, ибн-Сина кебек үк, дөньяның мәңгелек һәм объектив булуын күрсәтә. Уһ алла идеясен таныган хәлдә, аның асылы дөнья күренешләрендә дигән нәтиҗә ясый. Дөнья, алланың үзе кебек, мәңгелек һәм чиксез, бары тик дөньядагы әйберләр генә туктаусыз алышынып тора.

Дөньяны һәм алланың табигатен болай аңлатуы белән Мәрҗани, Әбүгалисина шикелле үк, пантеистик карашларда булуын күрсәтә. Ләкин ибн-Сина, билгеле булганча, неоплатоник тенденцияләргә йөз тота һәм дөньяны илаһи нурдан яратылган дип күз алдына китерә. XIX гасырда яшәгән татар мәгърифәтчесе исә алдынгы рус иҗтимагый-философик фикерләре һәм фәннең яңа казанышлары тәэсирен кичерә, шунлыктан аның пантеизмы да материалистик тәгълимат тарафына авышкан. Әбүгалисинадан аермалы буларак, Мәрҗани асылда алланың табигать белән кушылып

китүен таный, аны табигать белән тәңгәл күрә.

Шул рәвешле, Мәрҗанига дөньяның үз законнары нигезендә үсүе, күренешләр һәм әйберләрнең материаль табигате ачыла. Ул, ибн-Сина кебек, алла белән бергә материяне дә таный, аны үзгәрешсез, бертөрле һәм бүленмәс итеп күз алдына китерә. Шул материядән табигатьтәге конкрет күренешләр барлыкка килүен аңлату өчен ул форма идеясенә мөрәҗәгать итә. Ягъни беренчел материя, билгеле бер формага салынып, аерым әйбер яки күренешкә әверелә, бер җисем дә материя һәм форманың шундый бердәмлегеннән башка була алмый, дип саный. Галәм, Мәрҗани карашынча, вакыт ягыннан чикләнгән, ә сыйфат ягыннан чиксез күп төрле материаль җисемнәрнең мәңгелек һәм чиксез алмашынып торуы.

Татар мәгърифәтчеләренә ибн-Синаның «ике төрле чынлык» (дин белән философиянең мөстәкыйль яшәү һәм үсү мөмкинлеген тану) теориясенең дә йогынтысы сизелә. Шиһабетдин Мәрҗани мөтәкаллимнәрнең фәнне һәм философияне дин гыйлеменә буйсындырырга маташуларында зур хилафлык күрә, диннең дә, шулай ук фән белән философиянең дә, үз урыны, үз хаҗәте, үз алымнары бар, дип саный. Дини мәсьәләләрдә без изге чыганакларга — коръән һәм пәйгамбәр хәдисләренә йөз тотабыз, дип яза ул. «Пәйгамбәрләр фән түгел, ә шәригать нигезләрен тарату өчен иңдерелгәннәр», — дип басым ясап күрсәтә Мәрҗани (Г. Ибраһимов исемендәге тарих, тел һәм әдәбият институты архивы, 22 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 20, 88—89 битләр). Димәк, фәнни-философик проблемаларга килгәндә, бары тик акылга таянырга һәм әйберләрнең, күренешләрнең чынлыкта булган халәтен искә алырга кирәк була. Шул ук вакытта җисемнәрнең, күренешләрнең табигый үзлекләрен, кеше акылы ачкан кануннарны шәригать юкка чыгара алмый. Ш. Мәрҗани фикеренчә, хәтта шәригатькә каршы килүче фәнни нәтиҗәләрне дә җиңел генә кире кагу юлына басмыйча, үлчәү тәлинкәсенә һәр ике якның дәлилләрен салып карарга кирәк.

Мәрҗанидан соңгы татар иҗтимагый фикере үсешендә якты эз калдырган мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси дә (1856—1930) фәннең шәригатьтән бәйсезлеге идеясен күтәреп ала. Ул фәнни мәсьәләләрне диннән тагын да ныграк аера һәм дөньяви проблемаларны шәригать кушканча хәл итүгә кискен каршы чыга. Пәйгамбәр мирасы бары дингә генә кагыла, җисемнәрнең табигатен ачыклау аның хөрмәтле вазифасына керми, дип яза (Ш. Күлтәси. Хәйате җәдидә. Казан, 1896, 36 нчы бит). Шәригать аның үенчә, дини һәм әхлак тәрбиясе мәсьәләләрен хәл итү, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу белән шөгыльләнергә тиеш. Чынбарлыкның асылын, табигатен өйрәнү, галәм төзелешенең бәхәсле проблемаларын чишү исә фән өлешенә кала. Фәкыйһлар (дини хокук белгечләре) коръән һәм пәйгамбәр хәдисләрен үзләштерү нәтиҗәсендә мөселман хокуклары фәнен иҗат иткән кебек, галимнәр һәм философлар да табигатьне һәрьяклап өйрәнү, аның бөек серләрен ачу юлы белән дөньядагы күренешләрнең нигезен тәшкил итүче законнарны билгелиләр, дип саный Ш. Күлтәси.

Фәннәрне төркемнәргә аеру һәм аерым фәнни тармаклар тоткан рольне ачыклау мәсьәләсендә дә ибн-Сина идеяләренең Шиһабетдин Мәрҗанига йогынтысы сизелә. Мәрҗани әлеге классификацияне төзегәндә күренешләрнең асылын өйрәнү юлларын һәм белем-мәгълүмат туплау рәвешен нигез итеп ала. Шул принциптан чыгып, ул фәннәрне ике зур тармакка аера. Гыйльме нәкълия (традицион белемнәр) дип аталган беренче төркемне элек-электән җыелып килгән мәгълүматларга нигезләнүче фәннәр тәшкил итә. Гыйльме гакълия (акыл белән ирешелә торган белемнәр) төркеменә исә көндәлек эш практикасында, сынау-тәҗрибә нәтиҗәсендә һәм акыл, хис, фикерләү белән табылган мәгълүматлар керә (фәннәр). Гыйлемнәр системасында логиканың урынын билгеләгәндә Ш. Мәрҗани турыдан-туры ибн-Сина эзеннән бара, аны «белем тирәнлеген үлчәү фәне» дип атый. Мәрҗани фикеренчә, логика «хөкем-фикерне раслау яки кире кагу өчен дәлилләр кору тәртибен» билгеләүче, «чынны ялганнан аерырга ярдәм итүче кагыйдәләр һәм критерийлар җыелмасын тәшкил итә» (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 20, 65 бит).

Ибн-Сина классификациясендәге практик философиягә Шиһаб Мәрҗаниның сәяси фәннәр турындагы карашлары туры килә. Татар мәгърифәтчесе аларны өч төркемгә бүлә: кешенең шәхси тормышындагы сәясәт (Әбүгалисинада: адәм баласының шәхес буларак асылы турындагы фән), гаиләкөнкүреш сәясәте (кешенең йортына, хатынына, бала-чагасына һәм мал-мөлкәтенә мөнәсәбәтле үз-үзен тотышы турындагы фән) һәм дәүләткүләм сәясәт (Әбүгалисинада: шәһәрләр һәм илләр белән тулаем идарә итү турындагы фән).

Ибн-Синаның идея-теоретик мирасы Каюм Насыйрига аеруча зур тәэсир ясый. Бу бигрәк тә кеше акылының табигатен аңлату өлкәсендә ачык күренә. Акыл нигезендә шәхеснең табигате һәм иҗтимагый тормышы ята, ди К. Насыйри. «Табигать» төшенчәсе — ибн-Сина философиясендәге кешенең «табигый» кодрәтенә, «иҗтимагый тормыш» исә тупланган гакыл-мәгълүматка туры килә. Табигатьтән килүче сәләт — акылның даими нигезе, ул гадәти кешеләрнең һәркайсына хас, ди К. Насыйри. Ә тормыш-яшәеш тудырган күренешләр тәҗрибә һәм иҗтимагый бәйләнешларга бәйле рәвештә үзгәреп тора. «Тәҗрибә һәм белем туплау аң үсешенә һәм камиллегенә этәргеч ясый. Табигый сәләте булган кешенең акыл ягыннан үсеш дәрәҗәсе тәҗрибә зурлыгына бәйле» (К. Насыйри. Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият. Казан, 1884, 59 нчы бит).

Әхлак мәсьәләләрен хәл иткәндә дә Ка-

юм Насыйри Шәрык фикер иярләре, шул исәптән, ибн-Сина һәм әл-Фәраби карашларын нигез итеп ала. Билгеле булганча, ибн-Сина җисми көчләрне «әхлак сыйфатлары чыганагы» дип саный. Каюм Насыйри да кешенең әхлакый асылын эчке табигате белән бәйләнештә күрә. Аның фикеренчә, кешегә ике төп көч — фикерләү-аңлау һәм хәрәкәт-омтылу көчләре хас. Фикерләү-аңлау көче теоретик һәм практик тармакларга бүленә (игътибар итегез: Әбүгалисина кеше күңеленең нәкъ шундый сәләткә ия булуы турында яза). Хәрәкәт-омтылу көче исә мәхәббәт һәм нәфрәттән тора, дип күрсәтә К. Насыйри.

Татар мәгърифәтчеләренең барлык әсәрләрендә Әбүгалисинага олы хөрмәт белән карау сизелеп тора. Шиһаб Мәрҗани, мәсәлән, аны гыйлем түбәсен яулаган белем-мәгълүмат киңлеге, зиһен һәм фикер мөкәммәллеге ягыннан тиңе булмаган сәләткә ия бөек шәхес дип атый. «Әбү Гали Хөсәен бин Габдулла бин Сина галимнәргә башлык, табибларга бәк, философларга падишаһ булган, дошманнары да, дуслары да аңа искиткеч ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәткәннәр. Тырыш хезмәт белән ул фән һәм фәлсәфәнең барча тармакларын үзенә туплап, әйткән сүзе мәкаль һәм әйтемгә әверелгән бик зур галим була»,— дип яза Мәрҗани (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 нче фонд, 1 нче тасвирлама, саклау берәмлеге 20, 90, 114 битләр).

Ш. Мәрҗани «Әл-канун фи-т-тыйбб», «Әш-шифа» һәм башка әсәрләрне өйрәнү-тикшерү нигезендә, Әбүгалисина — Аристотель эшен иҗади дәвам иттерүче фикер иясе, дигән нәтиҗәгә килә.

Татар мәгърифәтчеләре ибн-Синаның идея-иҗади мирасын югары бәяләп кенә калмыйча, аны дини даирәләрнең һөҗүменнән дә саклыйлар. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, аның «Әш-шифа», «Ән-наҗәт» һәм «Ишарәт» китапларыннан файдаланган өчен төрлечә эзәрлекләүләргә каршы төшә, мөселман Көнчыгышында бик абруйлы булган имам әл-Газалиның әл-Фәраби белән ибн-Синаны динсезләр дип атавын гаепләп чыга. Әл-Газали китабының кырына: «Ислам дөньясының гаять күренекле имамы Фәраби һәм ибн-Синаны дәһрилектә гаепләп чыга икән, бу аның гыйлем дәрәҗәсенә берничек тә туры килми,— дип яза Мәрҗани.— Ул үзе, шәригатькә каршы килә дип, иблиска да бәддога укудан тыя. Ә менә ни сәбәптән бөек галимнәрне динсезлектә фаш итәргә тотынуы һич аңлашылмый. Күрәсең, философиягә һәм философларга карата чиктән тыш фанатик мөнәсәбәттән кала, бер сәбәп тә юктыр» («Мәрҗани» җыентыгы, 266 нчы бит).

Фән аксакалы һәм фикер иясе Әбүгалисина турындагы якты истәлек татар халкының күңелендә гасырлар буе яши. Аның үлемсез мирасы алдында дөньяның алдынгы кешеләре баш ия.

**Мидхәт Фәйзуллин,**
профессор, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе

## МӘШҺҮР ВРАЧ

Әбүгалисинаның үлүенә ун гасыр чамасы вакыт үтсә дә, халык аның турындагы якты истәлекне күңел түрендә саклый. Галим турында күп кенә хикәяләр һәм риваятьләр иҗат ителде, аның даны буыннан-буынга күчеп килә. Әбүгалисинаның табиплык итү сәнгатен һәм медицина өлкәсендәге бөеклеген гасырлар агышы гына кеше күңеленнән чыгарып ташлый алмый.

Әбүгалисина табигать серләрен гаять зур акыл белән өйрәнә белә, үсемлекләр дөньясының сулышын тоя, үләннәрнең кеше сәламәтлеге өчен иң кирәкле микъдарларын алып, дарулар ясый һәм аларны бик оста итеп куллана да. Без әле бүген дә бөек галим файдаланган даруларны өйрәнәбез. Әбүгалисинаның яраларны дәвалау өчен бальзам куллануы билгеле. Аның дәвалау үзенчәлекләрен «Табиб фәне кагыйдәләре» дигән хезмәтендә яктырта. Хәзер шундый бальзам Зарафшан тауларында табылды. Зариф-Задә атлы укыгучы таш гөмбәзләреннән ылыс исе аңкып торучы чем-кара майлы матдә белән капланган мәгарә таба һәм аның эченә керә.

Менә шушы сумала сөякләрнең ялгануын һәм җәрәхәтләрнең төзәлүен тизләтүдә кыйммәтле бер әйбер булып хезмәт итә. Зарафшан мәгарәсе сумаласы борынгы заманның бөек галиме файдаланган бальзам булгандыр, мөгаен. Таҗикстан ССР Фәннәр академиясе институтында һәм лабораторияләрендә, республиканың медицина учреждениеләрендә бу юнәлештә хәзерге көндә дә зур фәнни-тикшеренү эшләре һәм тәҗрибәләре алып барыла.

Ташкентта бөердәге ташларны эретеп чыгаруда һәм сидек юлларын дәвалауда бик файдалы булган артемизол дигән яңа дару уйлап таптылар. Аның төп нигезен Үзбәкстан тауларында үсә торган үләннәрдән алынган эфир мае тәшкил итә. Үз заманында Әбүгалисина шушы ук үләннәр кайнаткан суны бөер һәм сидек куыгындагы ташларны эретүдә кулланган булган. Артемизолны сынау яхшы нәтиҗәләр бирде һәм ул дәвалау учреждениеләрендә уңышлы кулланыла.

«Медицина кагыйдәләре» китабы галимне бик күп җирләрдә атаклы кеше итә. Бу хезмәт V—VI гасырларда медицина фәне

өлкәсендә кулланма булып тора. Венециядә латин телендә басыла һәм шушы тәрҗемәсе буенча Европада да тарала. Китапның уналтынчы йөздә Римда кабат-кабат басылуы билгеле. «Медицина кагыйдәләре» гарәп телендә дә XV гасыр урталарында Римда бастырып чыгарыла.

Әбүгалисина озак яшәми. 57 яшьлек гомерендә ул фәннең төрле тармаклары — философия, геология, астрономия, биология, медицина, музыка культурасы, әдәбият һәм башка өлкәләрдә искиткеч бай гыйльми мирас калдыра. Галим яшәгән чорда тарихи шартлар катлаулы була. Бу аның тормышында һәм иҗатында чагылыш тапмый калмый, әлбәттә. Ул үсмер чагында ук әдәбият һәм гуманитар фәннәр вәкилләре белән аралашып яши. Егет гадәттән тыш сәләтле була һәм 18 яшендә фәннең күп кенә тармаклары, аерым алганда, медицина буенча тәпле белем ала. Егерме тулганчы ук оста врач булып китә. Саманидлар династиясенең соңгы хуҗаларыннан берсе әмир Нух бин Мансур авырый башлагач Әбүгалисинаны чакырта. Галим аны дәвалый. Әмир рәхмәт йөзеннән аңа Саманидларның данлыклы китап хәзинәләреннән файдаланырга рөхсәт бирә. Әбүгалисина анда кереп чума, көне-төне укый. Көнчыгышның иң эре галиме дәрәҗәсенә күтәрелүдә китап хәзинәсенең тоткан роле зур. Әмма аның тормышы шулай шома гына бармый. Әтисе үлә, яклаучысы әмир дә дөнья куя. Караханнарның һөҗүме галимнәр иҗаты өчен шартларны бөтенләй бетерә. Алар берәм-берәм туган илләреннән китә башлыйлар. Әбүгалисина да туган-үскән туфрагыннан аерыла. Бохарадан китә һәм Хәрәзм солтаны Али ибн-Мәмүн янында яшәү урыны таба. Ул чорда Хәрәзм башкаласы Үргәнеч үз галимнәре белән дан тота, солтан фән кешеләрен ярата. Бирәдәге галимнәр белән очрашу, фикер алышу нәтиҗәсендә Әбүгалисинаның философия һәм медицина буенча яңа хезмәтләре туа. Көнчыгыш галимнәре Әбүгалисинаны күренекле врач буларак ихтирам итәләр.

Хәрәзм дәүләт буларак яшәү хокукын югалткач, Әбүгалисина иҗаты чәчәк аткан бер чорда, 37 яшендә, Иранга китә. Аңа кайбер шәкертләре дә ияра. Хамаданда врачлык эшчәнлеген киң җәелдерә, каты авырып киткән әмирне терелтә һәм шуннан соң аның вазире итеп билгеләнә. Бу өлкәдә галимнең эшчәнлеге аз билгеле. Эре феодал эксплуататор әмирнең киңәшчесе булу гуманист галим күңеленә хуш килмәгәндер дип уйларга кирәк. Озакламый әмир Әбүгалисинаны күралмый башлый, ул галимне берничә тапкыр үтерергә омтыла. Әмир үлгәч, Әбүгалисина вазирлектән баш тарта һәм Ираннан китү мөмкинлеген эзли. Вазирлек эшчәнлеге әмир улы тарафыннан галимне крепостька ябу белән тәмамлана. Төрмәдә ул «Китап эшшифа»ның («Шифалану китабы») аерым бүлекләрен язып бетерә.

Әбүгалисинаның крепостьтан чыгуы турында төрле чыганаклар төрлечә сөйли. Галимнең Исфаханда яшәве турында мәгълүматлар бар. Анда, үзе өчен чагыштырмача тыныч шартларда, Әбүгалисина күренекле хезмәтләрен, шул исәптән соңгы хезмәтен — медицина нигезләрен иҗат итә. Гарәп телендә язылган бу гыйльми әсәр биш китаптан тора.

Беренче китап асылда медицинаның гомуми мәсьәләләренә багышланган. Анда бу фәннең бурычлары, сәламәт организм нигезләре, авыруларның килеп чыгу сәбәпләре турында сөйләнелә. Китапта һәр тере нәрсәнең төрле күренешләрдә уттан, һавадан, судан һәм җирдән гыйбарәт булуы күрсәтелә. Шунлыктан аларның тормышы өчен коры, дым, җылы һәм салкын кирәк булуы раслана. Аның фикеренчә, шушы хакыйкать чагыштырмасын бозу авырулар китереп чыгара, әйберләрнең корылык, дымлылык, җылылык һәм салкынлык үзенчәлекләрен өйрәнү дәвалау чорында мөһим роль уйный.

Әбүгалисина кеше организмы табигатенең асылын һәм аның тышкы факторларга йогынтысын анализлый. Кешенең яшенә карап тешләргә характеристика бирә.

Анатомия-физиология мәгълүматларына багышланган бүлектә сөякләрнең һәм буыннарның формалары, нервларның, кан тамырларының үзенчәлекләре, йөрәк эшчәнлеге турында тулы языла. Артерияләрнең йөрәктән башлануы, канның веналар аша бөергә һәм аннан кире агуы күрсәтелә.

Китапта авыруларга һава шартлары һәм елның дүрт фасылы йогынтысы, саф һавада эшләүнең файдасы турында язылган бүлек игътибарга лаек. Организм өчен торак шартлары һәм туклануның әһәмиятенә басым ясала. Шәхси гигиена — мунча керү, ванна кабул итү, кеше организмына кояшның йогынтысы кебек мәсьәләләр дә читтә калмый. Әбүгалисина органнарның формалары үзгәрү — ябыгу һәм симерү сәбәпләренә туктала, пульс эшчәнлеге һәм сидек турында тулы мәгълүматлар китерә.

Галим беренче китапның өченче бүлегендә балалар авырулары турында сөйли. Бу бүлек акушерлык нигезләрен бәян итүдән башлана. Анда яңа туган балаларны карау, аларның гигиенасы, имезү, тукландыру, кулда күтәреп йөрүнең әһәмияте хакында әйтелә. Авыруларны дәвалау үзенчәлекләре турында сүз бара.

Икенче китап ике бүлектән тора, аларда дәвалау әйберләре һәм аларның үзенчәлекләре тасвирлана. Әбүгалисинаның дәвалау арсеналына үсемлекләр, авыр металлар һәм аларның кушылмалары керә.

Өченче китап — күләм ягыннан иң зуры. Анда эчке органнарның авыруы турында мәгълүматлар тупланган.

Дүртенче китапта бизгәк, түберкулез, организмның агулануы, параличлар һәм йогышлы авырулар турында тагълимат чагылыш тапкан.

Бишенче китап дарулар әзерләү алымнарын эченә алган.

Галимнең хезмәтләре медицинаны алга этәрүдә зур роль уйнаган, авторның мәшһүр фикерләре бүгенге көндә дә яшәү көченә ия булып кала.

# ХАЛКЫМ БЕЛӘН БЕРГӘ

*Заһид Хәбибуллинга 70 яшь*

Онытылмаслык бер эпизод хәтеремдә нык саклана: Казан консерваториясе педагогларыннан берәүнең квартирасын эзләп, Гвардейскаядан Толбухин урамына кереп барам. Ике катлы агач йорт алдында яшьрәк кенә ике ир (аларны мин төзелештә эшләүчеләр яки завод кешеләре дип аңладым) җырлап утыра. Музыкага бөтен күңелләрен салып, акрын гына бик ихлас җырлыйлар. Һәр сүзгә мәгънә биреп, моңлы җырлыйлар. Заһид Хәбибуллинның «Казакъ кызы — сөйгәнем» җырының халык арасында шулай барлык куплетлары белән, көйне һич бозмастан, тәгәл, бик музыкаль җырланганын ишеткәнем юк иде. Бу җыр үзенең төзелеше һәм интонацион яңгырашы белән аерата оригиналь. Әлеге яшь эшчеләрнең шул оригинальлекне саклап җырлаулары мине таңга калдырды... Җыр җырланып бетте. Җырчылар, үзара бер сүз дә әйтмичә, уйга талгандай тындылар. Аларның әле һаман да җыр әсирлегендә булуларында минем шигем юк иде...

Әгәр композиторның шагыйрь белән бергә тудырган яңа җырын халык яратып кабул итә икән, шулай ихлас күңелдән, аның үзенчәлеген саклап, бозмыйча җырлый икән — бу авторлар өчен иң зур шатлык. Заһид Хәбибуллин әнә шундый шатлыкны, иҗаттан туган бәхетле минутларны еш кичергән композитор.

Узганнарны искә төшерәм: моннан 45 ел элек Муса Җәлил белән бергә иҗат иткән «Сагыну», «Җырым булсын бүләгем» җырларын да халык бик тиз хуплап күтәреп алган иде. Ул җырларны бүгенге яшьләр, өлкәннәрдән ишетеп, инде халык көе дип җырлыйлар. Шулай, аның җырлары халык күңелендә бик тиз урын алучан булып китте. Бүгенге музыкаль культурабызны инде аның җырларыннан башка күз алдына китерү дә читен. Кемдер моңлана, кадерлесен сагына һәм үзе дә сизмәстән «Сагыну»ны көйли башлый. Дуслар табында очрашканда дәртле җырны — «Казакъ дустыма»ны искә төшерә. «Бормалы су»ны, «Казан кызы»н, горурланып «Кечке Идел»не мактый, «Айлы төн» белән соклана. Аның җырларында сәламәт рухлы якты лирика, үткенлек, тапкырлык, шаяру мул. Җырларының һәммәсе дә тирән гражданлык хисләре белән сугарылган. Аларда илебез кичергән бөек вакыйгаларның эзләре чагыла. Бу урында композиторның Ватан сугышы елларындагы җырларын искә алмый мөмкин түгел. «Команда, алга» (Г. Кутуй сүзләре), «Җиңеп кайт» (К. Нәҗми сүзләре), «Партизан егет» (Н. Арсланов сүзләре), «Дустым, сиңа хатлар язам» (халык сүзләре) җырларында ватандашларыбызның туган илгә чиксез бирелгәнлеге, сугыш кырындагы батырлыгы, тылда калган колхозчы һәм эшче яшьләрнең сугышчыларга кайнар мәхәббәте, турылыклылыгы бик җыйнак һәм сәнгатьчә оста, йөрәккә үтеп кererлек итеп әйтелгән. Радиокомитетның музыкаль редакциясенә сугыш елларында килгән йөзләгән хатларның берсендә: «Заһид Хәбибуллинның «Җиңеп кайт» җырының көендә һәм сүзләрендә минем йөрәгемдә туган сүзләр, минем иң саф, ихлас хисләрем әйтелгән»,— дип язылган иде. Мондый фикерләрне автор үзенең иҗат һәм гомер юлында кабат-кабат ишеткәндер.

Заһид Хәбибуллинның композиторлык иҗаты һаман дәвам итә. Аның ярты гасырга якын гомере җырларга багышланган. Ул — татар совет җырлары хәзинәсенә зур өлеш керткән, җыр жанрында үзен чын остаз итеп таныткан композитор. Күрше тугандаш республикаларның җырчылары, музыкаль коллективлары аның әсәрләре-



*Заһид Хәбибуллин һәм Салих Сәйдәшев (уңда).*

еш башкаралар. Илебезнең киң музыкаль җәмәгатьчелеге Заһид аганы күп милләтле совет музыкасының җыр жанрында актив эшләүче композитор дип хөрмәтли. Әле күптән түгел генә Чабаксарда РСФСР Композиторлар союзының чираттагы пленумы булып узды. Пленум концертларының берсендә Башкортстанның Дәүләт хоры Заһид аганың Нәби Дәүли сүзләренә хор өчен язган «Хатынь» җырын башкарды. Бу җыр композиторга зур уңыш китерде, еллар узган саен аның осталыгы үсә, камилләшә баруны раслады. Композиторның соңгы вакытларда язган җырларында без кабатлануны, инде элек табылган, мәгълүм алымнарны ишетмибез. Үзенә таләпчән олы музыкант актуаль темаларны ала. Аларны художество югарылыгында чын сәнгатьчә итеп гәүдәләндерә. Искә алынган «Хатынь», шул ук шагыйрь Нәби Дәүли шигыренә «Мин Ленинга ышанам», Сибгат Хәким шигыренә «Ветеран ул, ветеран», дигән яңа җырларында интонацион, ритмик яңа элементлар белән очрашабыз. Сибгат Хәким шигыренә язган «Мәмдүдә» исемле лирик җыр-романс (Г. Тукайның әнисенә багышланган җыр) шулай ук музыкаль сурәтләүнең яңа алымнары белән кыйммәтле. Композитор туачак җырның текстына аерата әһәмият бирә, ул тексттагы образны йөрәге белән тойганда гына музыка яза. Шуңадыр, күп шагыйрьләр иҗатына мөрәҗәгать итә,— алар 40 ка якын. Композиторның җырларын күздән кичергәндә без Һади Такташ, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Шәйхи Маннур, Әхмәт Исхак, Муса Җәлил, Нури Арсланов, Сибгат Хәким кебек өлкән шагыйрьләребез һәм алардан соң әдәбият мәйданына аяк баскан Гамир Насрый, Зәки Нури, Мәхмүт Хөсәен белән очрашабыз. Заһид Хәбибуллинның җырлары нинди сыйфатлары белән үзгә соң? Гадәттә, һәр композиторның үзенә генә хас интонацион дөньясы була. Ә менә З. Хәбибуллинның җырлары бер-берсенә һич охшамыйлар. Һәр яңа җырда ниндидер ишетелмәгән яңа яңгыраш була. Бигрәк тә ул ритмикага, аны төрләндерүгә әһәмият бирә. Монда аның хыял байлыгы аерата зур. Интонацион һәм ритмик яктан ул бик тә киң колачлы. Шуңа күрә дә аның җырын беренче тыңлауга «Бу — Хәбибуллин» дип әйтү ансат түгел. Монда җырның нәфислеге, сәнгатьчә эшләнүе белән генә әсәрнең авторын ачыклау мөмкин. Аның иҗатында шаян җырлар, халыкның кыска көйләрен, бию такмакларын иҗади үзләштерүдән, аларны йөрәгеннән уздырып, нәфис эшләнгән, шат, күтәренке, уенчак җырлар өстенлек алалар (әйтик, «Йолдызым», «Казан кызы», «Баулылар», «Яшьлек вальсы» кебек җырлар).

Заһид Вәлиевичның балалар өчен дә бик күп җырлар тудыруын әйтеп узмый мөмкин түгел. Ул Габдулла Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен (Тукай аларны «Энҗе бөртекләре» дип исемли) музыкага салды. Шул нәниләр өчен җырлардан композитор альбом төзи. Моңа өстәп, Заһид Хәбибуллинның беренче милли балалар балетын иҗат итүче булуын да билгеләп китик.

Заһид ага — халыкның музыкаль хәзинәсен яхшы белгән фольклорчы. Ул районнардан ишетеп кайткан байтак халык көйләре бүген концерт программаларында еш җырлана («Өммегөлсем», «Шома бас» һ. б.). Бик күп көйләр өлкән фольклорчыбыз тарафыннан фортепьянога кушылып җырлау, скрипкада уйнау, хор белән җырлау өчен эшләнгәннәр.

Заһид ага — искиткеч талантлы скрипкачы. Аның скрипкада уйнавы — гасырлар буе яшәп килгән халык музыкантларының, бигрәк тә скрипкачыларның, иң гүзәл традицияләрен дәвам иттерә. Халык музыкантлары көйне уйнаганда импровизациядән оста файдаланалар, бер үк көйгә әллә ничә төрле вариантлар, бизәкләр кертәләр. Заһид Хәбибуллин халык иҗатын тирән белү өстенә үзенең композиторларга гына хас осталыгы белән вариацияләрне, импровизацияләрне тиз таба. Татар музыкасында, фольклорчы буларак, тиңсез зур хезмәт калдырган композитор Александр Ключарев фортепьянода, Заһид Хәбибуллин скрипкада татар халык көйләрен шулай импровизация белән уйнап, халык талантларының уйнау алымнарына кабатланмас музыкаль һәйкәл куйдылар. Заһид аганың Александр Ключарев белән бергә уйнаган магнитофон һәм кино тасмалары да бик тә аз булуы гына кызганыч. Бер-берсен шул кадәр дә аңлап, халык моңының бөтен гүзәллеген шул дәрәҗәдә ача белгән халыкчан традицияне саклап уйнаучылар кабатланмас. Алар—соклангыч башкаручылар. Заһид Хәбибуллин бүгенге көндә бу өлкәдә бердәнбер музыкант-башкаручы.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнгән композитор Заһид Хәбибуллинга шушы елның 20 сентябрендә 70 яшь тула. Мин—алар квартирасында. Диңгез хәрби корабльләрендәге кебек искиткеч чисталык. Бер генә артык әйбер юк. Пианино. Өстәл. Китап. Ноталар шкафы. Янддагы бүлмә ишеге ачык. Анда да пөхтәлек. Ишеккә каршы караватта — Фәһимә ханым. Ул каты авыру. Әмма ике йөрәкнең бер-берсен аңлап тибүләре, Заһид Вәлиевичның кайгыртучанлыгы, уен-көлке сүзләр белән берәзлексез авыруның күңелен күтәрергә омтылуы авырудан көчлерәк булыр. Фәһимә ханым аякка басар. Фәһимә ханым — художник. Ул Заһид аганың барлык әсәрләрен — ноталарын матур итеп күчереп язган, аларны матбугатка чыгаруда ярдәм иткән якын дус. Алай гына да түгел, бик күп композиторларыбызның әсәрләрен матбугатка матурлап юллаткан тырыш художник та Фәһимә ханым.

Өчәүләп сөйләшәбез. Заһид аганың якынаеп килгән юбилее уңае белән сүз үзеннән-үзе ул узган иҗат юлына күчә. Заһид ага сорауларга җавапларны бик кыска бирә. Үзе турында сөйләргә яратмый.

Орск балалар йортында тәрбияләнүен, Актүбә шәһәрендә чәйханәдә йомышчы малай булуын, аннан Казанга килүен искә төшерә. Үз заманында Мәскәү консерваториясендә ныклы белем алган, бөек композитор П. И. Чайковский мактавына лаек булган скрипач, дирижер А. А. Литвинова скрипкада уйнау дәресләре ала, профессиональ музыка дөньясына аяк баса. Озакламый Салих Сәйдәшев җитәкчелегендәге симфоник оркестрда уйный башлый. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт драма театры оркестрында уйнау һәм җырчы-артист Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Асия Измайлова, Сара Садыйкова, талантлы скрипач Хәсән Гобәйдуллин, гобойчы Шиһап Рәхимов кебек музыкантлар белән очрашу, дуслашулар аның өчен тормыш һәм иҗат мәктәбе була.

Олы музыкант 1934—1938 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы татар Опера студиясендә укуын, күренекле совет композиторы, профессор М. Ф. Гнесин һәм профессор Г. И. Литинскийны рәхмәт сүзләре белән искә ала.

«Укытучым М. Ф. Гнесинның дәресләре һич онытылмаслар. Мин бүген дә аның васыятьләрен үтим. «Иҗатыңда халык моңнарына таян. Халыкның музыкаль хәзинәсе белән М. И. Глинка, И. А. Римский-Корсаков, П. И. Чайковскийлардан үрнәк алып эш ит», дигән сүзләрен иҗатымда чагылдырырга омтылам... Иҗатымның таңында менә

ягымлы каршы алган, җырларымны беренче башлап җырлаган, Мәскәүдә бергә укыган җырчылар — сәнгатебезнең хөрмәтле артистларына — Усман Әлмиев, Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатова, Халидә Зәбировага баш иеп рәхмәт дим. Арабыздан иртә киткән Шәфика Котдусова, скрипач Каюм Байбуровның якты истәлекләре алдында баш иям»,— дип сөйләде ул әлеге очрашу вакытында.

Заһид аганың халкыбызны музыкаль-эстетик тәрбияләүгә керткән өлеше очсызкырыйсыз. Республикада ул аяк басмаган бер авыл, бер эшче поселогы да юктыр, аның ярдәме тимәгән үзешчән сәнгать коллективлары да сирәктер... Бөек Ватан сугышы елларында Заһид аганың скрипка тотып көн саен диярлек госпитальләргә баруын, яралы сугышчылар алдында концертлар бирүен, Татарстан авылларында музыкаль кичәләр уздырып, колхозчыларны җиңүгә рухландыруын да аерым билгеләп узмый мөмкин түгел.

«Әйе, мин музыкам белән кешеләрнең күңелен күтәрергә, аларны рухландырырга телим. Җырларым яки скрипка өчен әсәрләремне тыңлаганда тамашачының йөзендә шатлыклы елмаю, канәгатьләнү күрәм икән — бу минем өчен зур бәхет»,— ди Заһид ага. Бераз сүзсез торганнан соң, эшчәнлегенә йомгак ясагандай, ике сүзне кабатлый:

— Мин гел халкым белән бергә, гел бергә!

Күп кырлы иҗаты булган олы композиторны 70 яшь тулуы белән ихлас күңелдән котлыйбыз, нык сәламәтлек телибез! Аңа гына хас юмор, тормышны сөю, күңел хөрлеге, күтәренкелек озак еллар дәвам итсен!

Зәйнәп ХӘЙРУЛЛИНА.

# КҮҢЕЛДӘГЕ МОҢ ЧИШМӘСЕ

*Исмай Шәмсетдиновка 70 яшь*

Исмай аганың тормыш һәм иҗат юлына әйләнеп карасаң, күңелдә хөрмәт хисләре уяна. Чынлап та, армый-талмый халыкка хезмәт итүе белән ул безнең яраткан композиторыбызга әверелде. Исмай аганың исеме республикабызда гына түгел, башка өлкәләрдә яшәгән музыка сөючеләргә дә таныш һәм кадерле. Композитор тарафыннан йөзгә якын популяр җыр, вокаль ансамбль һәм хор коллективлары өчен музыкаль әсәрләр язылган. Халык җырларын җыеп һәм эшкәртеп тамашачы-тыңлаучыларга җиткерүдә дә Исмай аганың өлеше шактый зур. Музыкантларыбыз аның камера-инструменталь һәм эстрада әсәрләренә еш мөрәҗәгать итәләр. Балалар концертларында да композиторның җырлары туктаусыз яңгырый. Күренекле җырчыларыбыз исә аның җырлары аша тамашачылар белән уртак тел таба.

Кеше буларак, Исмай аганы һәрвакыт ихтирам белән телгә алалар. Әйе, намуслылыгы һәм эчкерсезлеге аның шәхесен яктыртып тора. Бу сыйфаты аңа Татарстан Министрлар Советының телевидение һәм радиотапшырулар комитетында башта — редактор, аннары Бөтенсоюз беренче категорияле тавыш режиссеры булып эшләргә нык ярдәм иткәндер, дип уйлыйм. Исмай аганың радиокомитетта эшләү дәверен аеруча билгеләп үтәсе килә. 1952 елдан алып 1970 елга кадәр Исмай Шамсетдинов бирегә музыка, театр һәм нәфис сүз сәнгатенең алтын фондына кергән күп кенә язмалар әзерләп калдырды. Алар арасында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры тамашалары, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган опералар, М. Булатова, З. Хисмәтуллина, Ф. Насретдинов, Р. Билялова, И. Шакиров, Ә. Афзалова, Ә. Заһидуллина, Э. Җәләлетдинов кебек танылган артистларыбыз башкарган җыр язмалары бар.

Исмай ага студиядә эшләү белән бергә әледән-әле район үзешчәннәренә дә ярдәм кулы сузды, махсус командировкалар оештырып, аларга профессиональ музыка



*Исмай Шәмсетдинов (сулда) һәм Хөснул Вәлиуллин*

серләрен аңлатты, зур сәнгать дөньясына чыгарга булышты. Үз эшенә бирелгәнлек, музыкага мәхәббәт, бурычын намус белән үтәү, мәгаен, композитор күңеленә бала чактан ук салына килгәндер.

Исмай Гайнетдин улы Шәмсетдинов 1910 елның 16 (29) сентябрендә Төньяк Уралда, Надеждинск заводы (хәзер Свердловск өлкәсендәге Серов шәһәре) эшче гаиләсендә дөньяга килә. Бала чагында татар һәм рус мәктәпләрендә белем ала. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, заводта эшли башлый.

Әле укырга кергәнче үк кечкенә Исмай әнисенең курайда «Әллүки», «Салкын чишмә», «Зиләйлүк», «Туган тел» кебек халык көйләре уйнавын яратып тыңлый. Гаиләдәге һәр кеше нинди дә булса уен коралында уйный белә. Басыйр абыйсы — скрипкада, Галәф абыйсы — мандолинада... Апалары Марзия белән Халисә икәүләшеп җырлыйлар. Кайбер дин әһелләренә бу хәл ошамый, билгеле.

— Шайтан коткысы! — ди алар. — Мәчеткә килеп тәүбә итмәсә, нәселе корыячак әле Гайнетдиннның,— диләр. Гайнетдин абзый дин әһелләренең сүзенә колак та салмый. Киресенчә, үзе үк улларын чакырып китерә дә:

— Уйнагыз әле берәр моңлырак көй. Туган яклар — Апас яклары искә төшәрлек булсын! — ди.

Малайлар исә ялындырып тормыйлар. Әтиләренең граммофон сатып алуы аларны тагын да дәртләндереп җибәрә. Гаиләгә кадерлерәк кунак килсә, граммофонны иң элек кечкенә Исмай уйнатырга керешә. Гайнетдин абзый кунакларга көлә-көлә сөйли:

— Абыйлары скрипкада, мандолинада уйный белә, ә менә Исмай бик оста итеп граммофонда сыздыра...

Әлбәттә, оялта бу сүзләр. Әмма үпкәләми ул. Уен коралларында уйнарга өйрәнер әле, ашыкмаска кирәк.

Чынлап та, сүзендә торды малай. Көннәрнең берендә Басыйр абыйсы аны клубка алып барды.

— Яшьләр союзы йортына сугылып чыгыйк әле. Анда пианино бар. Уйнарга өйрәнерсең, бәлки,— диде Басыйр абыйсы.

Ике-өч ай узамы-юкмы, ул инде пианинода уйнап көй өйрәнә.

1929 елны Гайнетдин абзый гаиләсе белән Казанга күченеп килә. Музыкага һәвәслеге егеткә һич кенә дә тынгылык бирми. Һәм ул Казан музыка училищесына керергә омтылыш ясап карый. Ләкин уңышсызлыкка очрый. Исмай Шәмсетдинов башта ТАССР Халык комиссариатында эшли, аннары шофер һөнәрен үзләштерә. Аның хезмәт биографиясенә Бөтенсоюз «Союзтранс» берләшмәсендә шофер булып эшләве дә өстәлә.

Егет музыкадан аерылмый. Машинасында йөзләгән чакрым юллар әйләнеп кайткач, төрле клубларга йөри, үзешчән сәнгатьтә катнаша. Ниһаять, түзми, ул, әтисенең танышыннан иске рояль сатып ала. Хәзер инде үзенә дә көйләр чыгарып карарга мөмкинлек ачыла. Рояль клавишларында бармакларын йөгертә торгач, өр-яңа көй колагына чалына егетнең. Күңелгә дәрт өстәрлек көй була бу. Яшь музыкант аңа «Студентлар маршы» дип исем кушарга карар кыла.

Күршедә яшәүче музыкант Хәмит ага Әбүбәкеров та Исмайның сәләтен тиз искәреп ала һәм аңа музыка училищесына керергә тәкъдим итә.

— Читенсенмә син,— ди Хәмит ага.— Колакка ятышлы көй бу. Музыка училищесында укырга кирәк сиңа, энем. Әрәм итмә сәләтеңне. Юрий Виноградов кул астына эләксәң, тагын да шәп булыр.

Музыка училищесына имтихансыз алалар Исмай Шәмсетдиновны. 1936 елның 20 ноябре егетнең күңеленә шатлыклы көн буларак, гомергә онытылмаслык көн буларак уелып кала. Шушы көннән башлап ул Казан музыка училищесының композиторлар бүлегендә укый башлый. Юрий Васильевич Виноградовтан музыка серләрен өйрәнә, үзе дә музыкаль әсәрләр иҗат итүгә керешә. «Студентлар маршы» халык арасында тиз тарала. Ләкин киләчәктә мондый популяр җырлар язар өчен Исмайга нота грамотасын, профессиональ музыка нигезләрен үзләштерергә кирәк була. Тырышып уку, йокысыз үткән төннәр үзенең уңай нәтиҗәсен бирә: музыка училищесын тәмамлаганда аның инде иллегә якын музыкаль әсәре дөньяга килә. Алар арасында байтак жанрларны очратырга мөмкин: романс һәм төрле эчтәлектәге җырлар, хор коллективлары һәм балалар өчен махсус язылган җырлар, инструменталь әсәрләр.

Шул чор иҗатының матур үрнәге итеп «Сандугачкай» дигән вокаль дуэтны да санарга кирәктер. Музыка училищесын тәмамлаганда яшь композитор тарафыннан тынлы уен кораллары квартеты өчен Беренче сюита иҗат ителә. Әлеге сюита өч кисәктән тора: «Җәйге иртә. Скерцо. Эш көненнән соң». Болар һәрберсе табигатьнең матурлыгын якты һәм нәфис төсләр аша сурәтли, биредә татар халкының тормышкөнкүреше, эш сөючәнлеге һәм күңелле бәйрәмнәре чагылыш таба.

Хезмәт тәҗрибәсе туплаган егеткә музыка училищесы яңа дөнья ача: ул инде киләчәктә язылачак музыкаль әсәрләре өчен биредә күч һәм белем туплый.

Ләкин Бөек Ватан сугышы яшь композиторның хыялларын тормышка ашырырга ирек бирми. Исмай Шәмсетдинов, илебезнең батыр уллары һәм кызлары белән бергә, Ватан иреген сакларга фронтка китә. Великие Луки янында барган сугышларда каты яралана һәм госпитальдә дәвалана. Аннары яңадан көрәшчеләр сафына баса. Санитарлар машинасында меңләгән чакрым юллар үтә. Балтик буе республикаларын, Варшаваны азат итүдә, Одер елгасын кичүдә һәм Берлинны алуда катнашырга туры килә аңа. «Батырлык өчен» һәм башка сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

И. Шәмсетдиновның Бөек Ватан сугышыннан соң язган «Ана» (Муса Җәлил шигыре), «Азат ил» (Нур Баян), маршны хәтерләткән «Поход җыры» (Хәй Вахит) һ. б. җырлары, «Ана — бөек исем» (Һади Такташ), «Онытылмассың, Тукай» (М. Вилданов) кебек романслар композиторлар иҗатында гына түгел, татар музыка сәнгатендә дә яңалыкка бер адым була.

Бөек Ватан сугышыннан соң Исмай Шәмсетдинов, музыкаль белемен тирәнәйтү нияте белән, Казан дәүләт консерваториясенең композиторлар факультетына укырга керә.

Югары уку йортындагы остазлары А. С. Леман (композиция буенча), Н. Г. Җиһанов (оркестровка), Г. И. Летинский (полифония) композиторның мөмкинлекләреннән чыгып, аңа үсү юнәлешен күрсәтәләр.

Консерваториядә уку дәверендә И. Шәмсетдинов иҗатында яңа чор башлана. Агачтан эшләнгән тынлы уен кораллары квартеты өчен алты кисәкле икенче сюита

дөньяга килә: «Егет һәм кыз. Бишек җыры. Җәйге урман. Кыз биюе. Аппакай. Бәйрәм иртәсе». Шулай ук фортепьяно өчен сонатино, кыллы уен кораллары өчен квартет та консерваториядә укыган чорда языла. Төрле жанрларга һәм камера-инструменталь әсәрләргә мөрәҗәгать итү композитор иҗатында традициягә әйләнә. Бу әсәрләрендә ул еш кына халык көйләре һәм халык җырларына якын торган үз темаларын куллана. Квартетның эчтәлеге — сугыш турында сөйләү һәм совет солдатының батырлыгын, җиңү шатлыгын тасвирлау.

Композитор балаларны да онытмый. Мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына йөри, нәниләрнең күңел дөньясын өйрәнә. Ниһаять, кечкенәләргә багышланган егермеләп җыр барлыкка килә. Татар совет музыка сәнгатендә беренчеләрдән булып «Пионер кантатасы» (Әхмәт Ерикәй шигыре) туа.

Исмай Шәмсетдинов халык җырларын җыю һәм эшкәртү белән дә шөгыльләнә. «Аппакай, алмакай», «Гөлҗамал», «Умырзая», «Ком бураны», «Көзге ачы җилләрдә», «Көрәш җыры», «Таң атканда» (С. Хәким), «Туган тел» (Г. Тукай) һ. б. шундый җырлар Исмай ага эшкәртүендә өр-яңа яңгыраш тапты. Композиторның авылларда йөреп йөздән артык халык җырын магнитофон тасмасына яздыруын да зур эш дип бәяләргә кирәк.

Җитмеш яшь. Шушы гомердә ул ике йөз музыкаль әсәр иҗат иткән. Әлеге әсәрләрнең сан ягы гына түгел, сыйфат ягы да сокландыра. «Урал тауга менсәң» (А. Сәләхетдинов), «Аналар әгәр берләшсә» (М. Садри), «Язлар җитсә» (Л. Айтуганов), «Биләр яшьләре җыры» (А. Әхмәтов), «Йөр син безнең урамнарда» (З. Вәли), «Дуслык — Чаллыда» (Р. Харис) кебек җырларның һаман да радиотапшыруларда һәм сәхнәләрдә яңгыравы композиторның халыкчан уңышлары турында сөйли.

Исмай ага киләчәктә дә музыка белән бергә яшәр. Без аңа мактаулы һәм изге эшендә зур уңышлар телик. Яраткан композиторыбызның күңелендәге моң чишмәсе кимемәсен иде.

Фәридә ШӘМСЕТДИНОВА.

# МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

*Журналыбызның 1976 елгы сигезенче санында без «мәсәлчеләр мәҗлесе» үткәрә башлаган идек. Шуннан бирле дөньяның төрле илләре, илебезнең төрле милләт әдипләре әледән-әле бездә кунакта булдылар. Алар иҗатыннан сайлап алып татарчага тәрҗемә ителгән, уйлавыбызча, иң яхшы һәм эшләнешләре белән үзенчәлекле мәсәл үрнәкләре басылды. Дөнья әдәбиятында иң борынгы жанрларның берсе булганга, бу жанрның чордан-чорга яңара барып үсеше аңа нигез салучы Эзоп иҗатыннан ук башлап күзәтелде, аның теориясе һәм практикасына кагылышлы мәгълүматлар, әлбәттә, бик җыйнак күләмгә сыешлы иттереп, шактый күп очракларда бирелде.*

*Журнал билгеле бер план һәм система белән даими алып бара торган оештыруы бу иҗади эшкә йомгак ясау тәртибендә бүген урын туган әдәбиятыбызның кайбер мәсәлләренә бирелә. Киләчәктә исә юмор һәм сатира осталарыбыз аларны тагын да күбрәк һәм яхшырак язарлар дип ышанырга кирәк.*

**ЗӘКИ НУРИ.**

## *Габдулла Тукай*

## БАСКЫЧ

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар — бик авыр һәм дә озын баскыч.

Кирәклектә бәрабәр булсалар да басмалар бергә,
Югары басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә.

Югары басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, ди,
Ничек гали минем урным, түбәнгеләр, күрәмсез?» — ди.

Бер адәм килде дә шул чакта, әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югарысы — түбән төште.

*1910*

## *Мәҗит Гафури*

## ИКЕ ЧЕБЕН

Бер үгез көн буенча сөреп сабан,
Авылга кайтып килә кичкә табан.
Үгезнең мөгезенә кунып килгән
Бер Чебенгә бер танышы очраган.

Таныйшы шул вакытта моны күрде —
Килә бу сабан сөргән үгез белән.
«Күземә күренмәдең көн буенча,
Кайдан кайтып киләсең син?» — дип сораган.

Теге Чебен, эреләнеп, моңа карап,
Зурланып, тамак кырып, бирде җавап:
«Көн буе сабан сөреп, арып киләм,
Вакытсыз йөрмә әле бимазалап!»

Сөйләшсәң Чебен төсле кеше белән,
Мактаныр эшләмәгән эше белән.
Көн күргән кешеләр күп бу дөньяда,
Чебен кебек, башкаларның көче белән.

*1911*

*Әхмәт Исхак*

## ЯЛАГАЙ ҺӘМ БЮРОКРАТ

Чыкмасмы, — дип, берәр файдалы эш,
Пешереп бик зур бәлеш,
Чакырып үзенә кунакка,
Язу җибәрде Ялагай
Бер Бюрократка.

Бюрократ,
Күз дә салмыйча аның хатына,
Берәр гаризадыр, дип уйлап,
Салып куйды сукно астына:
Ялагай аны бик озак көтте —
Бер көн дә үтте,
Ике көн дә үтте,
Бәлеш тә катып бетте.

* * *

Бу мәсәлдән моральне
Эзләп тә торма хәтта:
Нинди мораль булсын соң
Ялагай белән Бюрократта?

*Габдулла Шамуков*

## ДУҢГЫЗ

Бер чучкага, чыгып туган илдән,
Бар дөньяны әйләнергә туры килгән

Күреп йөргән ансын-монсын,
Бик күп илнең башкаласын.
Байтак вакыт үтеп киткән:
Чучка тәмам буйга җиткән,
Үсеп, юанаеп, тулып,
Туган илгә кайткан... Дуңгыз булып.
Үз илендә ошамый бернәрсә моңа,
Кырын карый ансына-монсына,
Мыркылдый бу фәкать чит ил турысында...—
Аерылгысыз чит илдәге Дуңгызлардан.

...Телгә алып,
Мәсәл язып
Көлүе дә җирәнгеч бит мондыйлардан!

*Гамил Афзал*

## БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘР...

Агымдагы оператив эшләр беткәч,
Аю иптәш, Бүре иптәш, Төлке иптәш
Чыктылар бер җилләнергә һава сулап,
Объектлар карый-карый урман буйлап.

Аю әйтә: — Баш авырта, арыткан, ди.
Бүре әйтә: — Ничек карар Арыслан, ди...
Кыюланып Төлке әйтә шул урында:
— Ничек булыр чамаласаң өч борынга?

Аю, Бүре елмайдылар сүзсез генә.
Хәлне аңлап Төлке иптәш тиз-тиз генә
Шап иттерде бер Куянны колагыннан.
— Менә, диде, шушы дурак тәртип бозган!

Өзеп кенә каптылар да берәр кисәк,
Сөйләшергә тотындылар җиңне искә:
— Ягъни, дуслар, безнең аппаратка килсәк,
Штатны кыскартырга иде исәп.

— Куянетдин булдыксыз һәм ахмак иде,
Коты качкан ике күзе шакмак иде,
Андый куркак урманнарда сирәк иде...
Некролог әтмәлләргә кирәк инде.
Каерып алган каен тузы кайгы тойды:
«Бүген иртән Куян иптәш дөнья куйды,
Куян иптәш иртә китте арабыздан —
Моң-зар ага йөрәктәге ярабыздан.

Куян иптәш сизгер иде, тыйнак иде,
Ул һәр җирдә көтеп алган кунак иде,
Урлашмады, тайпылмады уңга-сулга,
Принципиаль чаба иде туры юлда.

Образы урманга нур чәчәр, диеп,
Күңелләрдә мәңге-мәңге яшәр, диеп,
Күзләребез мөлдерәмә яшьләр, диеп,
Кул куйдылар,
Бер төркем иптәшләр» диеп.

*Зәки Нури*

## БЕР ҖЫЕЛЫШТА

...Вакыт җитте карар кабул итәргә.

Төлке әйтә: «Рөхсәт сорыйм китәргә?» —
Яслегә ул йөртә, имеш, баласын,
Ничек аны соңга калып аласың?!
Аю исә, имеш, салмак селкенеп,
Күзе белән ашар була Төлкене.
Ә аннары әкрен генә тора ул,
Юлын ишек тарафына бора ул.
Залның кинәт шаулашуын күрүгә,
Кузгалырга вакыт җитә Бүрегә:
— Эшем көтә — көтү кайтыр чак җитә,—
Дип китә ул. Ишек тагын шап итә.
Кул күтәреп хәтта сорау бирмәгән
Куян, имеш, эсселәгән-тирләгән:
— Кердәм, — диеп, — өсне салып куям да... —
Ычкынырга хәйлә таба Куян да.
Залда кала Керпедер дә Көзәндер,
Белмим, Бурсык качмый ничек түзгәндер?!
Һәм уйлый зал: «Кара нинди шомалар,
Кара ничек оста итеп шылалар!
Зарландылар, имеш, тәнкыйть иттеләр,
Эшкә дигәч, ләммим дими киттеләр».
Эз җуйганда тиз-тиз атлап үзләре,
Ишетелеп калды әйткән сүзләре:
— Ә карарны... кемгә кирәк, шул карар!..

...Арсланга каршы иде ул карар.

## БӘП-БӘЛӘКӘЙ МӘСӘЛЛӘР

### БЕР БҮРЕНЕ ИШӘК... ЭШКӘ АЛА

— «Көтүче булыйм!» дисең алайса?..
Очына чыга алырсың микән?
— Әлбәттә, чыгам! Менә хәзер үк
Моннан туп-туры көтүгә китәм!

### ЯҢА ФЕРМАДА

Якты бина. Бетон идән. Җылы.
Су кирәксә — кран борасың...
Уйлый-Чучка: «Нигә сазлыгы юк?
Ә пычраксыз ничек торасың?!»

### ЧЕБЕННЕҢ ИСЕ КИТӘ

— Күп өйдә булып
күп кеше күрдем,
Ник бар да сәер
кешеләр икән:
Үзләре бары идән таптагач
Ни өчен түшәм
түшиләр икән?

### БЕРӘҮГӘ БӘЛА, БЕРӘҮГӘ КӨЛКЕ

«Фермада бүген ачык ишекләр
Көне!» дип хәбәр тарата Төлке.
Һәм Бүре шунда ашыгып чаба.
Барып җитүгә... Капкынга каба.

### КАЛАЧ ҺӘМ СОХАРИ

— Ник мин Калач: хәтта күзе начар
Күргәннәр дә мине шәйлиләр?..
— Белмәсәң, бел — бөтенесе сине
Йомшаклыгың өчен чәйниләр.

### БҮТӘН ҖЫРЫ ЮК

Йомыркасы кыза табада.
Тавык әле һаман кыткаклый...

Үзен-үзе, димәк, мактаудан
Бүтән җыр һәм яңа көй тапмый.

### БАРЫ ТИК МОРАЛЬ

...Ә моның бары морален укыйк,
Тыңлагыз, менә ничек ди мәсәл:
Туфрагын казып алган баздан да
Фәкыйрьрәк булыр җирдә ни нәрсә?

*Абдулла Сәләхетдинов*

## ИКЕ ИМӘН АРАСЫ

Яз җиткәч, кар киткәч,
Аю кышкы йокыдан торган.
Урманда иләс-миләс йөргәндә,
Бер Куян күргән дә аны
авызын ерган:
—И-и, кыш буе гырлаган —
Йокысы туймаган.
Күзең һаман ачылмый,
Йөнтәс йокы капчыгы!..

Куян такмагын ишеткән
Аю аңа үчеккән,
Артыннан куа киткән:
— Ах сине, чабата колак!
Китә алмассың ерак:
Барыбер тотам — колагыңны ертам!..

Урман-чытырман аша,
Тирән чокырлар аша
чаба-чаба алга,
Килеп чыга болар бер аланга.
Ә анда Куш имән
Ике каусә булып үскән.
Шулар арасыннан — ялт! —
Куян сикереп үткән.

Аю да аның артыннан
Туп ядрәседәй атылган,
берни чамалап тормаган.
Күрәселәре бар икән —
Ике Имән арасы тар икән:
Башы сыйган, гәүдәсе сыймаган...
Кыскасы, Куян шылган, Аю кысылган.

* * *

Кыйссаның шулдыр морале:
Аюны күз алдына китер дә,
чамала чаманы —
Үзең сыймас җиргә сикермә!

*Сәлим Шәйдуллин*

## ИКЕ КАРАНДАШ

Бер үк өйдә хезмәт иткән
Ике карандашның берсе — музейга,
Икенчесе чүп кәрҗиненә эләккән.
Соңгысы шунда ук куптарган гауга:
— Ничек түзеп тормак кирәк бу алдауга?!
Юна-юна
Калуга да карамастан очы гына,
Гап-гади бер Карандашны,
Ягъни минем замандашны,
Олылап бик,
Музейга куйдылар... һәм ник?!
Ә мин менә, төсле Карандаш булсам да,
Эләктем ошбу чуманга!
Кая хаклык? Кая гаделлек?

— Шау-шу кузгатканчы, элек
Сөйләргә кирәк аерманы белеп!—
Дигән аңа шул чак Акбур,—
Бит замандашыңның хөрмәткә хакы зур:
Аның белән — гаять мөһим булган
Бөек әсәрләр язылган.
Шулар белән сокландырды ул галәмне!
Шуңа аны чорның иң булдыклы каләме
Дисәк тә, булмас артык.
Ә син, үскәнем,
Гомер үткәрдең...
Бер игелексезнең кашын каралтып!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## БӘЙРӘМ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Республикада Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 60 еллыгына багышланган тантаналар үткәрелде. Татарстан башкаласына бу истәлекле вакыйганы тантаналы төстә билгеләп үтү өчен күрше автономияле республикалар һәм өлкәләрдән кунаклар җыелды.

17 июньдә Казанда Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнар Монументына, Татарстан Автономияле Республикасы төзү турындагы Декретка кул куючы В. И. Ленин һәйкәленә чәчәкләр куелды. Чәчәкләрне КПСС өлкә комитеты бюросы, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Татарстан АССР Министрлар Советы исеменнән, шулай ук Башкортстан, Мари, Мордовия, Чувашия, Удмуртия Автономияле Совет Социалистик Республикалары, Куйбышев, Киров, Оренбург, Ульяновск өлкәләре, Идел буе хәрби округы исеменнән куйдылар.

Республикабызга килгән кунаклар Дуслык аллеясына агачлар утырттылар.

## РСФСР КИТАПЛАРЫ

Казанда Совет Армиясе офицерлары йортында, Татарстан АССР төзелүнең 60 еллыгына багышлап «РСФСР нәшриятлары китаплары» күргәзмәсе ачылды. Аны нәшриятлар, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре буенча РСФСР һәм ТАССР дәүләт комитетлары оештырды. Күргәзмәгә куелган ике меңгә якын китап РСФСРның барлык 55 нәшриятында басылган.

Күргәзмә «60 ел В. И. Ленин күрсәткән юлдан» дигән девиз астында үтә.

## ЮБИЛЕЙ ХӨРМӘТЕНӘ

Татарстан Художниклар союзының күргәзмә залында ТАССР төзелүгә 60 ел тулуга багышланган республика сынлы сәнгать күргәзмәсе ачылды. Бу күргәзмәдә ике йөздән артык художникның егерменче еллардан алып бүгенге көнгә кадәр иҗат ителгән иң яхшы әсәрләре тупланган. Экспозициянең төп эчтәлеген Ленин, революция, Бөек Ватан сугышы, эшчеләр сыйныфы һәм колхозчы крестьяннар тормышы, бүгенге бәхетле чынбарлыгыбыз турындагы тематикалар тәшкил итә.

Күргәзмәне ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев ачты. Күргәзмәне ачу тантанасына җыелган Казан җәмәгатьчелеге вәкилләре алдында күргәзмә комитеты председателе ТАССР культура министры урынбасары Р. М. Харисов һәм СССР Художество академиясе членкорреспонденты, СССРның халык художнигы, СССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреаты Х. А. Якупов чыгыш ясады.

Күргәзмә шушы елның сентябренә кадәр эшли.

## ЯҢА КВАРТЕТ

Быел сентябрь аенда Казан дәүләт консерваториясенә 35 ел тула. Шул уңайдан консерватория укытучыларыннан кыллы квартет оештырылды. Дүрт кешедән торган бу ансамбль составына музыкантлар Шамил Монасыйпов (I скрипка), Марат Зарипов (II скрипка), Камил Монасыйпов (альт) һәм Альберт Асадуллин (виолончель) керде.

Квартетның беренче чыгышы Казанда Татарстанның юбилей көннәрендә булды. Концерт вакытында Гайдн, Рахманинов, Шостакович һәм Р. Еникеев әсәрләре башкарылды. Концерт алдыннан композитор, профессор А. Б. Луппов чыгыш ясады. Ул квартетның әһәмияте, алдында торган бурычлары турында сөйләде, квартетның сәләтле музыкантлардан торганлыгын, концерт программасының оста төзелүен әйтеп үтте.

Беренче концерт уңышлы үтте. Ренат Еникеев әсәрен тыңлаучылар аеруча җылы каршыладылар.

## ЯҢА ФИЛЬМ

Казан кинохроника студиясе коллективы Татарстанның 60 еллыгын каршылау өчен күп көч куйды. Шундый иҗат җимешләренең берсе буларак, экраннарга «Сабан туена юл» дип исемләнгән тулы метражлы документаль фильм чыкты. Аның премьерасы «Татарстан» кинотеатрында булды.

Сценарий авторы Р. Харис, режиссер Н. Вәлитов, оператор А. Привин, композитор А. Монасыйпов һәм башка бик күпләрнең уртак тырышлыгы белән иҗат ителгән бу фильм, татар халкының традицион бәйрәме булган Сабан туе белән бик оста бәйләп республикабызның үткәне, бүгенге казанышлары турында дулкынландырырлык итеп сөйли.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

ТАССР Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында татар һәм башкорт әдәбиятлары классигы Мәҗит Гафуриның тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды.

Конференцияне СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Татарстан Язучылар союзы оештырды. Анда Уфа, Казан һәм Алабуга шәһәрләреннең галим-әдәбият белгечләре катнашты.

Юбилей конференциясендә катнашучылар язучының иҗатын өйрәнүнең актуаль проблемаларын, хәзерге заман әдәбиятын үстерүдә аның урыны һәм роле турындагы мәсьәләләрне карадылар, текстологик тикшеренүләр тәҗрибәсе белән уртаклаштылар, мәктәп балаларына тәрбия бирүдә М. Гафуриның педагогик мирасын куллану турындагы чыгышларны тыңладылар.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Чаллы шәһәрендә Әлмәт театрының декадасы булып узды. Декадникта язучылар Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Р. Хәмид, Р. Батулла, тәнкыйтьчеләр һәм театр белгечләре И. Илялова, Д. Гыймранова, И. Гатова катнаштылар.

Чаллы тамашачылары Ф. Бурнашның «Таһир — Зөһрә»сен, А. Гыйләҗевнең «Әгәр бик сагынсаң», Ю. Сафиуллинның «Мене без дә үсеп җиттек», Р. Хәмиднең «Иске йорт кешеләре» спектакльләрен яратып кабул иттеләр. Декада барышында фикер алышулар булды.

* * *

Шагыйрь Равил Фәйзуллин Чебоксар шәһәрендә чуваш әдәбияты классигы Константин Ивановның тууына 90 ел тулуга багышланган тантанада катнашты һәм чыгыш ясады. Соңыннан ул бу тантанага килгән тугандаш халык әдәбиятлары вәкилләре белән бергә шәһәрнең хезмәт коллективларында булды, татар әдәбияты турында сөйләде.

* * *

Арча районында чыга торган «Коммунизмга» газетасы каршында «Тукай якташы» исемле әдәби-иҗат түгәрәге эшләп килә. Түгәрәк җитәкчесе — газетаның җаваплы секретаре Радик Фәизов яшьләр белән эшләргә вакытын кызганмый. Газетада айга берничә тапкыр әдәби-иҗат түгәрәге члennарының яңа әсәрләреннән әдәби сәхифә оештырыла.

Түгәрәк членнары чираттагы утырышларын Яңа Кырлайдагы Г. Тукай мемориал-музеенда үткәрделәр.

Аннары түгәрәк членнары музей залында үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, фикер алыштылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

* * *

Оренбург шәһәренең «Россия» культура сараенда «Чулпан» исемле яңа эстрада коллективы оештырылды. Коллективның яшь музыкант Таһир Абдрашин җитәкли. Бирелә эстрада коллективыннан тыш әдәби түгәрәк тә эшләп килә. Төрле тематик кичәләр үткәрелә. Соңгы айларда, мәсәлән, культура сараенда өлкәнең татар-башкорт укытучылары җыйналды. Аларга Татарстан язучыларының IX съезды материаллары буенча хәзерге татар әдәбиятының үсеше турында докладлар сөйләнде. Бирелә шулай ук Нәкый Исәнбәтнең 80 еллыгына багышланган әдәби кичә дә уздырылды.

Боларны безгә Оренбургтан журналыбызның актив пропагандисты, яшь язучы Зиннур Шакиров хәбәр итә.

## ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР КИҢӘШӘ

Май аеның икенче яртысында Чувашия башкаласы Чебоксарда язучы-тәрҗемәчеләрнең 2 нче Бөтенроссия киңәшмәсе булып узды.

Киңәшмәнең төп максаты — СССР халыклары телләреннән тәрҗемә итү практикасында очрый торган кыен мәсьәләләрне хәл итү, киңәшү, иҗат тәҗрибәсе белән уртаклашу иде. Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр тәрҗемәчеләр өчен актуаль булганлыктан, семинарлар беренче көннән үк кызыклы бәхәсләр белән башланып китте.

Семинарларга Мәскәү әдипләре Семен Шуртаков, Николай Ершов, Равил Бухараев, Марк Белавин, Роберт Винонен җитәкчелек итте.

Киңәшмәдә илебезнең төрле төбәкләреннән җыйналган язучылар һәм тәрҗемә осталары, шул исәптән Паслей Самык (Таулы Алтай), Гунга Чимитов (Бурят АССР), Семен Руфов (Якутия), Иоганнес Хидман һәм Рая-Лиза Пелля (Карелия), Әсхәл Әхмәтхуҗин һәм Дим Дәминов (Башкортстан), Виктор Гадаев (Мордовия), Зоя Романова һәм Николай Стуриков (Чувашия), Иван Минтяк (Чечен-Ингуш АССР) катнаштылар.

Татарстаннан киңәшмәгә яшь язучы һәм тәрҗемәче Солтан Шәмси килгән иде.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Мәскәүнең «Художественная литература» нәшриятында (1980 ел) В. И. Ленинның 110 еллык юбилеена багышлап «В. И. Ленин в поэзии народов СССР» дигән китап басылып чыкты. Китапка күп милләтле совет әдәбияты вәкилләренең шигырьләре тупланган.

Җыентыкка Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең «Ленинчылар» (В. Торопыгин тәрҗемәсендә), Һади Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасыннан өзек (Л. Мартынов тәрҗемәсендә), Сибгат Хәкимнең «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» (Я. Смеляков тәрҗемәсендә) кергән.

* * *

1979 елда Мәскәүнең «Изобразительное искусство» нәшриятында «История искусства народов СССР» дигән китапның чираттагы 5 нче томы чыкты (9 томда). Бу том СССР халыкларының XIX гасырның беренче яртысындагы сәнгатенә һәм архитекту

расына багышланган. Китапта сүз Казан татарларының йортлар бизәүгә, читек каю һәм ювелир әйберләр ясау эшенә оста булулары һәм аларның бөтен илдә, бигрәк тә Урта Азиядә сатылуы турында бара.

*

* *

Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшриятында «Праздники, обряды, традиции» дигән китапның 2 нче тулыландырылган басмасы дөнья күрде. Китапка кергән очеркларда хәзерге көндә безнең тормышыбызда киң таралган бай эчтәлекле төрле йолалар, гореф-гадәтләр һәм бәйрәмнәр турында язылган.

Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Сабан туе» дигән очеркында татар халкының иң борынгы, иң күңелле бәйрәме хакында сөйләнә.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

16 майда Чаллының КамГЭС поселогындагы китап кибетендә язучы Э. Касыймов матур әдәбият сөючеләр белән очрашты. Ул Чаллыдагы язучылар оешмасының бурычлары, иҗат планнары турында сөйләде, үзенең әле яңарак кына сатуга чыккан «Чулман—оныклар дәрьясы» романына кагылышлы сорауларга җаваплар бирде.

19 майда оешманың «Кама таңнары» һәм «Ләйсән» әдәби берләшмәләренең гомуми утырышы булды. Утырышта Чаллы халык театры режиссеры Мансур Кашаповның «Ник яраттың?» исемендәге инсценировкасы укып тикшерелде. Бу драманы ул күренекле язучы Атилла Расихның «Сынау» романы буенча язган. Әсәрдә романның төп идея сызыгы, ягъни мәхәббәт, гаилә, әхлак проблемалары уртага куелган. Драма шактый кызыклы килеп чыккан. Ләкин авторга ирешелгән белән канәгатьләнмәскә, әсәрне тагын да яхшырту юнәлешендә эшләргә кирәклеге турында файдалы киңәшләр бирелде.

21 майда КамАЗның профсоюзлар китапханәсендә (Яңа шәһәр) бер төркем язучылар һәм яшь авторлар матур әдәбият сөючеләр белән очраштылар. Шагыйрьләрдән Мәхмүт Газизов, Мансур Сафин, Рубин Фәтхи, Рина Асылбаева, Нина Дмитриева, Александр Макаров, Владимир Атнагуловлар эшче яшьләргә шигырьләрен укыдылар. Шигырьләр рус һәм татар телендә яңгырады. Кичәне язучы Эдуард Касыймов алып барды. Очрашуда китап сату да оештырылган иде.

26—30 майда Чаллыда күренекле шагыйрь һәм прозаик Әхсән Баянов булып китте. Ул бирегә яңа әсәре өчен материал туплларга килгән иде. Шул җәһәттән үзен кызыксындырган объектларда булды. Чаллы язучылары, яшь авторлар белән очрашты, бүгенге әдәбиятыбызга кагылышлы мәсьәләләр буенча кызыклы әңгәмәләр уздырды.

## «ЧУЛМАН» ӘДӘБИЯТ-ИҖАТ ТҮГӘРӘГЕНДӘ

Берничә ел инде Алабуга дәүләт педагогия институты каршында «Чулман» исемле әдәбият-иҗат түгәрәге эшләп килә. Аңа филология фәннәре кандидаты Әнвәр Шәрипов җитәкчелек итә. Студентлар түгәрәккә бик теләп йөриләр.

Түгәрәкнең быелгы утырышлары аеруча җанлы һәм нәтиҗәле булды. Түгәрәк утырышларының үзәгендә студентларның иҗатын тикшерү, алар турында фикер алышу торды. Утырышларда шулай ук күренекле язучыларның үз иҗатлары турында язган мәкалә һәм китапларын укып үзләштерүгә дә зур әһәмият бирелә. Быел, мәсәлән, Расүл Гамзатовның «Минем Дагестаным» китабы, татар язучылары Ф. Хөсни, Ә. Еники, М. Мәһдиев һ. б. ларның үз иҗатлары турындагы мәкаләләре укып өйрәнелде.

Студентлар алдында еш кына язучылар үзләре дә чыгыш ясыйлар. Узган уку елында студентлар Сибгат Хәким, Илдар Юзеев һәм Ибраһим Нуруллиннар белән очраштылар. Язучылар яшьләргә үзләренең иҗатлары турында сөйләделәр, әсәрләрен укыдылар. Ә быел исә «Чулман» түгәрәгенең киңәйтелгән утырышында Алабугада яшәп иҗат итүче тәнкыйтьче, АДПИ ректоры Тәлгат Галиуллин һәм АДПИ проректоры Фатих Урманчиевлар чыгыш ясадылар. Аларның иҗат лабораторияләре турындагы әңгәмәсе зур кызыксыну белән тыңланды. Соңыннан «Чулман» әдәбият-иҗат түгәрәге членнары үзләренең хикәяләрен, шигырьләрен укыдылар.

Түгәрәк членнары үзләре иҗат иткән әсәрләр белән вакытлы матбугатта да чыгыш ясыйлар. Алабуга район газетасы «Яңа Кама» «Бездә кунакта — «Чулман» рубрикасы астында әдәби битләр биреп бара.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

РСФСР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 16 июнь Указы белән түбәндәге иптәшләргә мактаулы исемнәр бирелде:

**«РСФСРның халык артисты»**

1. **Сәлимҗанов** Марсель Хәкимовичка — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры.
2. **Ишкова** Галина Семеновнага — В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры артисткасы.

*

* *

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 30 апрель Указы белән совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы-тәрҗемәче Яхъя Мөхәммәтгалиевич **Халитовка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Вакытлы матбугатка язылу башланды. Билгеле ки, бездә һәркем үзе теләгән газета-журналга алдан ук язылып куя һәм аңа ел әйләнәсендә шул газеталарны, журналларны китереп торалар. Әмма, укучылардан килгән кайбер хәбәрләргә караганда, еш кына көтелмәгән тоткарлыклар килеп чыга. Кызыксына башласаң, барысының да сәбәбе бер генә була: язылу чарасына соңга калып керешкәннәр, укучыларны газета-журналлар белән тәэмин итәргә тиешле «Союзпечать» оешмасы вәкилләре исә үз эшләрен түгәрәкләп куйганнар, планнар үтәлгән, отчетлар бирелгән. Бу очракта журналны алдырырга теләгәннәргә ярдәм итү катлаулана, хәтта бөтенләй мөмкин дә булмый.

Мондый күңелсезлекләр чыкмасын өчен, «Казан утлары» журналына язылуны алдан ук рәсмиләштереп куярга киңәш итәбез. Журнал Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы, ягъни каталогтагы күрсәткеч саны — 73210. Димәк, «Казан утлары»-на илнең теләсә кайсы шәһәр, авылында язылырга мөмкин. Бу эшне почта бүлеге һәм «Союзпечать» агентлыгы хезмәткәрләре башкарырга тиеш.

Урыннарда, нинди дә булса берәр сәбәп табып, журналга яздырмасалар, еллык бәяне түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз:

420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. Татарское республиканское агентство «Союзпечать» (для подписки на журнал «Казан утлары»).

Бу очракта да соңга калырга һич ярамый, адресыгызны бик төгәл һәм тулы итеп язарга кирәк.

Журналның еллык бәясе — 6 сум.

«Казан утлары»на язылган укучыны тирән эчтәлекле, чын сәнгатьчә иҗат ителгән берсеннән-берсе кызыклырак, мавыктыргыч яңа әсәрләр белән танышу шатлыгы көтә. Алар арасында Татарстанның күренекле өлкән әдипләренең дә, урта буын һәм яшь язучыларның да, әдәбиятта әле беренче адым ясаучыларның да язмалары булыр.

Прозаиклардан Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Ш. Бикчурин, М. Юныс, Б. Камалов, М. Хәсәнов һәм башкалар редакциягә кульъязмаларын тәкъдим иттеләр дә инде.

Шигырь сөючеләр яраткан шагыйрьләренең яңа әсәрләрен укып шатланачаклар.

Очерклар бүлеге укучыларны Татарстанның промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм культурасындагы проблемалар, алдынгыларның эш ысуллары белән таныштырып торачак.

Әдәби тәнкыйть мәкаләләрен язуга республиканың иң көчле тәнкыйтьчеләре тартылачак.

Җыр яратучыларга республика композиторларының иң матур әсәрләре тәкъдим ителәчәк.

Кыскасы, журналдагы уннарча рубриканың һәркайсы укучыга сөенечле яңалык, рухи байлык алып киләчәк. Укучылар исә танышкан әсәрләргә карата туган уй-фикерләрен шулай ук журналга язып чыга алачаклар. Моның өчен «Укучылар сүзе» исемле махсус бүлек бар.

Редколлегия һәм әдәби хезмәткәрләр журнал алдыручыларны канәгатьләндерү өчен көчләрен кызганмаячаклар.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ